ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2006





**Мәхмүт Галәү**
**(1886 –1938)**

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2006*

**9**

**(1007)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсннияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәниф ШӘРИПОВ. Меңнән бер өлеш. *Поэма*. .... 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. *Роман*. .... 12
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Наз сурәте. *Шигырьләр*. .... 56
Рәфкать КӘРАМИ. Олы юл да сикәлтәле. *Роман*. .... 60
Фәүзия СОЛТАН. Баллы миләш һәм кош жыры. *Шигырьләр*. .... 104
Фәния ЧАНЫШЕВА. Туган көнем. *Шигырьләр*. .... 107
Искәндәр СИРАЖИ. Күкләр никахы. *Хикәя*. .... 110

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Габдрахман МИНСКИЙ. Ана мәхәббәте. .... 118

ПУБЛИЦИСТИКА

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. .... 122

ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .... 131
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН, Фәрит ЙОСЫПОВ. Дастан эзләреннән. .... 136
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. .... 164
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. .... 168

ХӘТЕР

КАРЛ ФУКСНЫҢ ТУУЫНА 230 ЕЛ

Рашат НИЗАМИ. Кешелекле, мәгърифәтле шәхес. .... 142

АТИЛЛА РАСИХНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Камил КӘРИМОВ. Яңа ишан оныгы. .... 144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәридә ХӘСӘНОВА. «Мин елмаеп кына дөнья үзгәрерме?. .... 149

СӘНГАТЬ

Рауза СОЛТАНОВА. Татар театрының беренче рәссамы. .... 159

ЮМОР-САТИРА

Рәдиф СӘГЪДИ. Шикле машина. *Хикәя*. .... 176
Мөнирә ГАЛИМҖАНОВА. Борын. *Хикәя*. .... 179
Фарис ФӘСХИ. Эпиграммалар. .... 181

Юбилейлар. .... 172
«Казан утлары» архивыннан. .... 186
Берлекнең яңа әгъзалары. .... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .... 192

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Ф. САДРИЕВА «Счастье несчастных (продолжение), Р. КАРАМИ «Тернистый путь» (продолжение); рассказ И. СИРАЗИ «Брак на небесах»; поэма Р. ШАРИПОВА, стихи Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Ф. СУЛТАН, Ф. ЧАНЫШЕВОЙ.
«Из сокровищниц татарских рассказов»: Г. МИНСКИЙ «Материнская любовь».
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа».
«Память»: к 230-летию К. Фукса статья Р. НИЗАМИ. К 90-летию А. Расиха статья К. КАРИМОВА «Внук ишана».
«Литературная критика»: статья Ф. ХАСАНОВОЙ «О новых тенденциях современной поэзии».
«Искусство»: Р. СУЛТАНОВА. «Первый художник татарского театра».
«Наука»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА, Ф. ЮСУПОВА; «По следам дастана»; статья Ф. ГАРИПОВОЙ «История наших деревень» (продолжение); А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Юмор-сатира»: рассказы Р. САГЪДИ «Подозрительная машина», М. ГАЛИМЗЯНОВОЙ «Нос», эпиграммы Ф. ФАСХИ.
«Белый парус»: рассказ ТАНГУЛЬ «Курьер».
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина худ. Б. ГИЛЬВАНОВА. «Печальное ожидание»; поэт Н. КАШТАНОВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by F. SADRIEV «Happiness of unhappy people» (continuation), R. KARAMI «Thorny way» (continuation);
story by I. SIRAZI «Marriage in skies»; poem by R. SHARIPOV, poetry by F. GIZZATULLINA, F. SULTAN, F. CHANYSHEVA.
From Tatar stories treasury: «Maternal love» by G. Minski.
Publicism: R. HAKIM. «Metamorphoses of spirit».
Memory: to 230th anniversary of K. Fuks, article by R. NIZAMI. To 90th anniversary of A. Rasih article by K. KARIMOV «Ishan's grandson».
Literary critics: article by F. HASANOVA «About new trends of modern poetry».
«Arts»: R. SULTANOVA. «First artist of Tatar theatre».
Science: article by T. GALIULLIN, F. YUSUPOV; «On dastan trace»; article by F. GARIPOVA «History of our villages» (continuation); A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation».
Pages from «Tatar encyclopedia».
Humour-satire: stories by R. SAGDI. «Suspicious machine», M. GALIMZYANOVA «Nose», epigrams by F. FASHI.
«White sail»: story by TANGUL «Courier».
New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: picture by artist B. GILIVANOVA. «Sad waiting»; poet N. KASHTANOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.08.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3-720. Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Рәниф
Шәрипов

# МЕҢНӘН БЕР ӨЛЕШ

ПОЭМА

*Кол кирәкми, тол кирәкми, кыз кирәкми, наз кирәк;*
*Тән кирәкми, кан кирәкми, сүз кирәкми,—саз кирәк.*
Нәҗип Думави.

Үз чираты белән көннәр уза,
Ким дә булмый язмыш, артык та.
Гомереңә үз вакытын биреп,
Мәхәббәт тә килә, картлык та.
Каерылып әгәр бер карасаң
Яшьлек дигән ерак болынга,
Солдатларның тигез рәте кебек,
Көннәр кала гомер юлында.
Үткән көннәр корган мылтыкларын,
Йөрәгеңә төбәп торалар,
Бизәкләре белән төрле-төрле,
Ниятләре белән бер алар.
Мең атмаса, бер ата ул мылтык,
Бер ядрәсе тия, барыбер.
Бүгенге көн - ничек үтсә,шулай —
Йөрәгеңә килеп бәрелер.
Яшәү яме—байлык гаме түгел,
Бәхет дибез, затлы тун кисәк.
Мәхәббәтнең тик бер генә көне
Мең көнеңә сала мең бизәк.
Хәрефләрен үбеп чыгар өчен,
Шул исем дә җитә меңнән бер.
Бар Хакыйкать шул Мәхәббәт кебек,
Ә калганы, белмим, кемнәндер.
Көлемсерәр кемдер. Гаеп түгел.
Чын күңелдән була ялгышу.
Өмете бар әзли, таба аны,
Өметсезләр өчен каргыш ул.

Рәниф ШӘРИПОВ (1950)—*шагыйрь; «Тәрәзәдә уйлар», «Йорт иясе», «Мәңгелек сер» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

**Өметсезне Ул әйләнеп уза,**
**Өметлене куя Чиратка.**
**Бар ул, бар ул синең Мәхәббәтең,**
**Ул бары тик әле еракта.**
**Өметеңне өзми яшә генә,**
**Очратырга аны теләсәң,**
**Бас Чиратка, күр, еракта әнә**
**Фәрештәләр Сөю өләшә.**
**Уянуга иртән, бер куаныч булып,**
**Күз алдыңа килсә гүзәл сын,**
**Килеп җиткән, димәк, синең Чират,**
**Калганына инде түзәрсең.**
**Өметләләр, меңнәр арасыннан**
**Тигән сиңа меңнән бер өлеш,**
**Көтеп алган бәхет, тиңсез байлык,**
**Көтелмәгән кискен борылыш.**
**Берни күрми, белми йөрибез бит,**
**Күпме, азмы синең кебекләр?**
**Кеше җанын казып бер карасаң,**
**Күпме анда сагыш, өмет бар...**

**Көтмәгәндә түгел бу күрешү,**
**Шикләнәсең икән син әгәр,**
**«Очрак» диеп күпме тукысаң да,**
**Очраклыгы аның шулкадәр.**
**Бу дөньяда нәрсә очраклы соң?**
**Язган язмыштыр бу бүген дә.**
**Синең ерак, серле елмаюың**
**Көтеп ятты күңел түрендә.**
**Килеп җитте серне чишәр вакыт.**
**Гомеркәйләр узып бара бит.**
**Ләкин, Җирдә үталмаслык ара—**
**Синең белән минем ара бит.**
**Күпме язмыш, күпме ялгыш аша,**
**Ничек үттек шушы араны?**
**Дистә еллардан соң бу күрешү**
**«Очраклы хәл» була аламы?**
**Борылыштан килеп чыктың беркөн,**
**Калган иде меңнән бер адым.**
**Очып килдең кебек, кочып алдың,**
**Үбеп алдың, уйлап тормадың.**
**Миңа таныш серле елмаюда**
**Барысы да якын, үз иде.**
**Бу - елмаю гына түгел,**
**- Барысына,**
**Риза! Риза!—дигән сүз иде.**
**Бу мизгелдә дөнья бетте кебек,**
**Икәү генә калдык Галәмдә.**
**Аерылдык Җирдән, ә кочакта**
**Бәхетем дә иде, бәлам дә.**
**Очулары чиксез бәхет, ләззәт,**
**Төшүләре Җиргә мең хәтәр.**
**Куанычы никадәрле булса,**
**Аянычы аның шулкадәр.**
**Гөнаһсыз да, никахсыз да идем,**
**Язык эш бит кискен борылыш.**
**Мең өлеше Иблис эше булса,**

Ходайдан да бардыр бер өлеш.
Мизгелләре тиңсез, тик санаулы,
Ашыгыпмы шуңа йөгердең.
Мәхәббәт тә күтәралмый кайчак
Авыр йөген үткән гомернең.
Бер үк чир бу, сер бу, бер үк ләззәт,
Бер үк газап байга, ярлыга.
Ләззәтеннән күбрәк газап күрдем,
Йә, Ходаем, кичер, ярлыка.
Әллә Иблис биргән әче алма,
Әллә Ходай биргән татлы төш,
Әллә дәвасы юк йөрәк чире,
Әллә җитмеш җиде катлы көч.
Әллә булмә, әллә дөнья күкри,
Яшен булып тәнне яра ут,
Тыелгысыз хәлдә якынаеп,
Синең белән минем ара юк...

Без өйләнгәч төннәр кыска иде,
Без картайгач җәйләр кыскарды.
Сентябрьдә чыккан Кояш кебек,
Мин күзәтәм хәзер кызларны.
Сөю салып мизгелләре саен
Без үтәсе калган араның,
Ышык җирдә битең куеп торсаң,
Җылысы бар әле, бар аның.
Табалмыйча көткән сөйгәнеңне,
Юлда булсаң һаман син әгәр,
Никадәрле туңып, өшеп килсәң,
Җылысы да аның шулкадәр.
Эссе җәйдә, чиксез дала буйлап,
Арып-талып, сусап йөргәндә,
«Су иң тәмле ризык икән», диеп,
Әйтеп әйткән ди бит бер бәндә.
Без белмәгән серләр юк шикелле,
Ирештек тә, тиздән оныттык.
Тик, Мәхәббәт дигән серне генә
Кемдер чишәр дигән өмет юк.
Чишалмаслык сер иңдергән Ходай
Мәңгелек Яз, Дәвам хакына.
Гыйшык кергән күңел, күбәләктәй,
Утка таба оча, талпына.
Җырлап оча кемдер ут тирәли,
Омтылышы аның бер генә.
Ярый көйсә канат очың гына,
Кемнәндер бит кала көл генә...

Кайчак, күрми, белми үтәбез бит,
Тыныч кебек дуслар, танышлар.
Кеше җанын казып бер карасаң—
Күпме анда давыл, сагыш бар.
Көнкүрештә, чүп-чар мәшәкатьтә
Йоклый давыл тирән-түбәндә.
Гыйшык уты бер кагылып үтсә,
Кузгала бит, кайчак, «түбән» дә.
Кара көннәр килсә, кемнәрнеңдер,
Юк дигәндә, уты-шәме бар.

Бары тик, иң бәхетленең генә
Мәхәббәте, яме, гаме бар.
Исәп-хисап, акыл заманында
Чүптәй йөри җилдә тәгәрәп
Исәпне дә, хисапны да белмәс,
Акылын да «җүйган» Мәхәббәт.
Кадере юк инде аның күптән,
Кабере юк әле бүгенгә.
Кадере дә, кабере дә юкның
Күпме яме юкка түгелгән.
Бер текәлеп карыйк бу дөньяга,—
Юкмы алда кискен борылыш?
Дөнья чүбе меңләп-меңләп йөри,
Мәхәббәт ул меңнән бер өлеш.
Мәшәкатен ерып бу тормышның,
Арып-талып эшләп йөргәндә,
Бик сагындым сөйгәнемне, диеп
Әйтеп әйткән ди бит бер бәндә...
Сөю салып мизгелләре саен
Юкка чыккан ике араның,
Аулак җирдә, битең биткә куйсаң,
Җылысы бар әле, бар аның...
Ни кылсак та тәүбә итә-итә,
Ахыры бер, байга, ярлыга.
Мин бит синең меңнән бер өлешең,
Йә, Ходаем, кичер, ярлыка!

Ахирәттән хәбәр китергәндәй,
Тәрәзәдән салкын көз өрә.
Агачларга кунган бәс шикелле,
Чәчләремә ап-ак төс керә.
Йә, Мәхәббәт, картлыгыма кадәр
Озатып куй мине, өшетмә.
Бөек ләззәтеңә күтәрелик,
Тирән серләреңә төшик тә.
Китәсе бар. Еллар алга куа,
Күңелләр яшь әле дисәк тә.
Син ашыкма, син кал әле бераз,
Көннәрең бар әле исәптә.
Еллар аямый шул беркемне дә,
Син дә беркөн юлга чыгарсың.
Яшьлегеңне Вакыт ваткан чакта,
Бәгырькәем, ничек чыдарсың.
Еллар уза. Картлык дигән фасыл
Сылу сыннар өчен бик хәтәр.
Гүзәллегең никадәрле булса,
Аяныч аның шулкадәр.
Син, билгеле, карышырсың инде,
Килеп җиткәч аның чигенә,
Керфек-кашларыңа сөрмә тартып,
Иннек-кершән сөртеп битеңә.
Ләкин, күзләр, Кояш баткан кебек,
Төссезләнә, сүнә барырлар.
Җыерчыклар тәнең телеп-телеп,
Буй-сыныңны меңгә ярырлар.
Көй-авазлар инде ишетелмәс,
Якты төсләр инде күренмәс,

Тулып пешкән татлы җимешләргә
Тын күңелләр инде үрелмәс.
Истәлекләр белән күңел яшәр,
Тән онытыр ерак наз тәмен.
Тын көнләшү, өметсезлек белән,
Күзәтербез шаулы яз ямен.
Җәза көткән күндәм тоткын кебек,
Үз итәрбез Вакыт зинданын.
Нинди дару кабып карасаң да,
Чарасы юк инде, юк аның.
Карышырсың. Ләкин, иң хәтәре—
Өмет өзәр беркөн күңелең.
Сыгылырсың үксеп, күрерсең дә
Мәхәббәтнең мөмкин түгелен.
Мин көтәрмен. Ходай биргән яшьлек
Ким дә булмый инде, артык та.
Мин яныңда булмам. Мин көтәрмен,
Мин көтәрмен сине картлыкта.
Мин көтәрмен сине. Син ашыкма.
Син бит миннән бераз яшь әле.
Шулай булды инде, Мәхәббәтем
Гел аерым миннән яшәде.
Юк мәхәббәт белән юлны бутап,
Читләр булды якын-тирәмдә.
Бәгырькәем, сау бул, китә торам,
Соңгы әҗәтемне бирәм дә.
Әгәр Ходай мәрхәмәтле булса,
Кушылырбыз тагын йөгереп.
Килер, бәлки, җаннар кушылыр көн,
Соңгы әҗәт—соңгы шигырем.
Бу дөньяда күрдек барысын да,
Теге дөнья бирми бер хәбәр.
Никадәрле татлы булса Сөю,
Җавап тоту авыр шулкадәр.
Йә, Ходаем, кичер бу колыңны,
Юлымда бу соңгы борылыш.
Миңа тиеш булган мәхәббәттән
Бу бит, бары, меңнән бер өлеш.
Ничек яшәсәк тә ятасы бар
Бер үк җирдә—байга, ярлыга.
Тик Мәхәббәт иде бар хыялым,
Йә, Ходаем, кичер, ярлыка.

Без картайгач җәйләр кыска инде,
Без кавышкач гомер кыскарды.
Чит дөньяның чит кояшы кебек,
Мин күзәтәм хәзер кызларны.
Борылыштан килеп чыкты ул Көн,—
Калган инде соңгы бер адым.
Алла сүзен соңгы сүзем итеп,
Мин атладым, уйлап тормадым.
Сагышлы бу серле елмаюда
Барысы да якын, үз иде.
Бу—моңаю гына түгел,
—Барысы да
Уза! Уза!—дигән сүз иде.
Ничек үткән - шулай үткән гомер,

Төзәтерлек аны чара юк.
Гомер белән Хөкем якынлаша,
Тәүбә кылыр өчен ара юк
Без аңлыйбыз - гомер мизгелләрен
Җирдә ваклап-күпләп сатмыйлар.
Без яшәдек. Без көтәбез җәза.
Ә солдатлар никтер атмыйлар.
Җәза көткән көндәм тоткын кебек,
Барысына әзер инде без.
Бернидән дә инде курыкмыйбыз,
Бернигә дә китми исебез.
Барысын да күрдек бу дөньяда,
Яндык-көйдек, баттык суга да.
Тормыш сәер - кайчак баштан сыйпый,
Күз төбеңә башта суга да.
Без көтәбез соңгы җәза көнен,
Без түзәрбез аңа, без тыныч.
Бернидән дә курыкмасак та бик,
Җавап тотулары куркыныч.
Өметләнәм чәчәк куярлар дип
Кабер ташымдагы шәүләмә.
Бу шигырьне Ходай биргән икән,
Шәфкать иңәр, бәлки, тәүбәмә.
Мин дә аңлыйм, Ходай Мәрхәмәтен
Анда ваклап-күпләп сатмыйлар.
Өметле җан әзер барсына да,
Тик, солдатлар һаман атмыйлар.

Яшәү яме—ләззәт гаме түгел,
Бәхет дибез, килсә Мәхәббәт.
Ләкин, бәхет—тәүбә кылып көткән
Соңгы өмет—Олы Мәрхәмәт.
Көлемсерәр кемдер. Гаеп түгел.
Бозыклыктан була ялгышу.
Өметлеләр белә, күрә аны,
Өметсезләр өчен каргыш ул.
Өметсезне күрми узып китә,
Өметлене куя Чиратка.
Бар ул, бар ул Мәрхәмәтле Ходай,
Карап тора безгә еракта.
Уянуга беркөн, Зур Куаныч булып,
Күз алдыңда булса Гүзәл Сын,
Килеп җиткән, димәк, синең Чират,
Хөкеменә ничек түзәрсең?
Ә без монда дөнья җимерәбез,
Адым саен язык ялгышлар.
Күтәрелеп кара Ходайга бер,
Чыраеңда күпме сагыш бар...

Бәгырькәем, сау бул, китә торам.
Җәйләр кыска, төннәр озайган.
Кушылырмы, юкмы безнең җаннар –
Моны белми, хәтта, Ходай да.
Коткарырмы, юкмы Мәхәббәтне
Соңга калган ихлас тәүбәләр?
...Чапкан үлән кебек авып төшә,
Җан асраган фани гәүдәләр.

**Бер мизгелдә дөнья бетте кебек,**
**Тик берүзем калдым Галәмдә.**
**Аерылдым Җирдән, ә еракта**
**Бәхетем дә калды, бәлам дә.**
**Тагын күрдем - ә солдатлар инде**
**Өйләренә таба атлыйлар.**
**Атласыннар. Димәк, бүген инде**
**Алар беркемгә дә атмыйлар.**
**Тагын күрдем - мең төрле моң булса,**
**Барыбызның Җирдә зары бер.**
**Җитәкләшеп йөри**
**Бәла белән бәхет,**
**Ләкин, миңа инде барыбер.**
**Барысы да чүп шикелле хәзер.**
**Мин идемме шулай яраткан?**
**Сагыш тулы елмаюлы Чырай**
**Карап тора миңа еракта...**

*2005*

---

## ИГЪТИБАР! КОНКУРС!

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яна меңьеллыкка—яна дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яна дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятка, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Кыскасы, «Казан утлары» журналы, яңа хикәяләргә ачык конкурс игълан итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**

Фоат
Садриев

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

12

Сөембикә, бәби итәкле алсу күлмәген, укалы зәңгәр камзулын кигән килеш, калфак өстеннән ябынган чигүле яулыгын җилфердәтеп, фойеның әле бер ягына, әле икенче ягына йөгерде. Аны котладылар, һичшиксез беренче урын сезнең ансамбльгә тиеш, дип дәртләндерделәр. Казандагы танышлары, күрше районнардан килгән коллегалары аны кочтылар, үптеләр, шул ук сүзләр белән күңелен җылыттылар. Әмма жюриның, киемнәрнең искелеген сәбәп итеп, аларга өченче урын бирүе Сөембикәне башына күсәк белән суккан кебек итте. Күз яшьләренә буылып сәхнә артына чыкканда, аны уртача гәүдәле бер ир кеше туктатты. Ул үзен Ирекнең дусты Әхмәт дип таныштырды.

—Миңа чыгышыгыз искиткеч ошады. Газетада сезнең белән әңгәмә бирәсем килә,—диде ул.

Сөембикәнең каршы килүенә карамастан, бер-бер артлы сораулар яудырды. Инде сүз бетте дигәндә, Әхмәт:

—Үзешчәннәрне шушы кадәр әзерләгәч, нигә соң киемнәр мәсьәләсенә битараф калдыгыз?—диде.

Аның шулай әйтүе Сөембикәнең йөрәгенә килеп кадалды. Ул ярсып бу нәрсәне хәл итүнең үзеннән тормавын, акчага бәйле икәнен, ә акчаның хакимият кулында биек агач башындагы алма кебек кызыктырып торуын сөйләп китте. Аның инде буасы ерылган иде, ул клуб-китапханәләрнең шактый еллар бернинди ремонт күрмәве, культура учакларында спорт инвентарьларының, инструментларның юк дәрәҗәдә булуы, штатлар кыскартылуы турында сөйләде, тагын күп кенә тәнкыйть сүзләре әйтте. Әхмәт соңыннан Ирекнең тормышы белән кызыксынырга тотынды. Кайда эшли, язамы, пьесалары чыгамы, дигән кебек күптөрле сораулар белән күмеп ташлады. Сөембикә аңа, без бергә яшәмибез, дип әйтә алмады, «әйе», «юк» дигән кебегрәк җаваплар белән котылды. Әхмәт, яңа квартира алдым, диде, әгәр Ирек Казанга килсә, берүк туп-туры безгә төшсен, диде, адресын бирде, язган әйберләрен җибәрергә кушты.

Сөембикә, инде аннан аерылып китим генә дигәндә, үзенә таба туп-туры килүче кешегә игътибар итте. Ул кеше Сөембикә интервью бирә башлаганда ук почмактарак аннан күзен алмыйча карап тора иде. Башта ул аны, Әхмәтне көтеп торучыдыр, дип уйлады, ә хәзер үзенә туп-туры килүен күргәч, ялгышканлыгын аңлады. Менә ул аның каршына ук килеп җитте, авызының бер як чите белән генә сизеләр-сизелмәс елмаеп, җиңелчә генә баш иде дә:

—Исәнмесез,—диде.

*Дәвамы. Башы үткән санда.*

—Исәнмесез...

Уртачадан озынрак төз гәүдәле, илле яшьләрдәге бу кешенең затлы туны һәм бүреге, нindидер түрә булырга тиеш, дигән уй тудыра иде. Йөзе бөтенләй җыерчыксыз диярлек, төз борыны астында юка гына булып матур кара мыегы сызылган, алга чыгып торучы кин ияге аның тормышта ныклы адымнар белән атлый торган, зур ихтыяр көченә ия булуы турында сөйли. Кояшта янган йөзе, әле генә көньякта кызынып кайткандыр бу, дигән гөман уята. Сөембикәгә ул кемнедер хәтерләткәндәй тоелды, ләкин бүгенге дулкынланулардан соң, мөмкин булган барлык кичерешләрне дә күңеленнән уздырганнан соң, ул бу кешенең кем икәнлеген тәгаен генә хәтерләрлек хәлдә түгел иде.

—Сез мине, әлбәттә, танымыйсыз...

Ир кешенең тигез, шикәрдәй ак тешләре күренеп алды. Шунда Сөембикә аның уң як тешенең бераз китек икәнен абайлады. Аның күз алдында нindидер сурәт пәйда булды һәм, ни гаҗәп, ул сурәт кайдадыр еракта, зәңгәр өрфия белән өретелгән еллар артында шикелле дә, шул ук вакытта бик якын да кебек тоелды.

—Сез миңа кайчандыр салкын су чәчрәткән идегез, колонкадан...

Сөембикә кычкырып көлеп җибәрде:

—Әстәгъфирулла! Аннан соң бит инде йөз ел үткән!

—Үткән, ләкин онытылмаган, Сөембикә...

—Мин инде аның елын да хәтерләмим.

—Аның хәзер әһәмияте юк. Менә мин сезне һич уйламаганда очрату бәхетенә ирештем. Биюегезне карап, таң калдым. Ике генә авыз сүз булса да әйтәсем, күзләрегезгә якыннан карыйсым килде.

—Рәхмәт, Айдар,—диде Сөембикә.

—Менә бит. Сез дә мине онытмагансыз,—диде ул, куанычын яшерә алмыйча.—Беләсезме, Сөембикә, мин бит Татарстанга бөтенләйгә кайттым, Молдавия җирләрен ташлап. Хәер, мин дөрес башламадым.—Ул кулын селтәп куйды да, әллә тиешле сүзләрен эзләп, әллә болай гына уйланып калды.

Сөембикә, үзен көтеп торуларын белсә дә, аңардан аерыла алмады, күңеле белән шул сихри төн хатирәләренә уралды. Айдарның ягымлы тавышы аның хыялый сәфәрен бүлде:

—Нишләптер мин сезне әледән-әле хәтергә төшердем. Татарстан җиренә кайтырга уйлаган саен, күз алдыма сез килә идегез. Туган җир тарта икән. Өй сатып алып, каядыр төпләнәсем килә.

Сөембикә, «Сез боларны миңа нигә сөйлисез?» дигәндәй аңа мөлдерәтеп карап куйды.

—Бәлкем сезнең якларда өй сатучылар бардыр?

—Кызыксынганым юк,—диде Сөембикә коры гына.

—Әгәр районыгызга барып чыксам? Үзе яшәгән җиргә Болынкыр дип исем кушкан халыкның күңеле гаҗәп матурдыр сыман тоела миңа. Барыйммы соң?

—Мин сезне тыя алмыйм, ни өчен миннән рөхсәт сорыйсыз?

Айдар тыенкы гына көлеп куйды.

—Әйдәгез, икебез шушы сорауга җавап табыйк. Чынлап та нишләп мин сездән рөхсәт сорыйм икән?

—Белмим...—диде Сөембикә, дулкынлана башлавын тоеп.

—Мин дә белмим шул. Әгәр анда баргач, сезнең янга керсәм... киңәш сорарга, куып чыгармассызмы?

—Минем ирем бик көнче,—диде Сөембикә алдашып.

—Сезгә алдашу килешми, Сөембикә. Мин барысын да беләм...

—Гафу итегез, миңа китәргә вакыт.

Сөембикә шулай диде дә, башын игән хәлдә китеп барды.

Юлда кайтканда, анын уйлары гел Айдар тирәсендә бөтерелде. Сөембикә, аны онытырга теләп, күзләрен йомды, ләкин, үч иткәндәй, ул тагын да ачыграк булып күз алдына килде һәм беркемне дә кабатламый торган сөйкемле елмаюы белән анын йөрәген кузгатты...

## 13

Ирекка шатланырга, беркем шатлана алмаганча шатланырга кирәк иде. Ниһаять, бүген өй туе! Инде бер ай Зәнфирә төн йокламый шуңа әзерләнә. Өйне, веранданы сабынлап юып чыкты, тәрәзәләренә өр-яңа пәрдәләр элде, кредитка алып, һәр бүлмәгә люстра куйдырды, ишек алдына гөлт итеп янучы лампочкалар чыгартты. Ә Ирекнең күңеле, ерткыч сагалавын сизгән җәнлектәй, үзенә урын тапмады. Яза торган романы әллә кайчан туктап калды, театрдан төзәтергә алып кайткан пьесасының өстенә инде тузан кунды. Әйтерсең, анын тормыш арбасы олы юлдан чыгып каядыр салулады. Кеше хакына кермәде, кеше өстенә басып, бу өйне салдырмады, инде югыйсә авылда ялгызы яшәп ятучы әнисен алып килергә тулы мөмкинлекләр туды. Ләкин анын шушы бәләкәй, тәбәнәк, иске өйдән һич кенә дә атлап чыгасы килмәде.

Бүген ул әлеге уйларын онытырга тырышты. Килгән кунакларны елмаеп-көлеп каршы алды, кулларын кысты, кайсылары белән кочаклашып күреште, бәхете ташып чыккан кеше ролен уйнады, әмма үзе бөтенләй башка дөньяда йөзде. Әйтерсең лә ул бер бөтен түгел, берничә кисәккә бүлгәләнгән нииндидер бер зат, шушы көнне нииндидер вак мәшәкатьләрне төп-төгәл үтәргә тиешле машина иде. Авырып торганлыктан, әнисенең бүгенге мәҗлестә катнаша алмавы да анын кәефен кырды. Кунаклар алып килгән күпсанлы бүләкләр дә аңа әллә ни тәэсир итмәде. Мэлс абыйсы белән Нәфисә, үзегез ни телисез, шуны алырсыз, дип аларның кулына калын гына конверт тоттырды. Әхнәф белән Фәһимәнең өр-яңа стенка һәм китап шкафы бүләк итүләрен ул башына сыйдыра алмады. Алар әле генә кибеттән алынганнар, калын кәгазьләргә, катыргыларга төрелгәннәр, күтәргесез авыр иделәр. Машинага төяп килгән егетләр барысын да верандага кертеп өйделәр. Кешеләр җыелып беткәч, өй туен Мэлс абыйсы ачып җибәрде. Әхнәфкә, район больницасының баш врачына, өйне салган төзелеш оешмасына рәхмәт әйтте, шарт-шорт китереп шампан шәрабләре атылды, рюмка-бокаллар эчемлек белән тулды. Рюмкасына шифалы су салган Ирек, уртадагы буш урыннан әле түргә, әле як-якка барып, кунаклар белән чәкештерде, аларны ашарга-эчәргә кыстады. Мәҗлес кызганнан-кызды. Беренче тәнәфес җиткәндә, кунакларның телләре тәмам ачылып бетте, күңелле итеп баян уйный башлады, бердәм күтәрелеп җырларга керештеләр. Ирек кенә һаман каршылыклы кичерешләрдән аерыла алмады, туктаусыз эче янды. Әйтерсең лә бөтенесе җырлашып-гөрләшеп, нииндидер бәхет тавына күтәрелеп баралар, ә ул берүзе каядыр түбәнгә оча, берничек тә төшеп җитә алмый, алардан аерыла да алмый иде.

Икенче тәнәфестә инде кунаклар арасында шактый гына йомшаганнары күренде. Гадәт буенча бер почмакта җырлыйлар, уртада бииләр, танцы итәләр, төркем-төркем сөйләшәләр, ирләр туктаусыз чыгып тәмәке тартып керәләр. Кыскасы, бөтенесе хәрәкәттә, дәртләндергеч бер көйгә буйсынып, бәхет-сәгадәт дулкынында йөзәләр. Читтәрәк басып торган Ирек янына Әхнәф килде һәм анын иңбашына кулын салды.

—Йә, дустым, син канәгатьме?—диде ул, Ирекне күкрәгенә кысып.

Әхнәфнең күкрәге дә, кулы да ут кебек кайнар иде.

—Канәгать булмыйча...—диде Ирек, елмаерга тырышып.

—Юк, син нишләптер бик күңелсез, авырмыйсындыр бит?

Ирек Әхнәфнең күзләренә туп-туры карап баш чайкады, әмма елмая алмады.

—Бүген син минем белән бергәләп бер генә йотым булса да тотып куярсың, дип уйлаган идем.

Анын бу сүзләре гүя Ирекнең эчендә ничә еллар буәлеп торган, аны борчыган буаны ерып җибәрделәр! Ул ерылган урыннан гаҗәп тә таныш, ләззәтле чакыру анын башын әйләндерергә тотынды. Әхнәфкә буйсынып, ул карангырак почмакка атлады, алар килеп утырдылар. Менә дусты, ике буш рюмка алып, аларга коньяк салды. Ирек бөтен гәүдәсенең шатлык һәм курку ялкыны белән тулуын тойды, тагын әллә нәрсәләр бөтенесе бергә болганды, ул шушы дулкын эчендә чайкала башлады. Ул акрын гына кулына рюмкасын алды.

—Яна өйнен бәрәкәте, синең иҗат уңышларың өчен!—диде Әхнәф, рюмкаларны чәкештереп.

Ирекне баягы дулкын тагын да ләззәтлерәк итеп серле биеклеккә күтәрә башлады. Шушы зәһәр эчемлекне йотуга, ул янәшәсендәге бәхетле кешеләр белән бер дөньяга кушылачагын, алар кебек үк шатлык эчендә кайнарга керешәчәген күз алдына китерде. Бу искиткеч кызыктыргыч, искиткеч ләззәтле халәт иде. Ул инде эчемлекнең барлык тамырлары буйлап бөтен гәүдәсенә кайнар булып таралуын тойды, тәненнән рәхәт кымырҗуын, мәлҗерәвен хыялы белән ап-ачык сизде. Хыялны чын итү өчен нибары бер хәрәкәт ясыйсы... Әхнәф шуңа әйдәде, анын сүзләренә карышу мөмкин түгел иде. Ирек рюмкасын күтәреп иреннәренә терәде... Шунда рюмкасын көч-хәл белән иреннәреннән аерып, өстәлгә куйды.

—Гафу ит, күнелем болганып китте,—диде ул калтыранып.—Бераз һава сулыйм әле...

—Мин дә синең белән чыгам.

—Юк, юк, Әхнәф. Зинһар иярмә, миңа үземә генә булырга кирәк...

Ул бүреген, пәлтәсен, олтанлы итеген ашыгып киде дә, кунакларны ерып, абзарга таба китте. Бакча капкасын ачып, көрт ера-ера, карангы почмактагы балан куагы янына китте. Анын җыелып бетмәгән тәлгәшләренә кар мамыгы яткан. Ирек бер ботакны иде дә, тәлгәшләрне өзеп тә тормастан, иреннәре белән үрелеп, бозга әверелгән баланны карлары-ние белән шатыр-шотыр чәйнәргә кереште. Балан әчесе бөтен авызына таралды. Кинәт бер тешенә, өнне алырлык сызлатып, салкын йөгерде. Әмма күнелендәге сызлау аннан көчлерәк иде, шуны басар өчен ул комсызланып әле бер, әле икенче тәлгәшкә үрелде... Калтыранган куллары белән балан ботагына ябышкан килеш, үз-үзенә тавышсыз гына җикерергә кереште: бар, тизрәк кер дә эчеп җибәр! Тик шуны бел: син аны эчсәң, элекке кебек аракы дингезенә төшәчәксен! Ничә еллар буе корган шул афәттән аеручы диварны җимер, әйдә! Ишетәсеңме, сине җырлый-җырлый чакыралар! Кешеләр түгел, сиңа дип салынган агу җырлый. Бу дөньядагы иң якын дустың Әхнәф үзе чакыра! Бар кер, эч тизрәк! Якты дөньядан гүр кадерлерәк икән—тизрәк эч!

Ирекнең тәненә салкын тир бәреп чыкты. Күзгә күренми торган упкын якында гына, мөлдерәп аны чакыра... Ул өйгә бер адым атлады да кире чигенде. Үзенә булган ышанычы әллә кая китеп югалды, йөрәге Әхнәф чакыруына алгысудан туктый алмады. «Зинһар, тыелырга көч бир!» дип ялварды ул. Шул ук вакытта үз-үзенә рәхимсез сорауны бирде: син кеше булып кала алдыңмы? Бу сиңа соңгы сорау, соңгы сынау. Хәл ит: әгәр кала алмаган булсаң, тыелма. Әгәр аракы гомереңнән дә кадерлерәк икән, бу якты дөньяны, газиз әниеңне, Айгөл белән Зәнфирәне, туганнарыңны, дусларыңны корбан ит шуна.

Әгәр ул шушы яшенә кадәр җир йөзендә ниләрдер эшләвеннән дә олырак,

мөһимрәк, мәгънәлерәк икән—эч аны! Әле тагын бик озак елларга дип бирелгән тормыш китабыныңның укып бетермәгән килеш соңгы битен ябып куй. Әмма һич югы бу гамәлең кешечә булсын, һәрбарчасы белән бәхилләш. Ачы җимешләрен ашаткан бу балан куагы белән бәхилләш. Күктә җем-җем итүче әнә ул йолдызлар белән бәхилләш. Өй котларга җыелган кунаклар белән бәхилләш. Дөнья белән бәхилләш! Әгәр син җинәргә сәләтсез мескен икәнсең—җинел! Үзләрен җинәргә сәләтлеләр бу дөньяның ямен-тәмен татып, бәхет диңгезләрендә йөзеп, йөзгә кадәр яшәсеннәр. Ә синең урының җир өстендә түгел, аның салкын балчыгы астында...

«Көч бир!» диде ул тагын һәм шундук уе белән котырып каршы төште. Кем сина көч бирсен?! Көч синең үзеңдә генә. Читтән ярдәм беркемгә дә юк ул. Бөтенесе үз ихтыярында. Нәрсә туктап калдың, дип үз-үзен төрткәләгәндәй ачуланды тагын. Бар, кер, эч! Миллиард еллар аша бүләк итеп бирелгән гомереңне, яшәү ямен бер йотым агуга корбан ит! Кулыңдагы рюмкаң—ул синең казылган кабереӊ!' Тизрәк кер кабереңә, ашык! Гомер касәң дә үз кулыңда. Кайсын сайлыйсың—шунысын эчәсең. Беренчесен эчсәң, бөтенесе бик тиз хәл ителәчәк. Ә икенчесен эчү бик озак елларга сузылган яшәү ләззәте бирәчәк. Беренчесе гомереңне коточкыч газаплар, хурлык белән өзәчәк. Якыннарың, сине белгән кешеләр үлүеңнән соң да сиңа ләгънәт укыячаклар, исемеңне җирәнеп әйтәчәкләр, Айгөлең, оныкларың телгә алырга да хурланачак.

Күз ачып йомган арада ничек бөтен вөҗүде үзгәрде соң аның?! Бөтен хикмәт Әхнәфтә. Барлык дуслары, «аның кыставына түзеп булмый», ди торганнар иде һәм бу чыннан да шулай. Аңарда кешене буйсындыручы, сындыручы ниндидер көч бар. Димәк, син гаепсез! Әйдә, буйсын алайса! Акланырга бик әйбәт сәбәп. Шуңа ышыкланып куркыныч үткәненә юнәлергә әзер бит син. Сагынган булсаң, әнә генә ул мингерәүлек томаны эчендәге көннәрең. Иренмичә бер хәрәкәт ясасаң, шунда очасың. Әнә генә ул нурсыз, карангы бушлык. Бүтән берни дә юк. Шул бушлык эчендә ярым мәет хәлендәге хәлсез гәүдә йөрәк белән бергә, «сүнәм, сүнәм», дип калтырап тора. Әгәр шуны сагынсаң—эч! Рюмканы җир шарыннан да олырак, бу якты дөньядан да кадерлерәк дип санасаң, атла упкынга. Ләкин әүвәл һәр икесен дә бизмәнгә сал, кайсы басканын ныклап кара, алдатма! Алдатсаң, кире кайту юк, соң булачак! Шул бизмәнгә әниеңне дә, Айгөл белән Зәнфирәне дә, абыйларыңны да сал.

Ниһаять, Ирекнең уйлары төгәл калыпка керә башлады. Вөҗүденең кайсыдыр почмагыннан сабырлык күтәрелүе сизелде. Ул арада ихтыяр көче хәбәр салды: кеше ниндидер түбән йогынтыларга бирешергә түгел, һәркөн аз-азлап кына булса да үзен җинә барырга тиеш. Акрын-акрын югарыга хәрәкәтләнмәсән, түбәнгә тәгәрисең, упкынга очасың. Икеләнү, көчсезлек томаны аша өмет чаткысы сирпелеп алгандай булды, аның үз-үзенә ышанычы кабат күнеленә инде. Тормышның кызыктыргыч дәвамы үзенә чакырды...

Ул кергәндә, кунаклар җырлыйлар иде. Урынына барып утыру белән, Ирек аларга кушылды, дөньясын онытып җырларга тотынды. Аның тавышында яшьтән үк үзенә генә хас моң бар иде, ул моң күңеленнән шундый булып бәреп чыкты ки, барлык йөзләр аңа таба борылдылар һәм үзләрен каршылаган томса чырайлы Ирек урынында күзләре очкынланып януччы, йөзе яктырган, яшәргән кешене күрделәр. Ирек аларның үзенә ни өчен карауларын да, ни уйлауларын да бик яхшы аңлады. Өченче тәнәфестә ул биергә чыкты да Зәнфирәгә басты, алар парлашып очына-очына биеделәр, кунаклар арасында кул чапмаган, аларга сокланмаган беркем дә калмады.

—Әллә сине җен алыштырып кертте инде,—диде Әхнәф, аның янына

килеп.—Болай матур итеп җырлаганыңны да, биегәнеңне дә күргәнем юк иде. Яна йортка яңа сыйфатларыңны күрсәтеп керәсең син, молодец!

Дусты рюмка сузды, Ирек «юк» дип баш чайкады.

—Аннан ерак торганда гына кеше мин,—диде ул.—Борыныма исе керсә дә, дөньяның асты өскә килә...

Әхнәф аны бүтән кыстамады. Мәҗлес төнге икегә кадәр дәвам итте. Кунакларны озатып бетергәч, Ирек йөгерә-йөгерә Зәнфирәгә өстәлләрне җыештырырга, табак-савытларны юарга булышты. Алар сәгать дүртенче киткәч кенә йокларга яттылар. Күрәсең, арулары нык булгандыр, яктыргач кына уяндылар. Ирек күзләрен әйтеп бетергесез шатлык белән ачты, яшьлек җиңеллеге белән шундук сикереп тә торды. Ишек алдына чыгуга, эчендәге куанычы тагын да артты. Акрын гына ябалак-ябалак кар ява иде. Ирек кичәге упкын янына кабат беркайчан да бармаячагын аңлау шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Ул бирешмәде, ул—җиңүче иде! Аның бүген җиңү көне. Бөтен җиһанны яңгыратып: «Саумы, бөек көн!» дип кычкырасы килде. Кичә өй туе булса, ул бүген үзенең җиңү көнен бәйрәм итә. Әмма гомеренең яңа дәвергә чыгуын билгеләүче бу көнне ул беркемгә дә сиздермичә бәйрәм итәр. Хәер, әнә бит ак карлар сизгәннәр, аны котларга җиһан түреннән үк төшәләр. Аларның сафлыгы сабый бала сафлыгын хәтерләтә, алардан сабый бала исе килә...

Менә болдырда кочагына савыт-саба төягән Зәнфирә күренде. Ирек койма башыннан яңа яуган карны учлап капты да, хатынын иреннәреннән үбеп алды.

—Ни булды сиңа?!—диде ул, гаҗәпләнү катыш елмаеп.—Савытларымны төшертеп җибәрә яздың...

—Мин сине карлы иреннәрем белән кайчан үпкән идем? Хәтерлисеңме?

Аның соравын көтеп кенә торгандай, Зәнфирә шундук җавап бирде:

—Яңа ел кичендә... Чыршылар каршында, кешеләр йөреп торган җирдә... Шул исемә төшсә, хәзер дә оялып куям.

—Ә син оялма, карчык! Яратуның ояты юк,—диде Ирек, акрын гына төшүче кар бөртекләренә учларын сузып.—Яңа елга туры килмәсә дә, без бүген яңа тормыш башлыйбыз.

—Әйе, яңа йортта башлыйбыз,—диде Зәнфирә, аның сүзен җөпләп һәм күршеләренә савыт-сабаларын кертә китте.

Үткән еллар офыгының кайтавазы рәвешендә яңгыраган бүгенге көн Ирек өчен иң мәгънәле, иң кадерле көн булырга тиеш иде. Ул аның бер генә секундын да бушка үткәрмәскә карар кылды. «Минем көнемне шулай ямьләгән өчен рәхмәт сезгә, ак карлар!» диде ул күңеленнән. Нинди нурлы, нинди матур син, бүгенем! Минем тормышымда тагын бик күп, бик күп шушындый якты бүгеннәрем булачак әле! Мин аларны гомеремә һәйкәл булып калырлык итеп яшәячәкмен!

Ирек, кергән-чыккан кешеләрдән, телефон шылтырауларыннан качып, музейга барып бикләнде. Кәгазьләрен таратып, кулына ручкасын алуга, бу дөньядан аерылды. Аңа каяндыр шатлык нурлары коелды, илһам дигән тылсымлы көч ручкасын туктаусыз алга куалады, ак кәгазь битләренә хис-кичерешләре, фикерләре ташып түгелде. Ул өйлә туры узганын да, караңгы төшкәнен дә сизмәде, романының иң зур бер кисәген тәгалләде. Моңа хәтта ышануы да кыен, элек бу кадәр әйберне язарга аңа бер ай вакыт кирәк булыр иде. Бу—аның тормышындагы Бөек көн биргән бүләк иде, чөнки ул үзе дә башка кеше иде.

Романдагы каһарманнарыннан аерылып, урамның йомшак карына басканда, аны йолдызлар җемелдәп каршы алды. Ирек сәгатенә дә карамады, чөнки моның бернинди әһәмияте дә юк иде. Ул очынып-дәртләнеп өенә юнәлде,

үзе дә сизмәстән, авыз эченнән генә туктаусыз җырлады да җырлады. Юл буе аның өстенә күктән йолдызлар коелды, ә күнелендә яп-якты кояш балкыды. Үзенең күкрәгендә, кояш белән йолдызларны берләштереп, үткән еллар офыгы белән бүгенге көннең бәрелешүеннән туган кайтавазны тыңлый-тыңлый, Ирек киләчәгенә атлады...

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### 1

Бүген мәдәният хезмәткәрләренең район семинары иде. Андый көнне авыл китапханәчеләре, культура йорты мөдирләре Сөембикә бүлмәсенә агылалар, акча сорыйлар, башка мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итәләр. Бүген дә менә бер сәгать инде кеше агыла. Шунда аңа шылтыратып, Шәрифуллин ашыгыч үзенә чакыра, диделәр. Сөембикә ишек төбендә торучыларга көтәргә кушты да хакимияткә китте.

—Мин синнән моны көтмәгән идем,—дип каршылады аны Әхнәф һәм өстәлгә газета ыргытты.

«Күз яшьләре катыш интервью», дип укыды Сөембикә, эре хәрефләр өстеннән күз йөгертеп. Әхнәфнең күз алмалары сикерешергә тотынды.

—Икәүдән-икәү аңлашасы урында сиңа мине республика җитәкчелеге каршында пычратырга кирәк булган. Мондый кешеләргә таяну—суга таяну белән бер икәнен беләм мин...

—Кем икәнемне аңлатуың өчен рәхмәт...—Сөембикәнең иреннәре елагандагы кебек тартышып куйды, ләкин ул күз яшьләрен тыеп кала алды.—Синең культура дигән гарип үги малаеңны караудан гарык мин!—Ул өстәлдә яткан чиста кәгазьләрнең берсен алды да, гариза язып, Әхнәфнең алдына атты.—Резолюциянне сал да, син миннән, мин синнән котылабыз.

—Син усалланма, Сөембикә!—диде Әхнәф, тамырлары бүртеп чыккан кулларына урын таба алмыйча.—Алайга китсә, мин сине чәйнәп ташлый алам бит!

Аның ачуы тавышына гына түгел, рәхимсез ялтыраучы күзләренә дә чыккан иде. Сөембикә аңа мәсхәрәле караш ташлады.

—Нык тигән бу синең үтенә... Янаудан да курыкмыйсың.

—Курыксам, мин бу урында утырмас та идем.

—Кергәч тә шуннан башларга идең аны,—диде Сөембикә.—Арсланның муенын шартлатып өзгәнне, безнең кебек куяннар нәрсә сиңа...—Ул урыныннан торып басты.—Шулай да теләсә нәрсә чәйнәргә тырышма, тешенә зарар килүе бар.

Сөембикәнең бу сүзләре Әхнәфнең соңгы сабырлыгын алды. Ул җилләнеп сикереп торды, уң кулы белән җайсыз хәрәкәт ясап, өстәлдәге газеталарны сыпырып төшерде һәм:

—Утыр!—дип кычкырды ят, шомлы тавыш белән.

Сөембикәнең аны беркайчан да мондый хәлендә күргәне юк иде. Шуңа күрә ул ничек урынына утырганын сизми дә калды.

—Белеп тор: гарип малайны аякка бастырмый торып, сиңа тынгы булмаячак! Әле эшлисең!—Әхнәф аның гаризасын шатыр-шотыр ерткалады да, чүп савытына саласы урында, Сөембикәнең интервьюсы басылган газета өстенә атты.—Тик мин сиңа саграк кыланырга киңәш итәр идем. Сиңа карата булган элекке җылы тойгыларның бөртеге дә калмады минем...

—Минеке дә шулай.—Сөембикә торып басты.—Элекке дуслык хакына якын итеп кенә мин дә бер әйбер әйтим әле. Ялгыш якларга күп карап, чокырга туры килә күрмә...

Сөембикә, оста хатын-кыз булдыра алганча кыланып, юри салмак кына керт-керт атлап чыгып китте.

Семинар әйбәт кенә узды. Аннан чыгып, үзенен бүлмәсенә юнәлгәндә, ишек янында сумка тоткан Айдарны күрде. Кул бирмичә генә исәнләшкәннән соң, алар бергәләп бүлмәгә керделәр.

—Әйдәгез, утырыгыз,—диде Сөембикә, ана урын тәкъдим итеп.

Чишенегез, диюдән курыкты, алай итсә, ничектер аны көтеп торгандыр, ана ярарга тырышадыр кебек тоелды. Айдар урындыкка утырып, бүреген тезләренә куйды да, тыныч кына ана карап тора башлады. Сөембикә елмаеп җибәрде.

—Сез мине күзәтеп утырыр өчен генә килмәгәнсездер, дип уйлыйм. Миннән берәр төрле ярдәм кирәкме?

—Сезнен шулай җылы кабул итүегез үзе олы ярдәм инде.—Айдар сәгатенә карап алды.—Хәзер шушы җылыны йөрәгемә салган хәлдә, мина кунакханәне эзләп китәргә кирәк.

Сөембикәнен күнеле сыкрап куйды. Айдарны һич кенә дә үзеннән читкә җибәрәсе килмәде анын!

—Кунакханә моннан күренеп кенә тора.—Сөембикә шулай диде дә Айдарга каш астыннан гына назлы караш ташлады.—Тик нишләптер сезне анда куу унайсыз. Гаеп итмәсәгез, мина гына кайтырсыз.

Бу сүзләрне ишетүгә, Айдарнын йөзе яктырып китте.

—Су сипмәссезме сон?—диде ул елмаеп.

—Колонканын тимеренә кагылмасагыз, су сибелмәс.

Алар берьюлы көлеп җибәрделәр. Кайту мәсьәләсе шунын белән хәл ителде.

—Сәгать дүртләрдә кайтып китәрбез. Анарчы нишлисез сон?

—Бер житешеп килгәч, сезнен бу Болынкыр дигән күркәм жирегезне карап чыгыйм инде. Бәлкем берәр йорты күнелемә ошап куяр.

Айдар чыгып киткәч, Сөембикә шактый вакыт уйланып утырды.

Бу кешенен һәр сүзе, керфегенен һәр тибрәлеше, күз карашы, гәүдә хәрәкәтләре ана искиткеч сөйкемле, үз булып тоелды. Әхнәф яныннан чыкканда, йөрәген, монын азагы болай гына калмаячак, дигән шомлы ут көйдерсә, менә хәзер, Айдар килгәч, ул үзенә таяныч тапкандай булды. Юньләп әле танышып та өлгермәгән бу кеше әйтерсен лә аны якларга дип килгән һәм Сөембикә ана инде тулысынча ышана кебек иде.

Кичен, әзрәк мактанасы килеп, ул рульдә үзе кайтты. Машинаны капка төбенә генә куйды, гадәттәгечә шоферы аны үз вакыты белән килеп алып китә иде. Өйгә керүгә, Айдар өстәлгә Казан күчтәнәчләрен таратып ташлады. Киемнәрен салып, ак водолазкадан калгач, ул ябь-яшь булып күренде. Сөембикә ана карарга гаилә альбомнарын бирде, телевизорны кабызды, ә үзе кече якта ашыга-кабалана ашарга хәстәрли башлады, веранда базыннан тозлы кыяр, кәбестә алып чыкты. Ул арада Айгөл дә кайтып керде. Айдарны күргәч, ул ишек катында аптырап калды. Ирен араларыннан ишетелер-ишетелмәс кенә булып:

—Исәнмесез...—дигән сүз чыкты.

—Исәнмесез,—диде Айдар, анын каршына килеп.—Мин Айдар исемле. Сезнен исемегез ничек була, чибәр кыз?

—Айгөл...

—Ай, нинди матур гөл!

Айдар җитез генә иелде дә, сумкасыннан афоризмнар китабы алып, Айгөлгә сузды.

—Менә шушындагы фикерләргә таянып яшәсәгез, дөньянын ин бәхетле кешесе булырсыз,—диде ул елмаеп.

—Рәхмәт, шулай яшәргә тырышырмын,—диде Айгөл һәм чишенеп кухняга

үтте.—Нинди шәп китап! Мин бит моны күптән эзләп йөри идем, әни!— Аннары кызының йөзе җитдиләнеп китте.—Әни,—диде ул шыпырт кына.— Бу абый кем соң?

—Минем танышым, кызым. Казаннан килгән.

—Бер дә әйткәнең юк иде.

—Биючеләр конкурсында гына таныштым әле мин аның белән. Айгөл белән Сөембикә бергәләп ашарга әзерләделәр. Ашап-эчкәннән соң залга чыгып, өчәүләп күңелле генә әңгәмә корып утырдылар. Айгөлне берничә мәртәбә телефонга чакырсалар да, ул «Юк, мин чыкмыйм», дип җавап бирде. Бу вакытларда мәктәптәге берәр кичәдән яисә дискотекадан кайтырга тиешле кызының бүген өйдә утыруы сәеррәк иде. Хәер, ул моңа җавапны тиз тапты: кызы аны таныш булмаган ир кеше белән ялгызын гына калдырырга теләми иде. Сөембикә авылда әнисе белән яшәгән чакта кичергән бу тойгыны бик яхшы хәтерли. Ахыр чиктә ул—әни кешедән көнләшү, аны башка кешегә бирергә теләмәү, аны югалтудан курку.

Сөембикә Айдарга үз бүлмәсенә урын җәйде. Айгөл белән алар парлашып залдагы диванга яттылар.

—Айдар абый безгә озакка килдеме?—дип пышылдады ул әнисенең колагына.

—Белмим. Әгәр озакка килсә, ни дияр идең?

—Берни дә әйтмәм. Беләсеңме, әни, ул кемгә охшаган?

—Кемгә?

—Әбигә.

—Кайсы әбиенә?

—Җәүһәрия әбигә.

Кызының сүзеннән Сөембикә өнсез булып калды. Чыннан да Айдарның күзләре, борыны, бөтен йөзе әнисенекенә охшаган иде.

Ә иреннәре бөтенләй дә аерып алмалы түгел, елмаюлары да әнисенекенә тартым. Сөембикәнең күзенә нишләптер йокы кермәде, төрле уйларга батып төн уздырды...

Иртән алар урамга өчәүләп чыктылар. Мәктәп янына җиткәч, Айгөл кул болгап кереп китте. Сөембикә белән Айдар урам читеннән акрын гына атладылар. Таныш-белешләр Сөембикәгә сәлам биреп китсәләр дә, берничә адым үтүгә, кабат-кабат борылып карыйлар иде. Культура бүлеге бинасы турына җиткәч, Сөембикә:

—Мина эшкә керергә кирәк, сез нишләргә уйлыйсыз соң?—диде.

—Мин, Чаллы якларыннан йорт яисә квартира сатып алырга, дигән уй белән чыккан идем. Тик ул ниятемнән кайттым бугай.

—Ничек алай?

Айдар беркадәр вакыт җавап бирми торды. Аннары як-ягына борылып, караштырып алды да:

—Мин бирердән беркая да китмәс идем,—диде.

—Сатыла торган өйләр бардыр ич, белешергә кирәк.

—Өйләр барын бардыр, миңа аның сатып ала торганы кирәкми. Эчендә хуҗабикәсе дә булсын иде.

Ул Сөембикәгә серле караш таплады. Бу карашның мәгънәсен, төгәлрәк әйткәндә, аның ни теләвен аңларга була иде.

—Эзләгән кешегә андыйны да табып буладыр.

—Мин аны таптым кебек инде.

—Кичә килепме? Җитез икәнсез! Кайсы урамда?

—Урамын әйтә алмыйм, ә менә хуҗабикәсе минем каршымда басып тора.

Сөембикә бурлаттай кызарды:

—Мондый нәрсә белән шаярмыйлар, Айдар.

—Шаярырга уйласам, Казаннан шушында килеп йөрмәс идем...

—Яшермим, мин сезгә битараф түгел. Шуннан башка берни дә әйтә алмыйм. Хушыгыз.

Сөембикә кызулап эшенә кереп китте. Ул өс-башын чишенеп, төзәтенеп урынына утыргач та тынычлана алмады. Аның тормышында ниндидер зур үзгәреш башланырга тора иде. Ул инде бик якын һәм кызыктыргыч. Күңел ярларын ялгызлык ташкыны ашап газаплаган елларга, кайнар күз яшьләре белән чылатылган озын төннәргә, шатлыксыз булып аткан алсу таңнарга чик кую мөмкинлеге туа иде ахрысы. Бары бер тәвәккәл адым ясыйсы, тик ул ялгызлыктан коткарырмы? Әллә тагын да аяусызрак, гел уйга-башка китермәгән күңелсез көннәре белән тормыш дингезен кайната башлармы? Әгәр бу мөмкинлекне ычкындырып, әнисе кебек гел юктан үз бәхетен үзе югалтса? Ул хакта уйласа, әнисе өчен әрнүдән Сөембикәнең хәзер дә бәгыре телгәләнә. Әнисе гомере буе бәхеткә омтылды, ана якынайган саен, бәхете ерагая барды.. Әнисе Җәүһәрия кебек биюче юк иде. Бер уйлап караганда, аның бәхетсезлегенә күбәләктәй житез биюе сәбәпче булгандыр кебек тоела Сөембикәгә. Икенче караганда, нәкъ әнә шул биюе зур тормышка, бәлкем дан китерә торган зур сәхнәләргә алтын бәхет ачкычы да булгандыр. Район олимпиадаларында Җәүһәрия ел саен чыгыш ясый һәм беренче урынны ала торган була. Кыз чагында Казан сәхнәләрендә дә күпләрне таң калдыра, аны укырга чакыралар, ләкин ул фермада эшли бирә. Югыйсә, бәхет ачкычы кулында була бит!

Бер елны, олимпиада вакытында биегәнен күреп, ана районның жир бүлеге мөдире Даут үлеп гашыйк була. Зәп-зәңгәр күзле, житен чәчле, ап-ак тәнле, нәфис кенә буйлы, күзлекле бу егет көн саен диярлек кичләрен Тантугайга Җәүһәрия янына килә башлый. Даут аның өчен жанының яртысын ярып бирерлек булып йөргән, өйләнешергә тәкъдим ясаган, Казанга алып китәм, дигән. Үтә дә тәэсирләнүчән, йомшак күңелле Даут оста гармунчы һәм биюче булган. Алар бергәләп жырлаганнар, чәйләр эчкәннәр, кайчакларда парлашып Таңтугай урамнарын әйләнгәннәр, әмма Җәүһәрия, әллә ышанып бетмичә, әллә кызык итеп, ялындырып йөри биргән. Сөембикәнең әбисе белән бабасы да Даутны бик яратканнар, әнисенең шундый дәрәжәле кешене мәче тычканны уйнаткандай йөртүенә эчләре янып, аны ачуланганнар, кияүгә чыгарга кодалаганнар. Ахырда әнисе ризалаша. Алар өйләнешеп Болынкырга күчәләр. Әнисе культура йортына сәнгать житәкчесе булып урнаша, Даут аны өрмәгән жиргә дә утыртмый. Өч ай яшәгәч, ул куанып, икесенә дә санаторийга юллама алып кайта. Ашказаны авыртканлыктан, ел саен санаторийга бару аның өчен мәжбүри була. Ләкин Җәүһәрия санаторийдан баш тарта. Даут аптырашта кала, аны төрлечә үгетләп, кыстап карый. Алар беренче мәртәбә шунда ныклап ачуланышалар. Бер уйлап карасаң, әнисенең каршы килерлек сәбәбе дә булмый. Атна-ун көннән алар спектакль куясы булалар, Җәүһәрия шунда төп рольне башкарганлыктан, бу чараны өзәсе килми, район үзәгенә килеп, үзенең беренче олы эшен күрсәтү теләген жиңә алмый. Иртәгә китәсе дигән көнне, үгетләп тә эш чыкмагач, Даут:

—Чамала, сиңа үкенергә туры килмәгәе,—ди һәм китеп бара. Өч атна узуга, ул бер япь-яшь кызга өйләнеп кайта.

Җәүһәрия чәчен йолкымый, ана бернинди үпкә сүзләре белдерми. Әтисе үзенең бу адымын, миңа буйсынмый торган хатын кирәкми, дип кенә аңлата. Әнисе, барлы-юклы әйберләрен төяп, Таңтугайга кайтып китә. Даутның тәртибен райкомда тикшереп, партиядән чыгара язалар. Күпчелекнең яклавы аркасында гына аны эшеннән алу белән чикләнәләр. Яшь хатыны белән ул Казанга күченә, аннары бөтенләй Себер якларына китеп юк була. Әнисе, авылга кайтканнан соң, йөкле икәнлеген белә.

Бервакыт әнисенең әбисе каршында чәчләрен йолка-йолка елап аһырганын Сөембикә үз күзләре белән күрде: «Их, энкәй, Даут минем оҗмахым булган, мин шул оҗмахтан баш тарттым. Ничек үкенгәнемне белсәң!.. Ходай мине моның өчен беркайчан да кичермәс!..» дип елады ул.

Аннары әнисе Кәшифулланы йортка кертте, аның артыннан Сәфәргали килде. Шулар арасында Фәйзрахман, башкалар буталды.

Сөембикәнең авылдан китәргә теләвен белгәч, әнисе аңа бәбкәгә ташланган тилгәндәй ташланды:

—Мин сине беркая да җибәрмим!—дип ярсыды ул.—Мин синнән башка бер көн дә яши алмыйм.

—Әгәр мин кияүгә чыксам?—дип каршы төшә иде ана Сөембикә.

—Чыкмыйсың! Минем сүземне онытма: кияүгә чыгып, син беркайчан да бәхетле була алмыйсың.

—Нишләп?

—Безнең мангайга шулай язылган. Минем гөнаһларым өчен Алла сине җәзалаячак. Ялгызың яшәсәң, син бәхетлерәк булачаксың.

Сөембикә шушыларны хәтеренә төшереп баш ватты. Әллә соң әнисе хаклы булганмы? Ирек белән тормышлары барып чыкмады. Менә хәзер аның алдында бәхет офыгы яктыра башлады.

Алар, ингә-ин торып, Айдар белән Болынкыр урамнарыннан уздылар. Сөембикә юри башын югары күтәреп, төп-төз басып атлады. Күз яшьләре белән үткәргән елларына үч итеп, менә мин дә сезнең кебек бит, дип раслау иде бу. Ул күнелендә ниндидер келәнең шылт иткәнен сизде: әллә ачылды, әллә бикләнде... Ничек кенә булмасын, Сөембикә өчен бу бик тә ләззәтле иде...

## 2

... Айдар Болынкырда булып киткәннән сон, Сөембикәнең тормышы ничектер яктырды кебек. Алар бер-берсенә бернинди вәгъдәләр бирмәсәләр дә, аның киләчәген Сөембикә бөтен барлыгы белән тойды. Беркөн эштән кайтуга, аны Айдар ишек төбендә каршылады. Алар башта бер-берсенә шактый озак дәшмичә сынаулы караш ташлап тордылар. Бу үзенә күрә икесенең дә күнелләрендә нәрсә ятканын капшау кебегрәк халәт булды. Аннары Сөембикә үзе сизмәстән нишләптер көлеп җибәрде. Айдар аңа кушылды һәм алар бер-берсенең кочагына ташландылар. Шунын белән бергә яшәүләре хәл ителде.

Айдар Чаллыда бер бүлмәле фатир алган булып чыкты. Аның кулыннан балта-пычкы төшмәвен күреп, Сөембикә йортына ремонт кирәклеген аңлады. Җыйган акчасы юк иде, банктан ссуда алырга уйлады. Бүген кичкырын шул ният белән Фәһимә янына китте.

—Мөмкиндер бит?—диде ул, аның бүлмәсенә кереп.

—Әйдә уз.

Шулчак телефон шылтырады. Фәһимә трубканы алды да кеткелдәп көлеп җибәрде һәм бик кәефләнеп кем беләндер сөйләшә башлады. Ул, аягын аякка атландырып, йомшак кәнәфиенә ярым ятты,ниләрдер сораштырды, кемнеңдер көлмәгән, кемнеңдер түфлиләрен тикшерделәр, кайдадыр булган мәҗлес хәлләрен сорады. Сөембикә басып тора бирде. Ул, әлбәттә, утыра да ала иде, тик Фәһимәнең кул ишарәсе белән булса да урын күрсәтүен көтте, әмма андый ишарә булмады. Ниһаять, Фәһимә трубкасын куеп, борылмалы кәнәфиен бераз гына турайтып, Сөембикәгә карады:

—Тынлыйм.

Сөембикәнең йөрәге урыныннан купкандай булды. Фәһимәнең һәр хәрәкәтеннән, аңа карата битарафлыгыннан ул инде үзен өнәмәвен һәм бу

керүнен күтелгән нәтиҗәне бирмәячәген аңлаган иде. Шулай да, ятып калганчы атып кал, дигәндәй, ниятеннән чигенмәскә булды.

—Миңа ссуда кирәк иде, шактый гына күләмдә.

—Ссуда, ссуда...—дип кабатлады Фәһимә.—Ә нәрсәгә соң ул?

—Чыгым сорый торган эшләребез бар.

—Эшләрегез бар...—дип кабатлады Фәһимә, аның сүзләрен мыскыл итеп.—Яңа гаиләнең чыгымнары күп булыр шул...

Сөембикәнең күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды.

—Фәһимә,—диде ул, тавышын күтәреп.—Син нәрсә минем белән уйнап маташасың? Бирәсеңме, юкмы?

Фәһимә өстәлендәге ручкасын очыннан гына тотып шакы-шокы телефон аппаратына бәргәләп торды.

—Нәрсә, иске дуслар киткәч, капитал туплап булмый башладымыни?

—Син чамалап, Фәһимә!—диде Сөембикә теш арасыннан.—Мин бит сине чырайсыз да калдыра алам. Ишек төбендәге милиционерың да кереп житә алмас.

—Әйе, синнән барысын да көтәргә була. Күп эшләр майтардың, сөрдең дә, чәчтең дә...

—Ә мин синең җиреңә чәчмәдем. Нәрсә чәчсәм, шуны урып та алырмын.

—Урасың бит инде. Нәрсә урасың—анысын үзең беләсең.

—Тукта әле, Фәһимә, ни булды сиңа? Кергәндә үк мине чыраеңны җимереп каршыладың. Әллә мин синең юлыңа аркылы төштемме?

Фәһимә сикереп торды, ике атлауга аның каршына килеп басты.

—Кем юлына аркылы төшкәнеңне аңларлыгың да калмаган икән. Гомер буе дус булган булып йөрдең. Янадан эзең булмасын безнең тирәдә!

—Син борыныңны артык чөймә әле, Фәһимә. Вакыт житәр, син аны соңрак аңларсың! . .—ул ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Фәһимә күңеленнән бәйрәм итте. Күптән болай ләззәтләнгәне юк иде аның. Эштән кайткач та, шул тойгысыннан аерыла алмыйча, очына-очына ашарга әзерләргә кереште. Шулчак телефон шылтырады. Таныш булмаган ир кеше Әхнәфне сорады. Шаяртып, кыланчыкланып сөйләшә торгач, Фәһимә аның Рашат икәнен белде, әмма, күпме генә төпченсә дә, нинди йомышы барлыгын әйттерә алмады. Шулай да аның Казанда икәнен, телефон номерын белде. Кичен Әхнәф ашап-эчкәннән соң, гадәттәгечә диванга ятып газеталар караштырырга керешүгә, Фәһимә аның янына килеп утырды. Газетасыннан аерылып, Әхнәф хатынына сораулы караш ташлады:

—Нидер әйтәсең бар бугай.

—Бар шул,—диде Фәһимә, аның чәчләрен йомшак кына сыпырып.—Безгә үзара ныклы таяныч булырга кирәк, моның өчен бер-беребездән берни дә яшерергә ярамый.

—Минем синнән яшергән әйберем юк.

—Ә Арсланов малае Рашат белән нинди уртак эшең бар?

—Ни сөйлисең?—диде Әхнәф, битараф күренергә тырышып.

—Үзе әйтте, сине эзләп шылтыратты.

Әхнәф ансат кына котыла алмаячагын аңлады.

—Чаллыдан бер почмак алмакчы ул. Инде күптән ялвара, ярдәм сорый. Күрәсең, Арсланов минем анда элемтәләрем күплеген әйткән.

Әхнәф, бу сүзләргә хатыны дөртләп кабар, дип көткән иде, әмма алай булып чыкмады.

—И, карткаем, син булдыра алмаган нәрсә юк бит ул. Алып бир ана бер почмак. Рашат кебек тәвәккәл егетләрнең кирәк булып куюы да бар.

Фәһимә кайнар иреннәре белән аның иреннәренә үрелде...

Банктан Сөембикә күзләренә яшь тулган хәлдә, иреннәрен кан чыгарлык

дәрәҗәдә тешләп чыкты, өенә кайтып җиткәнче үкседе. Кабаланып чишенде дә бүлмәсенә кереп капланып ятты.

—Сөембикә, нәрсә булды?—диде Айдар, җинелчә генә анын инбашына кагылып.

Мендәр астыннан Сөембикәнең:

—Башым авырта, зинһар чыгып тор,—дигән сүзләрен ишеткәч, ул, авыр сулап, залга атлады, бераз уйланып торды да ишек алдына чыгып китте.

Фәһимәнең бу дәрәҗәдә бәрелүе Сөембикә өчен көтелмәгән хәл булды. Ул моның сәбәпләрен эзләде, әмма таба алмады. Дөрес, газетада теге интервью чыкканнан соң, Әхнәф белән аларның мөнәсәбәте үзгәрде, әмма бүгенге бәрелүгә ул гына сәбәп була алмый иде кебек. Нәрсә соң тагын? Әллә инде Сөембикәнең Айдар белән торуына бик күпләрнеке кебек анын да эче поша башлаганмы?

Соңгы вакытларда әнисенең бер сүзе нишләптер бик еш исенә төшә башлады: «Кызым, берүк кияүгә чыкма, нәкъ минем кебек булачаксың, без беркем белән дә тора алмаячакбыз». «Нишләп?» дип өзгәләнеп сорый иде аннан Сөембикә. «Чегән әйтте, уч төбемә карады да кыз чагымда ук әйтте: Сина, синең балана да гел яшерен ярату, яшерен очрашулар язган, диде». Гомеренең беренче өлеше караңгы авыл читәннәре, коймалары белән уратып алынган түгәрәк эчендә калды. Менә хәзер, бала ана карынынннан чыккан кебек, ул икенче яшәешкә күчеп маташа, үтә алырмы чикне, әллә чегәннең әйткәне тагын куып тотармы? Тормышның моңа кадәрге өлеше гаять тә буталчык, аңлаешсыз үтте, анда мин райком секретарен яуладым, дип яшерен горурланулар, борын чөюләр белән бергә шул эше өчен газапланулар, үз-үзеннән җирәнүләр бөтенесе бергә буталды. Җирәнде, бәргәләнде һәм тагын онытты. Бала чактан ук кешеләргә дә, үз-үзенә дә, әнисенә дә буйсынмас, баш бирмәс иде Сөембикә. Әнисе: «Уйнарга чыкмыйсың!—дип маңгаенда йодрык төеп тора, ә Сөембикә җаен таба, барыбер чыга, пычракка егыла, әнисе кыйный-кыйный, тирги-тирги өс-башын алыштыра. Ул тагын чыгып югала, тагын шул ук хәлдә кайтып керә. Урамда булмасын, мәктәптә булмасын, ихатада булмасын, маңгае, тез башлары, терсәкләре канлы яра, кутыр белән каплана, күгәрмәгән җире калмый иде. Сөембикә елый, бәрелмим, киемнәремне пычратмыйм, дип ант сулары эчә, кабат бәрелә, кабат пычракка бата...

Сүз дә юк, сак яши алмады ул. Авылда чакта кылган гамәлләренең яхшымы-яманмы икәнен белештереп тә бетермәде. Ирек белән яшәгәндә, аны үстерим, ижатына мөмкинлек тудырыйм, дип төрлечә баш ватты, үзенчә чаралар эзләде һәм муеныннан пычракка чумды. Чуммыйча да мөмкин булгандыр, һәркем ансатрак юлны сайлый, күрәсең. Билгесезлек куркыта, шуңа күрә Сөембикә үзе белгән, үзе сынаган юллар белән эш итте...

Авыл турында уйласа, анын хәзер дә бала йоннары кабара. Кеше гомеренең иң якты, яшьлек дип атала торган чоры анын өчен коточкыч кичерешләр белән тулы, бастырылу кебек куркыныч хатирәләр рәвешендә күнелендә калган. Аларны Сөембикә әле хәзер дә оныта алмый, ул барысын да күрде. Әниләренең хатын-кызлар, ир-атлар өерләре белән бергә эчкәннәрен, ызгышканнарын, өелеп сугышканнарын да күрде, тагын әллә нәрсәләр күрде. Күпме генә яшерергә азаплансалар да, күнел күзләре барысын да эләктереп барды.

Күршеләре Рәбигатти Сөембикәгә гел бер сүзне тукылады:

—Әниең сине әтиенә охшатып ярата.

Бу сүзләргә Сөембикә күпмедер ышана, чөнки әнисе Даутның фоторәсемен ала да бик озаклап аңа карап утыра, тавышсыз гына иреннәре кыймылдый, күзеннән яшь ага иде. Кайчакларда ул, Сөембикәне кочаклап, шул рәсемне тотып, әтисе турында әллә нинди җылы истәлекләр сөйли иде.

## 3

... Әнисе кече якта җирән Фәйзрахман белән эчеп утыра. Сөембикә идәндә курчак уйный, әнисе аны кертеп яткыра, йокларга куша, юрган белән томалап чыгып китә, әмма Сөембикә шундук атылып анын артыннан чыга. Әнисе белән Фәйзрахман өстәлнен ике башында кара-каршы утыралар. Җирән Фәйзрахман яланаяк, иске тишек трикодан гына. Олы аякларын сузып, әнисенен аяк йөзенә китереп баса. Әнисенен аягы авыртадыр, дип Сөембикә борчыла, ачуы кабара, түземе беткәч, өстәл янына атылып килә дә нечкә тавыш белән кычкырып җибәрә: «Әнинен аягына бачма!» Кычкырып кына калмый, олы курчагын сыйрагыннан тотып, Фәйзрахманның теҗенә бәрә. Әнисе белән алар көлешергә тотыналар, нәрсәдер пышылдашып алгач, Җәүһәрия йомрысына карлыган вареньесы салып болгата, шул ачы да, баллы да әйберне Сөембикәгә йоттыра. Ана рәхәт булып китә, ул көлә-көлә бии башлый, нишләптер әнисе белән Фәйзрахманның елмайган йөзләре дә, өстәл дә, урыны-урыны белән акшарын бозау кимергән моржа да, түшәм-стеналар да әйләнә. Ул әнисенен кулына авып төшә дә әллә кая оча, онытыла...

Бөтергечтәй бөтерелгән, туры сүзле, усал Җәүһәрияне авылда яратмадылар. Анын хәтта фермага барганын-кайтканын да күрми калабыз, дип сөйлиләр иде. Әнисен, төнлә силос-фураж урласа да, тота алмадылар, «җенледер син», ди торган иде аңа әбисе белән бабасы. Көпә-көндез ындыр табагыннан ярты капчык ашлык шудыру да Җәүһәриягә берни тормады. Ару-талунын ни икәнен белмәде, фермада эшләде, басудагы чүгендерен эшкәртте, печәнен чапты, урманга барып утынын әзерләде, коймасын койды, үзе веранда корды, мал өе салды, кулында балта-пычкы, сәнәк-көрәк уйнап кына торды. Ат арбасына печән-саламны берүзе төяде, берүзе ташыды, берүзе өйде, алҗау дигән әйберне белмәде. «Мина көнгә унбиш минут йокы җитә», ди торган иде ул. Әнисе аракысыз да йөрмәде, ир-атлар белән эчте, алар белән күнел ачты, хатын-кызлар аңа, оядагы йомыркаларын урлап эчкән саесканга карагандай, шикләнеп, сөймичә карадылар. Анын турында, берүзе ун хатын-кызга, ун иргә тора, диделәр.

Әнисе аркасында Сөембикәгә дә, «алма агачыннан ерак төшми», дип карадылар. Ә анын үзен бөтен кешедән дә яраттырасы килә иде. Мона комачаулаганы өчен ул әнисен күрәлмады. Авылда Сөембикәне кызганучылар да табылды, «әтиен булса, болай борлыгып йөрмәс иден, нинди кешене китәргә мәҗбүр итте бит, Алланын ачы каһәре төшкере», диделәр. Бу сүзләргә Сөембикәнен котырып ачуы чыкты, ул үзен кызгануларын һич кенә дә теләмәде. Мондый чакларда холыксызланды, кулына эләккән әйберләрне алып томырды, әнисе белән талашты, түзә алмаса, чыгып утын ярды, бакча казыды, күрәлгән карларны кабат көрәде, күнелендәге ачуны баса алмыйча иза чикте. Күнеле утырган, тыныч кына йөргән чакларда да ул карангы бу тормышны күрә алмады. Бу күрәлмау тойгысында ачу белән кызгану икесе бергә катышып буталган иде. Ачу дип ул бернигә дә каршы чыга алмады, кызганам дип беркемгә дә булыша алмады. Аларнын кечкенә Тантугай авылы дингез уртасындагы ялгыз утрау кебек яшәде, берданбер юл мәктәпкә, клубка, кибеткә, колхоз үзәгенә генә бар иде. Сөембикәне бер уй—авылдан ничек булса да чыгып качарга, дигән уй гына биләде. Ул аңа шулкадәр нык үтеп керде, Сөембикә үзе артыннан йөргән егетләргә дә игътибар итмәде, кем икәннәренә дә карамастан, бер сүз белән кире борды. Насыйбына язган егетләрнен юньлерәк җирдә—якты, шау-шулы шәһәрләрдә көтеп торуларына анын иманы камил иде. Шуңа күрә авыл каргалары белән вакыт уздырырга теләмәде, алар белән чуалырга дәрте дә булмады. Авылдан качу теләге

тегенди-мондый шаяруларга урын калдырмагандыр, күрәсең. Сөембикәнең теләгән белгән бабасы, аны янәшәсенә утыртып, сабыр гына үз уйларын сендерергә теләде:

—Онытма, кызым, чын тормыш авылда гына,—дия иде ул.—Шәһәргә качу—чын асылыңнан качу. —Анда ясалма корылмалар, ясалма тормыш.— Аның сүзләрен Сөембикә колак очларыннан уздырды, мәдрәсә белемле үткән заман кешесе каян аңласын аларның уй-хыялларын, дип уйлады. Ә бабасы һаман төрле яклап суктыра бирде:

—Әнә Фәйзрахман абыең белән әниеңне дә шәһәр аерды. Югыйсә балачактан ук гел бергә булдылар. Әллә ниләр эзләп, авылдан чыгып китте, шул китүдән зимагурлыкта йөрде. Ул кайтканда, әниең әтиеңә чыккан иде инде. Әтиең киткәч тә, әллә ничә мәртәбә күз яшьләре белән сорап килде...

Бәргәләнгән-йөдәгән чакларында Сөембикәнең бердәнбер таянычы әнисе белән бертуган Мөнир абыйсы булды. Акыллы кеше иде Мөнир Кәбиров. Шулай булмаса, гомер буе әле авыл Советы председателе, әле партоешма секретаре итеп эшләтмәсләр иде. Кәшифулла мәсхәрәләп, үзен шау-шу кубарудан туктатып калгач, ул Мөнир абыйсына Аллага караган кебек карый башлады. Аның никадәр хаклы булганлыгын Сөембикә соңрак аңлады. Унберенче класста укучы бер кыз алданып, шау-шу кубаргач, ул кызга бөтенесе бармак төртеп күрсәтергә тотынды, ачыктан-ачык мыскыллады, ир-атлар оятсыз тәкъдимнәр ясады.

Кәшифулла белән булган вакыйгадан соң, Мөнир Кәбиров кайбер нәрсәләрне Сөембикәгә ачыктан-ачык сендерде:

—Менә синең гөлең бар, утыртырга савытың юк. Атың бар, арбаң юк—кешедән алып торасың. Синең иң зур хыялың—авылдан чыгып китү, кая да булса урнашу. Аны тормышка ашырырга синең мөмкинлегең юк, ә бит сиңа ярдәм итәрдәй кешеләр бар. Шуларны табарга, файдаланырга кала. Ничек итеп булса да алгы планга төп мәнфәгатьне куясың. Бу—тормышның конституция кебек төп кануны.

Ул әйткән фикерләрнең асылына әүвәл бик үк төшенеп җитә алмады Сөембикә. Әнисенә җинаять эше ачылып, авылга тикшерүче Янчурин килеп йөри башлагач, Мөнир абыйсы үз фикерләрен тагы да аңлаешлырак итеп җиткерде. Сөембикәне олы курку биләде, ул хурлыклы упкынга сикерергә теләмәде, ләкин абыйсы каты бәрелмәде, аның эчке халәтен күреп, бу гамәлләрнең зарурлыгын дәлилләп күрсәтте. Шундый сөйләшүләрнең берсендә Сөембикә ярсып китте. Аңа әллә нинди гаепләү сүзләре ташлады, бу адымга беркайчан да бармаячагын әйтте. Ләкин Мөнир Кәбиров үзенә ташланырдай булып ярсыган Сөембикәгә бик тыныч карады.

—Ярар, сеңлем,—диде ул бераз үпкәләгәнрәк тавыш белән.—Мин сиңа үз тәҗрибәмнән чыгып ярдәм итәргә теләдем. Һавада очып йөрү әйбәт нәрсә, анда иркенлек, чисталык. Горур яшә, саф кал, әмма тәнең белән син менә шушы пычрак фермада аунаячаксың, сине авыл хатыннары язмышы көтә. Ирең дә булмаячак, күреп торасың, чын егетләр инде әллә кайчан авылдан качты, калганнары җыен әтрәк-әләм, егет аламалары гына. Менә син шунда якты кояш кебек саф, горур булып яшәрсең.

Аның бу сүзләре Сөембикәнең колак төбендә әллә ничә көн яңгырап торды. Уйлана торгач, ул аңа елап барды. Әмма Кәбиров дәшмәде, аны шул хәлендә калдырып чыгып китте. Шактый вакытлардан соң гына йомшап, яңа киңәшләрен бирә башлады:

—Мәхәббәт, гаилә юк икән—кыска, очраклы очрашулар тормыштагы уен гына,—диде ул.—Хыянәт тә, бозыклык та юк. Авыл кешеләренең тормышын кара. Әнә кемнәр кем белән генә буталмый. Яшәеш буыннан буынга шулай дәвам иткән. Тәннең дә, җанның да үзенчә яшисе килә...

Сөембикә булдыра алганча читкә тартылып азапланды, ләкин инде, өстенә өй биеклеге булып килүче рәхимсез дулкын алдында калган кешедәй, үзенең көчсез икәнлеген анлады. Анын бу карышуы сонгы талпыну, тел белән генә карышып азаплану иде. Янчуринның эшне төгәлләп судка тапшырыр вакыты житкәч, сузарга мөмкинлек калмады. Сонгы очрашуда Кәбиров ана:

—Жир йөзендә әнидән дә кадерле жан иясе юк,—диде.—Аны утыртсалар, икегез дә һәлак буласыз. Әгәр Янчурин сина шундый тәкъдим ясаса, әниен хакына... Анла: әз генә чигенүдән берни дә булмый; әз генә, чепети генә чигенү...

Янчуриннан сон, Шәвәлиев белән очрашуга Сөембикә өлгереп житкән иде инде. Бу кызык уеннан үзенчә тәм табарга да өйрәнде ул. Кая таба тәгәрәгәнлеген бик сонарып анлады. Сөембикә Мөнир абыйсы ярдәмендә бер көйгә тирбәлә-тирбәлә акты да акты. Ана үзенә юл ярырга кирәк түгел, бөтенесе әзер, күрсәтелгән, шул кушылган ихтыярга буйсынырга гына кирәк иде. Ярнын әле бер, әле икенче ягыннан абыйсынын ышанычлы сүзләре аны озата барды:

—Анла, бөтенесе вакытлыча... бөтенесе дә узачак. Аннары яна тормыш башлыйсын... Ә хәзергә тешенне кысып түз—котылу юлы бары шушы гына... Кеше үзен гомер буе ваклап-ваклап башкаларга өләшә...

Мөнир Кәбировнын бик күп сүзләре мәктәптә өйрәтелә торган, газета-журналлар, радио-телевизор аша туктаусыз сендерелә торган югары әхлак нормаларына тәнгәл килә иде...

Хатирәләр, елларны сикерә-сикерә әле ерактагы үткәннәргә, әле бүгенгегә кайтып, аны бик озак уратып йөрттеләр. Ул залга чыкканда, кызы телефоннан сөйләшә, Айдар өстәл янында газеталар укып утыра иде. Айгөл берничә кыска сүз белән трубкага нидер эндәште дә, кинәт Айдарга борылып:

—Сез нишләп минем сөйләшкәнне тынлап утырасыз?—диде.

Айдар сискәнеп китте һәм урыныннан сикереп торды. Ул кулындагы газетасын бөгәрләп, күкрәгенә кысты.

—Гафу ит, Айгөл... Мин синен сөйләшкәнне тынларга теләмәдем, газета укый идем.

—Тынлыйсыз!—диде Айгөл ачулы тавыш белән.—Сез һәрвакыт мин сөйләшкәнне тынлыйсыз!

Айдар газетасын куйды да башын иган хәлдә акрын гына өйдән чыгып китте. Сөембикә Айгөлнен сөйләшеп бетергәнен көтте дә ана ияреп кухняга чыкты. Кызы мәктәптән кайтып ашарга утырган булган икән. Ул, чәнечкесенә үрелеп, котлет ашарга керешә. Сөембикә аркасы белән кухня шкафына сөялде, кулларын күкрәк турына баглап куйды.

—Кызым, нигә син ана каты бәреләсен?—диде ул ялварулы тавыш белән.

—Минем сөйләшкәнне тынламасын.

—Сәбәп анарда түгел бит. Син ана һәрвакыт яратмыйча карыйсын. Айдар абыеннын сина бернинди начарлык кылганы юк. Ул синен өчен дә, минем өчен дә якын кеше. Ә син аны һәрвакыт гел авыр хәлгә куясын.

—Ярар, моннан сон гел елмаеп кына торырмын...

—Синен ясалма елмаюын кирәкми. Без кешеләрчә яшәргә тиеш. Син аннан көнләшмисендер ич?

Сөембикәнен бу сүзләренә Айгөлнен күзләре очкынланып китте, бит очлары кызарды.

—Мин көнләшмим. Әгәр ул сина бик кадерле булса, үзеннен бүлмәндә генә тот.

Айгөл сикереп торып чыгып китмәкче булды, ләкин Сөембикә аны беләгеннән эләктереп алды. Икенче кулы белән янагына чалтыратырга кизәнәм дигәндә, ничектер үз-үзен җиңеп, тыелып кала алды.

—Бу сүзләрең белән син мине бик нык рәнҗеттең, кызым,—диде ул теш арасыннан.

Айгөлнең кулын җибәрде дә кызулап ишек алдына чыгып китте. Айдар Ирек ясаган чатырга утырган да, күзләрен йомып, хәрәкәтсез калган. Каршына Сөембикә килеп басуга, ул күзләрен ачты, ләкин карашын читкә алды.

—Менә тагын көз житте,—диде Сөембикә, зәңгәр күк йөзенә, агач ботаклары арасыннан офыкка тәгәрәп баручы кояшның кызгылт нурларына карап.—Яфракларда җәйге яшеллек юк инде...

—Быел көз аяз булачак, кыш җылы килер, дип язганнар.—Айдар бармакларын чатыр өсталендә биетте, андагы биш-алты алманы урыннарыннан кучергәләп куйды.—Ә миңа нишләптер быел кыш бик салкын булыр кук тоела.

Сөембикә аның янәшәсенә килеп утырды, күзләренә туп-туры карады .

—Сиңа бик тә кыен, Айдар. Без бит кулга ияләшмәгән кыргый җәнлек белән бер...

Айдар аның чәченнән сыпырды да елмаеп:

—Бар, чиләк алып кил әле,—диде.

—Ник?

—Коелган алмаларны җыйыйк.

Сөембикә зәңгәр капрон чиләк алып килде. Алар чүгәләп алма җыя башладылар. Берчакны бер-берсенә якынаеп, иңбашлары терәлде. Айдар, бер зур гына алманы алып, Сөембикәнең иңбашына сөрткәндәй итте дә шартлатып тешләп алды, аннары аңа сузды. Сөембикә дә тешләп алма капты. Алар парлашып авызларындагы алмаларын тәмләп чәйни башладылар.

—Әйбәт кеше син, Айдар,—диде Сөембикә пышылдап.

—Синең белән мин башкача була алмыйм...

Айдарның тавышы шундый ягымлы, йомшак, елмаюы серле иде.

## 4

Май урталарында Ирек көнкүреш комбинаты коридорында Кәрәм Нәҗмиев белән кара-каршы очрашты. Күптән сагынышкан дуслар кебек, кул биреп күрештеләр, әлбәттә инде, хәл-әхвәл сораштылар.

—Менә шушы халык өчен бик кирәкле тармакны яшәтергә дип җан ату инде картайган көндә,—диде Кәрәм Нәҗмиевич, сыңар күзен кысып.

—Сезнең өчен бу кечкенә оешма нәрсә инде ул,—диде Ирек, аның салпы ягына салам кыстырып.—Сез бит районны тоткан кеше. Дер селкетеп, дисәң дә, хата булмас.

Бу мактау сүзләреннән Кәрәм Нәҗмиевичнең иреннәре җәелеп китте.

—Булды эшләр. Әйдәгез, минем бүлмәгә керәбез.

Гәпләшә-гәпләшә кофе эчкәннән соң, Нәҗмиев, райком заманнарындагы таныш мөштеген чыгарып, сигарет кабызды һәм, ике-өч мәртәбә тирән итеп сулыш алганнан соң, төтен эчендә элеккечә куәтле, усал зат булып гәүдәләнде.

—Таныш мөштек,—диде Ирек көлемсерәп.—Туза торган түгел.

—Аның тузарга җае юк, эченнән кайнар төтен йөреп тора. Бернинди микроб, эррозия ашый алмый. Менә сезне дә, иптәш Сабитов, үз мөштеге белән Шәрифуллин бик әйбәт суыра бит...

Сүзнең мондый юнәлеш аласын көтмәгән Ирек, тыныч кына чабып барган җәнлек ят тавыштан өркеп калгандай, сискәнеп китте:

—Элекләрдә сезнең төтен күзне әчеттерә торган иде инде ул әчеттерүен. Хәзер бигрәк тә зәһәрләнә бугай...—Ирек урыныннан торды.—Кофегыз бик тәмле булды, рәхмәт,—диде ул шактый ачулы тавыш белән.

—Ирек туган!..

Ирек чайкалып китте, Нәҗмиевның алай дип эндәшүен хыялга да китереп

булмый иде. Ялгыш ишетмәдемме икән, дип кабатлап сорарга мәҗбүр булды:

—Нәр-сә?..

—Син мине бүлдермичә тыңла. Мин үз гомеремдә шактый кешеләрнең язмышларын теләгән якка бордым, үзгәрттем. Хәзер бөтен нәрсәнең асты өскә килде. Шуңа да карамастан, татар дигән халык яшәргә тиеш. Ә син, Сабитов, безнең халыкның бер вәкиле. Болынкырда татарның асыл егетләре кем соң? Әхнәф Шәрифуллинмы, Ирек Сабитовмы?

—Ә нигә без икебез генә?—дип сорап куйды Ирек, аның сүз сөрешенең кая барганын аңламыйча.

—Халык сезнең бергә икәнегезне күреп тора. Тик Шәрифуллин милләт улы түгел. Ана халык кирәкми.

—Ул сезне эшегездә калдырган булса, бу сүзләрне әйтер идегезме икән?

—Мөгаен әйтмәс идем. Мин сиңа бер сорау гына бирмәкче идем. Әйткән җавабыңа карап, сиңа гына түгел, хәтта тулаем Сабитовлар нәселенә бәям үзгәрәчәк, яисә элеккечә калачак.—Нәҗмиев сүзен бүлде дә, авызындагы төтенен чыгарып бетергәч, Ирекка якын ук килде һәм, аңа иелеп, пышылдаулы карлыккан тавыш белән:

—Өй туена бүләк ителгән стенка белән шкафның картлар йортына кайтарылганын сез белдегезме?—диде.

—Ә?!!—Ирекнең сулышы өзелде, күкрәгендәге һава ни эчкә кермәде, ни тышка чыкмады.—Кәрәм Нәҗмиевич... бу бит... Сез беләсезме... мондый нәрсә белән шаярмыйлар.

—Димәк, белмәгәнсез...—дип сузды Нәҗмиев.

—Соң белсәм... мин шуны алыр идеммени?!

Нәҗмиев сигаретын мөштегеннән алып көл савытына китерде дә сытты, изде. Аннары тораташ каткан Ирекне бүлмәсендә калдырып чыгып китте. Ул секретарь кызның:

—Ирек Хәйриевич, әллә авырып киттегезме?—дип дәшүеннән бераз айныгандай булды.

Ирек, урыныннан кузгалып, нишләптер каршы яктагы почмакка атлады, аннары ялгышын аңлап, кире борылды да исерек кеше кебек бүлмәдән чыкты, саубуллашмый-нитми, коридор стенасына тотына-тотына, урамга чыгарга ашыкты.

Әллә атлап, әллә үрмәләп, музейга кайтып җитте. Керде дә урындыгына лапылдап утырды, уйларының очын да, азагын да табып булмый иде. Ничек Әхнәф шушыны эшли алган?! Ул бит бүләккә сынар китап күтәреп килсә дә Ирек канәгать иде. Стенка белән шкафның нинди бүләк икәнен сизгәндәй, ул әллә ничек бөтен барлыгы белән куырылган иде.

Кичен эштән кайтканда Ирек бәгыреннән бер тамырын суырып алган кеше хәлендә иде. Өйгә кергәндә үк, утынлыктан балтаны эләктерде. Бу әшәкелекне бары тик шуның белән генә төзәтеп булыр кебек тоелды аңа. Чишенеп тә тормастан, стенка каршысына килде. Зәнфирә анда матур итеп әйберләр тезгән, бер урынында алтын йөгертелгән кыңгыраулы сәгать текәлдәп утыра, урта өлешендә Ирекнең иң кадерле китаплары, астагы бүлкәдә аның язарга җыйган материаллары. Ул, тешен кысkan хәлдә, үзеннән сабырлык сорап, балтаны кабат урынына чыгарып куйды. Алар гадәт буенча, кайсысы алдан кайтса, шунысы чәй куя, ашарга әзерли торган иде. Ирек бүген берничә дә кагыла алмады, ул һаман шул чишенмәгән килеш өстәл янында утыра бирде. Менә Зәнфирә кайтты, Ирекнең шундый хәлдә кара коелып утыруын күргәч, гаҗәпләнүдән аның кашлары җыерылды, кулындагы әйберләрен өстәлгә куеп, ул Ирекка иелде.

—Нәрсә булды сиңа, карткаем? Бөтенләй төсең калмаган. Син бит авырыйсың.—Ул, аның кулын җәһәт кенә эләктереп, пульсын эзләп тапты.—

Йөрәгең дулап тибә, ашыгыч ярдәм чакырыйк.

—Кирәкми...—диде Ирек, авыр сулап.

—Жә, әйт, нәрсә булды?

Ирек, исерек кеше кебек, башын югары күтәреп, карашын Зәнфирәгә түгел, каядыр читкә юнәлтте :

—Шундый нәрсә... безнең, урамга чыгып, кешеләр күзенә карарлыгыбыз беткән икән...

Аның бу сүзләреннән Зәнфирә өнсез калды:

—Әйт тизрәк, ни булды?

—Булган инде. Кара син безнең стенкага, шкафка. Матурмы?

—Матур.

—Ә син беләсеңме аларның картлар йортында тәрбияләнүче гарип-гораба, авыру, тормыш тарафыннан рәнҗетелгән затларның өлеше икәнен?

Зәнфирә берни аңламады, аның йөзендә гаҗәпләнү артка괬нан-арта барды.

Ирек сүзен дәвам итте:

—Әхнәфләр ул әйберләрне картлар йорты хисабына китерткәннәр! Шәп бит, ә?!

Ирек әллә нинди ят тавыш белән көлгәндәй итеп куйды. Аның әйткәннәре Зәнфирәгә әле һаман барып җитә алмый иде: ул тавышсыз гына, түбәсенә китереп суккан кешедәй, башын чайкады. Ирек сикереп торып, җиңнәрен сызгана башлады.

—Әйдә, әйберләреңне бушат, мин үземнекеләрне алып куям, стенкасын да, шкафын да сүтәбез дә картлар йортына илтеп тапшырабыз.

Зәнфирә юынгычка атлаган җиреннән туктап калды һәм, аптыраулы карашын төбәп, Ирекнең каршына килде:

—Зинһар кызма әле! Нинди дер башка юл табарга кирәк.

—Башка юл юк.—Ирек тавышын күтәреп кычкырды:—Аңлыйсыңмы, башка юл юк! Кабахәтлек кабахәтлек булып кала. Мин аларны турарга дип алып кергән балтамны чыгарып бәргән идем. Әгәр син тагын мәмрәп торсаң, аны алып кереп, менә хәзер шушында күз алдыңда турап өям.

—Зинһар әз генә сабыр ит,—диде Зәнфирә, ике кулы белән башын тотып.—Әз генә тынычлан, шулкадәр куырма, башыма капты...

—Бушат әйберләреңне!

—Бушатмыйм, үзең теләсәң нишләт!—Зәнфирә кычкырып елап җибәрде.—Миңа берсенең дә кирәге юк, турап бетер! Ишек алдына алып чыгып, ут төртеп яндыр!—Ул елый-елый бүлмәсенә кереп китте.

Ирек катып калды. Аның йөрәге, келәшчә белән кыскандай, сызлап сулкылдады.Ул ишек алдына чыгып китте, тыкрыктан урап менде, караңгырак урыннардан кызу-кызу атлады, эчендә дөрләгән ялкынны ничектер сүндерергә, тынычланырга кирәк иде. Ул, йөреп кайтып капкадан кергәч тә, ишек алдында шактый басып торды. Ирек бер карарга килә алмады, моның сәбәбен ул ачык аңлады: Зәнфирә аны чигендерде. Өйгә кергәч, юынып өстәл янына килде. Кара-каршы утырып, бер сүз дәшмичә, мәҗбүри ашаткандай, чытык йөз белән ашадылар, чәй эчтеләр. Аннары икесе ике якка аерылды: Ирек залга чыгып телевизорны кабызды, ә Зәнфирә кухня ягында нидер эшләде.

Икенче көнне кич тагын шул күңелсез тарткалаш башланды.

—Мин бер котылу юлын таптым бугай,—диде Зәнфирә.

—Нинди юл?

—Бәясе билгеледер бит инде аның? Акчасын түләрбез. Аның бу сүзләренә Ирек дөртләп капты:

—Аннары һәрбер кешегә квитанция селкеп йөреп күрсәтербезме?! Әллә район газетасында белдерү генә бирәбезме? «Без ул әйберләргә акча түләдек,

тулы исәп-хисап ясалды», дип. Юк, Зәнфирә! Бу мөмкин әйбер түгел. Моны мин әйткәнчә генә төзәтеп була. Жыештыр әйберләренне!

Бераздан авыр сулап, икесе дә эшкә тотындылар. Ял көнне Ирек көне буе стенка белән шкафны сүтте, кисәк-кисәк итеп бау белән бәйләде һәм верандага чыгарып өйде.

## 5

Икенче көнне төштән соң Ирек, Нәжмиевтән УАЗ машинасы алып, өенә кайтты. Стенка белән шкафны төяп, картлар йортына киттеләр. Әмма директор аларны ихатага кертү түгел, капкага да якын китермәде, яла ягасыз, милиция чакырам, дип куып жибәрде.

—Сез Шәрифуллинның төзелеп ята торган йортын беләсезме?

—Беләм,—диде шофер, куркудан агарынып.

—Белсән, киттек шунда.

Алар Болынкыр читендәге каенлыкка терәп салынган өч катлы мәһабәт йорт янына килеп туктадылар. Анын турында ишеткәне, Әхнәфнен, килеп күреп кит, дип чакырганы булса да, Ирекнен монда аяк басканы юк иде әле. Ул үзенен эшләнеше, почмакларыннан күтәрелгән манаралары белән чын крепостьны хәтерләтә иде. Коймалары биек итеп тимердән тотылган, йорт үзе кызыл Мәскәү кирпеченнән салынган. Тәрәзәләрнен өсләре түгәрәкләп уелган, пыялалары көзгедәй елтырап тора, төн карангылыгы сендерелгән төсле ул пыялалар аша эчтәге бер әйберне дә күреп булмый. Ике катлы гараж, эчтәрәк тагын нинди дер корылмалар шәйләнә. Капка биредә дә бикле булып чыкты. Ләкин баганасына саннар төшерелгән калькуляторга охшаш нәрсә беркетелгән иде. Ирек шунын берничә санына баскалап алды. Күрәсен, өй эченә сигнал барып житте, ишек ачылып, озын гәүдәле, кара мыеклы, күн фуражка кигән бер ир салмак адымнар белән капкага юнәлде. Ныклабрак карагач, Ирек анын Миргаяз икәнлеген таныды. «Әллә сон мин төш күрәмме?» дип уйлады ул эченнән, аптыраудан гажиз булып. Ул арада Миргаяз:

—Һо-о-о, Ирек Сабитов!—диде дә, колачын жәеп, Ирекне кочаклап алды, ананардан аракы исе бөркелеп тора иде.—Нинди жилләр ташлады?

Картлар йортында бер абынып ялгышкан Ирек бу юлы ул ялгышны кабатламаска теләде:

—Менә абзый кертеп чыгарга кушты, тизрәк капканны ач,—диде ул, Миргаязны ашыктырып.

—Пожалуйста.

Нинди дер кнопкага басуга, зур капка шуып ачылып китте. Алар машина белән эчкә уздылар.

—Кая куярга кушты?—диде Миргаяз.

—Анысын әйтмәде, үзен хәл ит.

—Ярый, менә монда коридорга гына кертәбез.

Бәйләмнәрне кертеп сөяү озак вакытны алмады. Эш беткәч, Миргаяз:

—Әйдә, минем бүлмәгә керәбез, әзрәк чемердәтеп утырыйк,—диде.

—Керергә вакыт юк әле,—диде Ирек.—Онытты гыз бит мине.

Миргаяз ана дәшмичә күзен кысып, мәсхәрәле караш ташлагандай карап торды:

—Без бит вак кешеләр, ә синен масштаблар, Ирек Сабитов, хәзер зурдан. Менә бит кемнәр белән эш итәсен.

—Ә син?—диде Ирек.—Мин әле бу йортка беренче мәртәбә киләм, син яшәп үк ятасын түгелме сон?

—А как же!—диде Миргаяз.—Без дә төшеп калганнардан түгел.

—Турысын гына әйт әле, син ничек килеп эләктен монда?—Миргаяз шоферга карап куйды.

—Син бу егетенне җибәр әле, өенә тәпиләп кайткannан бер әйберең дә төшеп калмас. Хәзер мин сиңа йортны күрсәтәм, берәрне кәгеп тә алырбыз.

Ирек шоферга рәхмәт әйтте дә машинаны җибәрде.

—Мин монда хәзер ел ярым инде. Ә килеп эләгүемә тамак гаепле: бирелә безнең бригада эшли. Башта бассейн ясадык, хәзер теплица корабыз. Эш муеннан.

—Ә син кем соң?

—Мин монда үзем управляющий, үзем каравылчы, үзем ташчы. Әйдә инде берәрне тотыйк!

—Рәхмәт, мин бит ул әйберне ташладым.

—Их, бар иде күңелле вакытлар, малай, ә? Мин үзем дә шактый киметтем аны. Әле бүген хуҗалар Казанга кунакка киткәннәр иде, шуңа гына бераз бәйрәм итәм. Бу мәсьәләдә бик каты ул. Күрсә, кылыч белән башыңны гына кисә. Шаярырга ярамый.

—Ә бу күршедәге ике катлы йорт кемнеке?—дип сорады Ирек, беренче каты таштан, икенче каты шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган йортка күрсәтеп.

—Анысы Фәниснеке, хакимияттә эшли бит, Сәлахов. Шушы көннәрдә алар күченәләр инде.

Миргаяз Ирекне йортның эченә алып кереп китте. Беренче каты инде эшләнеп беткән, штукатурланган, алтын люстралар асылган икән. Шушы ук катта сауна, бассейн, үтә дә зур кухня, туалет, тагын ниндидер берничә бүлмә бар. Миргаяз шул бүлмәләрнең электр белән җылытыла торганында яшәп ята икән. Икенче, өченче катларда штукатурлау эшләре генә калган. Аларда йокы бүлмәләре, заллар, китапханә, спорт, бильярд бүлмәләре урнашкан. Аларны күреп-карап, хәтерләп кенә бетерерлек түгел икән. Миргаязның сөйләве буенча, инде бильярд та, музыкаль үзәк тә, һәр бүлмәгә япон телевизорлары, магнитофоннар, тагын әллә нәрсәләр складка кайтарып тутырылган. Өченче катның тәрәзәсеннән карагач, йорттан берничә йөз метр ераклыкта актарылып ташланган туфрак өемнәре күренде.

—Алары нәрсә була?—дип сорады ул Миргаяздан.

—Анда зур плотина төзеләчәк. Менә бу өйдән чыгып, бәрәңге бакчаларын узгач, әнә теге тип-тигез урынны күрәсеңме? Анысы туп тибә торган урын. Шуннан соң инде буага чумып була.

Ирекнең күңелендә әллә нинди давыл купты. Ул давылның нишләп купканын да, аны кая таба очырганын да ул инде сизми иде. Миргаяз белән әллә хушлашты, әллә юк—анысын да хәтерләмәде, шул давыл канатларында аягы белән бер җиргә тиеп, бер күтәрелеп, Ык буена кайтып җитте.

### 6

Миңзаһит урыныннан торып утырды, чүәкләрен дә элмичә, өстенә халатын да кимәгән хәлдә, нишләргә кирәклеген уйлый башлады. Аяк очларына гына басып, үзләренең бүлмәсе ишеген тоткасыннан бераз күтәреп этте дә тыңлап торды. Рашат бүлмәсеннән тавыш-тын ишетелмәде. Төнлә аның бөтен фатирны бер итеп шатыр-дөбер йөрүен котлары очып тыңлап ятканнар иде. Котырды, сүгенде, урындыкларны аударды, ниләрдер эчте, телевизор акыртты, ахырда кереп йоклады.

Миңзаһит үзен бу дәрәҗәгә төшәр, дип элек башына да китерә алмас иде. Кемне дә булса шундый хәлгә калган, дисәләр, кычкырып көләр, берни дә аңламас, аны адәм актыгы дип гаепләр иде. Хәзер нәрсә? Алар Рашатка һәм үзләрен чолгап алган шул хәтәр дөньяга каршы көрәшәләр. Иң элек малайларын эчкече, куркыныч марҗадан аерырга алындылар. Марҗа инде ачыктан-ачык килеп йөри, Рашат өстеннән генә түгел, алар өстеннән дә хакимлек

итеп азаплана иде. Ахырда Минзаһитка район эчке эшләр бүлеге начальнигына керергә, үзенең нинди эшләрдә эшләгәнлеген әйтергә һәм бүгенге тормыш хәлләрен сөйләп бирергә туры килде. Баруының нәтиҗәсе озак көттермәде: маржаны кулга алдылар, суд та булды. Ул кызлар һәм егетләрне наркотик кулланырга, башка бозыклыкларга өйрәткән булып чыкты. Рашат, бу хәлләрдә Минзаһитның катнашканлыгын белгәч, чын мәгънәсендә ерткычка әверелде. Аның акча сорап кул күтәрүләре гадәти хәлгә әйләнде. Минзаһит белән Хәят акчаны төрлечә бүлгәләп, яшереп тоттылар. Рашатның котыру дәрәҗәсе бик куркыныч булса, зуррак сумма, түзәрлек булса, кечкенәрәге бирелде. Рашатның берничәшәр ай югалып торган чаклары алар өчен бәйрәмгә әверелде. Андый югалулардан соң ул баеп кайта, рестораннарда гына типтерә, баш төзәтергә акча дауламый, сумкасыннан алып, затлы коньяклар гына чөмерә. Бервакыт югалып торгач, ул өстәлгә төргәге белән акча кайтарып ташлады. Минзаһит белән Хәят калтырана-калтырана акчадан баш тарттылар. Рашат, аларга мәсхәрәле карап, акчаны алды да сумкасына атты, башка күрмәссез, диде.

Минзаһит гомер буе ялган, икейөзлеләнү күреп газаплана иде. Шул ялганнан котылмакчы булса, тормыш куйган тәртипләр аның үзен дә шуна мәҗбүр итә иде. Ниһаять, менә аның теләге тормышка ашты; аларның тормышында бер генә ялган да калмады—шәп-шәрә дөреслек! Ә ничек рәхимсез, куркыныч ул. Йөрәге әрнегән чакларда аны әллә нинди үкенечле уйлар биләде. «Нәрсә таптың син бу Казанда? Нәрсәгә ашкындың син монда?» дип үзен үзе тиргәде. Ят иден Болынкырда рәхәтләнеп. Бакчасында бар дөньясын онытып уздырган көннәрен ул җәннәт рәхәтләре белән исенә төшерде. Аяк астында йомшак кара туфрак, яшел үлән, тирә-юнендә агачлар, кошлар тавышы, җил исә, яңгыр ява, ак кар бөртекләре күбәләкләрдәй оча, урамга чыксаң, таныш кешеләр сәлам бирә. Шушы таш базда җәфаланып яту кирәк идеме? Алардан кызы Эльза белән кияве дә читләштеләр, чөнки Рашатка үгет-нәсихәт укый башлауга, ул аларны куып чыгарды. Бервакыт Эльза Минзаһитка егет чакта алып барган көндәлекләрен бирер китте. Көрән тышлы бу дәфтәрне ул әле артыннан, әле алдыннан укыды. Укыган саен, күнелен үткен пычак белән телгәләгәндәй, үкенү-сагыш биләде. Көндәлекләрдә аның иң гөнаһсыз чорлары ярылып ята иде. Яшьлекнең матур хыяллары, тормышның һәр көненә соклану, игелекле зур омтылышлар, яшәү матурлыгы турында романтик уйлар, нинидер китаплардан күчереп куелган фикерләр. Ул чордагы Минзаһит белән хәзергесен чагыштырырлык та түгел, алар арасында бернинди дә уртаклык калмаган, бу ике затны бары тик исем генә берләштерә иде. «Нәрсә булды? Мин гомеремне нәрсә өчен яндырдым?!» дигән сорауларга җавап эзләп, башлары чәнләде. Аның бит яшьлек максатлары якты, үзен кешеләр өчен багышлауга юнәлдерелгән иде. Ә нишләп соң ул ният тормышка ашмады? Яшьлектәге якты хыяллар югалтылган иде. Нәрсә өчен икәнен хәзер инде әйтеп тә булмый. Башта Минзаһит илдәге тәртипләрне гаепләде, әмма тора-бара уйлары, җил куып китергән дулкын кебек, һаман бер ярга—үзенә китереп бәрделәр. Аның тарафыннан бик күп язмышлар җимерелде, шул исәптән Хәятка да ул бәхет китерә алмады. Икесенең ике дөнья булып яшәвенә, балаларны аерып тәрбияләүләренә ул бүтәнчә карый башлады. Бу үзгәреш беркөнне базарда үзе белән партия мәктәбендә укыган Гапсаматовны очраткач булды. Башта алар бер-берсен танымадылар, бик озак карашып тордылар, ахырда кочаклашып күрештеләр, хәл-әхвәл сорашырга керештеләр. Ике арадагы әңгәмәдән бигрәк Минзаһитны курсташының тышкы кыяфәте таң калдырды. Ул укыгандагы кебек ябь-яшь, йөзләре алланып тора, битендә җыерчыклар да юк диярлек, чәчләре дә чем-кара иде. Партия мәктәбендә чакта алар кул

биреп исәнләшеп китүдән ары узмаган булсалар да, Гапсаматов Миңзаһитны, айга-вайга карамыйча, үзенә кунакка чакырды. Ул ике бүлмәле фатирда яшәп ята икән. Хатыны да үзе кебек яшь, җиңел хәрәкәтле, ут борчасыдай очып йөри. Миңзаһитның кем икәнен әйткәч, аның бер алдына, бер артына төшеп, сандугачтай сайрады, житәкләп зал ягына алып чыкты, идәндә уйнап йөргән ике бала белән таныштырды: оныкларыбызның балалары, бакчага бирдермибез, үзебез карыйбыз, чатнатып татарча сөйләшәләр, татарча җырлыйлар, татарча биилэр, диде, җырлатып-биетеп тә күрсәтте, Миңзаһит ике бүлмәле фатирдагы иркенлеккә хәйран калды. Анда артык берни дә юк, яшәү җиренең яртысын биләүче күпереп торган затлы кәнәфи-диван кебек нәрсәләр тутырылмаган иде. Гапсаматов, табын янында утырганда, үзенең тормыш хәлләрен сөйләп бирде: аны әүвәл туган авылында партоешма секретаре иткәннәр, аннары балалары бик кыстагач, Казанга күчкәннәр, шәһәрнең кайсыдыр райкомында инструктор булган, шуннан пенсиягә чыккан. Алар, өстәлгә әллә ничә төрле затлы эчемлек куеп, Миңзаһитны кыстадылар да кыстадылар. Үзләре иреннәрен генә тигереп куйсалар да, ул нишләптер кыстаганга бирешеп эчте дә эчте, ахырда исерде. Дөресрәге, ул үзенең Гапсаматов кебек шушлай яшь, матур булып саклана алмаганына үч итеп эчте. Ахырда, тавышсыз гына еларга кереште. Гапсаматов белән хатыны хафаланып аның тирәсендә бөтерелә башлагач, исерсәм елый торган гадәтем бар, дип акланды. Йомшавын күреп, хуҗалар аны ихлас күңелдән кунарга кыстадылар. Миңзаһит, үзенең кайтырлык түгел икәнлеген чамалап, Хәятка шылтыратты да кунып калды.

Бу очрашу аның күңелен актарып ташлады. Тормышта бернигә дә ирешмәгән Гапсаматовның ул үзеннән мең мәртәбә бәхетле икәнен аңлады. Аларның җаннары тыныч, шул затлы җиһазлар белән бизәлмәгән фатирларында бәхет касәләре мөлдерәп тулып тора иде. Көн саен түгел, хәтта сәгать саен Миңзаһит үзләренең тормышын аларныкы белән чагыштыра башлады, чагыштырган саен, аянычрак нәтиҗәгә килде...

Рашатның аяк тавышы аның уйларын бүлде. Колагын ишек ярыгына куеп, тын да алмыйча тыңларга кереште. Менә ул аякларын сөйрәп кухня ягына юнәлде, нәрсәләрдер шалтырады, шешәдән аракы салганы, голт-голт эчкәне ишетелде. Аннары Рашат ютәлли-ютәлли туалетка кереп чыкты да үзенең бүлмәсенә бикләнде. Аяк очларына гына басып, Миңзаһит кухняга керде, өстәлдә буш аракы шешәсен күрде. Димәк, Рашатның запасы беткән. Ул тавышсыз гына плитәгә чәйнек утыртты, кабат үз бүлмәсенә таба атлаганда, телефон шалтырады. Миңзаһит өлгергәнче, Рашат чыгып трубканы алды.

—Газетадагы белдерү буенча?—дип сорады Рашат карлыккан тавыш белән.—Тә-ә-әк, андый нәрсә булмаячак!—Ул трубкасын атты да Миңзаһитның каршысына килеп басты.—Сез нинди квартира алыштырырга җыенасыз?

Ул арада Хәят та атылып чыкты.

—Безнең өч бүлмәлене икеле белән берлегә алыштырмакчы идек,—диде Миңзаһит, тотлыга-тотлыга.

—Ә мин?! Мин арттыммыни? Сезнең миннән котылырга теләвегезне мин күптән сизеп йөрим!

—Ни сөйлисең, улым!—дип сүз кыстырды Хәят.—Без бит инде болай яши алмыйбыз. Сиңа өйләнергә кирәк. Икелесен сезгә бирербез, берлесендә үзебез яшәрбез.

Рашатның кан баскан күзләре түгәрәкләнеп киерелделәр.

—Бар әле, ояңа кер!—диде ул, калтыранган бармагын ишеккә таба юнәлтеп.

Хәят чигенә-чигенә барды да бүлмәсенә кереп посты. Рашат кайнар юеш бармаклары белән Миңзаһитны бугазыннан буып алды:

—Әйт дөресен—ник алыштырасыз?!

Минзаһитнын тыны кысылды, сүзләрен көч-хәл белән генә кысып чыгара алды:

—Әниен әйтте бит... синен өчен...

—Мразь! Сина хәзер бернинди квартира да кирәк булмаячак!

Рашат икенче кулы белән Минзаһитнын инбашына китереп сукты һәм ул мәтәлләп, урындыкларны аудара-аудара, залнын түр ягына очты...

## 7

Сонгы вакытларда Әхнәф, жае чыккан саен, районда культура эшенен торышына канәгатьсезлеген белдерә килде. Ул аны экономика мәсьәләләрен тикшергәндә дә, жайлап-жайлап китереп чыгарып, исемен әйтмичә генә, чыбыркынын нечкә очы белән Сөембикәгә чиерттереп ала иде. Каршы бер генә сүз әйтмәсә дә, Сөембикәнен ачуы кабарганнан-кабарды. Бүген хакимияттәге атналык планлаштыру вакытында Әхнәф тагын жайлап кына теге таныш чыбыркысын кулына алды.

—Кайберәүләр республика матбугатында хакимият эшчәнлеген каралтып күрсәтергә тырышалар...

Монын кем адресына әйтелгәнлеген залда утыручы житәкчеләр барысы да анладылар. Сөембикәнен артында чышын-пышын килеп көлештеләр, кемнәрдер ана таба борылып карады. Ул коры дары кебек шартлап кабынырга әзер иде. Әхнәфнен сүзләре, залнын ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдашып алуы аны сикереп торырга мәжбүр итте.

—Нигә аны кайберәүләр дип торасыз? Ачыктан-ачык әйтегез!—диде ул, Әхнәфкә туп-туры карап.—Сәхнә киемнәре тектерергә акча бирмәвегез хак бит. Хәзер безнен районда гажәп атмосфера урнашты. Партия заманнарында бернинди тәнкыйть булмады, имеш, берәр сүз әйткән кешене эзәрлекләделәр, дип сөйләргә яратасыз сез. Ә үзегез өф иткәнгә чер итеп кычкырасыз. Культурага акча табылмаса да, якыннарыгызга йортлар салырга дигәндә табыла тагын.

Әхнәфнен чырае бурлаттай кызарып чыкты.

—Мин сезгә үзегез белмәгән нәрсәләр турында саграк сөйләргә кинәш итәр идем, Сөембикә Даутовна. Житәкче кеше бит үз сүзләре өчен жавап та тота.

—Куркытмагыз,—диде Сөембикә, ярсуын тыя алмыйча.—Урлаган әйберем юк. Мина карашыгыз шундыймы, әллә культурагамы—мин анысын төгәл әйтә алмыйм. Әмма акча дигәне сезнен бармак арасыннан безгә таммый. Планга кертелгән булса да, музыка мәктәбен ремонтларга да бирмәдегез, бүген ул ябылу алдында тора.

—Курыкмавыгыз әйбәт,—диде Әхнәф, тыныч булырга тырышып.—Залдагылар бу тырышунын сугып аударылган кешенен дүрт аякланып торырга азаплануы кебек икәнлеген ачык күрделәр.—Тик бу зур батырлык күрсәтә торган урын түгел. Сезнен ул музыка мәктәбен ремонтларга ин элгәре үзегезнен теләгегез булмады. Ярар, сез ремонтламасагыз, башка кеше ремонтлар.

—Рәхмәт. Гаризам өстәлегездә булыр.

Сөембикә кызу-кызу адымнар белән ишеккә таба атлады. Каршысында Фәһимәнен үзенә төбәлгән мыскыллы көлемсерәвен күрде, ачудан тыны кысылды. «Шул кәнтәй котырта, шунын сүзеннән чыга алмавы хак, күрәсен», дип уйлады ул.

Кызу-кызу эшенә атлаган жиреннән, Фәһимәгә ачуын аудармыйча тынычланмаячагын анлап, кире борылды. Банк каршына барып, шактый вакыт таптанып торды. Ниһаять, почмактан борылып чыгып, Фәһимәнен килгәне күренде. Анын йөзендә нәкъ баягы елмаю иде.

—Йә, күнелең булдымы, авылдаш?—диде Сөембикә, аңа үзе кебек үк мыскыллы караш ташлап.

—Кеше бәхетенә көнләшеп карауччылар барысы да синең хәлгә кала. Артың печән ашый башласа, рәхәт түгел шул ул.

Фәһимә Сөембикәне әйләнеп үтеп китмәкче булды, әмма ул аның каршына чыкты.

—Син район банкының сейфын гына түгел, иреңне дә итәк астыңа тыккансың.

—Ә ир-атның урыны кайда соң аның, шунда булмыйча?!—Фәһимә кычкырып көлеп җибәрде дә, Сөембикәне читләп үтеп, банкка кереп китте.

Сөембикә көне буе үзен-үзе ашады, бухгалтеры белән, инспектор хатын белән телгә килде. Аңа бөтен дөнья бармак төртеп күрсәткәндәй тоелды. Кичкырын, үзен эштән азат итүне сорап язган гаризасын алып, Әхнәфкә керде, ләкин ул юк иде. Аны кабул итү бүлмәсендә калдырырга мәҗбүр булды. Әхнәф белән Фәһимәгә әйтелмәгән ачуын эчендә саклаган килеш өйгә кайтты.

Ул ашарга әзерләп бетергәндә, ишектә Айдар күренде. Аның авызы колагында, күзләре очкынланып яна иде.

—Сөембикә, мине котлый аласың,—диде ул керә-керешкә.—Мин бүген эшкә кереп кайттым.

—Кайда, эшкә?!—диде Сөембикә гаҗәпләнеп.

—Спорт мәктәбенә. Каратэ көрәше буенча тренер булып. Түгәрәк алып барачакмын.

Көне буе җыелган ачуын чыгарып, Сөембикә кычкырып җибәрде:

—Ничек инде син минем белән киңәшмичә эшкә керәсең?!

Айдар җитдиләнеп калды, хәтта коелып төште:

—Ничек инде өйдә ятыйм... Мин сау-сәламәт, синең каршыда оят.

—Оят, оят...—диде Сөембикә, өстәлдәге савыт-сабаларны шалтыр-шолтыр китереп.—Аягың керсә, башың кермәгән, дигәндәй... нинди эш ди әле...

Айдар авыр итеп сулады да, түргә дә узып тормастан, ишек янындагы кечкенә табуреткага утырды.

—Менә бит ничек...—Аның тавышы бөтенләй диярлек ишетелмәде.—Ә мин инде ышанып беткән идем...

Сөембикә күз ачып-йомган арада аның каршына килеп җитте.

—Йә инде, Айдар, кичер инде син мин юләрне!—диде ул, аның битләреннән кат-кат үбеп.—Син эшкә кергәнсең, ә мин менә эштән китәргә гариза биреп кайттым.

Сөембикә яшьле күзләре белән аңа елмайды. Айдар акрын гына урыныннан торды:

—Син чынлап әйтәсеңме?

—Әйе. Авыр миңа Шәрифуллин белән эшләү.—Ул кулын селтәп куйды.—Бетмәс әле бер гади генә эш.—Аннары тагын Айдарның күзләренә туп-туры карады, гаепле кеше елмаюы белән елмайды.—Гафу итәсеңме мине?

Айдар баш чайкап көлеп куйды:

—Сине аңлый торган түгел,—диде ул.—Бер карыйсың—җен кебек бирешмисең. Җинәм, сындырам, димә. Икенче карыйсың—сүз дә кирәкми, керфек сирпүгә үк буйсынасың, ефәк кебек ураласың. Ничек шулай була инде ул?

Сөембикә аңа әллә нинди үкенечле кызганыч караш ташлады: ул әллә үзен, әллә Айдарны кызганды—моны аерырлык түгел иде.

—Алла шулай яраткач, нишлим соң?!

Айдар аның иңбашыннан кочып залга алып чыкты, икәүләп диванга утырдылар.

—Мина кискен үзгәрүчән континенталь табигать шартларына күнегү җинел булмаса да, ияләшергә туры киләчәк,—дип пышылдады Айдар анын колагына.—Хәзер генә кояш нурлары өттереп көйдерә, биш минуттан коточкыч давыл, кар бураны күтәрелә.

Сөембикә аның бу сүзләреннән елмаеп җибәрде. Айдарның керфекләреннән күнелне тынычландыра торган әллә нинди җылы нур сибелә иде. Шушы нурлар аны бүген беренче мәртәбә елмаерга мәҗбүр итте...

Бу кичне анын уйлары үзеннән, әнисеннән ерак китә алмады. Кече яшьтән үк Сөембикә үтә нечкә күнелле дә, хисчән дә булды. Шул ук вакытта, усаллыкта да аңа тиңнәр юк иде. Вакыты белән корычтай каты, чигенмәс Сөембикә, үзе дә анламыйча, бик тиз бирешә торган иде. Шушы сыйфатлар әнисенә дә хас булды. Ул гомер буе ясаган хаталарыннан сабак алмады, аларны кабатлый торды. Җәүһәрия Фәйзрахман белән дуслашып йөргән заманнарда колхозга Сәфәргали исемле кешене председатель итеп куйдылар. Киң җилкәле, зур башлы, әллә нинди сары күзле, эре сөякле адәм иде ул. Куркыныч чырае эре җыерчыклар белән капланган, сул ягында күз читеннән төшүче җыерчыгы бер урында, куркыныч булып бөтерелеп, өченче күз төсле тартышып тора иде. Сәфәргали зур гына түрә булган, нәрсә өчендер янган, дип сөйләделәр. Ул килү белән авылда каты тәртип кертте, көне-төне эш дип чапты. Колхоз күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Беркем тота алмаган Җәүһәрияне Сәфәргали ярты капчык фураж урлаганда каптырды. Фуражын фермага илттермәде, әгәр кабат эләксән, прокурорның үзенә алып барам, дип котын алу белән чикләнде. Шул олы җанлылыгы өчен нидер өметләнеп, кичләрен Сөембикәләргә килә торган булып китте, Фәйзрахманга юл киселде. Елмаеп-көлеп сөйләшсә дә, Сөембикәнең бу кешедән нишләптер коты алына иде. Өйдәгеләр, күрәсен, аңа күнегеп беттеләр, бер килүендә ул кунып калды һәм үги әтигә әверелде. Сөембикәнең күнеле дөрес сизенгән булып чыкты: элек елмаеп-көлеп кенә сөйләшкән Сәфәргали аш-судан да, башкасыннан да гаеп тапты, өйдәгеләрне дер селкетә торган бәндә булып чыкты. Ул кайта башласа, әбисе белән бабасы да, әнисе дә, бер басасы урынга биш басып, анын тирәсендә бөтерелделәр, анын һәр боерыгына өчәүләп йөгерә торган булып киттеләр. Өйдәгеләр генә түгел, авыл кешеләре дә Сәфәргалинең күз карашыннан куркалар иде. Аны өнәмәвен белдереп, халык исемен Сәпәрәйгә әйләндерде. Бервакыт фермада бергә эшләүче дусты Саимә кергәч, әнисенә бөтенесе алдында: «Нәрсәсен таптын шунын?—диде.—Шул үләтне куып чыгарсаң, тынычлап кына яшәр идегез.» Саимәнен бу сүзләренә әнисе күкрәгән киереп җавап бирде: «Ул бит, малакаем, колхоз председателе! Минем кем икәнне күрсеннәр әле! Ир ул сездә генә түгел, миндә дә бар.» «Яши алмаячаксыз бит, Җәүһәрия»,—диде Саимә. «Мина барыбер. Борын төпләренә такта куюым хак булсын.»

Тора-бара Сәпәрәй салгалап та кайтты, Җәүһәриягә кул күтәрә башлады. Андый чакларда Сөембикә әби-бабасы белән өйдән чыгып мунчага качты. Сәпәрәй кайчакларда кара янып кайтып керә, берни сөйләшми, кулларын артка куя да, дөп-дөп басып, бер почмактан икенче почмакка туктаусыз кыләп сара. Сөембикәләр котлары алынып, аны тып-тын гына күзәтеп утыралар. Сәпәрәй туктаусыз ягагын чәйни, ягагындагы теге төене хәшәрәт күзе төсле куркыныч булып бер җыерыла, бер җәелә. Анын эчеп кайтып дуамалланулары һаман ешая барды. Әнисе бер сүз дәшмәде, аңа берсүзсез буйсынды, сугудан-кыйналудан күз төпләре күгәрсә дә, анын кул астында кол кебек яши бирде. Әнисен жәлләп, Сөембикәнең йөрәгеннән кан тамды, үги әтисенә «әнигә тимә!» дип кычкырган чакларында, Сәпәрәй аны, көрәктәй кулы белән эләктереп алып, йә өйалдына, йә тышка—ишек төбенә

үк атып бәрә иде. Өйдәге гадәтләрен колхозда да күрсәтә башлагач, аның өстеннән шикаять язарга тотындылар. Берничә мәртәбә халыкның зармонын килеп тыңлап та киттеләр, ләкин мондый тикшерүләр, кисәтүшелтәләр Сәпәрәйне төзәтә алмады. Күпмедер тыелып йөргәннән соң, ул кабат котыра башлый иде.

Сәфәргалигә бабасы үзенчә бәя бирде:

—Мондый бәндәләрне шәһәр әвәли, балакаем. Авылда кеше бер-берсенең күз алдында. Оят дигән нәрсә иң элек авылда барлыкка килгән. Бер-беренне кызгану, бергәләп эшләү дә авыл сыйфаты. Шәһәр баласы Сәпәрәйләр андый нәрсәләрдән мәхрүм, шуңа күрә алар мәрхәмәтсез. Кала үзе дә ясалма, тормышы да чын түгел. Бәндәгә иман әүвәл җирдән иңә. Ул табигатьнең һәр күзәнәгеннән моң булып иңә, саркый... Авыл бетсә, халык чәнечкеле шайтан таягыннан тукылган күлмәк кигәндәй яшиячәк. Энәләре белән чәнчеп, шул күлмәк йокыдан уятачак, билгеле вакытта каптыр-коптыр ашатачак, эшкә куалап алып барачак, куалап алып кайтачак. Бәндә таштан-тимердән ясалган капчыктан чыга алмаячак. Аның сафлыгы, беркатлылыгы беткән була. Ачудан ул менә шушы Сәпәрәй кебек авылның яшәү тамырларын кисәчәк. Әнисен үтергән кеше рәхәт күрмәгән кебек, алар әнә шулай үзләренең яшәү тамырларын үзләре үк корыталар...

Сөембикә ерактагы шул газаплы үткәннәрен үзенең бүгенгесе белән чагыштырды. Айдар алдында күпмедер дәрәҗәдә Сәпәрәйне кабатлыйм түгелме соң мин, дип уйлады ул коты очып...

## 8

Ирек диванда уйланып яткан җиреннән йокымсырап киткән иде. Ул күзләрен ачып җибәрде һәм шундук сикереп торды. Инде сәгать унбер тулып килә икән. Тәрәзәләрдән, бөтен бүлмәне алтын нурга манып, август кояшы елмая, Зәнфирәнең теге якта өй җыештырып йөргәне ишетелә. Ирек иртәнге алтыдан бирле бер генә җөмлә дә яза алмыйча газап чикте. Әсәренең геройлары, иртәнге томан эреп юкка чыккандай, каядыр китеп югалдылар.

Ул тәрәзә каршында басып торган җиреннән сискәнеп куйды, аннары өстенә кайнар су койгандай булды: капка каршына кара джип килеп туктады! Менә аның ишеге ачылды, башта сул ягыннан Әхнәф, уң яктан Фәһимә сикереп төште. Алар нидер сөйләшеп алдылар, Фәһимәнең кулына тоткан төргәкләре күренде. Капканы ачтылар да өйгә якынлаша башладылар. Ирек, үзе дә сизмәстән, кулындагы ручкасын шартлатып сындырды һәм шул хәлендә хәрәкәтсез катып калды.

Стенканы Әхнәфләргә илткәч, Болынкырда чын мәгънәсендә мәхшәр купкан иде. ТИҮдә әгъза булып торучылар, Саттаров тирәсенә тупланып, үзләренчә хәрәкәт башладылар. Иректә ниндидер ярамаган нәрсә эшләгәндәй тойгы уянды. Шул ук вакытта аның Әхнәфкә булган рәнҗеше артты гына. Алар ялдан кайткач, эчендә нәрсәләр кайный, барысын да Әхнәфкә кереп аударырга ниятләде. Салкын акыл белән эш итә башлагач, ул моның җиңел эш түгеллегенә төшенде. Әгәр керәсең икән, аны сискәндерерлек кенә түгел, ә барысын да аңларлык һәм кыла торган гамәлләрен үзгәртерлек сүзләр табарга кирәк иде. Ирек шул сүзләрне эзләде, төрле кәлимәләрдә күңеленнән уздырды.

Ләкин аларның килгәнен күргәч, Ирекнең башы берни дә эшләмәс булды. Ничә көннәр буе җиз иләктән иләгән фикерләре, очкын төшеп шартлаган дарыдай, юкка чыктылар. Чөнки ул Әхнәф белән Фәһимәнең үзләренә килеп керәсен уена китермәгән, бу очракта нишләргә икәненә әзер түгел иде. Ирек, сынык ручкасын өстәлгә ыргыткач, сәдәфләренең каптырылганмыюкмы икәнен тикшереп чыкты, трикосын салмыйча гына кабаланып чалба-

рын киде. Сул як тәрәзә төбендәге гөлне бөтенләй кирәкмәгәнгә үзенең өстәленә алып куйды, башында бик еракта томан эчендә бер уй бөтерелде: «Ник шулай кыланам?» Ирек ана җавап бирә алмады, бирсә дә файдасы булмас иде, чөнки хәрәкәтләре берсе дә үзенеке түгел, аларны ниндидер көч йөртә, Ирек шул көчкә генә буйсына иде.

—Әйдәгез, узыгыз,—дигән тавышы ишетелде Зәнфирәнең.

—Әллә Ирек өйдә юкмы?—бусын Әхнәф сорады.

—Булмәсендә ул,—ишектән Зәнфирәнең башы күренде. -Әйдә, чык, Әхнәф абый белән Фәһимә апа килде.

Ирекнең ике бите ут булып яна башлады, гәүдәсе калтырауга охшаш киеренке халгә килде. Ул, аякларын көчкә сөйрәп, алар янына чыкты. Йөзе йокыдан көчләп уятылган кешенеке төсле караңгы һәм чытык иде.

—Исәнме, Ирек,—диде Әхнәф һәм анын кулына канатларын як-якка җәйгән фарфор бөркет тоттырды.—Илһам китерүче булсын бу...

Бөркет үзе ап-ак, үзе салкынча булса да, Иреккә кызган күмердәй кызыл һәм кайнар булып тоелды. «Бусы кайсы оешма хисабыннан?» диясе килде анын, әмма теле әйләнмәде. Бу бит бүләк түгел иде. Түбәнсетелүеннән котылу өчен ул бөркетне кабаланып урындыкка куйды. Үтә дә кыен, үтә дә авыр киеренкелек урнашты. Аны бетермәкче булып, Зәнфирә әрле-бирле сугылды, Әхнәфләрнең алып килгән күчтәнәчләрен өстәл өстенә таратты, үзенең ризыкларын ташыды, аларны табын янына кыстады. Аларның кымшанмавын күреп, Иреккә:

—Кунакларны утырырга кыста инде!—дип ялварды.

—Кунакларны?..—Шушы сүзнең мәгънәсен аңларга теләгәндәй, Ирек мангаен җыерып торды. Аннары, әйдә, миннән булсын яхшылык, дигәндәй, кул селтәп куйды да:—Узыгыз, бәй...—диде.

Әхнәф теләр-теләмәс кенә стена буендагы урындыкка барып утырды, Фәһимәгә чакырулы карашын юнәлтте, әмма ул баскан килеш тора бирде.

—Көтмәгәндә килдек бугай,—диде Әхнәф, йөзен Иреккә борып.—Эшеннән бүлдек, ахрысы...

Ирекнең иреннәрендә мыскыллы елмаю җәелде:

—Көтмәгәндә... көтмәгән эшләр эшләү... синең холкына сеңгән бугай ул...

Инде бирегә килергә чыкканчы ук шартлардык хәлгә җиткән Әхнәф чәчрәп сикереп торды:

—Бу ни дигән сүзең була инде?!

—Аңламыйсыңмыни ни икәнен?—Фәһимәнең тавышында тыелгысыз ярсуы һәм ачуы ярылып ята иде.—Безне күрәсе килми анын. Әйдә, кузгалдык!

—Ни сөйлисең, Фәһимә апа!—дип өзгәләнде Зәнфирә.—Чәй эчәбез әле күчтәнәчләрегез белән. Ирек, ник кыстамыйсын кунакларны?

—Нәрсә соң син табаны пешкән мәчедәй кыланасың?!—диде Ирек, Зәнфирәгә дөртләп кабынып.

—Насыйпны корытма, Ирек, чәй эчеп тормабыз инде без болай булгач.—Әхнәф анын күзләренә туп-туры төбәлде.—Минем бер генә нәрсә сорыйсым килә: безне адәм хуры иткәч, канәгатьләндеңме инде?

—Казанга ук килеп житте тавышы,—дип өстәде Фәһимә.—Рәхмәт, бик әйбәт эшләдең. Тынычландымы күңелең?

—Ул әле дөрли генә башлады. Утны төрткәч, әрдәнәдән «янасыңмы?» дип сорамыйлар...

—Синең күзләреңдә әллә нинди куркыныч ялкын,—диде Әхнәф баш чайкап.

—Әйе, ялкын!—диде Ирек ярсулы тавыш белән.—Мин эчемнән үкереп елыйм! Әйе, сезнең белән бер өстәл артына утырасым килми!

—Ирек!—дип йөгереп килде анын янына Зәнфирә.—Шундый нәрсә булмый бит инде! Авырый ул, температурасы югары анын.

—Алдашма!—дип бүлдерде аны Ирек.—Син аларнын безне эткә санап калжа ыргытуларына нишләргә белмисен.

—Оялыр иден! Авыр чакларында сине Әхнәф күпме коткарды!—Фәһимәнен күзләре ачудан кысылдылар.—Син—чын эгоист, горурлыгын дөньяга сыймый.

—Горурлыгым ничектер—анысын әйтә алмыйм, әмма тәбәнәк булса да үз тавым бар.

Зәнфирә аны иркәләгәндәй итте, туктатмакчы булды, ләкин Ирек аны читкә этте:

—Тик тор, мин клоун да, цирк эте дә булырга теләмим!Дәүләтебезнен хәерче дигән катлавына керүче тулы хокуклы гражданины! Үзем баш, үзем түш, беркемнеке дә түгел.

—Ю-у-у-ук!—диде Әхнәф.—Син милли герой ролен уйныйсын. Мине юкка чыгару өчен.—Анын аяк янындагы мине әллә ничек усал булып ялтырап китте.—Мин бу өйгә янадан үз гомеремә бер мәртәбә дә аяк басмаячакмын!

—Ә мин сине каргыйм, Ирек!—диде Фәһимә, анын каршына ук килеп.—Шундый итеп каргыйм, каргышым һичшиксез төшәчәк!

Алар кабаланып чыгып киттеләр. Зәнфирә елый-елый артларыннан иярде һәм Фәһимәгә ялварды:

—Зинһар каргама, Фәһимә апа. Әллә нинди ул сонгы вакытта, йоклаганда ынгыраша—баш өянәге кабат кузгала бугай. Минем белән дә юньләп сөйләшми, юньләп ашамый, күптән инде язганы да юк. Тан ата башлау белән, Ык буена китә дә яр буенда йөри дә йөри. Кич житсә—тагын шунда. Берәр нәрсә генә эшләп ташлый күрмәсен, дип котым оча. Зинһар анын бүгенге кыланмышын гаеп итмәгез... Ул Ирек түгел, анын эченә нидер керде...

Машинага утырырга әзерләнеп ишекне ачкан Фәһимә борылып Зәнфирәнен каршына ук килде:

—Эченә ни кергәнне әйтимме, үскәнем? Аракыдан дәваланучыларнын гадәте ул.

—Ул дәваланмады, үзе туктады бит.

—Барыбер. Ычкыныр чаклары житкәндә, алар әнә шулай һәркемгә бәйләнәләр. Кулларыннан килсә, кояшны да, күзне чагылдыра, дип тартып төшерерләр, аяк астындагы сазга салып таптарлар иде. Әле күрәчәкләрен алда. Исән чакта Баллы Төбәгенә ычкын син, монда калсан, үкенәчәксен.

Фәһимәнен тагын ниләр әйткәнен дә, машинанын ничек кузгалып китүен дә Зәнфирә ишетмәде. Ул капка баганасына сөялгән хәлдә тораташтай катты. Әйтерсен лә анын баш түбәсеннән үкчәсенә кадәр яшен уты үтәли кисеп чыккан һәм кумергә әйләнгән гәүдәсен шунда сөяп куйган иде. Яшьле күзләре белән ул Ык буена карады, анда су коенырга төшүчеләрнен машина пыялалары ялтыраганын чамалады. Магнитофоннан дөпе-дөпе килгән ниндидер замана көе колагын тырнап үтте. Менә ерак та түгел чирәм өстенә әллә карга, әллә чәүкә көтүе фырылдап килеп төште. Алар Заһит дәфтәрләрен яндырганда жир өстеннән йөгергән кумерле кәгазьләр төсле йөгерештеләр...

Зәнфирә кергәндә, Ирек шабыр тиргә баткан хәлдә башын тотып өй буйлап йөри, йөзе кәфен төсле агарган, үзе дер-дер калтырый иде.

—Ник син аларнын табанын ялыйсын?—Ирекнен теше тешкә тиеп шакы-шокы килде.—Дөнья урталай ярылган, ә син алар белән... Аларга яхшы булу өчен жан атасын. Менә бу бөркет аларнын безгә чираттагы калжасы!

Ирек бөркетне идәнгә бәреп чәлпәрәмә китерде дә диванга барып ауды.

—Юк, Ирек,—диде Зәнфирә күз яшьләре аша.—Сина әйбәт булсын өчен... Минем үземә берни дә кирәкми...

* * *

Әхнәф белән Фәһимә юл буе бер-берсенең йөзенә карамыйча, бер сүз дәшмичә кайттылар. Фәһимә аны эченнән түйганчы әрләде. Ирекнең бүләкне китереп ташлавын да, Саттаровларның азынуларын да Фәһимә Әхнәфнең куркаклыгыннан күрде. Аның уйлары да, гамәлләре дә яртылаш: бер кавым бара да чигенә, бара да чигенә. Бер карасаң, аннан да батыр, тәвәккәл кеше юк, икенче караганда, әле генә очына-очына барган юлыннан мыштым гына кирегә борыла һәм шуна мең төрле аклау таба. Ул бер эшкә дә үзе генә тулысынча тәвәккәлли алмый, аңа төрткәләп, өстереп, күрсәтеп торырга кирәк. Әгәр нәрсәгә дә булса үзе генә, кемнеңдер төрткәләвеннән башка алынса, ялкау ат камчы көткәндәй, артына борыла башлый һәм ярты юлда туктап кала. Яна йорт төзегәндә, башта икенче катны, аннары өченче катны салуга аны күндерү өчен, Фәһимәгә елан кебек бөтерелергә, нинди генә хәйләләр кулланырга туры килмәде! Күрше ике районның үзләре белән аралаша торган хакимият башлыкларын хатыннары белән кунакка чакырып, табын артында алардан басым ясатуга кадәр барырга туры килде. Бөгелеп төште Әхнәф. Аның уйлары да шул кадәр яшерен, җиде йозак белән бикләгәндәй томалана. Шул ук вакытта Фәһимә ныклап тотынса, ул җиде йозак кинәт келт итеп ачыла да китә. Әле алар егет белән кыз булып йөргән чакта ук әбисе: синең бу егетең ефәктәй йомшак, яшь тал чыбыгыдай сыгылмалы күренә. Суга салсаң балыкка, һавага ыргытсаң кошка, утка ташласаң ялкынга әвереләчәк—элэктер, дигән иде. Эләктерүен эләктерде Фәһимә, ләкин сыгылмалылык дигәнең житәкче кешенең яртылаш алга, яртылаш артка чигенүенә әйләнгәч, башбаштаклыкка юл ачыла...

Капка төбенә кайтып туктагач, Әхнәф руль артында утыра бирде.

—Нишләп төшмисең?

—Эшкә барып кайтам.

—Бүген бит беркая да бармыйм, дигән идең.

—Яна исемә төште, карап куясы документлар бар.

—Сөяркәләрем исемә төште, диген ичмасам!

Машина ишеген шартлатып ябып, Фәһимә капкага таба атлады. Иренең өйләнешкән чакларыннан ук үзенеке генә түгеллеген белеп яшәде ул. Аның ике ире бар: берсе—төссез, салкын, бозык Әхнәф. Икенчесе—югарыда, анысына район халкы баш ия, әүлия итеп карый. Аларны аермалы түгел, сиам игезәкләре сыман бергә берекәннәр. Берсе әшәке, икенчесе кирәк. Кирәк тәмугка кертә. Иренең кыек юлда йөрүләрен Фәһимә белмәмешкә, күрмәмешкә салыша. Бүгенге авыр тормышта аерылышу турында уйлый да алмыйсың. Намус-вөҗдан дигән шикле алдавычларга ияреп, аерылу, Әхнәфнең уч тутырып алган акчаларыннан, хан сарае кебек йортларыннан, ажгырып торган чит ил машиналарыннан, иң яхшы санаторийлардан, хастаханәләрдән баш тарту ахмаклык булыр иде. Тормышта бөтенесе дә өстә күренеп ятмый, барысы да бизмәнгә салып үлчәнми. Әхнәф күбрәк отамы, Фәһимәме—анысын бер Хода белә...

## 9

Ирек кабул итү бүлмәсенә кергәндә, халык бик күп, барысы да пошаманда, йөзләре каранѓы иде.

—Инде ай була, кабул итми—нишләргә белгән юк,—диде бер хатын, Ирекне өнәмәвен сиздереп.

—Элек Үзәк Комитетка, обкомга жалу яза идек. Хәзер кая язасың?—дип өстәде кайсыдыр.

Ирек чыгып китте дә төштән соң сәгать өчтә килде. Бүлмә ишеген ачу

белән аптырап китте: секретарь кыздан башка беркем дә юк иде.

—Казаннан зур галим килде, Әхнәф Хәсәнович беркемне дә кабул итмәячәк,—диде секретарь.

—Шулай да әйтеп карагыз әле.

Секретарь аңа шылтыратты да:

—Керегез,—диде.

Ирек тирән итеп сулыш алды, яр өстеннән салкын суга сикергәндәй, Әхнәф бүлмәсенең ике катлы ишеген ачты. Керү белән аның күзенә озын өстәлгә таратып ташланган кәгазьләр күренде. Бик зур башлы, киң маңгайлы, күзлекле кеше ул кәгазьләр эченә чумып утыра. Ирек аларның йөзләреннән әле генә ашап-эчеп чыкканлыкларын чамалады, сизелер-сизелмәс кенә аракы, каклаган балык исе килә, арткы бүлмәнең яртылаш ачык ишегеннән анда эшләп утырган телевизор күренә. Ирекка бу кеше ничектер таныш кебек тоелды, аннары кем икәнлеге хәтеренә төште. Ул университетта философия тарихыннан лекцияләр укыган профессор Сазонов иде. Искиткеч үз фикерле булуы, партия җитәкчелегендәге ялгышларны шул елларда ук яшермичә әйтүе белән студентларны таң калдыра иде Сазонов. Аннары профессор кинәт юкка чыкты, эшеннән алганнар, дип сөйләделәр.

Ирек иң элек аның белән, аннары Әхнәф белән күреште. Әхнәфнең күз карашы да, кул кысышы да салкын иде.

—Таныш бул, минем диссертация җитәкчем,—диде дә ягымлы елмаеп Сазонов янына килде.—Сезне хәзер кунакханәгә алып барып урнаштырырлар, мин кич белән кагылырмын.

Сазонов, компьютерда басылган диссертацияне һәм кәгазьләрне җыештырып, гаять зур сары сумкасына салды да хушлашып чыгып китте. Ул ишектән чыгуга, Әхнәф, тәрәзә каршына барып, Ирекка сырты белән басты, ике кулын чалбар кесәсенә тыккан хәлдә, үкчәләрен бер күтәреп, бер төшереп, аягында, атынырга кереште.

—Йә, ник килдең инде син?—диде ул салкын тавыш белән. Әмма бу битараф тавыш түгел, аның һәр сүзе кургаштай авыр, рәнҗешле иде.

—Кирәк булды менә...

—Өеңнән куып чыгарганда, Әхнәф кирәк түгел иде. Хәзер кирәк булдыкмыни?

Ирек кулындагы блокнотын бөтерергә кереште, сүзен ничек башларга белмәде.

—Әхнәф... син туктамасаң, харап булачаксың.

—Шушыны әйтергә дип кердеңме?

—Бу кечкенә әйбер түгел.—Ирекнең әллә кайчан уйлап, җепкә тезгәндәй тәртипләп куйган фикерләре таралдылар да беттеләр.—Ник кирәк ул хан сарайлары, машиналар, башкасы?!

Әхнәф корт чаккандай, тәрәзә яныннан атылып, Ирекнең каршына килеп басты.

—Ничек оят түгел сиңа?!—аның ияк читендәге мине дерт-дерт тартышырга тотынды.—Мин җәмгыять кешесе, шәхси тормышым да, әйберләрем дә юк.

—Ә намусың?

—Намусым да шунда! Гомер буе халык өчен яшим, барысы да кешеләр өчен. Ә үземә берни дә юк!—дип кычкырды Әхнәф һәм бүлмә буйлап йөри-йөри, ярсып туктаусыз сөйләде:—Җанын шайтанга саткан Фауст кебек, үземне шушы эшкә саттым. Мин аш ташыганда—чүмеч, туфан ташыганда—көймә. Бер генә күзәнәгем дә, бер генә минут вакытым да үземнеке түгел. Мин өемә кайткач та глава, хатыныма ир, малаема әти түгел. Көндез дә, төнлә йоклаганда да мин глава, туктаусыз шалтыраталар, әле янгын, әле авария, әле башкасы, өемә килеп керәләр—мин һәркөн сугыш кырындагы кебек.

Йортымны да, башкасын да белмим, белергә дә теләмим! Мина ял итү урыны кирәк: тау куышымы ул, йортмы—барыбер. Тартып алырга телисезме? Алыгыз!

—Мин анын өчен килмәдем. Жан дигән әйбер дә бар бит әле.

—Жаным да юк минем. Ул әнә эш дигән шул гыйфриткә корбан ителгән.

Ирек аны хәйран калып күзәтте. Бу элекке Әхнәф түгел иде. Анын һәр хәрәкәте, күз карашы, һәр сүзе нниндидер олы ялганга буйсындырылган уен иде. Ул урыныннан торды да чыгарга кузгалганда болай диде:

—Мин сине кисәтеп куям, сине халык жыенына чакырачаклар.

Әхнәфнен нәрсәдер әйтергә теләп ачылган авызы хәрәкәтсез калды, мангае буйлап сузылган жыерчыгы тагын да тирәнәйде, карашы сагайды. Анын хәрәкәтсез калуы Ирек әйткән сонгы сүзләрне анларга тырышуын күрсәтә иде.

—Димәк, син оештырасын...—диде ул карлыккан тавыш белән.

—Мин түгел, иҗтимагый үзәк членнары.

—Борынгы кешеләр бер-берсен ашаганнар,—Әхнәф усал карашы белән Ирекне рәхимсез капшады.—Менә хәзер цивилизацияле каннибализм килде, мине ашарга жыенасыз... Син минем уңышларымнан, тормышымнан көнләшәсен. Минем ярдәм белән аякка баскач, мина каршы күтәрелден. Башкаларны да мина каршы котыртасын!

—Син әзрәк суын але, Әхнәф,—диде Ирек, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.—Жир йөзендә... безнен тормышта шундый нәрсәләр бар...—ул анын ярсуын басардай сүзләр эзләде.—Ул нәрсәләр күренми дә кебек... тамырлары әллә ничә буында... безнен дә канда... аларны өзсән, хөкем котылгысыз. Ул—вакыт кебек сиздермичә генә килә...

Аны тынлаган саен, Әхнәфнен күзләре кысыла барды һәм ул бер-берсенә тоташа язган керфек очлары арасыннан мыскыллы караш ташлап:

—Син шушыны анлатырга килденме?—диде.

Ирек сөйләшүнен барып чыкмаганлыгын анлаган иде инде. Шулай да анын тып-тын гына бөгелеп чыгып китәсе килмәде.

—Анламаячаксын, дустым!—диде Ирек.—Ник икәнен дә әйтәм: син бит хәзер ике кеше. Берсе—чын үзен, икенчесе—хыялын белән тудырылган гөнаһсыз фәрештә. Ана бер сүз дә әйтергә ярамый, ул кагылгысыз. Янәшәндәге яраннарын фәрештәнне туктаусыз өреп кабарталар, ә ул кабарган саен биеккәрәк күтәрелә. ..

—Булды! Анладым, рәхмәт!—Әхнәф кылануга охшатып бераз башын иеп куйды.—Бу ишекнен кай якка ачылганын онытмагансындыр.

—Үзенә чакырып алырга туры килмәсен.—Ирек эре-эре адымнар белән чыгып китте.

## 10

Сөембикәләр бүген бәрәнге алырга чыктылар. Айдар казыды, ул чүпләде. Өйлә житкәндә, ишек алдыннан Мөнир Кәбировнын кереп килүе күренде. Ул шактый йончыган, көрән фуражкасы астыннан чал чәчләре тырпаеп чыгып тора, кашлары элеккечә кап-кара булса да, күзләрендә курку ярылып ята иде.

—Мин Казанга очам,—диде ул, сәгатенә карап.—Сезнен белән күрешеп чыгарга гына кердем.

—Абыйны озатып килим инде алайса,—диде Сөембикә Айдарга.

Сөембикә аны өйгә алып керде, чәй әзерләргә керешге. Ләкин Мөнир абыйсы аны бу эшеннән туктатты.

—Синнән оят булса да, әйтим, чәй минем өчен хәзер бик куркыныч әйбергә әйләнде. Төнен өч-дүрт уята.—Ул өстәлдәге савытка өеп куелган

кызыл алмаларның берсен алды да шартлатып тешләп чәйнәргә кереште.— Менә шушы җитә миңа, башка берни дә кирәкми. Былтыр хирург Надировка каралырга кердем. Ул мине карады да җилкәмнән кагып: «Әле тагын йөз ел яшисең. Бу яшьтәгеләрнең күбесе шулай инде ул, борчылма»,—диде. Мин, шуның сүзләренә ышанып, бер ел гомеремне үткәрдем. Хәлем бик кыенлашкач, беркөн икенче врачка кергән идем, Казанга барырга кирәк, диде. Сизеп торам, Надиров сүзе белән гомерне оттырдым бугай. Бу хирург әйтә, нишләп монарчы йөрдең, ди. Уйлап карасаң, коточкыч! Гомер бит ул! Бирәү генә. Башка юк та, булмаячак та.

—Син юкка хафаланма әле, Мөнир абый,—диде Сөембикә.

Ул аның элек-электән үлемнән бик курыкканын, тәненә бетчә чыкса да, яман чир галәмәтедер, дип больница юлларын таптаганын хәтерли иде. Сөембикә аның кирәк-яраклар тутырылган зур сумкасына берничә алма, әле көндез генә плитәдә кыздырган зур тавыкның яртысын тыкты да, үзе кул очына күтәрде. Билетына регистрация ясаткач, аэропорт артындагы тип-тигез киң яланга чыктылар. Саргайган каен полосалары, ямь-яшел уҗымнар, сөрелгән басулар, сары эскертләр, саргаеп-кибеп баручы үләннәр—һәммәсе дә көнелдә әллә нинди сагышлы уйлар уятты. Каен полосасы янындагы бәрәңге җирләрендә сабак яндыралар, сыек төтен шуның әчкелтем исен алып килә. Әллә шул истән, әллә башка нәрсәдән Мөнир абыйсы туктаусыз борынын тарта-тарта сөйләргә кереште:

—Әллә кайтам, әллә юк... синең белән сөйләшмичә китә алмадым... Мин синең алда шул кадәр гаепле, сеңлем...

—Ни сөйлисең, Мөнир абый!—дип каршы төште Сөембикә.—Иң авыр чакларымда таянычым гел син булдың.

—Булмадым! Дөреслекне әйтәсе урында Надиров кебек алдаганмын. Син кырдагы ялгыз чәчкә кебек сыек идең. Җил кайсы яктан иссә, чәчәк шул якка бөгелә, катырак иссә, сына да. Мин начар җил булдым. Янчуринга ыргыттым... Аннары... үзең беләсең...

Сөембикә күңелендә ниндидер кайнар, ачы нәрсә кузгалуын тойды. Ул вакытларны һич тә хәтеренә төшерәсе килми иде аның. Әмма сүз башланган икән, төгәлләмичә кая барасың.

—Хәзер шулай кебек тә... Ул чакта авылда калу минем өчен үлем иде бит.

—Кем белә... Боздым тормышыңны, боздым!..

Аның кашлары сикереп куйды, карашын ул туп-туры Сөембикәнең күзләренә төбәде, сүзләре өзелеп калды.

Аны озатып кайтканда да, Сөембикәнең баш миен һаман шул сүзләр бораулады. Алар таныш сүзләр иде. Нәкъ шушы сүзләрне әнисенә Сәпәрәй әйткән иде. Халыкның аңа түземе тәмам төкәнгәч, Сәпәрәйне бервакыт, төнлә кайсыдыр хатынның өеннән чыгып килгәндә, башына капчык кигергәннәр һәм туйганчы кыйнаганнар, күтәреп берничә мәртәбә койрык сөяге белән җиргә бәргәннәр, үкчәсен төйгәннәр, диделәр. Ул ун-унбиш көн кузгала алмыйча, сидеген эчеп ятты. Аягына баскач, районнан кемнәрдер килеп төште, халык белән сөйләштеләр, аңлатмалар җыйдылар. Июнь азагына хас матур бер көнне Сәпәрәй канаты сынган кош кебек кайтып керде. Сөембикә китап укый, әнисе фермада, әбисе белән бабасы чәй эчеп утыра иде. Ул, бер сүз дәшмичә, кулларын артка куеп, почмактан почмакка йөри башлады. Аның чыраенда усаллыкның әсәре дә калмаган иде. Шулай да Сөембикә куркудан бөтен тәне белән дер-дер калтыранды, алып бәрмәсә ярар иде, дип коты очты. Сәпәрәй Җәүһәрия кайтканчы шулай йөрде, аннары бер сүз дәшмичә өйдән чыгып китте. Кичкырын Гарәфи алашасына җигелгән кабык арбага утырып кайтып килде. Арбада зур гына тартма бар иде. Аны өйгә алып кереп, өстәлгә конфет-прәннекләр, биш-алты кап шикәр алып

куйды. Ашарга әзерләп йөргән Җәүһәриягә зур бер түтәрәм бик симез сыер ите сузды, аннары костюм кесәсеннән боерык чыгарып, өстәлгә куйды:

—Менә монда мина тиешле өч центнер ипи, алып кайтырсыз,—диде.

Сөембикә дә, әбисе белән бабасы да, берни анламыйча, аптырап карап утырдылар.

—Ни булды?—диде әнисе, ана таба якын килмичә генә.

—Минем шул кадәр кеше буласым килгән иде...—Сәфәргали авыр сулап никтер ишек катыннан әйләнеп килде, теше сызлаган кешедәй, янагын сыпырып куйды.—Була алмадым. Кабат яши алсам, сезне уч төпләремдә генә йөртер идем. Булмый инде... Сизеп торам: күпме тырышсам да, барыбер үзгәрә алмыйм мин.—Аннары дымланган күзләрен әллә ничек чыт-чыт йомып, соңгы мәртәбә күреп калырга теләгәндәй, Җәүһәриягә карап торды да төшенке тавыш белән әйтеп куйды:—Мин генә боздым синең тормышыңны!

Ул кыршылып беткән зур чемоданына барлы-юклы әйберләрен тутырды.

—Мин сезне яңадан борчымам. Теге дөньяда очрашканга кадәр хушыгыз!—шулай диде дә чыгып китте.

Ул киткәннән соң бер атна эчендә әнисе суырылып кипте. Моны Сөембикә дә, әбисе белән бабасы да шаккатып күзәттеләр. Әнисе юньләп сөйләшмәде, юньләп ашамады, эштән кайтты да караватына барып ауды.

Чыгарылыш кичәсе көнен Сөембикәнең мәңге онытасы юк. Ул иртүк әнисе белән әбисенең мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышына күзләрен ачты. Аннары шундук йомды, йоклаган булып яткан килеш тыңларга кереште:

—Нәрсәсен таптың шуның?! Ни кыяфәте, ни холкы, ни кешелеге!—диде әбисе.

—Их, әнкәй! (Әнисенең лышык-лышык борын тартуы ишетелде).—Мина тәмуг кирәк. Ул минем өчен җәһәннәм иде. Бу гөнаһлы тәнемне кайларга куйыйм?!. Әллә мине әти белән синнән, Сөембикәдән оялмый дип уйлыйсыңмы? (Аның тагын озаклап сулкылдаганы, борын тартканы ишетелеп торды.) Мин әле тәмугта янсам да, ир хатыны идем. Хәзер берни дә түгел. Мич алдындагы утын агачы да миннән бәхетлерәк: ул яна да көлгә әйләнеп котыла. Ә мин күз көеге булып йөри бирәм. Шырпы төртеп яндыручысы юк...

—Алладан курык, кызым! Һәркемнең дә язмышы Алла тарафыннан язылган.

—Минем өчен дога кыл, әнкәй.

—Даутны оныта алмыйсың син.

—Ул минем оҗмахым булган. Мин шул оҗмахтан баш тарттым.—Ничек үкенгәнемне белсәң, әнкәй! Бу газаплар шуның өчен мина...

Әнисенең күз яшьләре, кайнар кургаш кебек, Сөембикәнең йөрәгенә тамдылар.

Сөембикә, торып ашагач, бакчада эссе кояш астында тыелгысыз ярсу белән бәрәңге кәтмәнләде, ызан араларында күтәрелеп килүче алабута, песи тарысы, билчән, эт эчәгесе кебек чүп үләннәрен рәхимсез кырды. Өйгә керсә, ни күрсен: Сәфәргали вакытында бизеп беткән хатыннар кабат җыелышып эчеп яталар. Сөембикә, йөрәген ничек басарга белмичә, велосипедына атланып, урманга китте.

Ул кайтып кергәндә, әнисе караватта йоклап ята иде. Сөембикә чәчәкләрне салкын сулы чиләккә утыртты да чыгарылыш кичәсенә киясе күлмәген үтүкләргә ниятләде. Өстәлгә одеал җәйде, учактан алып, үтүккә күмер салды, күлмәген алу өчен сандыкны ачты. Өскә генә куелган ак күлмәк юк иде. Ул әйберләрне актарырга кереште, сандыкның төбенә үк төште, кабат-кабат актарды һәм, ниһаять, күлмәкнең юклыгына инанды. Ишек алдында йөргән әбисе янына йөгереп чыкты:

—Әби, минем ак күлмәгем кая микән, белмисеңме?—дип сорады.

Әбисе аптырап иңбашларын сикертте,авыз эченнән пышылдап, нәрсәдер укынды:

—И, балакаем, өченче көн генә карадым бит, шунда гына тора иде.

Сөембикәнең күнеле ниндидер күңелсез нәрсә сизенә башлады. Ул йөгереп кердә дә аракы исе аңкытып, тирләп йоклап яткан әнисен селкетергә кереште. Шактый вакыттан соң Җәүһәрия күзләрен ачты.

—Әни, минем күлмәгем кайда?—диде Сөембикә өзгәләнеп.

—Минем эчемдә,—диде дә Җәүһәрия, гырлап йоклап китте.

Сөембикә, үз-үзен белештермичә, аның иңбашларына, кабыргаларына сугарга кереште, үзе туктаусыз елады, нәрсәләрдер кычкырды. Әбисе кереп аның кулларыннан эләктерде дә ишек алдына алып чыкты, чәчләреннән сыпырып, иңбашларыннан кагып тынычландырды, салкын су белән юындырды.

—Синең чуар чәчәкле күлмәгең бар бит, кызым. Әле ул агына караганда матуррак та,—диде ул, аның бер алдына, бер артына төшеп.

Сөембикә велосипедына атланды да кабат урманга китте. Ул анда юләр кеше кебек кичкә кадәр йөрде, печәнчеләрдән калган шалашка тап булды. Кояш баеганда, шунда кереп ятты һәм ничек йоклап киткәнен сизми дә калды. Ул уянганда, таң беленә иде инде.

Алар ике көн буе әнисе белән сөйләшмәделәр. Кичтән фермадан кайтып, эш киемнәрен алыштырып маташканда, Сөембикә, аның тәнен күреп, өнсез калды: әнисенең иңбашлары, ябык беләкләре күп-күмгәк иде. Сөембикә кычкырып елап аңа ташланды. Кысып кочаклап алды, күгәргән тәннәрен шашынып үбәргә кереште.

—Әнием, зинһар гафу ит. Кичерә аласыңмы мине?!—Ул аның күзләренә мөлдерәп карады.—Кичерә аласыңмы син мине?!

—Син мине кичер, кызым...—Әнисе тавышсыз гына үкседе.—Мин кабәхәт, чучка...

Алар бик озак елаштылар, Сөембикә һич кенә дә тынычлана алмады, бөтен тормышларын күз алдыннан үткәрде. Күкрәгендә үзе өчен дә, әнисе өчен дә үч алу тойгысы кабынды. Әгәр кулыннан килсә, ул барлык ир-атларны үзенә буйсындырып, кол итәргә әзер иде. Шуны эшләү мөмкинлеге бар, тик гомеренне генә бир, дисәләр, ул моңа берниндиикеләнүсез ризалашыр иде. Ул ирләрдән гомере буе үч алырга ант итте, әмма антында тора алмады, әнисе кебек үк ир-атларны үзенә генә хас ярату белән яратты Сөембикә...

## 11

Ирек белән Зәнфирә эштән кайтып ашарга гына утырганнар иде, ишек кыңгыравы шылтырады. Кашыгын куеп, Ирек өйалдына чыкты, ишекне ачып җибәрде. Каршысында иңбашлары аска иелгән, иреннәре ачудан кысылган Әмир Саттаров басып тора иде.

—Әйдә, керегез, Әмир абый,—диде Ирек һәм күрешергә кул сузды.

—Мин сезгә кул бирмим!—Әмир, күзләрен усал елтыратып, кулларын артка яшерде.—Без ышанган идек... Ә сез сатлык булып чыктыгыз !..

—Туктале, Әмир абый, әйдәгез өйгә кереп аңлашыйк. Ни булды?

—Кермим. «Мин сезне Шәрифуллинга әләклим», дип туп-туры әйтергә идегез ичмасам!—Әмир туктап тын алды да мыскыллы тавыш белән дәвам итте:—Ана каршы бара алмыйм, булдыра алмыйм, имеш!

Аягына элеп, Ирек аның янына чыкты.

—Сез юньләп аңлата аласызмы?

—Аңлатып торасы да юк. Әнә хәзер ТИҮдә йөрүче егетләрне берәм-берәм сындырып бетереп баралар. Сәлахов милициясен дә, прокуратурасын да,

башкасын да эшкә җиккән. Минем дә үткәннәрне казый башладылар, дәресләремә көн саен йә РОНОдан, йә үзебездән кеше керә. МСОның бухгалтеры белән мелиорация егетен кыса торгач, берсе эшеннән чыгып, Болынкырдан китәргә йөри, икенчесе, йөрәге тотып, больницага эләккән. Ник ялгыштык без сезгә әйтеп!

Ирек эшнең нидә икәненә төшенеп бетте. Ул үзенең намусы алдында гаепсез булса да, Саттаровлар каршында мең мәртәбә гаепле иде.

—Мин барысын да яшермичә, аның йөзенә бәреп әйттем. Сез мина ышанган кебек, мин дә ана ышанган идем,—диде Ирек һәм борылып ишеккә атлады.

—Туктагыз әле, каты әйткәнем өчен кичерегез,—диде Саттаров, аның артыннан ияреп.—Сездән башка булмый. Без бер мәртәбә җыелган идек инде.

—Соң?

—Кычкырыштык та таралыштык. Безгә хәзер аеры-чөере килмәскә, бер йодрык булып сугарга кирәк.

Ирек, аның эчендә нинди утлар янганын үтәли күрсә дә, алар теләгән учакның үзенең күнелендә кабына алмавын тойды. Ул кемдер эткәнгә йөри алмый, эчке инанусыз кыймшанмаячагын күптән белә. Ләкин менә бүген, хәзер, ул үзенә чигенер урын калмаганлыгын аңлады. Җаны-тәне белән карышса да, үзен аклау өчен генә булса да, ул хәзер иҗтимагый үзәк кешеләре алдына чыгып басарга тиеш. Шушыларны уйлаганнан соң, Ирек көрсенеп куйды да:

—Сез ТИҮ егетләрен чакырып чыга аласызмы?—диде.

—Алам, әлбәттә.

—Ул чакта иртәгә сәгать өчкә музейга җыелыйк.

* * *

Сәгать өч тулганда, иҗтимагый үзәк әгъзалары берәм-берәм музейга җыела башладылар. Утырырга урыннар аз иде, күпчелек кешеләр басып торды. Санап карагач, ТИҮдәге кырык җиде кешенең уналтысы килгән булып чыкты. Сөйләшү бик кискен башланды. Берәүләр җыен җыю ягын каерса, икенчеләре югары органнарга адресланган хат белән Казанга баруны хуп күрде. Ирек, тарткалашучыларны тынычландыра алмаудан йөдәгәч, музейдагы җиз кыңгырауны шалтыратырга кереште. Шул чак шартлап ишек ачылып китте һәм анда Әхнәф Шәрифуллин белән Фәнис Сәлахов күренде. Бу хәлдән бөтенесе, яшен суккандай, аптырап калдылар. Карашлар Ирекккә төбәлгән иде. Шушы ана нинди көч бирде:

—Без монда җыелыш үткәрә идек,—диде ул, дулкынлануын яшерергә тырышып.—Әгәр музейга йомышыгыз булса, җыелышны туктатып торабыз.

—Рәхмәт—диде Әхнәф.—Революция штабы утырышы шушында, дигәннәр иде, хак икән. Безгә дә катнашырга ярыйдыр бит?

—Катнашырга ярый,—дип куйды Ирек.

Әхнәф, экспонатларны барлагандай, кулы белән акрын гына кагыла-кагыла эчкәрәк узды.

—Лентасы-ние белән пулемет бар, автомат-винтовкалар, штык-кылычлар бар. Кораллы восстаниегә һәммәсе әзер.—Ул стенадагы мамонт сөякләрен сыпырып куйды.—Мамонт сөякләре дә янәшәдә генә.

—Тере мамонтларны мондый кораллар белән генә җиңеп булмас шул,—диде Ирек.—Хәзер аларны аудару өчен атом бомбасы кирәк.

—Йә, нәрсә тикшерәбез?—диде Әхнәф, аның янына килеп.

—Мин бит кисәткән идем,—диде Ирек.—Җыен җыю турында киңәшәбез менә.

—Җыен әйбәт нәрсә инде ул,—диде Әхнәф һәм ТИҮ әгъзаларының йөзенә

берәм-берәм озаклап карап чыкты.—Анда ни сөйләшмәкче буласыз инде?

Шул чак Саттаров башкалардан аерылып алгарак чыкты.

—Булабыз, дип әйтегез, Әхнәф Хәсәнович,—диде ул, һәр сүзенә басым ясап.

Әхнәф көчәнеп елмайды:

—Ярар, сезгә каршы килмим: ни сөйләшмәкче булабыз?

—Халык хакимият җитәкчеләре белән сөйләшергә бик сусаган, диләр.— Ирек Әхнәфкә охшатып елмаерга тырышты.—Шуны оештырырга исәп. Ленин әйткән бит, югарыдагылар булдыра алмый, астагылар өнәми. Бездә дә шундыйрак хәл.

Әхнәф бу кешеләрнең ахыргача барачакларын йөзләреннән аермачык күрде. Куркытулар тәэсир иткән булса, алар бирегә килмәсләр иде. Сәлахов белән ул мәгънәле генә карашып алды да болай диде:

—Ә нигә безгә менә шушлай күзгә-күз карап сөйләшмәскә? Барысын да ачыктан-ачык. Әңгәмәне тәфсилләп газетада яктыртырбыз.

—Әлбәттә, шулай эшләргә кирәк,—дип күтәреп алды аны Сәлахов.—Дөнья кубарып халык җыйсак, бу бит бөтен республикага таралачак. Газета-журналлардан, телевидениедән иснәнеп килеп җитәчәкләр. Үзебезнең эчке мәсьәләләрне үзебез хәл итәргә сәләтле түгелмени без?

—Ай-яй, хәйләкәр сез—дип баш чайкый-чайкый көлеп җибәрде Саттаров.— Хәзер алай эшләргә соң инде.

—Нишләп соң булсын?

—Әгәр сез безнең ТИҮ кешеләрен эзәрлекләмәгән булсагыз, бәлкем моны эшләп тә булыр иде.

Әхнәфнең йөзенә аптырау билгеләре чыкты:

—Кайда ул? Кемне эзәрлекләгәннәр?—диде ул, як-ягына каранып.—Сез беләсезме, иптәш Сәлахов?

—Минем андый нәрсәне ишеткәнем юк,—диде тегесе.

—Сез инде безне гел юләргә саныйсыз, ә бездән калган халык, гомумән, ахмак, дип уйлыйсыз. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик.

—Саттаров!—диде Әхнәф, кинәт усал итеп.—Әгәр турыдан-туры сөйләшсәк, син үзеңнән спирт исе генә калганын беләсеңме?

—Әйе, кайчандыр андый чирем бар иде. Ләкин мин ул өянәкне җиндем. Ә менә сезнең чирегез—халык күз алдында эшләнә торган җинаять.

—Әле син хакимият башлыгына җинаятьче исеме дә тагасыңмыни?—диде Сәлахов, аның каршына ук килеп.

Саттаров аны этеп җибәргән төсле хәрәкәт ясады:

—Бик якын килмә, бирedә нинди кораллар барлыгын күреп торасың.— Аның күзләре әллә нинди кыргый ялтырау белән кабынып китте.—Без сезнең чын йөзегезне ачмыйча туктамаячакбыз.

—Кем кемнекен ачар—карарбыз,—диде Әхнәф.

Алар, дөп-дөп басып, музейның ишеген дә япмыйча чыгып киттеләр.

Җыелыш азагында Ирек:

—Сезгә зур үтенечем бар,—диде.—Мин бүлекчәне оештырдым, күп еллар җитәкләдем. Хәзер сәламәтлегем бик какшады. Шуңа күрә башка кеше сайласагыз, әйбәтрәк булыр. Менә гаризам.

Ирек гаризасын өстәлгә салды, моның шулай буласын белгәндәй, Әмир Саттаров сикереп тә торды, сөйләргә дә кереште:

—Без сезне аңлыйбыз, Ирек Хәйриевич. Бүлекчәнең формаль җитәкчесе булып кына торыгыз, ә барлык эшләрне үзебез башкарабыз.

Аның сүзләрен хуплап, тагын берничә кеше чыгыш ясады.

—Ышанычыгыз өчен рәхмәт,—диде Ирек алардан соң.—Мин күз буяп йөрергә теләмим. Хәлемнән килгәнчә ТИҮ эшендә катнашырга сүз бирәм.

Ә бүлекчәне житәкләүне без Әмир Жаббаровичка тапшырыйк.

Ахырда анын тәкъдимен хупладылар.

Саттаров житәкче булып алгач, тынгысызлыгы, ару-талуны белмәве белән тан калдырды. Ул иртүк торып Наратбашка китә, мәктәптә дәресләр беткәч, Болынкырга кайтып житә, әле теге, әле бу оешмага кереп, ниндидер мәгълүматлар жыя, төрле чаралар билгели, һәркемгә нинди дә булса эш йөкли. Күп тырыша торгач, ул халык жыены жыйнауга да иреште. Әмма жыелыш көнне Әхнәф юкка чыкты, аны ашыгыч рәвештә Казанга чакырып алганнар, диделәр. Анын урынбасарлары, бүлек мөдирләре, аппарат житәкчесе Фәнис Сәлахов куелган сораулардан төрлечә качтылар, яисә өстән-өстән генә жаваплар биреп котылдылар, Әхнәфне яңладылар. Кыскасы, бу жыелышта үзара кычкырышудан башка берни дә булмады. Ахырда районлагы гаделсезлекләрне чагылдырып, республиканын мәртәбәле газетасына зур мәкалә язарга дигән карар кабул иттеләр.

## 12

Әхнәфнен көне буе кәефе булмады. Башка көннәрне кичке алтыларга-жиделәргә кадәр эшләсә, секретарена бүген булмаячагын әйтте дә, сәгать бишенче яртыда жәяүләп кенә кайтып китте. Районда ниндидер зур нәрсә кузгала, анын исе менә шушы сулап барган һавадан да ачык сизелә иде. Фәһимә белән озаклап сөйләшеп, мона каршы тору планын эшләргә, барысын да жентекләп уйларга, хәстәрен күрергә кирәк. Ул ерактан ук үзләренен турында Фәһимәнен машинасы торганын күрде. «Нишләп сон әле машина монда?» дип уйлады Әхнәф. Ул болдырга күтәрелеп ишекне тартты, әмма ул бикле иде. Кесәсеннән ачкыч чыгарып ачты да сак кына адымнар белән эчкә керде. Каядыр еракта Фәһимәнен чыркылдап көлгән тавышы ишетелә иде. Көлүдән ул кычкыруга да күчкән сыман булды, аннары тынып калды. Шоферы Сәгыйрьнен бер генә сүз әйтеп куйганы ишетелде. Әхнәф, ишек төбеннән үтмичә, һаман тынланып торды. Анын кергәнен сизгәндәй, эчтә дә тавыш бетте. Әхнәфнен күнелен нидер тырный башлады, башына әйбәт булмаган уйлар килде. Эчтә савыт-саба шалтырады, шарлатып су агыздылар. Күрәсен, алар кухняда иде. Әхнәф туфлиләрен салды да плащын ычкындырган, фуражкасын тоткан килеш кухняга узды. Сәгыйрь белән Фәһимә юынгычта шаулатып су агызып нидер эшлиләр һәм көлешәләр иде.

Ул тамак кырып куйды, алар ялт итеп икесе дә ана борылдылар.

—Исәнмесез, Әхнәф Хәсәнович!—диде Сәгыйрь, кулындагы яшел үләненнән идәнгә су агызып.

—Исәнмесез,—дип төксе генә жавап бирде Әхнәф.

—Менә ухага әрмән үләне кирәк булды да кайтырга туры килде,—диде Фәһимә акланганлай.

Ул үләнне, Сәгыйрьнен кулыннан алып, полиэтилен букчага салды. Сәгыйрь узып киткәндә, аннан аракы исе бөркелде.

—Син кая жыендын сон әле болай?

—Ничек инде син шундый сорау бирә аласын?!—диде Фәһимә, гажәпләнүен яшермичә.—Ревизорларны сыйларга кирәк, кунакханәгә киттем.

Хатынынын да авызыннан аракы исе бөркелә иде.

—Озак тоткарланма, сөйләшәсе сүз бар,—диде Әхнәф.

—Кызык син, әйеме? Сина иртән кайтырга да ярый, кунакнын күнеле булганчы сыйламасан, ул икенче көнне әллә нәрсәләрне казып чыгара башлый.

Әхнәф Фәһимә белән сүз көрәштереп тормады. Аларнын машинага утырып киткәнен тәрәзәдән карап торды да, ихатага чыгып, Миргаяз утыра торган почмактагы кечкенә бүлмәгә керде.

—Килүче-китүче булмадымы?

—Фәһимә Әсгатовналардан башка юк.

—Алар ничәдә кайткан иде?

—Нәкъ дүрттә,—диде Миргаяз.

Әхнәф анын янынnан күнелсез уйлар белән чыкты. Димәк, Сәгыйрь белән Фәһимә өйдә бер сәгатьләп булганнар. Шул гомер нишләмәк кирәк? Ул хатынынын иренендәге помаданын да сөртелеп бетә язганлыгына игътибар иткән иде. Сәгыйрьдән бер генә хатын-кыз да калмый, дип сөйлиләр. Әгәр Сәгыйрь шундый икән, Фәһимә каршы тора аламы? Ул үзенен шундый түбән уйлар белән утыруына хәйран калды. Бу чын мәгънәсендә ваклану, ир кеше буларак үз-үзенне югалту иде. Ә ни өчен ишек бикле иде сон? Ни өчен шофер белән начальник кеше шулай көлешә, чытлыкланып сөйләшә? Аны аяклары ихтыярсыз рәвештә йокы бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Урын-җир изелмәгән, бар нәрсә дә урынында иде. Бәлкем алар эчкәннәрдер? Ул кабаланып барып, берәм-берәм рюмкаларны тикшерде, чынаяк-бокалларны иснәп карады--берсеннән дә аракы исә килмәде. Ә нигә алар өйдә эчәргә тиеш? Кичә алар кунакханәдә булдылар, Фәһимә бүген дә шунда ревизорларга сый-хөрмәт күрсәтә. Нишләптер Сәгыйрьнен уртачадан тәбәнәк, юантык гәүдәсе, түп-түгәрәк йөзе, күпереп торган мыегы, муенына кадәр үскән саргылт йоннары гел күз алдында бөтерелде. Әллә инде галлюцинация башлана, дип уйлады Әхнәф. Ул һәммәсен дә онытырга теләде, ләкин башын, чүкеч белән төйгәндәй, бер сорау авырттырды: бер сәгать! Бер сәгать нишләп була? Бу бит коточкыч күп вакыт. Әрмән үләнен үстереп алмаганнар ич алар. Түтәлдән алып кереп юу өчен биш минут вакыт җитә.

Төптән уйлап карасан, һич тә анлата алмаслык хәл: асылда Әхнәф Фәһимәгә битараф бит. Ә нигә болай бәргәләнә? Менә шушында чагыштыру дигән нәрсә күнелгә килеп керә. Фәһимәнен шоферы яшь, өрлектәй таза, ут чәчеп тора. Әгәр ул аны Әхнәфтән кайнаррак иркәләсә, анa күбрәк ләззәтләр бирсә? Фәһимә, шуны чагыштырганнан сон, гомерен Әхнәф белән бәйләгәне өчен үкенсә? Юк, хатынынын күзе алдында һич тә мескен булып күренәсе килми анын! Аннан да хәтәррәге—алданасы килми! Чыннан да хыянәт итәме ул, әллә шулай тоела гынамы? Ул хатынынын күзләреннән, йөрәк тибешеннән, йөзеннән, тәнендәге исеннән, һәр хәрәкәтеннән, үз-үзен тотышыннан әлеге сорауга җавап эзли—таба алмый. Районда беренче зат бул да, өйдә мәхлукка әйлән инде. Акылга муафыйкъ кешенен йөрәге мондый каршылыкка түзә алмыйча шартлап ярылырга тиеш!

Әхнәф инде мененче мәртәбә тагын бер хакыйкатькә инанды: әгәр бәндәнен башына бер уй керсә, ул, коры мүккә төшкән очкын кебек, ин элек пыскый башлый, аннары төтенли, ахырда ялкынланып үрләргә тотына. Ялгышып кына кергән уй да кешене тәмам чыгырдан чыгарырга мөмкин икән. Сәгыйрьдән ул кайчандыр, әллә ничек кенә шикләнгәндәй булды. Монын өчен үзен шундук эт итеп сүкте дә әле. Ә теге уйнап кына калыккан уй эченә корт кебек керде дә утырды, үрчепме-үрчеп, бөтен барлыгын биләде. Хәзер инде ул уйдан Әхнәф Зәлия янында да котыла алмый. Мин монда, алар кайда икән, дип яшерен хафалана, очрашунын тәме китә...

Әгәр Фәһимәгә туп-туры, мин барысын да сизеп йөрим, дип әйтсән? Ә ул, мин комсомолдан ук сизеп йөрим, гомер буе түзәм, нишләп син сабыр итмисен, дип авызынны капласа? Ә син, йөргәнне исбатла, дисән? Син дә минекен исбатла, димәсмени Фәһимә? Нигә бу тормыш адәм баласын газаплый торган, җавабын берничек тә табып булмастай табышмаклар бирә икән?

Кайчакларда ул, бөтенесенә күз йомып, кул селтәмәкче була. Йөри бирсен, ул бит күпме генә йөрсә дә, Зәлиядән арттыра алмаячак, дип уйлый да, шундук сискәнеп туктап кала. Чү әле, ди, туктале, ди икенче тавыш. Зәлияләрдән дә хәтәррәк кыланса? Менә бу сорау Әхнәфне инде чын чиргә

сабыштыра. Фәһимәнең күзләреннән гомер буе комарлык, йөзеннән бетмәс-төкәнмәс дәрт бөркелде, йөрәгенең ярсып тибүеннән, күкрәгеннән чыккан кайнар һавадан борын яфраклары ярсу атныкы төсле киерелеп тора. Ун Зәлияне уздырырга мөмкин ул ачарбак. Болай уйлагач, Әхнәфтә хатынына карата нәфрәт катыш җирәнү тойгысы уяна, кичләрен аның янына кереп ятарга үзен мәҗбүр итә алмыйча газаплана. Фәһимәнең йоклап киткәнен көтеп, залда юк әйберне бар итеп гомер уздыра, янына ятарга кергәч, хатынының ак, таза инбашларын, беләкләрен умырып-умырып чеметәсе, йодрыклары белән төясе килә.

Менә бит нинди яман чир йокты. Операция белән кисеп ташлый торган булса, күпме акча сорасалар да, кызганмас идең. Әмма кисеп ташлана торган нәрсәләр рәтенә керми шул бу каһәр. Ниһаять, анарда бирәр көчлерәк экстрасенска күренеп карау теләге туды. Чөнки бу кичерешләреннән бик үк нигезле түгеллеген Әхнәф чамалый башлаган иде инде. Казанга алдагы баруында, дөньясының чите кителсә дә, психотерапевтка керергә ныклап карар кылды.

Ул телевизорны кабызды. Фәһимә әзерләп куйган котлетны җылытып ашады. Башы таш булып каткан, бөтен гәүдәсе арыган иде. Телевизор карый башлауга, йоклап та китте, әллә нинди куркыныч төшләр күрде, бастырылып бетте. Фәһимә кайтып кергәндә, сәгать унынчы киткән иде. Аның күзләренең майланып елтыравы, ике битенең чиертсәң кан чыгарлык булып янып торуы, ерактан килеп бәрелгән тәмәке катыш аракы исе Әхнәфнең ачуын китерде.

—Әллә син тарта да башлагансың инде?

—Тартып күрсәтимме соң? Ха-ха-ха!

Фәһимә, көлә-көлә кухняга чыгып, бер стакан салкын су эчте дә кабат залга керде.

—Нишләп шул кадәр тәмәке исе килә синнән?

—Мин ревизорларны тартудан тыя алмыйм ла инде. Җитмәсә Сәгыйрь дә машинада туктаусыз пыскыта.

—Нишләп син ана тарттырасың?

—Минем тәмәке исе яратканымны беләсең лә. Тәмәке төтене иснәгәч, минем башым яктырып китә, әллә нинди фикерләр килә.

—Бик әйбәт вакытың икән,—диде Әхнәф кинаяле тон белән.—Беләсеңме, ТИҮ бүлекчәсе Ирек җитәкчелегендә тагын халык җыены җыймакчы була, диләр.

—Алар тырнак астыннан кер эзләргә ясап куйган кебек инде.

Әхнәф, борынын җыера-җыера булса да, аның янәшәсенә утырды:

—Нишлибез соң?

—Хәзер бу сорауны бирергә соң инде,—диде Фәһимә, аңа ачу белән карап.—Безне синең әнә шул стенкаң харап итте. Бармыйк шул хәерчеләргә, араны шартлатып өзик, дидем. Ә син тыңламадың. Хәзер мин сиңа нинди киңәш бирим?

—Киңәш бирмә, бергәләп уйлашыйк. Без бит синең белән барысын да ачыктан-ачык сөйләшергә сүз бирештек, бернине дә яшермәскә.

—Әйе шул,—диде Фәһимә.—Син аны үтисеңме соң?

—Үтәмичә.

Фәһимә кинәт урыныннан сикереп торды, аның иреннәре дерелдәп китте, ачудан күзләре түгәрәкләнде.

—Сөйләп торасың, сөйрәлчек!

—Нишлисең син?!—диде Әхнәф гаҗәпләнеп.—Әллә корт чактымы?

—Әйе, Зәлия исемле шөпшә чакты. Мин юләр сиңа ышандым, ә син һаман шул азгынлык юлында. Җирдәге тормышны кабат динозаврлардан башлап буладыр, сине генә янадан ясап булмый.

—Хәзер син дә гайбәт җыеп йөри башладыңмыни инде?

—Дәшмә, оятсыз! Әнә шул фахишәннән кинәш сора! Әле бит шуны элемтә бүлекчәсенә урынбасар итеп куярга җыенасың, диләр.

—Барысы да гайбәт!—Әхнәф аклану өчен шуннан ары сүз таба алмады.

—Нишләп синең бүлмәнә кереп йөри ул?

—Миңа теләсә кем керә.

—Фахишәләр свиданиегә киләләрме?

—Тукта зинһар! Әйт: кем миңа шундый пычрак ата?

—Әйтсәм, иртәгә үк ябырылыр иден. Ирләрнең сөяркәсе турындагы хәбәр, бөтен халык сөйләп, онытып бетергәч кенә, аның хатынына барып ирешә, дигән сүз хак икән. Әгәр шул фахишәне урынбасар итеп куйсаң, белеп тор: шул көнне үк судка аерылышырга гариза бирәчәкмен! Бусы бер. Икенчедән, син аны районнан китәргә мәҗбүр итәргә тиеш.

—Ничек?

—Юлын тап. Аңа якынаерга юл тапкансың бит.

—Фәһимә, син бөтенләй сүзне икенче якка бордың. Хәл бит бик җитди. Аннан котылу юллары турында минем белән сөйләшергә ниятең бармы?

—Юк!—диде Фәһимә кистереп.—Мин арыдым, минем йокым килә. Миңа башка бер сүз дә дәшмә!

Үз бүлмәсенә кереп, аның чаштыр-чоштыр чишенгәне, шифоньер ишеген япканы һәм включательгә басып утны сүндергәне ишетелде. Әхнәф, аякларын аерып баскан килеш, япа-ялгыз торып калды. Тулаем алганда, Фәһимә хаклы, әмма менә хәзер аяк астында җир янып килгәндә, ул хаксыз гына түгел, Әхнәфкә һөҗүм итүче дошманга әверелгән иде. Ә кайда соң бер ярдәмче, таяныр кеше? Гомер буе шушы Болынкырда яшәп, нишләп соң аның янында җанын бирерлек бер генә ышанычлы кеше дә юк? Моңа кем гаепле? Әхнәфме, Фәһимәме, биләгән урынмы, әллә бу берни аңламаслык бкырдап аккан болганчык тормыш елгасымы?..

## 13

Узган елны әйбәт кенә төгәлләделәр. Саннарны әзрәк матурламыйча да булмады, һәркайда да шулай инде: Татарстан Мәскәү күзгесенә карап, районнар Казан күзгесенә төбәлеп, керфекләрен озайталар, сөрмәсен тарталар, иннеккершәнен салалар, затлырак киенәләр. Әхнәф яңа ел тантанасы биргән күтәренке рух белән бик озак йөрде. Әмма һич көтмәгәндә аяк астында бомба шартлагандай булды: «Вечерняя Казань» газетасында Әхнәфне җитәкче буларак тар-мар китергән зур мәкалә чыкты. Аны Саттаров язган иде. Мәкаләне укыганда, Әхнәфнең күзләреннән кан тамды кебек. Иң элек аның, район башлыгы булгач та, киң колач белән эш җәелдерүе, экономиканы алга җибәрү, яңа төзелешләр алып бару буенча куанычлы адымнар ясавы күрсәтелгән. Шуннан соң, башка күсәк белән органдай, ангырайта торган утлы юллар китә. Шәрифуллинны, дигән Саттаров, халыкка ят уйлар били башлады, аның күңеле бүтән эшләргә тартылды. Аның исеменә халык тарафыннан хәзер тискәре мәгънә салына, дигән. Моның сәбәпләре дә күрсәтелә. Өй салулар, машина алулар, максатчан җибәрелгән акчаларның югалуы... Ул акчаларның суммалары, һәрберсенең документ номерларына кадәр күрсәтелгән. Саттаровның моны кайдан, кем аша белгәнлегенә Әхнәф хәйран калды. Мәкаләнең шактый өлешен кадрлар мәсьәләсе алып тора. Имеш тә үз фикерен әйткән кешеләр, җитәкчелеккә ризасызлыгын белдерүчеләр эштән куылган. Алар урынына ялагайлар, хакимият башлыгының әшнәләре, туганнары җыелган.

Мәкаләнең шулкадәр көйдергеч ирония белән язылуында Әхнәф Ирек каләмен күрде. Мондый стиль, мондый үтергеч тел белән бары ул гына яза

ала. «Әгәр Ирек үз фамилиясен куйса, бу кадәр рәнҗемәс идем!»—дип газетаны Фәһимәнен борын төбендә шатыр-шотыр селкеде ул. Бу арттан пычак кадау гына түгел, аннан да әшәкерәк гамәл иде. Саттаров, мәкаләне ксерокс аша чыгарып, һәр авылга тараткан булып чыкты. Район халкы шау-гөр килде, бу тәнкыйть күпләрне канатландырып җибәрде. Казанга шикаять арты шикаять яудыра башладылар, халык белән ике арадагы каршылык көчәйгәннән-көчәя бара иде...

Бүген Әхнәф эш бүлмәсеннән кайтырга чыкканда ук йөрәк даруларын тамчылап санап тормыйча, чәй калагын тутырып кына җибәрде. Урамга чыккач, баскычта бераз тирән сулап торды. Йөрәге тынычлангандай булып китте, ишеп-ишеп кар ява, җил дә чыга, төнгә буранга көйләргә уйлый ахрысы. Урам лампалары яктысында менә шулай бөтерелеп карлар яуганда, ул элекләрдә очынып-дәртләнеп атлый, бер басасы урынга биш баса, күнеле әллә кайларга ашкына иде. Шушы яктылыкта бөтерелүче кар бөртекләре ак күбәләкләр төркемедәй анын күнеленә очып кереп тулалар, каядыр күтәреп алып китеп, еллар катламын кичеп, сабый балага әверелдерәләр; аягына тимераяк, чаңгы тактырып, чана тарттырып, авылнын таныш тавына сөйрәп менгерәләр, инешендә чума-чума коендыралар, серле ай нурлары белән тулган урамнардан кызлар-егетләр белән җырлатып үткәрәләр иде... Ә менә хәзер яуган бу кар бөртекләре Әхнәфкә күктән укмашып төшкән корым кисәкләре булып күренделәр. Өенә уравыч урамнар белән кайтса да, борчулы уйлардан ул котыла алмады, җаны тынычланмады, нервылары тартылган кыллар кебек зенләделәр. Ул кайтып кергәндә, капка төбендә Фәһимәнен машинасы тора иде. Шоферы Сәгыйрь белән сүзсез генә кул биреп күрештеләр.

—Берәр җиргә барасызмыни?—дип куйды Әхнәф кырыс кына.

—Мин белмим, көтәргә кушты,—дип җавап бирде шофер.

Ишектән керү белән, Әхнәфкә бизәнгән, төзәтенгән Фәһимә карчыгадай очып кунды:

—Нәрсә бик иртә кайттын? Групповой секс булмадымыни?!

Әхнәфнен башына кан бәрде, йөрәге ярсып тибәргә кереште.

—Син ни сөйлисен?!—диде ул, йөзенә гөнаһсыз кыяфәт чыгарырга тырышып.

—Синен тәтәйләр йортынны телевизорга төшерергә килгәннәр бит, адәм тәганәсе!—Фәһимә елый ук башлады.—Бөтен халык шаулый. Мин анын шулай икәнлеген сизеп йөрдем. Бу дәрәҗәдә түбәнлеккә төшәрсен, дип уйламаган идем.

—Әйдә, син дә җыя бир инде гайбәт, бергәләп тырышыгыз...

—Ичмасам дәшмәскә иден, кабахәт!

Бу сүзләрне әйткәндә, Фәһимә киенеп беткән иде инде. Ул нәрсәләрдер тутырылган сумкасын алды да ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

## 14

Бүген физкультура дәресендә чаңгыда узыштылар. Айгөл кызлар арасында икенче урынны алды. Соныннан бер төркем малайлар, кызлар спорт мәйданчыгында туйганчы шаярыштылар, үртәштеләр, куыштылар, кар сибештеләр. Әле өйгә кайтып кергәндә дә, Айгөлнен дулкынлануы бетмәгән, бит алмалары ут яна иде. Зал ягында китап укып утырган Айдар абыйсына да ул башка күзләр белән карады, анын муеныннан кочаклап аласы килде. Ике-өч мәртәбә анын яныннан акрын гына үтеп китте, әмма ул күтәрелеп карамады. Сонгысында Айгөл бер генә мизгелгә анын кырында туктап калды, чәченнән сыпырмакчы булды. Ул хәтта арттан килеп кулын да сузды, бармак очы белән анын дулкынланып торучы чәчләрен турылыйсы һәм маңгаена төшкән бер учмасын өскә күтәреп куясы килде, тик кыюлыгы җитмәде.

Әйе, әтисе хаклы. Аларга бергә яшәргә, бергә яшәп аеры да, аеры яшәп бергә дә булып була икән шул. Әнисе дә, әтисе дә анын Айдар абыйсы белән тату яшәвен тели икән, ни өчен карышырга? Монын сәбәбе дә юк кебек.

Ул кухняда кулларын юып, плитәгә чәй куеп йөргәндә, гадәттәгечә анын чыгып өстәл әзерләвен, гадәттәгечә мәктәп хәлләрен соравын көтте. Әмма бүген Айдар абыйсы чыкмады. Әле бая гына анын янында җылы тойгыларын ничек белдерергә белмичә бөтерелеп йөргән Айгөлнен ачуы кабарды. Ул юньләп ашамады, савыт-сабаларын да юмады, шалтыр-шолтыр китереп, өстәлгә өйде дә куйды. Айдар һаман дөньясын онытып китап укып утыра иде. Әйдә, санаса Айгөлне бала-чагага саный бирсен. Ул үзенен бүлмәсенә керде дә күлмәген, гамажын салып ыргытты, тиздән күпкә югары халатын киеп, көзге каршына килде, аннары нидер уйлады да анын өске һәм аскы сәдәфләрен ычкындырып җибәрде. Халат, уртадагы сынар сәдәфкә эләгеп, ярым ачык хәлдә калды. Ана күлмәген үтүкләргә марля кирәк иде. Юри дөп-дөп басып чыгып, залдагы сервантнын бер бүлкәсен ачты да актарынырга керешті. Шулчак Айдар, ана таба башын борып:

—Чит кеше каршында болай йөрмиләр бит, Айгөл,—диде.

Айгөлнен ачудан күзләре елтырап китте, йөзенә мыскыллау билгеләре җәелде:

—Син бит чит кеше түгел,—диде дә, әллә нинди ят, үтергеч басым белән:— Үги әти,—дип өстәде.

—Әти кеше алдында бигрәк тә ярамый.

—Ничек телим, шулай йөрим!—Монарчы тыеп килгән ачуы Айгөлнен тәнен калтыратып җибәрде.—Сина ошамый икән, анысын мин әйтә алмыйм. Ошый торган кешеләренә кара.

Айгөл марляны алды да, дөп-дөп басып, тагын бүлмәсенә кереп китте. Бүген беркая барырга тиеш булмаса да, кайсыдыр күлмәген алып үтүкләде, киенде, һәм, бер сүз дә әйтмичә, ишекне шартлатып ябып чыгып китте.

Урамга чыкканда, ачудан аягы белән карны капкага таба типкәләде, чәчте, итеге тизгә кадәр карга буялды, аны ике куллап тырный-тырный чистартты, әмма күнелендәге ачу һаман басылмады. Кая барганын да белмичә, урам буйлап китте. Айгөлне Айдар абыйсынын үзенә карата бөтенләй битарафлыгы котырта, ул вакыт-вакыт ана йодрыклары белән ташланыр дәрәҗәгә җитә. Ин гайрәт чигергече шунда, битарафлыгын яшерү өчен, ул һәрвакыт игътибарлы булып кылана. Ә бит әнисе белән ул үзен бөтенләй башкача тота, анын бер генә мәртәбә дә Айгөлгә әнисенә елмайган төсле елмайганы юк. Салкын, ясалма елмаюы йөзенә май сөртеп ялтыраткан төсле төче булып ярылып ята. Шул чакта анын чыраен тырнап төшерәсе килә Айгөлнен. Ә күз карашы? Әнисенә җылы караш ташлый, күзләрендә серле, әллә ниләр анлатучы очкыннар уйный, әмма андый җылылыкны ул Айгөлдән кызгана. Сүзләре дә икенче төрле, эчтәлекләре дә башка. Әнисенә ярым пышылдап йомшак әйтелгән сүзләр, Айгөлгә юлланганда, салкын җилле янгыр, борчактай рашкы кебек килеп бәреләләр. Айгөл үзенен нинди кеше икәнен бик күрсәтер иде, әмма курка. Нәрсәдер куркыта аны. Ул ана якынаюдан курка һәм шуннан котылу өчен, Гандәлифә апасы өйрәткәнчә, усал булып кылана. Айгөл урамнан атлап барган жиреннән кинәт кирегә борылды. Нигә сон әле Гандәлифә апасы янына кермәскә? Ул һәрвакыт аннан тынычланып, күнеле хушланып чыга. Ә менә бүген, бүген генә түгел, инде күптәннән күнеле тулы борчулы уйлар йөрткәндә, нигә кермәскә ана?

Гандәлифә Айгөлне кочаклап каршы алды.

—И, кызым, бер дә күренмисен. Әллә уку бик катымы?—диде, анын киемнәрен чөйгә элеп.

—Бар инде,—дип куйды Айгөл.—Мәктәпне тәмамларга җыенабыз бит.

Таһирдан хат юкмы?

—И, кызым, булса, хәбәр итмимме соң инде мин?

Болынкырда имеш-мимешләр, гайбәт таралмасын, дип Гандәлифә адресына хат язуны Таһир уйлап тапкан иде. Конверт тышына «Т. Чукаевтан» дип хат яза да, аннары Айгөл тып-тын гына килеп ала.

Гандәлифә ана тары ярмасы белән пешерелгән кабак бәлеше салып бирде, кайнарлап чәй ясады. Үзе анын йөзеннән күзен алмады, ахырда үзен борчыган уен белдерде:

—Күнелен тыныч түгел бугай, кызым...

Айгөл чәен шопырып йотты да чынаягын куйды.

—Нәрсәгә иканен үзем дә анламыйм...

—Үги әтиен белән боткан пешмиме?

—Барысы да миннән, Гандәлифә апа,—диде Айгөл, авыр сулап.—Мин аны кўралмаска тырышам. Әгәр кулымнан килсә, женгә, парига әйләндерер идем. Аны начар итеп күрсәтү өчен, әллә ниләр эшлим, төртмә сүз әйтәм, мыскыллыйм, бәйләнәм. Ә ул, үч иткәндәй, һаман башын түбән ия, буйсына гына бара, кызгандырырга телиме—белмим.

Гандәлифә,анын белән килешмәвен белдереп, башын чайкап куйды:

—Юк, кызым, ул сезнен икегезне дә ярата, хөрмәт итә. Шуна күрә каршы әйтергә дә кыймый. Алай кискен бәрелмә син ана. Үтәрсенме мин әйткәнне?

—Белмим,—диде Айгөл, башын аска иеп.

Айгөл чыгып киткәч, Гандәлифә үзенен иргә чыккач, аерылгач кичергән газаплы коточкыч көннәрен хәтеренә төшереп утырды.

* * *

Айгөл кайтып кергәндә, әнисе өстәл артында елап утыра иде. Анын битләре шешенеп беткән, чәчләре, күз яшьләренә чыланып, янакларына ябышкан. Айгөл йөгереп барып, әнисен кочаклап алды:

—Ни булды, әни?

Әнисе аны этеп җибәрде:

—Шатлан, телэгенә ирештен!—диде ул үксеп һәм алдында яткан кәгазьне Айгөлгә атты.

Айгөл бер күз атуда аны укып чыкты: «Сөембикә, Айгөл! Мин түзә алган кадәр түздем. Бүтән сезгә яшәргә комачауларга теләмим. Бәхетле булыгыз! Мин китәм. Айдар.»

—Әни, мин бит анын китүен теләмәдем!..—диде Айгөл өзгәләнеп.

—Теләден, аны син мәҗбүр иттен! Син ана көн күрсәтмәден. Рәхмәт, кызым...

Айгөл кычкырып елап җибәрде:

—Юк, юк, юк! Мин анын китүен теләмәдем, әни!—Айгөл сәгатькә күз төшереп алды, әле сонгы автобус китәргә биш минут вакыт бар иде.—Мин аны хәзер барып алып кайтам!

Ул курткасын кулына гына эләктерде дә чыгып йөгерде. Анын йөрәге чыгардай булып типте, күкрәге уттай янды, күзеннән кайнар яшь акты. Ул Айдар абыйсынын кыерсытылган, мыскылланган хәлдә вокзал ишеге төбендә боегып басып торуын күз алдына китерде. Айгөл тынына буылып, урам буйлап чапты. Ул барып җиткәндә, автовокзал бушап калган иде. «Сонгы автобус китте инде», диде кассир. Бу сүзләр Айгөлгә хөкем карары кебек янгырады. Менә хәзер анын күз алдына кызганыч, рәнҗетелгән кыяфәте белән әнисе килеп басты. Ул хәлсезләнеп автовокзал ишегеннән ерак булмаган электр баганасына барып сөялде...

*Ахыры киләсе санда*



Флера
Гыйззәтуллина

# НАЗ СУРӘТЕ

## Исәнме, мәхәббәт!

—Исәнме, мең яшәр мәхәббәт!
Кил, әйдә... уз, әйдә түремә!—
Чак кына соңардым...—дисеңме:
Күзләрең ник моңсу күренә?
Моңайма!—
«Кайдадыр җил куып» йөрмисең.
Күкләргә үрләгән учактай,
Син минем җанымда дөрлисең.
Син миңа:
—Сүрел?—дип ялварма!—
Мин синең иң тугры колыңмын...
Теләсәң, аягың очында
Төнозын тезләнеп торырмын.
Энәмә таңнардан нур саплап,
Мин сиңа мендәрләр чигәрмен..,
Теләсәң—йөрисе юлыңа
Хуш исле чәчәкләр сибәрмен
Һәм кайчан, кайларда йөрсәң дә
Мин сине ашкынып көтәрмен.
...Соң түгел...
Иң кирәк чагымда
Син мине күкләргә күтәрдең.
Моннан да зур бәхет бармы соң...—
Китәргә торганда дөньядан?
—Яратам... Ихластан сөям!—дип,
Мәңгелек утларда мин янам.
Яратып, ышанып тез чүгәм:
—Йа, Тәңрем! Сөюдән аерма!
Минем дә башкалар шикелле
Хакым бар—хыялда баерга...

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА—*шагыйрә; «Чишмә юлы», «Сәлам хаты», «Уйларымда шаулый карурман» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Көтәм

...Кызганычкадырмы—
Сине юксынудан
Газиз башкаемны
Җиргә кадәр идем.
Кызгандырсам да мин,
Бары синнән генә
Бары синнән генә
Кызгандырыр идем...
Бары сиңа гына
Елап сөйләр идем
Сине көтә-көтә
Хәлсез калганымны.

Хәл бир миңа?—диеп,—
Җан өр миңа, диеп,
Әҗәл күкрәгенә (!)
Башым салганымны.

Сөенечкә микән,
Көенечкә микән
Сине юксынуым,
Сине яратуым...
Син яшәгән яктан,
Син киләсе яктан
Көтәм таң атуын.
...Әйе... таң атуын!

## Лачын

*Һаваларда оча ике аккош,*
*Каурыйлары җиргә коела*
Әхсән Баян

Һаваларда оча бер яшь лачын
Каурый сибеп язгы ташкынга.
Гашыйкларның хыял чыганагы—
Очар кошның канат астында.

Һаваларда оча бер яшь лачын...
...Очмыйдыр ул,—нурда йөзәдер...
Шул очыштан илһам алган күңел
Күккә ашмый ничек түзәдер?

Һаваларда йөзә бер яшь лачын:
Сибелә чәчем канат җиленнән.
Җиргә яз китергән шушы җилләр
Саклап килә мине үлемнән.

Һаваларда оча бер яшь лачын!
Очсын, әйдә, очсын—иркендә...—
Ул дәвамы минем яшьлегемнең,
Ул бурычлы түгел беркемгә!..

## Егет күлгә кармак төшерә

Балык тота халык боз өстендә...
Март кояшы балкый, боз ашап!
Балкысаң да, үксеп еласаң да—
Узачак ул гомер, узачак.

...Ястык кебек калын бозны тишеп,
Егет күлгә кармак төшерә.
Март аенда туган ир-егетнең
Алтын балык керә төшенә.

Күл өстендә бозлар тиз эреми:
Дулкын бозны төпкә кагачак!..
Күлләреңне күккә күчерсәң дә
Яначак ул, йөрәк, яначак.

Балык тотып егет «илһам ала»,
Мин дә шул ук күлдән су алам.
...Газиз халкым!..
Бигрәк назлы инде
Март аенда туган бу балаң!

…Балык тота халык!..
Бу халыкны
Еллар әле уйга салачак.
Алтыннарга тиңләп яратсаң да
Калачак бу дөнья, калачак…

## Учларымда минем наз сурәте

Мәхәббәт ул сынмый сабырлыктан.
Мин яратам сине хәзер дә!
Шулай да син миңа кил әле бер,
Җаның сусаганда кадергә.

…Үт әле бер… безне аерып торган
Гамьсез, кырыс еллар аркылы.
Шул елларга тоташ күңелемнең
Өзелергә торган һәр кылы.

Мәхәббәт ул сүнми назланудан—
Һәрбер гашыйк моны тоядыр…
Учларымда минем наз сурәте,
Синең сурәт—мәрмәр кыядыр?!

…Шулай да син миңа кил әле бер,
Диңгезендә назның йөзәрсең.
Рәхәт булса—җиргә баш иярсең,
Күңелең тулса дәшми түзәрсең.

## Сагынам

Сагынам сине.
Сагыну-сагышларны
Бикләп тотып булмый сандыкта…
Йөрәк серләреңне сөйләрсең дип
Пар сандугач чиктем яулыкка.

Әмма белмим, мин бу кульяулыгын
Озатырмын Сиңа кем аша?
…Биегәя күкләр… очар кошлар
Берсен-берсе кочып уйнаса!..

Сагынам сине:
Җирдә кыяклана
Күктән иңгән сагыш бизәгем.
…Кульяулыгым җилгә очырдым да,
Ак болытка кулым изәдем.

Сине сагыну—миңа чиксез бәхет!
Бәхетнең мин көтмим үзгәсен.
Һәм Сиңа да бәхет алып килсен
Ак болыттан яуган күз яшем.

Пар сандугач чиккән кульяулыгым
Булсын Сиңа миннән истәлек…

…Сагынам Сине,
чәчләреңнән назлап
Искән җилләр кебек нечкәреп.

## Исеңдә тот…

…Без сөюгә талган офыклардан
Инде миллион йолдыз атылгандыр.
Чәчләреңә, кыйгач кашларыңа
Кырпак-кырпак булып чал кунгандыр.

Ул чагында без бит икебез дә
Шул кадәрле гүзәл, бөек идек:
Янып яратуның һәр мизгелен
Һаваларга йолдыз итеп чөйдек.

Бәлки инде безнең гомерләргә
Бу мизгелләр кабат ялганмас та...
Йолдызлардан исәп, сан алганда
Шулай да син тырыш алданмаска.

Шулай да син мине исеңдә тот!
Мәхәббәтне мәңгелеккә юра...
Миңа таба тәгәрәтер өчен
Хисләреңне йомгак итеп ура.

***

...Шигырь—тылсым...
Мәхәббәт тә—тылсым.
Табынуым, Тәңрем,
Хәерлегә булсын!

***

Сайрый былбыл, сайрый,
Талга басып сайрый.
Сайрауларын аның
Ятлап булса икән!
Талны бөгелүдән,
Җанны өзелүдән
Саклап булса икән.
Саклап булса икән!..

***

Бәргәләнә бәгырь, өзгәләнә үзәк:
—Авыз ачып калма—күрәчәгең күзәт,
Чәчләреннән сыйпап,хаталарын төзәт!?
...Күрәчәгем исә мине танымады.
Әллә җиде ятны сөеп табынамы?
Картайганым өчен әллә... каныгамы?

***

...Айурагым—нурдан!...—
Кылган урам... кылган!

Шуңа күңелем тулган:
Кичерешләрем—зиндан!

***

...Ай-йолдызлы серле төннәр узып,
Хыял таңнарымны сызылдырып,
Күтәрелә Кояш җир өстенә.
Могҗизалы, нурлы шул күренеш
Морадыма мине ирештерә,
Күрәчәгем белән күрештерә.

*Бу айда шагыйрәнең юбилее. Аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз!*

**Редакция**

Рәфкать Кәрами

# ОЛЫ ЮЛ ДА СИКӘЛТӘЛЕ

РОМАН

## VIII

...Беренче көнне, палаткалар кору һәм башка вак-төяк эшләр белән мәшгуль булып, эленке-салынкы йөрсәләр, икенче көнне иртүк, үгезне мөгезеннән эләктереп дигәндәй, Габделнурларны сафларга тезеп, танкодромга алып киттеләр. Шулай итеп, бер айга сузылачак тактик өйрәнүләр башланды.

Солдатларның иңнәрендә камыт кебек бөтереп төрелгән шинель-скатка һәм авыр карабин, янтыкта кыска саплы җыйнак сапер көрәге—шанцевый инструмент һәм противогаз савыты.

Юл буенда таллар, сирәк-мирәк тәбәнәк каеннар, куаклыклар күзгә чалына, өзлексез кошлар сайрый. Рота командирының калын тавышы да аларны куркытмый.

—Калмаска! Җәһәтрәк атла!

Алан-йолан каранып, солдатлар алга бара. Менә берзаман ачыклыкка, тигез җиргә килеп бастылар.

—Тукта! Тарал!

Алда, күз күреме җитәрлек ераклыкта, ясалма калкулыклар, күпер шикелле нәмәрсәләр, кыска баганалар, танк яки йорт макетлары.

Каршыда гына танк эзләре бихисап. Танкодром дигәннәре шушы икән. Ул гаять зур дүртпочмакны хәтерләтә. Еракта-еракта, танкодром артында, урман шәйләнә. Аннан да арырак, Пулково тирәсендә, һавада сирәк-мирәк кенә самолетлар күренгәли—берсе төшә, берсе күтәрелә.

Ротный, кече командирларны җыеп нидер аңлаткач, тегеләр үз отделениеләрен танкодромга каратып бер сафка тезделәр дә ни-нәрсә эшләргә кирәген аңлаттылар.

—Һәрберегезгә окоп казырга! Тирән булсын, иркен булсын!

Һәм егетләр коралларын, скаткаларын, противогазларын бер кырыйга салып куйдылар, аннары сапер көрәген эшкә җиктеләр. Баштарак бик җилле тотындылар, янәсе, кем алданрак казып бетерә. Ләкин аска төшкән саен җир катылана барды һәм чәч төпләре, аркалар тирләп чыкты, хәлсезрәкләр, пилоткаларын салып, бил каешларын ычкындырып, туктап-туктап ял итә дә башлады.

Габделнурның сафтагы урыны алдарак булганга, ул иң кырыйда иде. Алны-ялны белми җир чокыды. Рота командиры аның янына килеп, бер тын карап торды.

—Гаделжанов, ну-ка чүгәлә әле.

Егет мөмкин хәтле гәүдәсен җыебрак окоп төбенә чөмәште.

---

*Дәвамы. Башы үткән санда.*

—Яхшы. Тагын бер ун сантиметр казысаң, таман була. Дәвам ит.

Габделнур, дәртләнеп, янә сапер көрәге белән жир "кимерергә" кереште. Берзаман, нинди тавыш килә икән, дип алга караса, еракта күренгән калкулыкларга таба бер-бер артлы менә-төшә өч танк бара. Аларның гөрелтесе монда өзек-өзек килеп ирешә, чөнки танклар калкулыкка үкерә-үкерә меналәр—артларыннан куе кара төтен болыты бөркелеп-таралып кала, ә аска төшкәндә тавышлары бөтенләй ишетелмәс була.

Бүтәннәр дә, эшләреннән туктап, танкларны күзәтәләр иде. Менә бермәлне танклар, бер рәткә тезелеп, нәкъ Габделнур казыган окоп турысындагы юлдан бирегә таба килә башладылар.

—Барыгыз да окопларга!—дип кычкырды рота командиры.

Габделнур чүкте. Окоп кашыннан чак кына башын калкытып, алга карады. Ажгырып киләме килә авыл өе хәтле, кырык-илле тонналы "корыч айгыр" нәкъ Габделнур өстенә. Ул якынайган саен егет, муенын жыерып, ирексездән башын жилкәсенә батырды, гәүдәсе кечерәеп калгандай тоелды. Ә танк килә: үкереп, жир селкетеп, ажгырып... Изәм, сытам бөтен дөньясын, башыгызны бетерәм, дигәндәй якынаюын дәвам итә. Торып йөгерә алмыйсың—приказ. Дөрес, танклар йөри торган юл Габделнур окобына дүрт-биш адым кала борыла. Ләкин ул бит машина! Аның холкын белеп булмый... Башына икеле-микеле уйлар килсә дә, гәүдәсе үзеннән-үзе жиргә сеңсә дә, Габделнур окоптан карап торуын дәвам итте.

Өзлексез әйләнеп торучы киң чылбырларыннан алга таба коры балчык, тузан коела, яссы түгәрәк башня уртасындагы бүрәнә юанлыгы озын тубы алга төбәлгән... Һәм, инде окопка килеп житте, солдатны сытты дигәндә генә, танк кырт кына сулга борылды. Габделнур жинел сулап куйды, чак кына калкынды. Окоплардан берәм-берәм башлар күтәрелде. Сынау әле моның белән генә бетмәгән икән. Янәшәдә генә басып торган рота командиры, солдат каршына килеп, кулындагы кечкенә йомры туп кебек шартлату пакетының шнурына ут төртте дә, Габделнурның артына, окопка ташлады. Үзе күзен алмыйча карап тора башлады. "Ни булса, шул булыр",—дип, Габделнур да окоп кашы аркылы ротныйга күзен терәде. Кинәт артта шартлау авазы янгырады, аркасына һава дулкыны килеп бәрелде. Ул бермәлгә генә күзен йомып алды. Ротныйның елмаеп торганын күргәч, үзенең дә ирен читләрендә елмаю галәмәте чагылды.

Бераздан команда янгырады.

—Сафка тезелергә!

Шинель "камытларын" баш аркылы киеп, сапер көрәге һәм противогазларын янтыкка жайлап беркетеп, кулларына карабиннарын тотып, сафка бастылар. Командир шактый озак нотык сөйләде, беренче сугышчан заданиены үтәүләре, чирканчык алулары белән котлады, мактау сүзләрен жәлләмәде. Габделнурга һәм тагын ике солдатка рәхмәт белдерде.

—Служим Советскому Союзу!—диделәр егетләр.

Ә берәү, танктан куркып окоптан чыгып качкан, куаклыкка таба йөгергән икән.

Командир:

—Беркайчан да алай эшләмәгез,—дип, әлеге солдаттан бигрәк, бүтәннәргә дә сабак булсын өчен, барысына да мөрәжәгать итте.—Дошман пулясы сезне бик тиз куып житәчәк... Сез—булачак кече командирлар. Үзегез үрнәк булырга тиеш...

Аның вәгазе шактый озакка сузылды.

Аннары ротный хәзер нишләргә тиеш булачакларын аңлатты.

—Задание тагын да катлаулана,—диде ул.—Сезнең бурыч шуннан гыйбарәт: каршы килгән танк астында калып, ул үтеп киткәч тә сикереп торырга һәм

яндыргыч катнашма тутырылган шешәне, бу очракта гранатаны, танкка ыргытырга!

Ротный кат-кат саклык чаралары турында кисәтте, әгәр кем дә кем үз-үзенә ышанмый икән, иң яхшысы, урыннарыннан кузгалмаска кушты.

—Танкларның тизлеге бу юлы артык зур булмаячак, алар интервал калдырып, берәмләп кенә киләчәк, ләкин барыбер ул машинаны секундның ничәнчедер өлешендә генә туктату мөмкин түгел. Шуңа күрә бу очракта, мин әйтер идем, сак була белү—үзе иң яхшы батырлык. Мин сездән шуны таләп итәм.

Солдатлар бер-беренә карашып алдылар. Барысы да алга куелган бурычны дөрес аңлый: монда максат танкны шартлату, юк итү түгел, ә үз-үзенне сугышка, тәвәккәллеккә әзерләү, танк хәтле танктан да шөлләмәскә, куркып калмаска өйрәтү.

—Иң беренче отделение командирлары бу сугышчан бурычны үти, аннары—сез.

Габделнур әчке бер дулкынлану кичереп алды һәм үзенең тәвәккәлләячәген аңлады. Менә кайда сынала солдат, тез буыны ныкмы-түгелме икәне ачыклана. Бу инде сиңа тыныч залда кино карап, совет солдатларына сокланып, аларның батырлыгын хуплап кул чәбәкләп утыру гына түгел. Синең үзеңнең дә кемлегенне күрсәтер сәгать житте. Чөнки булачак кече командирларга бу хакта, мондый бурычлар турында Кронштадтта да кат-кат әйткәннәр, бәйнә-бәйнә сөйләгәннәр иде. Рухи яктан һәрберсе әзер сыман күренде. Ләкин менә сынау вакыты житкәч, кайбер егетләрнең йөзендә каушап калу, икеләнү, күзләрендә курку галәмәте дә чагылды. Әйе, сүз сөйләү, лаф ору—бер нәрсә, ә үзең тыныч кына, артык шапырынмыйча гына ниндидер гамәл кылу—икенче. Күрәсен, сугыш вакытында батырлык күрсәткән егетләр дә әнә шул мизгелгә гомер буе (хәер, егерме яшьлек егетләрнең яшәүләрен, зурдан кубып, гомер буе, дип әйтеп була микән, алар бит әле яши генә башлаган!) әзерләнәләр. Юк, алар, менә мин шушы минутта фәлән итәрмен, төгән итәрмен, дип уйламагандыр, ә яшәү рәвеше, ата-ана, мәктәп, пионер, комсомол тәрбиясе, аларны чолгап алган мохит, укыган китаплар яки караган кинолар кирәк чакта шул юлга этәргәндер. Шулар нәтиҗәсендә каһарманлык кылу юлына басканнардыр, бәлки шул адымны ясарга мәҗбүр булганнардыр.

Отделение командирлары берәм-берәм һич куркусыз танклар астына ташланып, нәкъ ротный әйткәнчә, сикереп тордылар да гранаталарын танкка тондырдылар. Монда бит әле гранатаны китеп баручы танкка тидерергә дә кирәк иде, ул сине көтеп тормый! Бары бер сержантныкы гына "корыч айгыр"ны куып житә алмады...

...Габделнур танк үтәсе юл кырына тузанлы балчык өстенә сузылып ятты, башын чак кына күтәрде. Килә. Ротный тизлекләре артык зур булмас дигән иде, ә бу ажгырып нәкъ аның өстенә килә. Бер генә мизгелгә егетне икеләнү тойгысы биләде, ирексездән жиргә сеңәсе, башын иеп, аны куллары белән тотасы яки торып йөгерәсе килде. Ләкин ул бик тиз үз-үзен кулга алды. Ничә адым калгач тиз генә ике гусеница арасына ятасын, башын каплыйсын, аннан ничек сикереп торасын күңеленнән янә бер кабатлады. Ә танк килә... Алагаем зур, чылбырлары киң... өлгерә алырмы?.. Һәм... инде килеп житте дигәндә генә Габделнур, калкынып, күз ачып йомган арада гәүдәсен сулга таба атты—танк астына ташланды. Авылда күпер астында утырганда өстән трактор узып киткәндәй куркыныч булды... Ләкин уй-хисләргә бирелергә вакыт юк... Илле тонналы тимер аждаһа үтеп китү белән сикереп тә торды һәм, кырт борылып, уң кулында кысып тоткан гранатаны бар көченә танкка ыргытты. Граната башня төбенә үк барып төште, ләкин шартламады. Хәер, монысы инде Габделнурның фантазиясе генә иде. Чөнки аның эчендә шартлаткыч матдә дә, ядрә дә юк, ул—уенчык граната гына... Ләкин барыбер

бу тию—танкны юк итү, җиңүгә бәрабәр иде. Танкны гына түгел, ә үзүзеңне җиңү иде. Моннан соң инде кеше күзенә күренергә дә оят түгел, күзгегә карап, «их син, булдыксыз, җебегән», дип ямьсез кыяфәтеңне дә шелтәләүнең кирәге калмый. Чөнки син җиңдең: куркуыңны, икеләнү-шикләнүләреңне, кадерле җаныңның кайчагында бер мизгелдә генә булып ала торган ваклыгын... Моннан соң син гомер буе үкенү хисләре кичермәячәксең, кешеләргә туры карарга кыймыйча яшәмәячәксең, чөнки син нидер эшли алырга, кирәк чакта утка-суга керергә сәләтле икәнеңне беләсең... Әйе, бу мизгел зур җиңүгә тиң иде!

Ләкин бүген күрәселәре әле моның белән генә бетмәгән икән. Резин көпчәкле арбага көйләнгән кыр кухнясы янында тамак ялгап, беркавым ял иткәч, төштән соң сугышчан уен башланды.

Рота командиры, саф алдында йөренеп:

—Хәзер—техника заманы, шулай булса да солдат һәрчак үзенең физик көченә дә ышанырга тиеш,—диде.—Пуля—юләр, штык—молодец, дип юкка гына әйтмәгән Суворов. Кул сугышы алымнарын да яхшы үзләштерергә омтылыгыз. Аннары, Кутузовның: «сабырлык һәм вакыт—менә минем сугышчыларым—баһадирларым!» дигән сүзләрен дә онытмагыз. Һәр нәрсәнең үз моменты була. Обстановкага карап эш итегез, теорияне практикада кулланыгыз.

Һәм куаклык, әрәмәлек арасында, чытырманлык эчендә бер отделение икенчесенә каршы "сугышырга" тотынды, разведчиклар "тел" алырга тырыштылар. Габделнурлар каршы як отделениесының солдатларын "кырып бетереп", командирларын "тел" итеп алдылар. Таза гәүдәле сержант тиз генә бирешмәде. Габделнур һәм тагын икәү мышный-мышный аның өстенә ятып, кул-аякларын бәйләделәр. Алар бу шөгыльне шулхәтле тырышып, бирелеп башкардылар ки, хәтта үзләрен сугыш киноларындагы кыю разведчиклар итеп тоя башладылар, онытылып киттеләр. Күрәсең, егетләр аны катырак бөтереп алганнар, сержант аты-юлы белән сүгенә үк башлады.

—Җибәрегез!—дип кычкырды ул.—Чишегез!

Ләкин, кулга бер эләккәч, андый кадерле "тел"не җибәрү кая! Сержант күпме генә чәбәләнмәсен, ай-ваена карамыйча, Габделнурның сыртына салып, "штаб"ка алып кайтып тапшырдылар.

Ара шактый бозылырга мөмкин иде. Шулай да үз отделение командирлары ничек кирәк алай бәхилләтте булса кирәк дустын-коллегасын, сержант кабат буза куптармады, Габделнурларга бәйләнмәде, ачу сакламады.

Кечке якта танкодромда мәхшәр купты. Танкистларның үз расписаниеләре буенча өйрәнүләр билгеләнгән икән: пулемет тырылдаталар, бөтен тирә-юньне дер селкетеп (палатка тәрәзәләре зыңлап тора) туптан гөрселдәтәләр. Берсенең авазы таралып бетүгә, икенчесе тондыра. Кайчагында бер-бер артлы дөп тә дөп, бух та бух бәрәләр генә. Әйтерсең, өрәзлексез күк күкрәп тора. Ләкин яшен яшьнәгәне—күктә кылыч яки камчы уйнатканнары күренми, хәтәр ут баулары һаваны ярып җиргә төшми... Бик озак тыңлап ятты Габделнур бу өйрәнүләрнең авазын...

Чөнки бу гөрселдәүләр ана Чупай таш карьерында эшләгән чорын хәтерләтте. Таш шактый тирәндә ятканлыктан, аның өстендәге җир катламын алырга кирәк. Ә кыш көне экскаватор-бульдозерларга җир кимерүе читенгә туры килә. Шуңа күрә кечкенә буровой ярдәмендә башта шурфлар тишелә. Махсус чакырылган белгечләр әлеге тишекләргә тутырылган аммоналны бикфорд шнурлары сузып шартлаталар. Ул вакытта карьерда эшләр туктатыла, кешеләр читкә китә, будкаларга керә. Шартлау бик көчле була, каты балчык кантарлары әллә ни ерак атылмаса да, вак кисәкләр шыбыр-шыбыр будка түбәләренә коела, әллә кайларга оча иде...

Палаткада йокыга китә алмыйча кыбырсып яткан яшь солдатның да уйлары

еракларга оча: Әлмәткә барып җитә, Рәйсәнәләр өе тирәсендә чуала башлый...

...Бер михнәтнең бер рәхәте була, дигәндәй, җәйге лагерьга килеп ике атна яшәгәч, шимбә-якшәмбе көннәрне аларны, машиналарга утыртып, экскурсиягә алып киттеләр. Царское селода булып, Петродворец фонтаннарын карап йөрделәр. Ял көне, кайткач, Габделнур өчен тагын сөенеч—Рәйсәнәдән хат.

Кыз җылы гына хат юллаган солдат егеткә. Әшен, өйдәге хәлләрен тәфсилләп язган, Сабантуйлар җитүен дә искәрткән. Кыскасы, Габделнурның түбәсе күккә тиде хат укыгач. Йөреп кайткан экскурсияләрдән алган тәэсирләре суынып та җитмәгән, шуның өстенә тагын бер куаныч. Ул түзмәде, палаткада берүзе генә калгач, шундук хат язарга кереште. "Исәнме, Рәйсәнә! Сәлам хатынны алдым. Рәхмәт. Мин синең өчен бик шат. Үземнең хәлләр дә әйбәт, хезмәт дәвам итә. Без әле һаман өйрәнүләрдә. Мин сиңа алдагы хатта язган идем. Бүген менә ял көне, тагын экскурсиядән кайттык, патшаларның җәйге ял итү урыннарын карап йөрдек. Петергофның (ә аны Русский Версаль дип йөрткәннәр) бакча-паркы гаять зур, Фин култыгына хәтле канал казыганнар, шлюзлар бар, фонтаннар атып тора, төрле зурлыктагы дворецлар, павильоннар—ни генә юк. Олы каскад, Түбән каскад дигәннәре аеруча нык тәэсир калдырды. Андагы сыннарның саны-исәбе юк, һәрберсе алтын белән йөгертелгән, сап-сары. Ут биреп торучы Прометей да, мөгезле егет тә, ялангач хатын-кызлар да бар. Бигрәк тә Самсон дигәне шаккаткыч: арсланның авызын каерып тора, көчле, гайрәтле. Һәр җирдә фонтан—кояш нурында су бөртекләре уйный, салават күпере хасил була, гаҗәеп манзара инде. Драконнар каскадында зур-зур шахмат такталары ята. Их Рәйсәнәм, сиңа да аларны күрсәтәсе иде! Ул матур җирләр сиңа да бик ошар иде! Бигрәк тә кытай ефәге белән бизәлгән бүлмәләрне күрсәң, ушың китәр иде...

Мондагы каскадлар Европа илләрендә күптәннән булган икән, Петр Беренче, шулардан күреп, тагын да матуррак итеп эшләткән. Александр Бенуа, таң калып, болай дип язган: "Зур каскад—ул дөнья һәм галәм моделе".

Рәйсәнә, сугыш вакытында мәшһүр, зиннәтле Екатерининский дворецны фашистлар конюшня иткәннәр, янтарь кабинетның бер ташын да калдырмыйча урлап алып киткәннәр. Әле булса табылганы юк. Ә бит ул янтарь панноларны Петр патшага Пруссия короле Фридрих Беренче бүләк иткән була. Немецлар үз бүләкләрен үзләре урлаганнар. Без шактый озак йөрдек, бөтенесен диярлек карадык. Трон залына кергәндә аякка киндер бахилла кидерделәр. Син, дагалы кирза итек белән шул затлы җиргә кертмәсләр инде, диярсең. Юк, гражданскилар да шулай керә. Ул соклангыч паркет идәнгә аяк басарга да читенсенәсең. Әле тау куышы—грот бар. Ул серле, сихри һәм куркыныч. Грот эчендә виноград һәм башка җимешләр куелган өстәл тора. Кулыңны сузсаң, фонтан сиптерә башлый. Кеше куркып китә... Гроттан чыкканда өстән су ага. Ә инде Царское село дигәнен дәреслекләр буенча хәтерлисеңдер, анысы лицей һәм Пушкин белән бәйләнгән. Булса да була икән могҗиза, дип уйлыйсың боларны карагач. Башка төрле уйлар килә. Күпме художник, скульптор, төзүчеләр аны эшләгән, никадәр көч салганнар... Минем кичәле-бүгенле күргәннәрне бер утыруда гына язып бетерерлек түгел. Икенче хатка да калсын. Очрашкач, барысын да берәмтекләп сөйләрмен әле, ямә, бәгырем..."

## IX

Рәйсәнәдән килгән хат Габделнурның күңелен күтәреп, мәхәббәт учагына ялкын өстәп, яшь йөрәген тагын да ешрак, сөенебрәк тибәргә мәҗбүр итсә, Хөрмәтнең хаты егетне пошаманга салды. Габделнур бер-ике көн үз эченә бикләнеп, килеп туган хәлне бөтен тулылыгы белән анларга тырышты. Әйе, үзе генә. Чөнки киңәш-табыш итәр кеше юк. Гәрчә, кече командирлыкка

бергә укучы ярыйсы гына төпле егетләр бар, отделение командиры да аны чит итми. Ләкин бу мәсьәләдә алар ничегрәк фикер йөртерләр, ниндирәк кинәш бирерләр—Габделнур өчен караңгы. Моны белеп булмый. Гомумән, аларны катнаштыру кирәкме? Дусты бит хатны ана атап кына язган. Шуңа күрә Габделнурның кемгәдер, чит кешегә эч серен чишәсе килмәде. Бер баш—яхшы, ике баш—тагын да шәбрәк, дисәләр дә, никтер күңеле тартмады.

Хөрмәт тә, Габделнур кебек, каравыл ротасына эләккән һәм хезмәтеннән канәгать иде. Һәрхәлдә, алдагы хатлары шул хакта сөйли, мон-зар сизелми иде. Хәер, авыл малайлары беркайда да киреләнеп маташмыйлар, "кәҗәләнеп" тормыйлар—кая җибәрсәләр, кая куйсалар шунда тырышып хезмәт итәләр, авырлыкларга—түзем, теләсә нинди шартларга да тиз ияләшәләр, нинди генә кыен хәл тумасын, сыкранмыйча аны ерып чыгалар. Билгеле, Хөрмәт кебек таза тәнле, шат күңелле егет бер җирдә дә югалып калачак, ким-хур булачак түгел иде. Ләкин Габделнурның күңел түрендә, бәлки кайсыдыр почмагында гынадыр, гел бер шик йөрде. Әнә шул шөбһәләнү аны гелән бимазалап, йөрәк тирәсен тырнаштырып торды, аңа тынгы бирмәде. Бу—Хөрмәтнең Трофимов белән бер частька эләгүе иде. Һәм юраганы юш килде. Дустының соңгы хаты моны раслады.

Хөрмәт, сәламнәр юллап, Габделнурның хатын алуын язганнан соң, болай дәвам иткән: "Яшьти, госпитальдә яткан көнем. Трофимов, көч белән җинә алмагач, аркага пычак кадады. Кайда, кайчан, ничек икәннәрен язып тормыйм. Аны нишләтерләр, белмим. Прокурор на всю катушку бирмәкче җәзаны. Минем исем китми. Теләсә нишләтсеннәр. Частьта гына калдырмасыннар. Иначе мин аны яшәтмим".

Шушы юлларны укыгач, Габделнур туктап калды. Янә хатка күз салды, ары таба укуын дәвам итте: "Хәтерләмим, исерек идем, дип әйтә икән. Юлит, сволочь! Бөтенесен белеп эшләде". Бу юллар егетнең әллә ни исен китәрмәде. Хөрмәтнең шундый бәлагә таруы, ярасы ничек кенә тирән булмасын—инде кире кайтара торган түгел, булган хәл. Габделнурны иң нык борчыганы; шик-шөбһәгә салганы, "иначе мин аны яшәтмим", дигән сүзләр иде.

Үчен кайтарасы килү аңлашыла. Бигрәк тә Хөрмәт кебек типсә тимер өзәрдәй егет ул хәшәрәтне болай гына калдырмас. Ләкин бер бәладән котылып, икенчесенә килеп эләгүе ихтимал: үзенең йә дисбатка, йә таш капчыкка килеп кабуы бар. Шуңа күрә мөмкин хәтле йомшак итеп, мин-минлегенә тимәскә, аңа "акыл сатуын" сиздермәскә, бер үк вакытта хәтерен калдырмаска тырышып, яшьтәшенә хат язды. Әлбәттә, ул да җитмеш яшьлек бетәшкән карт түгел. Үзе дә нәкъ Хөрмәт кебек уйлый һәм эшләр дә иде. Ләкин ахыры ни белән бетәр? Нәрсәгә алып барыр да, нәрсәгә китереп җиткерер андый үчләшү, башсызлык? Хөрмәт бит бу дөньяда ялгызы гына түгел. Аны өйдә ата-анасы, туганнары, ниһаять, сөйгән кызы көтә... Һәрхәлдә, дусты аны дөрес аңлар шикелле...

Кая барсаң да бер кояш, дигән шикелле, Кронштадтта да июль ае Габделнурның туган ягындагы кебек: көннәр җылы, кояшлы. Дөрес, шәһәр Фин култыгында урнашканлыктан, өзлексез диярлек салкынча җил—бриз исеп тора. Ул, диңгез өстен дулкынландырып, ярга таба эреле-ваклы дулкыннар тәгәрәтә. Кояш, су өстендә күзләрне чагылдырып, төрле төсләргә кереп, уйный. Озын канатлы акчарлаклар да уйный сыман, ләкин боларның шөгыле үзгәрәк—алар балык язмышы белән уйный.

Габделнур белән дә язмыш үзенчә уйный иде. Ул, хәрби хезмәткә алынган, фәкать шул эшнең остасына әверелеп, иңенә мылтык асып, өч ел буена илен сакларга тиешле солдат, бүген авыл агайлары яки урманчылар башкара торган гап-гади эшкә—урман кисәргә барырга тиеш. Тиеш икән, димәк, шулай кирәк. Ахыр чиктә, алар мичкә ягар өчен утын әзерләргә бармыйлар—ул

хәрби максатлар өчен кирәк икән—яр буена өстәмә маяк мачтасы куясылар. Хәер, алай булмаса да командирлар әмеренә буйсынмыйча чараң юк.

...Машина тимер юл белән янәшә сузылган асфальттан бара, дачалар, авыллар кала. Монда тоташ агачлык: нарат, чыршы, каен, юкә, чәчәк атып утыручы сирень. Габделнур бер ят агач та күрде. Ул аның туган авылы инеше буендагы тәбәнәк таллар биеклегендә, вак ботаклары һәм яфраклары өстә генә, ябалдаш алагаем зур зонтик кебек кабарып-күпереп тора, ә аста—карасу төстә бик күп ботаклар, әйтерсең тал агачының аскы яфракларын сыдырып алганнар. Хәер, аскы өлешендә вак ботаклар да юк.

Юл буйлары чиста, агачлар арасында өстәл биеклеге валуннар—зур-зур йомры, шома ташлар күренә. Алар элек-электән, бозлык чорыннан анда калганмы, әллә аларны матурлык өчен махсус куеп чыкканнармы—эш анда түгел, һәрхәлдә, алар урман эчен, юл буйларын ямьләп, үзенә бер үзгәлек биреп торалар, күзне иркәлиләр. Бу тирәдә элек финнар яшәгән диләр.

Кронштадт турысындагы Лисий Нос, Горская кебек кечкенә шәһәр һәм поселоклар, уң якта Разлив күле, ә юлның су ягында кайчандыр Ленин бабай качып яткан печән куышы—шалаш һәм, зур автобуска төялеп, аны карарга килгән чит ил туристлары да артта калды. Арырак Сестрорецк, Солнечное, Репино, Комарово, Зеленогорск кебек эреле-ваклы кала-салаларны машина выжлап кына үтте, Выборг юнәлешенә таба җилдерүен дәвам итте. Юл әле урман эченә керә, әле аланлыкка элдертә, әле Фин култыгы ярына ук килеп чыга. Анда, очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп яткан гаҗәеп күренеш хасил була.

Күп тә үтмәде, машина янә урман эченә кереп китте. Тар гына юлдан шактый баргач, кабат яр буена килеп чыкты, ниһаять, туктады.

...Палаткалар кору, урнашу, ашау-эчү мәнфәгатьләрен кайгырту, балта-пычкылар кайрау—болар барысы бергә эшләнде һәм икенче көнне иртүк яшь, таза егетләр урман кисүгә керештеләр.

...Урман эченә, гаять зур өчпочмак ясап, көннән-көн күбрәк керә бардылар. Эше авыр булса да—агачларны аударасы, ботакларын чабасы, үлчәп кисәсе, читкә ташыйсы—табигате, яшәү шартлары уңай булганлыктан, зарланучы сирәк иде. Көндез, төшке ашка туктаган арада диңгезнең саф суында коенып, тәннәрен сихәтләндерделәр, кичләрен взвод командирына балык тотарга булыштылар... Кыскасы, эш тә барды, ял да иттеләр.

Взвод командиры балык тотарга бик әвәс кеше булып чыкты. Ул һәркөн диярлек тамаклык балык эләктерә иде. Кайчагында аның янына Габделнур һәм башка егетләр дә килеп утыра. Балыкларны куркытмас өчен шыпырт кына сөйләшәләр. Кулында кармак сабы, күзе су өстендәге калкавычта булса да, күбрәк ул сөйли. Табигатьнең һәр мизгелен аңлап, алда ни буласын белеп-сизеп тора бугай. Мәсәлән, яр буена акчарлаклар килеп утырганны күрсә, ул:

—Акчарлаклар ял итә, димәк, һава бозылачак,—ди.

Һәм аның сүзе дөрескә чыга.

Монда табигать бик күркәм, үзенчәлекле. Фин култыгына бер карыйсың, көчле җил исә, эре-эре дулкыннар, ак сыртларын кабартып, тәгәрәшә, икенче карыйсың, бигрәк тә иртәнчәк, өсте шулкадәр тыныч, еракка-еракка күз салсаң, су белән һава кисешкән урын—горизонт—бөтенләй беленми, әйтерсең кушылганнар. Кичке шәфәкъ—үзе бер тылсымга тиң вакыт.

Рейдта торучы сылу хәрби кораблар, Ленинградка килүче һәм китеп баручы зур ак теплоходлар—мондагы пейзажның аерылгысыз бер өлешләре.

Диңгез суы чиста, гәүдәң күмелгәнче керсәң дә су төбендәге ташлар, диңгез кабырчыклары аермачык күренә. Тирәнгәрәк кергән саен салкыная...

Урман кисү дәвам итә. Бәлки солдатлар эшләрен бетереп, сузып салынган өчпочмакны хәтерләткән ачыклыкны—маяк мачтасына кирәкле урынны—хәстәрләп тә куйган булырлар иде, ләкин көтелмәгән хәл килеп чыкты:

Ленинград егете Петровны агач басты.

Габделнур алардан еракта эшли иде. Кулдашлары белән шау-шу килгән якка йөгерделәр. Петровнын болай да ак чиста йөзе кәгазь кебек, анын жуйган, мангаеннан кан ага...

Машинага салып, госпитальгә озатканда ул әле исән иде.

Солдатлар бик кайгырыштылар.

—Исән калыр микән?

—Ничек алай килеп чыкты икән?

Взвод командиры:

—Юкка борчылмагыз, ул—исән!—диде ачу белән, чөнки таякның юан башы ана һәм бу арада көндезләрен гел югалып торучы рота командиры жилкәсенә төшәчәк иде.—Телегезне дә артык озайтмагыз. Барыгыз, эшегездә булыгыз.

Ләкин эш кайгысы түгел иде инде өлкән командирларда. Кронштадттан, кайтырга, диган әмер килгән. Тиз-тиз генә жыенып янә Кронштадтка кайтып киттеләр. Сүз күп булды: кемдер андый эштә тәжрибәсе булмаган шәһәр егетенен үзен гаепләде, кемдер солдатка урман кистерүне дөрес дип тапмады. Ни генә булмасын, Габделнурлар Петровны янадан казармада күрмәделәр. Терелүен терелгән, диделәр. Мөгаен, комиссовать иткәннәрдер. Анысын инде табиблар һәм командирлар хәл итә.

## X

Кронштадтта укуын әйбәт кенә тәмам итеп, Габделнур янадан үз частенә әйләнеп кайтты. Казармага кергәч тә ин башта коридордагы дневальный белән исәнләште.

Аннары:

—Ротный үзендәме?—дип сорады.

—Әйе,—диде телефон куелган тумбочка янында басып торган солдат.— Бар кер. Үзе генә бугай.

Габделнур коридор буйлап алга үтте. Ишек шакыды. Эчтән жавап килгәч, бүлмәгә узды. Капитан погоннары таккан булса да, бу аны Кронштадтка укырга димләп озаткан рота командиры түгел иде. Ләкин бүлмәсе дә, өстәле дә, дивардагы дөнья картасы да шул ук, дневальный да «үзендә», диде. Димәк, честь биреп, үзенең кем икәненне, нигә керүенне анлатудан башка чара юк.

—Иптәш капитан, ефрейтор Галелжанов хезмәтен дәвам иттерү өчен ротага кайтты!

—Анламадым. Син кем?—дип сорады нәрсәдер язып утырган капитан конгырт төстәге кыска чәчле башын калкытып, сөзеп карап.

Төз гәүдәле, ябык йөзле ефрейторны анын беренче күрүе иде, аптырабрак баштанаяк карап чыкты. Хәер, янаклары тулышып торган, утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге офицерны Габделнурнын да монарчы бу частьта очратканы юк иде. Солдат үзенең кем икәнен, каян кайтуын хәрбиләрчә кыскалык һәм төгәллек белән, әмма анлаешлы итеп әйтеп бирде.

—Ә-ә, хәтерлим, элекке ротный әйткән иде,—диде капитан һәм, бераз уйланып торгач, дәвам итте.—Син хәзергә үз отделениеңдә булырсың. Аннары, «картлар» киткәч, күз күрер.

Әйе, кабинет шул ук, ни жиһазлардан, ни дивардагы кәгазь-фәләннән— берниндн үзгәреш юк. Ә барыбер нәрсәдер житми: ят бүлмәгә килеп кергән шикелле хис итте үзен Габделнур. Комбат белән элекке ротный кодалап, аны мактый-мактый юмалап укырга жибәрделәр. Дөрес, мәжбүр итмәделәр. Габделнур, алар сүзенә колак салып, китеп барды, укуын яхшы гына төгәлләп, ан-белем алып кайтты. Ә монда... Ниндидер авыр тойгы биләп алды солдатны,

билгесезлек, бушлык дип әйтсенме... Үзен кирәкмәс кеше кебегрәк хис итте. Әлбәттә, ул ата-анасы янына түгел, элек хезмәт иткән һәм хәзер дә итәчәк хәрби частька әйләнеп кайтты. Аны колач җәеп каршыларга тиешләр дигән уйдан ерак тора. Ләкин ул шушы ротадан, шушы казармадан, җан дуска әверелә башлаган иптәшләреннән аерылып, билгесезлеккә китеп барды бит... Яңадан әйләнеп кайтырга дип. Аны җибәрделәр. Булачак кече командир кайтыр дип, аңа зур өметләр баглап торганнардыр дисә, бик нык ялгышкан икән. Хәер, бу офицер бит яңа кеше. Аны гаепләп тә булмый. Әгәр мәслихәт биргән элеккесе шулай кырыс каршыласа...

—Китәргә рөхсәт итегез?

—Бар.

Казарма буш. Солдатлар кайсы дәрестә, кемнәрдер каравылда, берише нарядта икән.

Дневальныйдан:

—Старшина мондамы?—дип сорады.

—Юк.

Шуннан Габделнур түргә узды, каптеркага керде. Өлкән дусты белән кочаклашып диярлек, бик җылы күрештеләр.

—Oho,—диде Нурмөхәммәтов аны күздән кичереп,—әллә үсеп тә киткәнсең инде. Дәрәҗә дә биргәннәр.

—Син үзең дә тик ятмагансың,—дип көлде Габделнур егетнең погоннарына ишарәләп.—Кече сержант. Авылга кайткач, бөтен кызлар синеке булыр инде.

—Сорап алмадым, биргәч—каршы килмәдем,—диде гәүдәсе бераз калыная төшкәнгәме тагын да кечерәебрәк калган сыман күренгән Нурмөхәммәтов.

—Монда үзгәреш булган икән.

—Әйе. Утыр, нәрсә казак сыман басып торабыз. Кайтуың хөрмәтенә әзрәк тотабызмы? Минем күптәннән бер акбаш ятадырые. Сине көткән икән.

—Юк. Соңрак. Әле сыңар аяк кына кергән килеш, урнашмаган да бит.

—Дөрес әйтәсең, кул куям. Киләчәктә дә шул линиядән тайпылма... Монда ротный гына түгел, комбат та бүтән.

—Ничек? Ә Зирюк кайда?

—Югарырак урынга алдылар. Ротный академиягә керде.

—Ничего себе!

—Ул бик белемле, толковый офицер иде бит, хәрбиләр токымыннан, үсәсе килгәндер.

—Безнең егетләр барысы да исән-саумы?

—Әйе. Литвалы өч егет пожарныйга күчтеләр. Бер ай элек.

—Шулаймыни? Кемнәр?

—Синең дус Заранка, тагын Красаускас белән Бразаускас.

—Алай икән.

—Син отделение аласыңмы сон?

—Белмим. Бик атлыгып тормыйм. Дөресен генә әйткәндә, үз яшьтәшләрем өстеннән командовать итәсем дә килми. Әле биргән кеше дә юк. Кайттым гына бит. Ротный, сез киткәч, ди.

Беркавым сөйләшеп утырдылар. Нурмөхәммәтов дембельгә әзерләнә икән, беренче партиягә эләкмәсә дә, икенчесеннән калмаска өметләнә, шуңа күрә кара погонга алтынсыман сары тасмалар тагып яткан көне. Габделнур белә: кызыл погонлы егетләр дембельгә дип караны әзерли. Юкса, монда «Ф» хәрефе белән кызыл погон да бик килешле, ярыйсы гына күренә. Ләкин кызыл погон—пехота билгесе—почетта түгел.

Чемоданын калдырып, коптеркадан чыкканда (дусты белән очрашуга карамастан) Габделнурның кәефе төшенке иде. Ләкин борын салындырып йөрү хәерлегә илтмәс, әле ике ел хезмәт итәсе бар, шуңа күрә яңа шартларга

жайлашырга, үз урыныңны табарга кирәк. Әйе, әлегә шушы котсыз зур бинада аның ятар урыны да юк, чөнки караватында бүтән солдат йоклыйдыр. Ул барысы бертөрле пөхтә итеп жыештырылган тимер койкаларга, алар арасындагы тумбочкаларга, ятканда киеменне жайлап салып куя торган артсыз урындыкларга караштырып, диварның зур тәрәзәләре өстенә һәм алар арасындагы буш урыннарга эленгән, беркетелгән портретларга, плакат яисә шигарьләргә күз ташлап, сарыга буялган такта идәнле казармадан чыгып китте. Янгын сүндерү командасына барып (ә ул хәрби шәһәрчек эчендә үк, моннан биш минутлык арада гына урнашкан), Заранкаларны күреп кайтырга иде нияте.

Ләкин тышта, баскыч төбендә, рота старшинасы белән бәрелешә язды, йөзгә йөз очрашты. Бөердән чыккан тавышы белән:

—Гаделжанов, ипләбрәк!—диде аны танып старшина һәм, киң елмаеп, кул сузды.—Әйләнеп кайтуың белән.

—Рәхмәт, иптәш старшина.

Рота старшинасының хәрби дәрәжәсе дә старшина, погонында «Т» хәрефенә тартымрак аркылы һәм буйлай калын сары тасма сузылган. Уртача буйлы таза гәүдәсен төз тота, калын мыеклары ике якка тырпаеп тора, козыреклы фуражкасын батырып кигән, куе яшел гимнастеркадан, аркылы-торкылы тар каешларны погон астына кертеп жибәргән, билендәгесе исә киң. Аның түшендәге орден-медаль ленталары дүрт рәт. Күкрәгенең уң ягын нәни байрак сыман гвардия значогы бизи. Коры кеше булса да, сугышта утны-суны кичкәнлектән гаделлеге белән аерылып тора иде.

—Кая юл тоттың? Ротныйда булдыңмы?

—Әйе, булдым. Әле болай гына чыгуым иде.

Солдат үзенең кай таба юнәлүен әйтеп тормады. Старшина аны үз артыннан ияртте. Ялгызы гына ротныйга кереп чыккач, Габделнурга бер буш койканы күрсәтте.

—Суслов әлегә лазаретта. Урын-жирен алыштыр.

Шулай итеп, иске казармада яңа тормыш башланды.

...Стадионда, сезон ябылуга багышлап, жинел атлетика буенча ярышлар үтәсе икән. Габделнурны, әле генә сержантлар мәктәбен бетереп кайтуын исәпкә алып, йөз метрга аерым йөгерергә һәм эстафетага да куйдылар, өстенә кияргә зәңгәр төстәге юка спорт костюмы, аягына жинел кеды бирделәр.

Стадионга частьнең бөтен подразделениеләреннән дә спортчылар, ярыш карарга дип хезмәттән буш офицерлар һәм «макаронниклар», аларның хатыннары һәм бала-чагалары жыелган иде. Егетләр күзләргә кыз-кыркын да килгән—алар бер читтә, аерым төркем булып торалар. Баш-башында ятьмәле футбол капкасы булган зур спорт мәйданы гөж килеп тора. Гравий жәелгән йөгерү юлларында тезләрен югары күтәрә-күтәрә бер урында таптанып, сикерә-атлый йөренеп, спортчылар ярышка хәзерләнә; музыка уйный.

Габделнур янгын сүндерү командасы егетләрен ерактан ук шәйләде. Ләкин алар арасында Заранка да, якташлары да (егет кичә алар янына барып кайтса да, иркенләп сөйләшә алмаган иде) күренмәде.

—Алар дежурда,—диде бер солдат аның соравына каршы.

Ярыш гаять каты булды. Матрослар арасында да шәп йөгерүчеләр байтак икән, ә сакчы этләр белән эш итүче солдатлар һәм янгынчылар элек-электән спорт ярышларында дан казана, бөтен тартыш алар арасында бара иде. Шулай да Габделнур да сынатмады: шәхси беренчелектә икенче урынны алды, эстафетада да өч этапта иң ахырдан килүче каравыл ротасын бу хурлыктан коткарды—унбер команда арасында бишенче урынга менгезде.

Ярыш беткәч аның янына бер офицер килде. Ул уртача буйлы, жирәнгә тартымрак саргылт чәчле һәм шул ук төстәге калын кашлы кеше иде. Бик әдәпле генә итеп исәнләште.

—Исәнмесез.

—Исәнмесез, иптәш өлкән лейтенант.

Габделнур үзенә карата шундый итагатьлек, хөрмәт күрсәткән ят офицерның сипкелле йөзенә текәлде. Күрәсең, өлкән лейтенант аның турында инде белә иде. Шуңа күрә ул әллә каян уравычтан килеп, боргалап маташмады, сүзне хәрбиләрчә кыска тотты.

—Мин янгын сүндерү часте башлыгы. Сезнең йөгерү миңа бик ошады. Безгә күчәргә теләмисезме?

«Дембель башланды бит, тагын китүчеләре бардыр»,—дип уйлады Габделнур һәм аның житди карашына, сүзләрен украиннарга тартымрак сөйләвенә дә игътибар итте. Беренче минуттан ук бу офицерга карата үзендә ниндидер эчке бер жылылык туганын тойды. Кыскасы, әүвәлге күрешү унай тәэсир калдырды. Ләкин ул бит солдат, житмәсә әле генә кече командирлар мәктәбен бетереп кайтты. Ә аны зур өметләр баглап, кайткач кече командир итәчәкләренә исәп тотып жибәрделәр. Үзен яхшы яктан күрсәтсә, тора-бара дәрәжәсе дә үсү ихтималы бар... Кыскасы, Кронштадтка ул әнә шундый перспективаны истә тотып озатылды. Дөрес, аны кодалаган капитан да, подполковник та хәзер юк. Ә каравыл ротасы бар, ул беркая да китмәгән дә, таралмаган да. Андагы замполит, старшина, взвод һәм отделение командирлары, ниһаять, солдатлар үз урынында.

Күрәсең, Габделнурның дәшми торуы озаккарак сузылды.

—Мин ашыктырмыйм, уйлагыз!—дип өлкән лейтенант үзенең спортчы егетләре янына карап алды, китәргә ашыга иде булса кирәк.

—Мин каршы түгел, риза!—диде Габделнур, ниһаять, телгә килеп.—Ләкин мин үз иркемдәге кеше түгел. Кучүне үзем генә хәл итә алмыйм.

—Мин анлыйм. Мөһиме—сезнең теләк. Калганын үзем жайлармын.

...Кич белән Габделнур нарядка билгеләнде. Дөресрәге, патруль булып йөрергә тиеш иде. Сәгать ун тулганда, хәрбиләр телендә егерме ике дә ноль-нольдә, ул киенеп, шинелен кысып буган бил каешына штык-пычак тагып, казармадан чыгып китте һәм ана хәтле йөргән патруль солдатны алыштырды. Вазифа шуннан гыйбарәт: пекарня, котельня, кибет тирәләрен караштырырга. Аерым будка ише нәрсә юк, шуна күрә ял итәргә, жылынырга кая тели, шунда кереп чыга ала.

Ноябрь житсә дә әле көннәр үзәккә үтәрлек салкын түгел. Моннан бер-ике көн элек явып киткән юеш кар эреп юкка чыккан, ләкин кояш саран яктыртканлыктан асфальт кибеп өлгермәгән. Баганалардан, зур тәрәзәләрдән төшкән ут яктысында чокыррак төшләргә жыелган су ялтырый. Каен, өрәнге, тупыл кебек агачлар инде шәрәләнгән, ә нарат һәм чыршы үз гүзәллеген дә жуймаган, хәрби шәһәрчеккә дә ямь биреп утыралар. Клуб һәм командирлар яши торган йортлар тирәсендә әле яшьләрнең шау-шуы басылмаган...

Ул сәгать уникеләргә хәтле урамда киләп сарып йөрде; кичтән үк бикләнгән кибетнең солдат бияләе хәтле йозагы үз урынында, тәрәзәдән котельня учагынын яныл торганы күренә, пекарняда да эш туктамый, урамда шикле кешеләр күренми. Сул кулын чак кына өскә күтәреп сәгатенә карады: уникe туларга унбиш минут калган.

Габделнур тәвәккәлләп пекарня ишеген ачты. Чөнки ул алыштырган солдат казармага кайтып китәр алдыннан ана нишләргә икәнен, монда бер жайга салынган тәртипне искәрткән иде.

—Кыенсынып торма, ул шулай көйләнгән инде.

—Унайсыз бит.

—Син—беренче, син—ахыргы түгел!—диде солдат китеп барышлый.

Зур авызлы эссе мич каршында ак халатлы, юантык гәүдәле олы яшьтәге бер хатын мәш килә, икенчесе—яшьрәге, зифа буйлысы—әле генә мичтән

чыккан шакмаклы ипиләрне дивар буендагы киштәләргә тезә. Пекарня эче хуш ис—яна пешкән тәмле, бәрәкәтле ипи исе белән тулган. (Хәер, ул бөтен урамга ук таралган иде инде, ике сәгать буена Габделнурның борынын кытыклап, авыз суларын китереп торды.) Егетнең башы әйләнеп киткәндәй булды: гүя үз авылына кайткан да, үз өйләренә кергән. Нәкъ ул бәләкәй чактагы кебек, менә хәзер әнисе мичтән озынча кайнар шишара алыр да, аны сындырып бер түтәрәмен ана тоттырыр һәм ягымлы тавышы белән: «Аша, улым»,—дияр.

Юк шул, монда әнисе, юк! Шулай да таза хатын әниседәй мәрхәмәтле булып чыкты. Башындагы яулыгын төзәтеп, кул аркасы белән маңгаена тибеп чыккан тир бөртекләрен сыпырып, артына борылды.

—Настя, солдатка бер буханка бир,—диде ул исәнләшеп кыяр-кыймас ишек катында тукталып калган Габделнурга карап алгач.—Чәй дә сал. Утыр, солдат!

Уң кул якта почмагы кыршылган шакмаклы клеенка җәелгән кечерәк кенә өстәл бар иде. Аның өстендә стаканнар, чынаяк, чәйнек һәм чәй кабы, банка белән шикәр комы, калак ише нәрсәләр. Егет калҗыраган артсыз урындыкка килеп утырды. Яшь хатын өстәлгә, аның каршына китереп куйган кайнар ипине бармакларын пешерә-пешерә урталай сындырды. Аннары, кибән башын яратуы исенә төшкәч, яртысын тагын бүлде һәм кетердәтеп ашый башлады. Ипи сыныгыннан биткә җылы бөркелә, бераз чәйнәгәч, үзе авызда эри кебек. Күптән болай тәмле итеп кадерле нигъмәтне ашаганы юк икән. Тыгылмыйм тагы дип, вакыт-вакыт стаканның яртысы шикәр комыннан гыйбарәт булган чәйне калак белән болгаткалап һәм уртлап, күшәвендә булды. Ипинең яртысын тәгәлләгәндә чәе дә бетте. Настя тагын ясап китерде.

—Бик тәмле, рәхмәт!—диде Габделнур ипинең калган өлешен дә «хәл иткәч» һәм күбрәк олы яшьтәге хатынга карап әйтте.—Аяк-кулыгыз сызлаусыз булсын.

Хатын аның чыраена, акцент беләнрәк сөйләшүенә һәм соңгы җөмләсенең урысча бигүк төгәл һәм шома булмыйча колакка ятрак яңгыравына игътибар итте, ахры, кайдан, кайсы милләттән булуы белән кызыксынды. Егет әйтеп бирде.

Хатын өстәлгә якынрак күчте.

—Минем иремне сугышта бер иптәше үлемнән коткарып калган, синең якташың. Шәһәрен дә әйтә торган иде, хәтеремнән чыкты. Мавзолей сүзенә охшаганрак исем.

Габделнурның моңа бик күңеле булды һәм республикадагы ваграк шәһәрләрне атый башлады.

—Менә, менә, Мензелинск!—диде хатын сөенеп.—Кызганыч, ул татар егете Берлинны алганда һәлак була. Ирем гел сагынып искә ала иде. Хәзер үзе дә юк инде. Яралары күп иде шул...

Чыгып киткәндә бу миһербанлы апа солдатка тагын бер бөтен ипи сузды.

—Иптәшләреңә алып кайт!

## XI

...Бер атнадан ефрейтор Галелжановны янгын сүндерү частенә күчерделәр. Теге өлкән лейтенант тәки сүзендә торган: бөтенесен үзе хәл иткән.

Әйе, мондагы хезмәт, кем әйтмешли, шикәр түгел, бермә-бер авыр: катлаулырак та, хәтәррәк тә. Чөнки янгынның графигы юк, көне-сәгате дә билгеләнмәгән—теләсә кайсы вакытта машинага төяләп чыгып чабарга кирәк булачак! Яшерен, үтә дә мөһим һәм зур объект өстенә, әле хәрби шәһәрчек һәм гражданский халык яшәүче поселок, аңа терәлеп торган авыл да бар. Бөтенесе өчен фәкать ике машинасы булган команда җаваплы. Аннары, монда

кеше дә аз, расчетта һәркемнең үз урыны, үз вазифасы билгеле. Ләкин болар Габделнурны өркетми, киресенчә «хезмәт авыр булган саен ул—мактаулырак», дигән төшенчә егетнең аңына сеңдерелгән.

Аны егетләр белән таныштыргач, өлкән лейтенант бөтен хуҗалыкны күрсәтеп чыкты. Иваново шәһәрендә махсус хәрби училище бетергән бу офицер үз эшенең-хезмәтенең чын остасы булса кирәк, кул астындагы техниканы, җиһазларны бөтен нечкәлекләренә кадәр иренмичә тәфсилләп аңлатты.

—Янгын сүндерүчегә физик көч, җитезлек һәм курку белмәс йөрәк кирәк!—диде ул.—Ләкин башсызлык түгел! Саклык, бер-береңә ярдәмгә килү—безнең хезмәтнең төп шартлары, пожарный өчен иң мөһим сыйфатлар.

Габделнур шунда "пожарник" сүзе белән "пожарный"ның аермасын да белде. Авылда янгын сүндерүчеләрне пожарник, дип йөртәләр. Баксаң, пожарник түгел, ә пожарный икән алар. Чөнки янгынга дучар булып, хәер сорашырга чыккан кешеләргә әйтелә икән "пожарник" сүзе.

Офицер янгын сүндерүнең тарихына да кагылып үтте.

—Патша Алексей Романов 1649 елның 30 апрелендә "Шәһәр иминлеге турында" Указ чыгара. Шулай итеп, Россиядә профессиональ янгын сагы оештырыла. Ә Петр Беренче исә, гомумән, агачтан йортлар салуны тыйган. Шулай да янгыннар булып торган. 1812 елда, Наполеон шәһәргә кергәч, Мәскәү өч тәүлек яна. 1907 елдан исә мичкәле арбаларны машиналар алыштыра башлый, каланчалар төзелә.

Габделнур өлкән лейтенантның сүзен җөпләп, баш кагып кына утырды. Шулай да ул әйткәннәрнең кайберләре таныш икән. Лермонтовның: "Скажи-ка, дядя, ведь недаром, Москва, спаленная пожаром, французу отдана?..." дигән, уку программасына кертелгән юллары хәтеренә килде.

—Янгынны сүндерүгә караганда кисәтүе җинелрәк,—дип сүзен дәвам итте Лукъянчук.—Безгә объектны карап-тикшереп тору вазифасы да йөкләнгән. Анда игътибарлы булыгыз, тиешле-тиешсез урыннарга кермәгез, коралларга кагылмагыз, артык сораулар бирмәгез. Безнең бурыч—профилактика һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Бер атна эчендә Габделнур командирлар, Заранка кебек дуслары һәм бүтән солдатлар ярдәмендә каланчадагы тәрәзәләргә пычкы теше сыман киртләч җайланмалы баскыч—"штурмовка" куя-куя дүртенче катка менәргә, житен жинсәләр күтәреп тар гына бумнан чабарга (менә кайчан искә төшә икән ул малай чакта мәктәп ишегалдында турникта атыну, бүрәнәдән йөгерү, арканнан өскә үрмәләү, биек баскычтан фәкать куллар белән генә югары күтәрелү...), йөгереп килгән шәпкә ике метрлы коймa аша сикереп "очып" чыгарга өйрәнде. Ут сүндергеч белән дә үзлегеннән эш итә ала, жинсә башына кидерелә торган көпшә белән су сиптерергә дә булдыра ала. Монда вакыт секундлар белән генә исәпләнә! Сине өйрәтеп-тикшереп торучының кулыннан кесә сәгате (чылбырлы, "штамповка" дигән андый сәгатьне Габделнурның абыйсы Германиядән алып кайткан иде) шикелле түгәрәк, түшкә асарлык итеп бау таккан секундомер төшми.

Баскыч та, көпшә дә, кирәк чакта җинсәләрне тоташтыручы переходник-лар—барысы да дюралюмин дигән материалдан коелган икән. Чөнки, беренчедән, җинел, икенчедән, су тигәч тутыкмый, күгәрми.

Габделнур әйткән бер сүзне эләктереп алырга тырышты, тиешле инструкцияләрне һәм кәгазьләрне өйрәнде, һәр күнегүне җиренә җиткереп, шагыйрь әйткәнчә, эшкә чын күңел биреп башкарды; аз гына уңышка да куанды, нормативка сыешкан чакларында шатлыгы эченә сыймады. Кыскасы, аңа ышаныч белдергән офицер (җитмәсә, ул әле укыган чорда спортның пожарно-прикладной төре буенча "СССРның спорт остасы" дигән исемгә дә лаек булган икән) алдында да, бу хезмәтне үз итеп өлгергән солдатлар каршында

да сынатасы, булдыксыз ярлыгы тактырасы килмәде. Эчен-тышын айкап бакмыйча бернәрсәне дә юньләп белмәячәген яхшы аңлаганга күрә ул гидрант һәм колонкаларның да, машинадагы насос эше механизмнарның да төзелешен, эш принцибын һич иренмичә җентекләп өйрәнде.

Шулай дәртләнеп йөргән көннәрдә ул хат алды.

—Гаделҗанов, бие!—диде почта китерүче солдат.—Сиңа биш хат! Дүртесе Кронштадттан ук әйләнеп кайткан. Син китеп өлгергәнсең, күрәсең, ә бусы туры монда килгән, почеркы бик матур, кызлар язуына охшаган.

Кулын югары күтәргән солдат Габделнур үрелүгә читкә тайпылды.

—Шаяртма. Бие!

Нишләсен, йоласы шундый булгач, егет тыпырдап алды, башкалар кул чабып торды.

Иң әүвәл конвертлардагы адресларга күз салып чыкты: Әлмәттән килгәне, чыннан да, Рәйсәнәдән икән; Коспаш шәһәреннән—шахтадагы туганнан туган абыйсыннан; Азнакайдан—ташчы булып эшләүче классташыннан; Ерак Көнчыгыштан—балык тотудагы күрше егетеннән; авылдан—колхозда тракторчы булып калган яшьлек дустыннан...

Билгеле, иң башта сөенә-сөенә Рәйсәнә хатын ачты. Ләкин... андагы хәбәр егетнең башына күсәк белән китереп органнан ким тәэсир итмәде.

«...Син бик әйбәт егет. Ләкин... Гафу ит син мине. Чөнки мин соңгы вакытта бик күп уйландым, озак баш ваттым һәм сине аңладым: син музыкага тартыласың, рәсем ясыйсың, нечкә күңелле, хисчән егет. Бәлки әле укырсың да... Син әле үз юлыңны табып бетермәгән сыман тоелдың. Егерме яшь—нәрсә ул?! Бигрәк тә егетләр өчен. Ә мин җир кешесе. Мин инде бүтән укымыйм. Кияүгә чыгып, бәби табып, балалар үстереп, табигать алдындагы вазифамны үтәп, иремә әйбәт кенә хатын булачакмын. Мине әни шулай тәрбияләде. Шәһәр кызы булсам да мин авылча үстем. Шуңа күрә миңа ачу саклама, каргама да, каргышы башына төшә күрмәсен. Минем әни гел шулай ди. Матур гына аерылышыйк. Хуш. Мин сине онытмам. Ир малай тапсам, синең исемеңне кушармын... Габделнур, гафу ит. Мәнә сине көтә алмадым. Мин кияүгә чыгам. Кабат миңа хат язма... Хуш!..»

Егет хатны бер укыды, ике... Ләкин андагы җөмләләрнең эчтәлеге үзгәрмәде, хәрефләр урыннарын алыштырмады. Ачык һәм конкрет язылган сүзләр тезмәсе бераздан гына яшь егетнең түнгән миенә барып җитте. Ул аптырап калды. Ничек була соң әле бу? Бер ел гына үтте ләбаса... Аның китүенә бу айда нәкъ бер ел тулды. Бүтәннәр көтә иде бит, өчәр ел...

Заранка—зирәк акыллы егет, дустының коелып төшүен сизде. Янына килеп утырды. Чөнки хат алу ул гел сөенечле хәбәрләр генә түгел, һәркемнең өе, әти-әнисе, туганнары—үз мохиты бар, хәвефле хәлләр дә килеп ирешүе ихтимал.

—Нәрсә бар?—дип сорады ул.

Аның да гел елмаеп диярлек торган кызгылт йөзенә борчу чыккан иде.

Габделнур аңа конверты белән хат сузды.

—Мәнә, укы,—диде ул битараф караш, төшенке күңел белән һәм, дустының йөзендә аптырау галәмәте чагылганны күреп, конвертны кире алды.—Гафу, син бит татарча белмисең... Кыз кияүгә чыккан.

—Ничек?

—Үзем дә шуңа аптырыйм.

Солдатларның бер-береннән сере булмый. Заранка Рәйсәнә турында белә иде. Дустының альбомында кызның карточкасын беренче тапкыр күргәч:

—О, маргейтес гражес!—дип сокланган иде. (Аларча, чибәр кыз, дигәнне аңлата.)

Бүген Заранка булдыра алганча Габделнурны юатырга, аның хәленә керергә тырышты.

Ике катлы бинаның өскесендә казарма, аста янгын сүндерү машиналары гаражы, кечкенә генә ял бүлмәсе, мастерской кебегрәк урын, җиһазлар куелган бүлмәләр иде.

Бераздан Габделнур, урындыктан торып тәрәзә янына килде. Шәрәләнеп калган шыксыз агачларга карады. Аларның өске ботаклары һавага сузылган ялварулы бихисап кулларны, бармакларны хәтерләтте. Алар арасында ике саескан нәрсәдер бүлешә алмыйча даулаша—ботактан-ботакка сикерешә... «Боларга да дөнья тар, нидер житми...»

Егет көне буена боегып йөрде.

Төштән соң, фотоальбомын ачып, озак кына Рәйсәнәнең сурәтенә карап утырды. Гүя аның йөзен хәтерендә калдырырга теләгәндәй, аскы ирене белән ияге арасындагы үзенә килешеп торган кечкенә миненә хәтле игътибар итте. Һәр чалымы таныш. Егет хәтта рәсем артындагы язуына кадәр ятлап бетергән иде инде: "...Мин бәхетле шундый өзелеп-өзелеп юксынырлык кешем булганда". Әйе, Габделнур да бәхетле иде. Менә бүген ул бәхет юкка чыкты. Гүя ул сокланып туймаган аяз күкне кара болыт басты, гүя җылы суында коенган якты күл өстен салкын боз каплады. Саклап кына куенында йөрткән кадерле әйберсен югалтты ул... "Ярар, башны ташка орып булмый!—диде егет кисәк кенә һәм карточканы альбомнан куптарып алды да ачу белән тураклап атты.—Хуш! Син дә... Хуш!!"

Ләкин күңел түренә кереп урнашкан гүзәл фәрештәне тиз генә куалап җибәреп, исемен йөрәгеңнән сызып ташлап буламы соң?!

Кичке якта ул дежурда иде. Кабул итү беткәннән соң урамга чыкты. Гараж каршында туктады. Башы ничектер мингерәүләнеп калды бугай. Кая барырга, дигән сыман алга карады. (Гәрчә, дежурствоны ташлап беркая да китмәсен белсә дә.) Анда урман, объект. Урманы калын, куе, чын карурман. Юаныч табарга теләгәндәй бик озак аның биек агачларына карап торды солдат. Эченә кереп китсәң иде шул карурманның, йөрсәң иде адашып, кайгы-хәсрәтеңне басып, җырлап... "Карурманга кермәс идем, карурманда атларым; кычкырып җырламас идем, бик ямансу чакларым..." Габделнур, тиктомал монда чыгып басуына хәйран калгандай, як-ягына каранды, карашын өскә юнәлтте. Күк йөзендә сирәк болытлар йөзә. Кояш баеп килә. Болытларга гүя ут капкан—барысы да кызгылт төскә манылган, ә астарак, бөтен көнбатыш тараф кып-кызыл—болытлары да, арасындагы ачык урыннар да... Кояш үзе күренми инде, ә кызгылт ялкыны ярты күкне, бөтен әтрафны чолгап алган... Гүяки ялкын капкан бөтен дөньясына... Аны ничек сүндерәсе булыр иде, бу кадәр ялкынны йөгәнләрдәй көч-куәт юк бит әлегә кешедә... Аның да йөрәге мөлдерәмә сагыш, эче тулы ялкын... Ничек сүндерергә? Дөртләп кабынып ничек янып үлмәскә? Ничек үзендә сыгылып төшмәслек көч-дәрман табарга? Башны алып кая олагырга? Аһ-зарыңны кемгә сөйләргә дә, тубалдай газиз башкаеңны кемнең тезенә куярга? Кем басар синең тау дәрьясыдай йөрәк ярсуыңны?.. Кайгысын эченә йотып күпме йөри алыр ул?..

Икенче көнне, «ирекка» чыккач, Заранка аны мәҗбүри рәвештә диярлек клубка алып китте.

—Әйдә клубка барабыз.

—Нәрсәгә?

—Анда бүген танцы.

—Ин әйбәте—кибеткә. Үзем сыйлыйм.

Дустының нинди хәлдә икәнен яхшы тойган Заранка каты торды. Чөнки белә: су тулы савытны ут өстендә озак тотсаң, ул кайнап чыга һәм түгелә... әгәр парын чыгармасаң.

—Юк. Бүген түгел.

—Йөргән кызың бармы әллә?

—Әйе.

Хәрби шәһәрчекнең зур клубы шыгрым тулы. Халык чуар: тоташ кара киемле булсалар да коры җирдә хезмәт итәргә мәҗбүр, кайчандыр күбесе хәрби-диңгез училищеларын тәмамлаган көяз офицерлар һәм төрле сәбәпләр аркасында үзләре теләп хәрби хезмәтне дәвам итүче мичманнар, яшькелт төстәге армия формасы кигән лейтенантлар һәм старшиналар, язмышларын шулар белән бәйләгән яшь хатыннар, матрослар һәм солдатлар, яңа өйләнешкән парлар, граждански киемле кыз-кыркын һәм егет-җилән... Күбесе оркестр уйнаган көйгә зур, иркен фойе уртасында бөтерелә. Кайберләре дивар тирәли яисә ишек катында басып тора, утырганнар да бар.

Күп тә үтмәде, ишектән кергән ике кыз туп-туры Габделнурлар янына килеп басты. Исәнләштеләр. Заранка кызларны дусты белән таныштырды һәм бераздан кечерәк буйлысын танцыга алып кереп тә китте. Габделнурга, башын чак кына ия төшеп, икенчесен—калкурак һәм тазарак гәүдәлесен—биергә чакырудан гайре чара калмады.

Кызның биюе ярыйсы гына, сүзгә дә кесәгә керә торган түгел—телетелгә йокмый, кыюлыгы да җитәрлек: вальсның беренче хәрәкәтеннән үк егеткә сарылды.

Уртак сүзләр бик тиз табылды. Кызга егет ошады. Берәр сәгать биегәч, як-ягына каранды да, үрелебрәк, Габделнурның колагына пышылдады.

—Качабызмы?

—Кая?

—Миңа. Мин бүген үзем генә.

Егет артык сорау да бирмәде, кыстатып та тормады. Юкса, ялындыра башласаң, бу чибәр нәрсә аны калдырып, бүтән белән китәргә дә күп сорамас. Ни булса, шул булыр, тәвәккәлләргә кирәк! Дөньясы болайга киткәч, нигә әле ул намус саклап ятарга тиеш! Яшьлек бер генә килә ләбаса. Ул бит басса бакыр изәрдәй таза егет, төс-кыяфәте дә кешедән ким-хур түгел... Ир-атка, җиккәндә ат куркып китмәслек булса ярый инде, дип әйтсәләр дә, кыз-кыркын кемне сайларга икәнен үзе белә, теләсә кемгә килеп сүз катмый... Моңарчы Габделнур үзен, һәрхәлдә, маймылдан чүт кенә кайтышрак саный иде—насыйбы чыгар... Ана да табылыр... Менә инде берсе табылды да...

Биш катлы йортка җитәрәк, кыз фатир номерын әйтте һәм:

—Мин алданрак керәм,—дип, кулын егетнең биленнән алды, җәлт кенә култык астыннан чыгып, китеп тә барды.

Кыз аны коридорда каршылады.

—Шаулама, әкрен генә кер!—диде ул аның колагына авызын якын ук куеп шыпырт кына.—Кызымны уятырсың.

Габделнур ачык ишектән килеп керүгә үк, ут та алдырып тормыйча, Зоя аның шинелен, фуражкасын һәм итекләрен салдырып, бүлмәгә уздырды. Сабырсызланып солдатның корычтай таза гәүдәсен кочарга, ирennәреннән үбәргә кереште. Икесе дә ашык-пошык чишенгәч, караватка ятты һәм бераздан, исерек кешедәй сөйләнә-сөйләнә, «тукта, юләркәй, анда түгел, ашыкма, менә шулай», дия-дия егетне "тирбәтергә" кереште...

—Син беренче тапкырмы әллә?—дип сорады ул, хәлсезләнгән гәүдәсен ятакта таратып ятканда.

—Әйе...—диде үзен ничектер бушанып калган хәлдә сизеп, чалкан яткан Габделнур чак ишетелерлек итеп.

Шуннан хатын калкынып, шатлыгыннан елмая-елмая, дымлы куллары белән егетне янә чорнады, көйдереп алырдай кайнар иреннәре белән үбәргә кереште.

—Милый ты мой... Хорошенький... Чистенький... Мин сине үзем барысына өйрәтермен...

## XII

Яңа урында Габделнур солдатлар белән бик тиз уртак тел тапты.

Билгеле, аны да беренче көннәрне сынап карадылар. Отделение командиры бик җитди кыяфәт белән аңа бер бит кәгазь бирде.

—Ефрейтор Гаделҗанов, менә шушыны матур итеп, үзегезнең фамилиягезне куеп, күчереп язарга кирәк.

—Есть.

—Тик башта укып чыгыгыз.

Бу—беренче отделение солдатының шәхси социалистик йөкләмәсе иде. Габделнур укый башлады һәм өченче пунктта төртелеп калды. Чөнки анда: "Узган ел өч янгын сүндергән идем, быел бишне сүндерергә йөкләмә алам", диелгән.

—Иптәш сержант, монда хата киткән,—диде ул.—Янгынны алдан белеп булмый. Формулировкасын үзгәртергә кирәк.

Боларны сырып алган солдатлар бердәй көлеп җибәрделәр. Шунда гына егет моның шаяру икәненә төшенде.

Сержант әле һаман «җитди чырайлы» иде. Ул, солдатларга карап, күз кысып алды да шыттыруын дәвам итте.

—Син, Гаделҗанов, бер дә кайгырма, янган әйбер череми ул,—диде.— Янгын чыгып, сүндерә алмыйча калганда да исең китмәсен, «иптәш командир, янгын сүнделде, йорт янып бетте», дип чатнатып әйтеп бир.

—Аңлашылды,—диде Габделнур елмаеп.—Шулай итәрмен.

—Менә, акыллы кешегә бер әйтүдә үк барып җитә...

Монда ике рәтле гармун бар иде. Габделнур бер дә иренмичә еш кына аны кулына алды, урыс көйләрен дә сайрата башлады. Ул да ярдәм итте ахры. Аны стена гәзите редакторы итеп куйдылар. Бусы командирларга ошады. Әгәр син хөрәсән ялкавы булмасаң, һәр җирдә яраталар... Хезмәттән зарланмады, ни кушсалар да авырыксынмыйча башкарды. Хәтта арттырып җибәргән чаклары да булды: «камыт»ның олысын кияргә, «бүрәнә»нең авыр башын күтәрергә тырышты. Әлбәттә, болар иптәшләре тарафыннан бәяләнмичә калмады. Биредә халык санаулы гына, һәрчак сугышчан әзерлектә торырга кирәк, ул-бу була калса бер-береңә ярдәмгә килү кадәресе дә бар бит әле. Шуңа күрә солдатлар һәм сержантлар дустанә яши иде.

Гадәттәгечә, егетләр төрлесе-төрле төбәктән хезмәткә алынган, холык-фигыльләре дә аермалы, белем дәрәҗәсе һәм тормышны танып белүләре дә үзгә.

Постнов фамилияле егет, мәсәлән, Мәскәүнең үзеннән. Башка егетләр белмәгән күп нәрсәләр аңа таныш, бөтен илгә билгеле бер атаклы футболчы белән күршеләр икән.

—Ул институтта ун ел укый инде,—дип көлдерде.—Аягы ашаткач, баш кирәк түгел бит.

Ләкин Постновта кәпәренү дигән нәрсәнең әсәре дә сизелми. Югыйсә, үзе беренче разрядлы хоккейчы, капкада торган. Шулай да армиядан кыякламаган. Кызык егет ул. Үзе яшен ташыдай атылган резин шайбаны тота алучы, курку белмәс капкачы, йөзендә ничәмә-ничә җөй, ә үзе тычканнан да курка. Табигать кочагында сирәк була торган чын шәһәр малае.

Бервакыт, дежур торганда, Постнов, черем итеп алырга дип, ян бүлмәгә кереп ятты. Ул гадәттә кулын баш астына куеп, уң ягына ята һәм еш кына: "Король—чалкан, саран—йөзтүбән, ә акыл иясе яны белән ята",—дип әйтергә ярата иде. Бу юлы да шулай яткан. Дусты-якташы Лавров, теге йоклап киткәч, җинелчә генә аның җилкәсенә кагылды.

—Слава, тартырга бир әле.

Янгын командасында хезмәт итүчеләрнен йокысы сак була бит. Постнов шундук сикереп торды.

—Нәрсә?

Лавров гозерен кабатлады.

—Тартырга бир әле.

Постнов кулын галифе кесәсенә тыкты һәм... шул секундта ук кире чыгарды.

—Володя, тычканны ал!—дип кычкырып җибәрде ул.

Тегесе башын юрганга салды.

—Нәрсә? Нинди тычкан?

Кулын күтәргән килеш кырын яткан Постнов еларга житешеп ялына башлады.

—Зинһар ал инде! Кабы белән бирәм папиросны!

Кай арада Лавров тычканын тоткан, кай арада дустының кесәсенә салып өлгергән, беркем сизмәгән...

Постнов бик эрудицияле егет. Спорттан тыш музыкага да әвәслеге бар: гитара кылларын чиртә. Музыка мәктәбендә укыган булса да, монда ул житди музыка уйнамый, сөйләшкәндә дә композиторлар, музыкантлар тормышының кызыклы вакыйгаларын, көлкеле ситуацияләрен генә искә төшерә. Чөнки урыны башка, кешеләре бүтән! Беркөнне, мәсәлән, ижат әһелләренең аралашуы хакында сүз иярә сүз чыгып, ул болай дип сөйләп китте.

—Пришел Римский-Корсаков к Бетховену в гости. Тот начал его угощать Мясковским, Хренниковым, Сметаной и Чайковским. Вдруг у Римского-Корсакова получилось Пуччини. Он выбежал на Дворжак, шлеп-шлеп по Глинке. Сорвал Лист для Шопена, подумал, что будет Гуно, а получилось Бах и образовалась Могучая Кучка.

Әлбәттә, моны аңлар өчен классик музыкадан азмы-күпме хәбәрдар булырга кирәк иде. Техникумда нота грамотасын үзләштергән, сольфеджио өйрәнгән, баян буенча дәресләр алган Габделнур беренче жөмләдән үк төшенде сүзнең кемнәр турында баруын, рәхәтләнеп көлде. Һәм бу Постновның игътибарыннан читтә калмады. Шуннан соң ул яна солдатны үз тиңе күреп йөри башлады.

Алар еш кына гапләшәләр, яшәеш, музыкага карата уй-фикерләре белән уртаклашалар.

—Музыка өч компоненттан тора: ритм—йөрәк тибеше, тавыш—күк күкрәү һәм жил, хәрәкәт—жиһанда бар нәрсә хәрәкәттә,—диде Постнов берчакны.— Бу борынгы заманнардан ук мәгълүм нәрсә, кешеләр шуларга колак салганнар.

Бәлки моны берәр акыл иясе әйткәндер, һәрхәлдә, солдат үзе уйлап чыгармагандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, Габделнур өчен дә Постнов—аның рухына якын әңгәмәдәш иде. Чөнки ул да үзен табигать белән бербөтен итеп тоя, аның һәр мизгеленә, үзгәрешенә колак сала, аңа мөкиббән китеп яши.

Кызык инде ул хәрби тормыш. Юктан гына да мәзәк табып, уен-көлке белән үткәрергә ярата аны солдат халкы, үз күңелен үзе күрергә, шукланырга тырыша. Беркөнне, старшина казармага кереп, солдатлар белән сөйләшеп торганда, Габделнур үзе белән бер чама буйлы Лавров артына яшеренде. Аннан, ике теш арасыннан һава сызгыртып чыгара башлады. Ул аны өзек-өзек чыгара, тавыш исә сызгыруга түгел, ә нәкъ мәче мияулаганга тартым иде.

—Нәрсә бар монда?—дип артына борылды старшина.—Песи баласымы?

—Кайда, кайда?—диештеләр солдатлар юри белмәмешкә сабышып.

Шуннан старшина ишек төбеннән түргә таба китте. Барысы да аның артыннан

иярделәр. «Песи баласы» да алардан калмады. Старшина, иелеп, карават асларын карый, аптырагач тумбочкаларны ача—песи юк. Ә тавыш—бар.

Ахырда ул:

—Да ну сезне, үзегез тотыгыз!—дип, кул селтәде дә, казармадан чыгып китте.

...Йөз метрга йөгерүдә җингән Габделнурны өлкән лейтенант Лукъянчук ике атнадан ярышка да куйды. Бу спорт төрен янгынчылар үзара шаяртып «ат спорты» дип йөртәләр. Кирза итек кигән егетләрнең лап-лоп йөгерүен атлар чабуы белән чагыштырды микән берәрсе, әллә башка сәбәпме, кыскасы, читтән карап торучыга бик җиңел сыман тоелса да, ярышка әзерләнгәндә аттан ким тир түкми егетләр.

Җитезлек, осталык белән генә түгел, монда әле ярышның иң соңгы этабында тәвәккәл һәм курку белмәс йөрәкле булуың да ярап куя. Дүрт почмаклы, сай, зур гына тимер савытка—протвеньгә—су кушып бензин салынган. Ярыш вакытында аңа ут төртәләр һәм спортчы-янгынчы шуны сүндерергә тиеш.

Габделнур башта командир өйрәткәнчә эшләргә исәп тотса да, никтер ул уеннан кайтып, савытның эченә үк керергә ниятләде: ут сүндергечне як-якка боргалап, тиз генә ялкынны ялмап алмакчы булды. Бит-кул пешү дә, киеменә ут кабу ихтималы да аны куркытмады, фәкать тизрәк сүндерсен генә! Спорт ярышларында була торган азарт биләп алды егетне.

Ул йөгереп килгән уңайга савыт эченә кереп, ут сүндергечне як-якка боргалый башлауга, майор погоннары таккан баш судья аты-юлы белән акырып җибәрде:

—Выйди... немедленно! Синең аркада төрмәдә утырасым килми! Чык!

Габделнур берни дәшми савыт читенә чыгып басты һәм, иелә төшеп, ут сүндерүен дәвам итте. Майор әле һаман тынычлана алмый иде.

—Син нәрсә, егет, янып үләсең килдеме әллә?! Кабат алай эшләмә!

—Алай тизрәк,—диде Габделнур аңа карамыйча гына.

—Ә шунда янып китсәң?!

...Ярыштан соң спортчылар янына хезмәттәшләре җыелды.

—Ну син майорны астына җибәрттең!

—Ул хаклы!—диде өлкән лейтенант Лукъянчук, ләкин артык орышмады, чөнки бүгенге ярыштан бик канәгать калган иде.—Озакламый Костромага барабыз. Ныклап әзерләнегез!

Габделнур моңа бик шатланды. Бераз сөйләшеп торгач, казармага юл алдылар.

...Костромада шулай ук сынатмадылар. Ярыштан соң шәһәр күрү дә насыйп булды. Ул таулар-калкулыклар өстенә салынган, Идел буендагы борынгы кала. Романовлар династиясенең патшалык итә башлавы да шушы тирә белән бәйле: урыс патшасына хезмәткә күчкән бер татар морзасы нигез салган Ипатьев монастыре, Домнино авылы (Романовлар гаиләсенең нәселдән килгән утары), Иван Сусанинның Михаилны поляклардан коткарып калуы, соңгысының тәхеткә утырырга ризалык бирүе...

Шулай да иң истә калганы ярыш та, шәһәр дә түгел, ә бу шәһәр командасыннан бер егет белән танышу булды. Дөресрәге, сержант үзе килеп Габделнур белән күреште. Ул Кострома каласының "Татар бистәсе"ннән булып чыкты. (Иделнең сул ярында шундый урын бар икән.) Ефрейтор Гаделҗановны кунакка чакырды егет, адресын да калдырды.

Габделнур, рәхмәт әйтеп, аның чакыруын кабул итсә дә, аларга барып чыга алмаячагын яхшы белә иде. Шулай да әллә кайдагы, кем әйтмешли, җәһәннәмдәге бер ерак калада үз кешеңне күрү, житмәсә, үз телеңдә (сержантнын, вата-җимерә булса да, бик тырышып ана телендә аралашасы килә иде) бер-ике авыз сүз сөйләшү бик рәхәт иде.

...Габделнурларга объектта янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең төгәл үтәлешен тикшерү вазифасы да йөкләнгән иде. Беркөнне алар, ике солдат, икенче проходнойдан (әле өченчесе дә бар, ләкин аның аша фәкать офицерлар гына керә ала иде) эчкә узып, корал һәм запас җиһазлар саклаиучы складларны карарга киттеләр.

Бер бинага кергәч, әле яна гына агач әрҗә эченнән чыгарылган, өстәл зурлыгы бер җиһазга тап булдылар. Корпусына бәләкәй генә калай кисәге дә ябыштырылган. Язуны укыгач Габделнурның күз төпләре дымланды.

—Якташ, саумы?!—диде ул үзе дә сизмәстән җиһазның салкын тимер корпусын сыйпап.

Чөнки ана «Казан компрессорлар заводы» дип язылган иде.

—Нәрсә бар?—дип сорады Заранка иптәшенен туктап калуын күргәч.

Язуны укыгач, ул дустының халәтен аңлады, гадәтенчә елмаеп читкәрәк китеп торды.

...Армияда да саксызрак әйтелгән, кешенең мин-минлегенә тия торган сүз җавапсыз калмый. Бервакыт, аскы катта шаярганда (көч-куәте ташып торган яшь-җилкенчәк тик тора беләмени?!) Габделнур Лосев фамилияле солдатның муенын ялгыш катырак кысты, ахры. Теге, кызарып-бүртенеп, көчкә сулу алды да:

—Татарин!—диде.

Ничек тиз булгандыр, соңыннан Габделнур үзе дә аптырады: ул каршында еламсырап торган Лосевка киерелеп бер тартты. Бичара Лосев калай белән тышланган түгәрәк мичкә барып сыланды. Монда булган егетләр—Постнов, Лавров, Тресков—бер сүз әйтмәделәр. Лосев, лышык-лышык борын тартып, икенче катка менеп китте.

Ул Вологда өлкәсеннән армияга алынган, беренче елын гына хезмәт итүче солдат иде. Уртача буйлы, сипкелле, тырпаеп торган сары чәчле, дөнья күрмәгән—монарчы беркая да чыкмаган авыл малае. Өч көн буена Габделнурга дәшмәде. Аннары килеп, кулын сузды.

—Гафу ит.

Билгеле, ачу сакламаган бу егеткә Габделнур яңадан кул күтәрү түгел, авыр сүз дә әйтмәде. Хәер, сәбәбе дә булмады.

Андый, кем әйтмешли, гадәттән тыш хәлләр сирәк була. Күбрәк бергә җыелып альбом актаралар—фотолар карыйлар, тормыш, кызлар турында сөйләшәләр. Кәеф күтәренке булганда җырлыйлар. Мондагы җырларның, билгеле, байтагы солдат хезмәтенә кагылышлы. Кем чыгарган—аны белүче юк, ләкин солдатлар буыннан-буынга аларны бер-беренә тапшыралар. Җырларның исемнәре дә бар: "Самовольщик", "Янгынчы мәхәббәте", "Профилактика бүтән", "Гашыйк янгынчы җыры", "Картлач-янгынчы анты" һ.б.

Постнов ялындырып тормый: үзе гитара чиртә, үзе җыр суза.

Замела метель гидранты, запорошила,
Рукава разбросаны вокруг...

## XIII

Гимнастерка төймәләрен, каеш пряжкасен чистартып, итеген көзгедәй ялтыратып, Габделнур беренче этажга—гаражга төште. Анда солдатлар ак брезент курткалар киеп, кечкенә балта тагылган киң бил каешлары буып маташалар иде. Ул да тиз генә өс киемен һәм башына кызыл йолдызлы яшел каска киеп алды да сафка тезелә башлаган егетләр янына килеп басты.

Уен-көлке, сөйләшүләр тынды, чөнки гаражда Лукъянчукның биек фуражкасы һәм сипкелле йөзе күренде. Дежур сержант ике отделениене дә

сафка тезеп, янгын сүндерүчеләр начальнигына рапорт бирде.

—Иптәш өлкән лейтенант...

Гәүдәсен төз тотып йөрүче командир, рапортны кабул иткәч, яшь офицерларга хас таләпчәнлек белән һәрберсенең өс киемен тикшерде, устав һәм инструкция буенча белергә тиешле кагыйдәләрне сорады.

—Сез үзегезнең нинди частьта хезмәт итүегезне, сезгә Хәрби Диңгез флотының гаять әһәмиятле бер объекты ышанып тапшырылганын исегездән чыгармагыз,—диде ул башта инде солдатлар яттан белгән сүзләрне кабатлап, аннары өстәде.—Бу арада көннәр бик коры тора, объектта, хәрби шәһәрчектә һәм поселокта да янгын чыгу ихтималы бик зур...

Инструктаждан соң солдатлар ялтырап торган кызыл буяулы машиналарны, аларга урнаштырылган янгын сүндерү җиһазларын элекке сменадан кабул итеп алдылар. Отделение бер тәүлеккә дежурга басты. Балта тагылган киң каешларын, брезент курткаларын һәм каскаларын салып, стена буендагы озын эскәмиягә тезеп куйдылар.

Габделнур иптәшләре белән бер-ике партия домино, шашка уйнады, берсенең фотокарточкалар альбомын карап утырды. Дневальныйны алыштырыр алдыннан гаражга кереп, машинадагы әйберләрне янә бер тапкыр барлап чыкты, эскәмиядәге киемен, йөгереп килгән унайга киярлек итеп, җайлабрак куйды. «Белмәссең дөнья хәлен. Чыннан да бу арада бик эссе...»

...Отбойдан соң өске каттагы йокы, астагы дежур бүлмәләре тынып калды. Өлкән лейтенант белән старшинаны озаткач, отделение командиры:

—Мин бераз черем итеп алам,—диде һәм күрше бүлмәдәге койкаларның ишек катындагысына барып ятты.

Габделнур гараж ишеген ачып куйды. Өстәл тартмасыннан кичтән әзерләп куйган конверт белән чиста кәгазь, гимнастерка изүен ычкындырып эчке түш кесәсеннән авторучка алды. Конвертка, мәктәптә матур язу дәресендәге кебек, хәрефләрне тигез тезеп, әкрен генә адрес һәм әтисенең исем-фамилиясен язды. Аннары ак кәгазьгә хатның беренче юллары төште. «Исәнмесез, хөрмәтле әти һәм әни! Сезгә үзенең кайнар солдат сәламнәрен озатып, тормышыгызда уңышлар һәм үзегезгә нык сәламәтлек теләп калучыны улыгыз Габделнур дип белерсез...» Аннары егет әбиләренә, туганнарына һәм агай-энеләргә, берәм-берәм исемнәрен атап, сагынычлы сәламнәр юллады. Йөрәк җылысы белән сугарылган, күңел түреннән чыккан хисләрен тәфсилләп, ничек барысын да күрәсе килүен, сагынуын кәгазьгә төшерәсе дә килә, ләкин аларның—уй-борчуларының бөтенесен дә бәйнә-бәйнә тезеп китсә, артык төчеләнү булмасмы, моң-зар булып ирешмәсме, дип тә шиккә кала. Язуыннан туктады. Каршыдагы телефонга, яндагы тәрәзәгә карап, бераз вакыт уйланып утырды. Күрше бүлмәдә иптәшләренең тигез сулап йоклавы, вакыт-вакыт койка пружинасы шыгырдавы ишетелә. Тәрәзәдән төшкән ут яктысында казарма каршындагы агач яфраклары, солдат куллары шомарткан турник тимере ялтырап күренә. Арырак—бруслар, ике баганага эре ятьмә тартылган волейбол мәйданчыгы, солдатлар уйнаганны карарга килүчеләр өчен куелган тар эскәмияләр.

Солдат тормышына тәмамысы ияләнеп җиткән булса да, үзе язганда яки ерак-ераклардан килгән сәлам хатларын укыганда аның күзләре кымырҗый, күңеле җилкенә, алгысый башлый, йөрәге сыкрый, кысылып-кысылып куйгандай итә. Юк, аның йөрәге әле, әбиләре әйтмешли, сөбханалла, ул аның кайда икәнен дә белми. Бу—сагыну, жирсү аны шулай дулкынланырга мәҗбүр итә, шул хәлгә китереп җиткерә. Көндез алай ук түгел, иптәшләр белән, хезмәт белән вакыт сизелми дә диярлек уза. Ә төннәрен йоклый алмыйча ятканда яки үзе генә калган мизгелләрдә аны әйтеп бетергесез, берни белән дә басып булмас шикелле тоелган, һич чиге-чамасы күренмәстәй

сагыш биләп ала. Ундүрт яшеннән, әле яна гына бәлигъ булган бала яшеннән, өйдән чыгып китү, туганнарыннан, өеннән-жиреннән аерылу—аны һәрдаим бимазалап, йөрәк бәгырьләрен телгәләп, гел әчтә нәрсәнедер тырнаштырып-сызлатып тора иде. «Бар бит ул бәхетле кешеләр!—дип куя кайчак Габделнур.— Үз өендә, ата-анасы, кардәш-ыру янында гомер ки...»

Шулчак шык иткән тавыш ишетелде. Габделнур башын күтәрде. Өске каттагы телефон станциясеннән торба буенча жетон—номер сугылган калай кисәге төшергәннәр иде.

Солдат сикереп торды. Йөгереп барып жетонны алды. Шул секундта тревога кнопкасына басты. Үзе уктай атылып гаражга керде. Тревога сигналыннан дивар зыңлап торды, дежур бүлмәсе шундук хәрәкәткә килде. Солдатлар, дәррәү урыннарыннан торып, дөбер-шатыр гаражга йөгереп керделәр.

Артык сүз юк. Хәрәкәтләр өзлексез булып торган күнегүләр дәвамында кабат-кабат чарланган—төгәл, бернинди каушау, алан-йолан карану, кием эзләп маташу, этеш-төртеш яки тиктомалга унга-сулга бәрелешү, болганыш-тулганыш галәмәте юк.

Берничә секундта киенеп, машинага утырдылар. Шак-шок кабина ишекләре ябылды. Ул арада Чхиквадзе стартерга басты. Габделнур жетонны шофер белән янәшә утырган отделение командирына бирде.

—Икенче проходнойга!—диде ул Шотага карамыйча гына һәм кая барырга кирәген әйтте.

Машина гараждан чыккан унайга ике тапкыр әче итеп сирена улатты һәм, унга текә борылып, таш юлдан чапты.

Объектка керә торган проходнойдагы солдатлар зур тимер капканы кин итеп ачып куйганнар иде инде.

Берсе, өч бармагын погонына куеп, объектта кем барын аңлатты һәм:

—Батя!—дип, телдән дә кычкырып, кулы белән алга ишарәләп калды.

Сержант шоферга:

—Ку!—диде.

Әйтмәсә дә була иде, чөнки Шота үз эшен яхшы белә торган егет.

Объектның иң аргы башына килеп житкәч, йокылары качкан солдатлар, кулларын артка куеп басып торган тулы гәүдәле, кыска муенлы полковникны—часть командирын һәм әледән-әле сәгатенә карап торучы, озын буйлы штаб начальнигын күрделәр. Машинаны тиз генә бассейн янына урнаштырып, жинсәләр суздылар, «янгын» сүндерергә әзерләнделәр. Беләк юанлыгы житен жинсәләрдән су килүгә сержант саф адымы белән өлкән офицер каршына барып басты, честь бирде һәм әзерлек турында белдерде.

—Иптәш полковник...

Канәгатьлеге йөзенә чыккан командир рапортны тынлагач, кулын селтәде. Бу аның, отбой, дигән сүзе иде. Отделение сафка тезелгәч, ул:

—Тиз килеп життегез!—дип мактады.—Сезгә рәхмәт белдерәм!

Суланып авырайган житен жинсәләрне машинага төяп, тирләп-пешкән солдатлар кире гаражга кайттылар. Аларны өлкән лейтенант Лукъянчук, старшина (яши торган фатирлары шушы озын бинаның икенче башында гына иде) һәм монда калган расчет каршы алды. Машинага коры жинсәләр куеп, юешләрен гараж эченә кибәргә элеп, техниканы тәртипкә китергәч, солдатлар тагын ял итәргә яттылар.

Габделнурның вакыты әле чыкмаган иде. Ул үз урынына утырды. Тавышлар тынгач, кемдер өстәл тартмасына салып куйган баягы язылып бетмәгән хатын алды.

Егет, фикерләрен жыеп, бераз уйланып утырды. Уңышлы үткән тревогадан соң аның күнеле күтәренке иде. Менә бит, әгәр чын тревога булса... Мондый вакытларда Габделнур үзендә һәрвакыт горурлык хисе тоя.

Әлеге тревогадан соң бик нык дулкынлану кичергәнгәме, ул зиһенен бер ноктага туплый алмады. Хатны бер читкәрәк этәреп, өстәл тартмасыннан инглиз язучысы Голсуорси китабын алып, кичә тукталып калган төшенә кыстырган кәгазьне өстәлгә ташлады да, укый башлады. Романдагы вакыйгалар аны үз эченә алып кереп китте, бит арты бит ачылды. Күпме вакыт үткәндер, укуга мавыгып, ул тиз генә әйтә дә алмас иде, мөгаен, кинәт Габделнурны сискәндереп, телефон шалтырады. Ул трубканы алды.

Трубкада ашыгудан тотлыга-тотлыга сөйләгән хатын-кызның өзек-төтек чәрелдек тавышы ишетелде.

—Пожарный!.. Яна!.. Поселокта яна!..

—Нәрсә?—дип сорады Габделнур.—Тыныч кына әйтегез.

—Яна! Сарайлар яна! Тизрәк! Зинһар! Бик нык...

Сөйләшкәндә үк урыныннан сикереп торган Габделнур телефон трубкасын оясына ташлады да тревога кнопкасына басты...

...Ярты минуттан кызыл машина, утларын яндырып, улаган сиренасы белән төнге тынлыкны ярып, янгын сүндерергә чыгып чапты. Хәрби шәһәрчек тә, объект кебек, урман эчендә, куе булып үскән биек нарат һәм чыршы агачлары арасында урнашкан иде. Июль чилләсендә әлсерәп, монсуланып утырган агачлар фара яктысында берәм-берәм артка чиктеләр.

Машина якынлашуга КППның тимер капкасы шар ачык иде инде. Машина ажгырып хәрби шәһәрчектән чыгып та китте. Алда, поселок урнашкан иңкүлектә, һавага төтен күтәрелә, ялкын телләре айкала-чайкала отыры биеккә үрләп төнге бушлыкта нидер кармалыйлар, каяндыр астан, ике катлы йортлар артыннан, бертуктаусыз күтәрелгән очкыннар тирә-юньгә һәм югарыга таба чәчрәп, янгынның инде шактый нык җәелгәнен һәм аны сүндерү җиңел генә булмаячагын искәртәләр иде.

Отделение командиры объекттагы, хәрби шәһәрчектәге һәм поселоктагы барлык «кое»ларның кай тирәдә урнашуын, алардагы гидрантларның нинди хәлдә икәнен биш бармагы кебек белә иде. Чөнки өченче елын төгәлләп килүче бу сержантка еш булып торган тревогалар вакытында аларның һәммәсен дә карап-барлап чыгарга туры килде. Әйе, күнегү-өйрәнүләр бер нәрсә, ә бүгенге янгын—алар өчен житди сынау.

Ике тоннадан артык су сыйдырышлы цистернасы булган авыр машинаны шофер урам уртасына—«кое» янына китереп куюга, егетләр, «ә» дигәнче кабиналардан коелып, эшкә керештеләр: башы кәкре тимер җайланма белән «кое» капкачын ачып ташладылар, гидрантка машина янтыгының бер бүлкәсеннән алынган колонканы борып керттеләр. Аларның кулы-кулга йокмады, тиз-тиз генә колонкага басымлы-суыручы ике кыска җинсә ялгап, икенче башларын насоска беркеттеләр. Аннары, төргәкләрнең берсен жиргә таратып җибәрделәр дә башын машинага тоташтырып, икенче башындагы тоташтыргыч “эшләпә”гә янә бер җинсә ялгадылар, линия суздылар. Һәр нәрсә үз урынында, хәрәкәтләре төгәл, күнегелгән, исәпләнгән...

Ә менә янгын берни белән дә исәпләшми: каяндыр вакытлы-вакытсыз исә башлаган төнге җилдә ул отыры көчәя, котырына, дулый, бөтен әтрафны ялмап алырга теләгәндәй өскә һәм як-якка үрли...

Поселокның һәр тарафыннан—ике катлы таш йортлардан, озын бараклардан—халык җыела: өс-башына ни туры килсә шуны эләктергән ир-ат, эчке күлмәкчән яки халаттан гына атылып чыккан хатын-кыз, күзләре шар ачылган һәм йокы аралаш ни булганын абайлап та өлгермәгән бала-чага... Кемдә чиләк, кемдә чүмеч димәсән, кулына нинди савыт туры килгән шуны эләктергәннәр; акырыш-бакырыш, елау-сыктау, хафалану-өзгәләнү машина тавышын да күмә, такта, шифер һәм башка нәрсәләр янган авазлар белән буталып, тирә-юньдәге гарасатка тагын да ямьсезрәк, куркынычрак төс бирә...

Габделнур һәм аның иптәшләре үз эшләре белән мәшгуль: колонкадагы краннар ачылды, машина артындагы насос эшкә керешге, жинсәләр су белән тулды, түгәрәкләнде, юешләнде, бер урында энә очы кадәр генә тишек булган икән, бәләкәй генә фонтан хасил булды—аннан өскә таба нәзек кенә булып су чәптерә башлады...

Габделнур дөрләп янган сарайларга мөмкин хәтле якынрак килде дә, жинсә очындагы дюралюмин көпшәне каты куллары белән тоткан хәлдә аның кранын ачып жибәрде, дүрт-биш атмосфера басым белән килгән су агымын утның нәкъ үзәгенә юнәлдерде...

Көчле басым астында куылган су юлында ни очраса шуны очырта башлады. Көпшәне жайлы-жайсызрак тотсан жинсә пожарныйны селтәп атарга да күп сорамый. Шуңа күрә Габделнур янында аның кулдашы-ярдәмчесе тора иде. Ләкин ялкын бер-берсенә терәтеп корылган егермеләп сарайның яртысына капкан иде инде...

Ул арада сирена улатып икенче машина да килеп житте. Өлкән лейтенант Лукъянчук «дилбегә»не үз кулына алды, кыска-кыска, әмма солдатларга аңлаешлы командалар бирә башлады. Сарайлар ике рәт булып, әле берсе генә яна иде. Шуңа күрә, анысын коткарып калу мөмкин булмаганга, ул икенче рәтне саклап калу чарасын күрергә кушты: бер машина исән сарайлар өстенә су бөркергә тотынды.

Жыелган һәм әле һаман агылуын дәвам иткән поселок халкы да аңына килде: бер сафка тезелеп, чиләкләр белән булса да су биреп тора башладылар.

Батыррак ир-атлар утка якын ук торып багор, көрәк ише нәрсәләр белән сарайларны сүтеште. Поселок белән янәшә авыл. Аннан да кулына нәрсә дә булса тоткан ир-атлар ашыга-ашыга янгын сүндерергә киләләр иде.

Хәрби шәһәрчектән йөгереп килгән солдатлар һәм матрослар, офицерлар һәм мичман-старшиналар да ут сүндерүчеләргә кушылды.

Тавыш, шау-шу, кычкырыш-елаш колак төбендә өзлексез шаулап торды. Су агымы өскә, аска һәм утның үзәгенә бәрә... Шарт-шорт килгән тавыш өзелми, чытыр-чытыр ниләрдер яна, тирә-юньгә күңелне болгата торган исләр тарала.

Өлкән лейтенант Лукъянчук елашып торган хатын-кызлар янына килде.

—Сарайларда шартлый торган әйберләр юкмы?—дип сорады ул.

Бензин, керосин ише нәрсәләрдән тыш, хәрби объектта эшләгән кешеләрдә шартлаткыч матдәләр дә булуы ихтимал иде. Гәрчә бу мәсьәләдә контроль бик каты булса да, ул әлеге сорауны бирмичә кала алмады. Чөнки ул-бу була калса, солдатлар өчен командир жавап бирә.

—Юк, юк!—диделәр хатыннар.

Күккә ялкын ургыла, төтен күтәрелә, як-якка очкыннар чәчри. Янгынның туктарга исәбе дә юк. Инде сарайлар рәте бер башыннан икенче башына хәтле тоташ ут эчендә. Алар тирәсенә якын килерлек түгел—температура күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Өскә таба өзлексез чаткылар оча...

Күпмедер вакыт узгач, таң беленгәндә һавага зәңгәр төтен күтәрелә башлады, ялкын басыла төште.

Лукъянчук егетләре армый-талмый эшләделәр. Ләкин ничек кенә тырышмасыннар, бер рәт сарайлар янып бетте. Икенче рәтне саклап калдылар. Сарайлар тирәсе су белән тулды. Лачтыр-лочтыр су ерып йөри башладылар. Киемнәре манма булды.

Халык үз сарайлары тирәсендә кайнаша. Солдат-матрослар да шул тирәдә мәш килә: янган велосипед, мотоцикл, карават башлары кебек тимер-томырлар сөйрәп чыгаралар.

—Егетләр, пешкән бәрәнге ашыйк!—диде бер матрос иптәшләренә мөрәжәгать итеп.

Ә каравыл ротасыннан килгән солдат:

—Кая, кем аракыга йөгерә, монда шәп закуска бар!—дип кычкырды.

—Нәрсә?

—Дуңгыз ите.

Аны сырып алдылар. Ул арада икенче баштан берәү:

—Монда тагын бер чучка баласы кара күмергә әйләнгән!—диде.

Шул тирәдә булган Габделнур, якын килгәч, имәнеп китте.

—Кит, юньсез, кеше бит бу!—диде ул.

Карарга чирканыч хәлдәге янган кешене аның беренче күрүе иде. Мондый җан өшеткеч күренешкә тап булганы юк иде әле.

Халык җыелды. Бер хатын якынрак килде һәм аяк-куллары кара күмергә әйләнгән, чырае да танымаслык хәлгә килгән ир-атның гәүдәсенә иелеп карый башлады.

—Әйләндер әле!—диде бер офицер янындагы солдатка.

Янып үлгән кешенең аркасында калган зәңгәр комбинезон кисәген танып:

—Шул, үзе!—диде хатын һәм йөрәк өзгеч тавыш белән чәрелдәп ире янына тезләнде.—Витенька, милый!.. На кого ты нас оставил?! Ой! Ой!..

Һәм хатын өзек-төзек сүзләр, аңлаешсыз авазлар тезә-тезә, яртылаш кына калган иренең җансыз гәүдәсен коча-коча илереп кемгәдер ялварырга, кемнедер каргарга, такмаклап еларга тотынды.

Моны карап торуы ук, әле ничә сәгать элек кенә исән кешенең, кемнендер кадерле иренең, кемнендер газиз атасының менә шулай мәгънәсез үлеме, кара күмергә һәм инде хәзер мәеткә әйләнүен күрүе егетләргә дә авыр тәэсир итте. Күбесенең мондый фаҗигале үлем-җитем белән беренче мәртәбә очрашуы иде.

Хәрби шәһәрчектәге гараждан өч-дүрт машина да килеп туктаган иде. Бераздан, хатыны өеннән алып чыккан одеалга төреп, мәрхүмнең гәүдәсен машина әрҗәсенә илтеп салдылар.

Габделнурлар әле һаман пыскыган кисәүләрне сүндерү белән мәшгуль булды. Янгын беткәндә һавага аксыл-зәңгәр төтен күтәрелде. Бөтен поселок төтен исе белән тулды.

Әлеге янгынның шаукымы озакка барды. Каян, ничек килеп чыгуы турында сүз күп булды. Дөрес, янгынчыларга тел-теш тидерүче табылмады. Чөнки алар тиз килеп җиттеләр, хәлдән килгәнчә тырыштылар. Ләкин иң хәтәре—өч көн буена егетләрнең тамагыннан юньләп ризык үтмәде. Ашарга утыруга мәрхүм ир-атның күмерләнгән аяк-куллары күз алдына килә, өстәлдәге ризыктан пешкән адәм итенең авыр исе борыннарына килеп бәрелгәндәй була. Хәтта биредә мул булып үсүче шәмәхә төстәге каражиләк ашаганда да кисәү күмерләре күз алдына килгәли иде.

Бу араларда Габделнур еш кына әтисен, аның сөйләгәннәрен исенә төшергәләде. Дөрес, Галләм абзый, чын мәхшәрнең үзен күргән, кан койган кеше буларак, сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Фәкать сирәк-мирәк, бераз «төшереп» алгач кына, ул үзенең сугышчан дусларын хәтереннән барлый. Аларның—япь-яшь егетләрнең—ачы язмышы, үкенечле үлеме турында да әйткәли иде. Окоптан сикереп чыгып, ингә-ин терәлеп дигәндәй йөгереп һөҗүмгә барганда җан дустына әверелгән солдатның йөрәгенә пуля тиеп, кинәт туктап калуын һәм сүз дә әйтә алмыйча авып җан бирүен күрү бик авыр булгандыр шул. Галләм абзый бигрәк тә бер Кукмара егетенең үз кулында үлүен авыр кичерә иде. «Адресы да хәтердә калмаган, семьясына хат та язып сала алмыйм бит»,—дип уфтана иде ул.

## XIV

Беркөнне, гадәттәгечә кич белән очрашкач, танцы вакытында Зоя Габделнурга сүз катты.

—Ярославльне күрәсең киләме?

—Ә минем аны күргәнем бар, хәтта берничә тапкыр, анда ике вокзал барын да беләм: Главный һәм Московский,—диде егет шаяртып һәм хатынның тулы булса да җинел биюче, буйсынучан гәүдәсен үзенә тартып, колагына пышылдады.—Бүген минем сине генә күрәсем килә...

—Мин синең карамакта,—дип тыйнак кына көлде Зоя башын күтәрә төшеп егеткә яратып карагач һәм сүзне баягы эзгә төшерде.—Син шәһәрне узып барышлый гына күргәнсең бит.

—Анысы да дөрес. Килүен килә дә... Ничек диләр әле: оҗмахка керер идем дә, гөнаһларым җибәрми шул.

—Ә синең нинди гөнаһларың бар? Гауптвахтага утыртканнары юк шикелле...

—Сүз уңаенда гына әйтүем. Мин бит солдат. Ярославльгә хәтле чыгып китә алмыйм. Безгә рөхсәт монда һәм поселокка чыгу өчен генә бирелә. Шәһәргә бару өчен күп вакыт кирәк.

—Әгәр мин сөйләшсәм?

Габделнур музыка ритмына җай гына биегән хәлдә иңнәрен сикертеп куйды. Ул Зояның әтисе отставкадагы офицер икәнне белә иде инде. Күрәсең, шуңа аркалануыдыр.

—Әтиең беләнме?

—Билгеле. Лукъянчук аңа каршы килмәстер.

—Мине дөрес аңлар микән соң?

—Тыйнаклык большевикларны да бизи...

—Эш анда гына түгел. Әле иптәшләр дә бар бит. Ә миңа алар белән хезмәт итәсе.

—Бөтен дөньяның бөкресен син генә төзәтеп бетерә алмассың. Әзрәк үзең турында да уйла.

—Ярар, сөйләш...—диде Габделнур теләр-теләмәс кенә.

Әлбәттә, табигате белән кызыксынучан егетнең берничә мәртәбә узып киткән шәһәр белән якыннанрак танышасы, аны сәйран кылып йөрисе килә килүен... Ләкин... «Ярар, егетләр гаеп итмәс әле. Мин алар өлешенә кермим бит. Ялга да кайта алмадым. «Әниең каты авырый», дигән пичәтле телеграмма килгәч Епифановны җибәрергә туры килде...»

Аннары, дип фикер йөртте солдат, әгәр мөмкинлек чыкканда файдаланмасаң, форсатны кулдан ычкындырсаң, үкенечтә калачак. Тагын кайчан килә әле бу якларга? Ай-һай... Кем көтеп тора аны Ярославльдә? Ярый әнә Ленинградны бераз күреп калды. Хәзер анда кайчан барасың? Гомумән, бара алырсыңмы, юкмы үз гомереңдә?!

Зоя сүзен сүз итте.

Шулай да, ефрейтор Гаделжановның кулына кәгазь тоттырганда, өлкән лейтенант Лукъянчук кисәтте.

—Патруль күзенә чалынмаска тырыш...

Алар вокзалда очрашырга килешкәннәр иде. Габделнур беренче килде. Ул һәрвакыттагыча «иреккә» чыга торган киемнән: кыска козыреклы биек фуражка, калын яшькелт китель һәм шундый ук төстәге галифе чалбар, ләкин ул як-якка кабармаган, ә тәненә сыланып диярлек тора, биләндә сары аеллы киң каеш, аягында гади кирза итек. Ләкин бар булганы пөхтә: үтүклисе—үтүкләнгән, чистартыласы—елкылдый.

Менә бераздан Зоя да күренде. Зифа буйлы яшь хатын, гаскәриләр телендә «ножки с бутылочкой» дип аталган тыгыз балтырлы, төз аяклары белән тиз-тиз атлап килә иде. Аның өстендә җинелчә җәйге ак кофта белән кара итәк, аягында тәбәнәк үкчәле кара туфли. Кулында җыйнак кына ридикюль. Чәчләрен чак кына артка җыебрак эләктереп куйган. Ләкин аяк атлаганда бераз көдрәрәк алтынсыман сары чәчләре җилкәсен каплап, селкенеп-таралып

китәләр; киң, биек маңгае, кабарынкы иреннәре, ачык йөзе кояш нурында тагын да яктырак күренә. Иртәнге һаваның сафлыгына, бәхет вәгъдә итүче якты көнгә сөенгән күзләре дә нурлана төшкән; бүген ул бөтенләе белән балкый сыман. Иннек-кершәнне чама белән генә сөртеп бизәнгән, зәңгәр күзле, коңгырт кашлы, тулышып торган яңакларына ятышлы гына озынча юка туры борынлы Зояга егет, беренче мәртәбә күргәндәй, текәлеп карады.

Кисәк кенә Габделнурның күңел түрендә бер хыялый фикер чагылып үтте: каршына Зоя түгел, ә сары чәчле, зәңгәр күзле түбән оч кызы—аның беренче мәхәббәте килсә икән хәзер!..

Зояның колагындагы кечкенә фирәзә кашлы алкасына һәм ачыграк калган түшенә үк төшеп торган алтын чылбырлы кулонга, бармагындагы алтын йөзегенә—бар булган зиннәтле әйберләрен тагын килүенә дә игътибар итте егет. Шулар янына кофта эчендәге калку күкрәге дә мулдан. Ни генә димә, олырак яшьтәге ир-атның гына түгел, үз чордашлары егет-җиләннең дә күзе төшәрдәй яшь, таза тәнле, чибәр хатын басып тора иде аның каршында.

Егет түзмәде.

—Син бүген үтә матур!—дип соклануын яшермичә мактап куйды.

—Син мине кызартасың...—дип, чыннан да оялыбрак, солдатына яратып карады Зоя. Ә серле өмет белән тулы зәңгәр күзләре: «Кадерен бел. Мин синең өчен, фәкать синең өчен генә бизәндем-ясандым бүген»,—дип әйтәләр иде.

Туку фабрикасында смена мастеры булып эшләүче Зоя ярыйсы гына укымышлы да булып чыкты. Бераз гына тирбәлеп барган вагонда кайнар тәне белән егеткә терәлеп шәһәр һәм аңа бәйләнешле вакыйгалар турында сөйләде.

—Князь Ярослав Мудрый Которосль елгасы Иделгә килеп кушылган шушы урында, урманга ауга чыккач, бик зур аю белән очраша. Һәм шунда Ярославль шәһәренә нигез сала. Шәһәр гербындагы аю да шуны аңлата диләр...

Габделнур Зояга сирәк-мирәк кенә сораулар да биргәләде, бүтән темаларга да кереп чыккаладылар. Кыскасы, авызга авыз куеп дигәндәй, Ярославльгә барып җиткәнче гәп куерттылар.

Кояшлы җәйге көн булгангамы, бу юлы тимер юл вокзалы—Ярославль Главный—аксыл төскә буялган бер катлы озын бина—аларны ачык чырай белән каршылады. Бер катлы булса да биек, гаҗәеп матур, якты иде ул. Перроннан вокзал бинасы аша киң мәйданга чыгып, бераз баргач, егет түзмәде, артка борылып карады, туктады.

—Кая барабыз?—дип сорады Зоя.

—Белмим. Монда син хуҗа. Мин ияреп кенә йөрүче,—диде Габделнур, һәр нәрсәгә мөкиббән китеп, әле артка каерылып, әле як-якка карый-карый вокзал бинасыннан ераклаша барганда.

Бу шәһәрне дөньяга танытан бүтән шәхесләр дә байтак икән. Шагыйрь Некрасов шәһәрдән ерак булмаган Карабиха авылында еш кайтып йөргән. Аның «Рус илендә яшәү кемгә рәхәт?» поэмасын белмәгән кеше юктыр. Үз әсәрендә сорауны шулай катгый итеп куйса да, бер зур йорты, ике флигеле (аерым өйләр) һәм өч буасы булган усадьбада шагыйрь үзе начар яшәмәгәндер... Ә менә авыл исеме...

—Ул авылда берәр татар баеның тол хатыны яшәгәнме әллә?—дип сорады Габделнур елмаеп.

—Нигә алай сорыйсың?

Егет ул сүзне икегә аерып, ике татар сүзеннән ясалган булуын әйтте. Ягъни, кара—төсне аңлата, ә биха—бикә, барыня.

Зоя моны ошатмады, ләкин солдатка сиздермәде.

—Белмим!—диде дә сүзне икенчегә борды.

Җырчы Собинов, рәссам Саврасов та (Габделнур аның «Каргалар килде»

исемле картинасын яхшы белә) бу шәһәрдә туганнар икән. Мәскәү сенатында һәм Эчке эшләр министрлыгында хезмәт иткән шагыйрь Иван Аксаков та, хөр фикерләре өчен кулга алынгач бирегә эшкә җибәрелә, башкаладан сөрелә. Космонавт Терешкованы әйткән дә юк инде.

Шулар өстенә, унсигезенче йөз ахырында Мусин-Пушкин тарафыннан «Слово о полку Игорове» әсәре дә бираддәге Спасс монастырендә табылган икән. (Күрәсең, Мусин-Пушкин да безнең халыкның бер вәкиледер, ерак бабаларыннан берсе Муса булгандыр, дип уйлады егет. Ләкин дәшмәде).

—Әнә тегендә, еракта, Туговая гора дигән урын бар,—диде хатын.—Татар-монголлар белән сугышта һәлак булган рус баһадирларын шунда күмгәннәр. Хатыннары шунда килеп елаганга тауга Туговая исеме бирелгән.

—Ә нәрсәне аңлата соң ул?

—Хәсрәтләнү, кайгыруны, ягъни, тужить, дигәнне.

—Тушить дигәнне беләм.

—Аңысы сезнең, янгынчыларның эше инде. Ә тегесе икенче. Бер җырда бар бит: «Любо, братцы, любо, любо, братцы, жить. С нашим атаманом не приходится тужить...»

Әлбәттә, шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган бу яшь хатынның Габделнурны Ярославльгә дәшүе тиктомалдан гына килеп чыккан уй түгел иде. Авылда туып-үскән, бәләкәй генә бер шәһәрдән армиягә алынган, тыныч холыклы бу таза, ирлек гайрәте ташып торган асыл егетне ничек тә үз ягына аудару, зур шәһәрнең мавыктыргыч тормышы белән кызыктыру, аннары инде рәтен-җаен белеп эш йөрткәндә, бер тотынгач, кулдан ычкынмаслык итеп бәйләп тә кую иде. Әле бер мәлне, ике ай чамасы элек, Зоя, әллә балага узыйм микән, дип тә уйлаган иде. Ләкин бу төпле фикер йөртә белүче, житди егетне, яшь кенә булса да, кем әйтмешли, чүбек белән генә алдап булмас, дип, андый адым белән генә үзенә бәйли алмаячагын төшенеп өлгерде. Аннан соң, мәҗбүрилек белән эшләнгән эшнең ахыры хәерле бетәр, дип кем гарантия бирә ала? Ярар, уздың да ди, бала да таптың ди, алай-болай киреләнә башласа, сабыеңны күтәреп командование каршына да бардың, ди. Шуннан, ярар, өйләндерден дә, ди. Ә хезмәт срогы беткәч аны кем тотып тора ала? Койрыкны сыртка салмас дип кем әйтә ала? Аны чылбырга утыртып булмый... аю түгел... Шуңа күрә хатын егетне үзенә карату өчен бүтән юл сайлады: кала тормышы, анда эш яки уку мәсьәләсендә үзенә ошаганны, җанын теләгәнне сайлау мөмкинлеге булу һәм башка нәрсәләр белән кызыксындырырга кирәк тапты. Егет үзе фикер йөртсен, нәкъ Зоя теләгән уйга үз башы белән килсен. Хатынның бөтен тырышлыгы шул максатка юнәлде. Шуңа күрә ул булган хәтле акчасын җәлләмичә тотты, бу сәяхәтне төрлеләндерергә тырышты, күбрәк өлешен күңел ачуга корды. Шәһәрнең дә иң күркәм, күңелгә хуш килердәй урыннарын гына әйләнделәр. Биек таш койма белән әйләндереп алынган, почмакларында очлы чатырлы тәбәнәк каланчалары булган, Казанныкыннан шактый кайтыш җыйнак кына Кремльгә, шәһәрнең борыңгы тарихын үзенә туплаган архитектура тыюлыгына, сәнгать музеена кереп, өстән-өстән генә булса да күз йөртеп чыгу—шул планны гамәлгә ашыру өчен кирәк иде.

Ары киттеләр...

Менә каршыда бихисап колонналы озын бина—сәүдәгәрләр курасы. Аны күргәч, солдат:

—Бу Ленинград һәм Кронштадттагы гостиный дворларны хәтерләтә,—диде.—Күрәсең, алар барысы да бер проект белән төзелгән һәм бер үк вазифаны—сәүдә итү үзәге вазифасын үтәгәннәр.

Сәүдә йортына кереп, үзенә вак-төяк сайлаганда Зоя Габделнурны да истән чыгармады.

—Болары сиңа!—диде ул елмаеп һәм сәгать браслеты белән авторучканы аңа сузды.

— Рәхмәт, кирәк түгел иде...

Алар текә яр читенә килеп чыктылар да яшел түбәле, бүрәнә юанлыгы алты ак колонналы, аскы өлеше бизәкле тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган, тирә-юнендә агачлар үсеп утырган, түгәрәк формадагы күзәтү чатырына керделәр.

—Бу—Пушкин беседкасы дип атала,—диде хатын.

—Нигә алай?

—Әллә тагы. Яр буенда шушындый өч беседка бар, уртадагысы—исемле.

—Кызык.

Моннан гаҗәеп манзара ачылды.

Әнә пристаньга ике, өч палубалы ак теплоходлар килеп елышкан, читтәрәк әкрен кыймылдаучы бәләкәй генә буксир кайнаша, нәфис гәүдәле су трамвае килә, елга уртасында моторлы көймәләр күренә...

Тыныч су өстендә сирәк-мирәк акчарлаклар каерылып оча, балык күзли. «Шул ук Идел, акчарлаклары да бездәгенә охшаган,—дип уйлап куйды Габделнур.—Тик шәһәре, иле-җире генә башка». Кая бара икән бу теплоходлар? Өскә күтәреләме, әллә аска төшәме? Утырып китсәң иде шуларның берсенә су буйлап түбән таба... Кайтып төшсәң иде Казанга... Дөрес, Идел монда таррак, Казан тирәсендәгедәй түгел. Ләкин ул барыбер—Идел! Идел... Габделнур әле аның үзен күргәнче үк җырларда ишеткәне бар иде. Аның әнисе бик моңлы итеп җырлый торган иде ул малай чакта. «Идел бит ул, Идел бит ул, Идел бит ул, киң бит ул. Караңгы төн, болытлы көн, без аерылган көн бит ул...» Уртанчы малаеның тальян гармунда уйнарга өйрәнгән иң беренче көе дә «Идел бит ул...» иде. Бары соңрак кына егет аның «Су буйлап» дип аталган, Бөек Ватан сугышы чорында барлыкка килгән татар халык җыры икәнен белде. Никадәр моң һәм сагыш салынган бу җырга... Габделнур, янында кем барын да, кайда басып торуын да онытып, күкрәк тутырып киң сулап, кычкырып җырлап җибәрүдән үзен чак кына тыеп калды. Ә җырлыйсы килә... Ярсыган йөрәкне ни беләндер тынычландырасы, түзә алмаслык мизгелләре булган сагыну хисен җыр белән басасы килә... Үзе генә булса ул, һичшиксез, шулай итәр иде. Җыры-көе генә түгел, сүзләре дә телгә килеп тора бит аның: «Сары каеш билләрдә лә, җилфердәми җилләрдә. Сандугачлар да сайрамый сез булмаган җирләрдә...» Хәер, монда да сандугачлар сайрый торгандыр. Су буеннан искән тымызык җилдә сизелер-сизелмәс кенә чайкалучы, яфракларын серләштерүче агачларда ниндидер кошлар аваз сала бит. Араларында сандугачлар да буладыр...

Шулчак башта каяндыр ерактан ишетелгән кебек, ә аннары янәшә генә җыр агыла башлады. Җыр сузучы—Зоя иде.

Светится город над Волгой,
К морю уходят суда.
Пусть я уеду надолго,
Снова вернусь я сюда.
Пахнет прохладой вечер
Липами темных аллей,
Здесь непременно я встречу
Старых и новых друзей.
Ярославская сторонка,
Ярославская земля,
Я иду дорогой звонкой,
Там, где юность шла моя.

Здесь ждала меня подруга,
Здесь живет любовь моя—
Ярославская сторонка,
Ярославская земля.

Егетнең әсәрләнеп, ерак-еракларга җәелеп аккан елгага карап торуын Зоя үзенчә анлады, юньлегә юрады: «Идел бик ошады ахры».

—Матурмы?—дип сорады ул егеткә яннан карап.

—Әйе.

—Монда җәен-кышын балык тотарга була. Безнең бу якларда Иделгә коючы Которосльдән башка да Пахма, Туношна, Солоница, Ить, Черная елгалары бар. Аларда да балык мыжгып тора дип сөйлиләр. Безнен эштә бер хатынның ире балыкчы.

—Кара елга диденме?

—Әйе.

—Кызык. Ленинград өлкәсендә дә Кара елга бар.

—Беләм. Пушкинның дуэле шунда булган.

—Анда берничә Кара елга бар.

—Кызык.

—Күрәсең, сазлык урыннарда сунын чиста булмавына, төсе дә карангырак булуга ишарә рәвешендә исем кушылгандыр.

—Әйе, безнен якта да сазлыклар бар. Аның каравы черника, клюква күп...

Хатынның, һәр сүзенә мәгънә салып, егет тирәсенә ятьмә корып маташкан көне. Әләгерме ул мона? Алдагысын Алла белсен... Анын ефәк бавы нык булырмы? Әллә беренче тартылуда ук шартлап өзелерме?

Көн жылы. Арттан ишетелгән шәһәр гөрелтесенә теплоход авазлары килеп кушыла. Су буеннан өзлексез җил исеп торганга салкынча һава биткә килеп бәрелә, агач яфраклары шыбырдый. Яр буенда акчарлаклар чыелдый, су өстендәгеләре каерылып-каерылып оча, түбәннән генә очып балык күзли, кайберләре өзлексез дулкын уйнаган елгага төшеп тә утыра. Бер акчарлак, сулга таба карап, агымга каршы утырды. Ләкин агым аны мәҗбүри рәвештә отыры артка таба агызып алып бара. Акчарлак бик озак интегә-интегә арты белән йөзеп барды. Канатларын җилпеп калкынып-калкынып карый да янә суга утыра бахыр. Аны нәрсә тота икән соң һаман шулай: тәмле балык күзлиме, башка сәбәп карышырга мәҗбүр итәме? Ахырда агым аны үз унаена борды. Әмма, бераз агып баргач, горур кош, буйсынасы килмичәме, ак канатларын тиз-тиз җилпеп, судан күтәрелде, түбәннән генә беркавым очып барды һәм әкренләп югары үрләде—каты томшыклы, «кара эшләпә» кигән башын алга сузып, ерак-еракка очып китте. Габделнур аны, сокланып, тавышсыз гына озатып калды.

Зоя үзенчә, егетне кызыксындырдым, дип уйласа да, асылда киресе килеп чыкты ахры. Казан ягына агучы Иделне, әнисен, үзенең балачагын искә төшерүләр Габделнур күнелен янә алгысытып җибәрде. Табигате күнеленә хуш килсә дә, ул кайдадыр читтә яши алмас иде. «Матур булса да торган җир, сагындыра туган ил»,—дип юкка гына җырламаганнардыр зимагурлар, иленнән аерылганнар...

Кузгалдылар. Яр буендагы юан-юан юкәләрдән хуш ис бөркелә. Киң сукмактан ял итәргә чыккан яшьләр, гаиләләләр атлый, карт-коры эскәмияләрдә утыра, асфальт юлдан машиналар уза.

—Хезмәтенне бетергәч, шәһәрдә эш табуы кыен булмас,—дип куйды аңа елышып утырган Зоя трамвайда барганда.—Барысы да синең теләктән тора...

Ләкин ул артыгын җәелмәде. Үзенең соңгы сүзләренең егеткә ничек тәэсир итүен дә белә алмады, чөнки әле Габделнурның ел ярым диярлек солдат

шулпасы чөмерәсе бар иде. Дөрес, әгәр анын белән тормышын бәйләргә уйласа, әтисен үгетләп, анын элек күрсәткән хезмәтләрен эшкә жигеп, егеткә бер ел узуга ук—сентябрьдә, ягъни министрнын приказы чыгу белән үк дембель оештырырга була...

—Әйдә бер жиргә кереп чыгабыз.

Монарчы дәшми барган, шулай да хатынның киная белән әйткәннәреннән нәрсәнедер төшенә башлаган Габделнур, уеннан бүленеп, кисәк кенә сорап куйды.

—Кая?

—Мина. Тулай торакка.

—Сонга калмыйбызмы?—диде солдат яна браслетлы иске сәгатенә карап, чөнки ул вакытында кайтып житәргә тиеш.

— Өлгерербез.

...Трамвайдан төшеп, жәяү киттеләр.

—Әнә безнен «Красный Перекоп» проходное,—диде Зоя һәм, алга таба ымлап, каршыдагы ике катлы бинага төртеп күрсәтте.—Мин шунда эрләү цехында эшлим.

—Без фабрикага керәбезмени? Тулай торак эчтәмени?

—Юк инде, юләрем минем!—диде хатын серле, назлы тавыш белән.—Бүтән жирдә...

Сул кул якта өч катлы яна ак йорт, ә унда кызыл кирпечтән корылган иске озын бина сузылган. Алар фабрикага таба китмәделәр, ә ак бинага житәрәк Стачкалар урамыннан сулга борылдылар һәм бераздан Бахвалов урамына килеп чыктылар.

Биш катлы таш йорт. Керделәр. Исәнләшкәч, вахтер карчыкнын колагына иелеп нидер әйтте Зоя. Читтәрәк торган Габделнурга карап алды. Вахтер да ана күз төшерде. Зоя, имән бармагын иреннәренә тидереп, карчыкка тагын нидер әйтте. Тегесе башын як-якка чайкап куйды. Алар янә пышылдашып алдылар.

—Әйдә, өскә менәбез!—диде Зоя егет янына килеп.

—Бар, солдат, кер!—диде вахтер алар узып киткәндә.

Аерым бүлмәдә тора икән хатын. Әллә ни жиһазлы түгел. Ун почмакта шифоньер, каршыда, тәрәзәгә якын жирдә өстәл, урындыклар, стена буйлап ике якта ике карават: зур, тимере—үзенекедер, ә кечкенәсе, агачы—баласыныкы булса кирәк. Хатын тиз генә чәй хәстәрләде, тумбочкадан шешә чыгарды... Ләкин ашау-эчү белән озак мавыкмадылар. Бер рюмка тоткач та Зоя, урыныннан торып, елмаеп, егет каршына килеп басты. Аны итләч, дымлы куллары белән әкрен генә тартып дигәндәй торгызды, кайнар беләкләре белән муенына сарылды, үзенен дәртле иреннәрен егетнен иреннәренә тидерде...

Бик озак үбешеп торганнан сон:

—Чишен,—диде ул сихри ләззәт вәгъдә иткән йомшак, назлы тавыш белән.

Үзе дә тиз генә бөтен киемнәрен салып атты. Габделнурнын анадан тума хатын-кызны болай якыннан беренче күрүе иде. Дөрес, Алабугада укыганда ук Кама буенда комда кызынып ятучы кыз-кыркынны күргәләде. Шәрә хатыннар сурәте төшкән открыткалар да кулына эләккәләде. Армияга киткәндә Татвоенкомат каршында телсез егеттән сатып алганнарын Ленинградта, Флот экипажында «конфискацияләделәр». Пляждагылар су коену костюмыннан булса, открыткадагылары кәгазьдә генә иде. Ә бүген анын каршында тере, зифа буйлы, яшь чибәр хатын...

Тәжрибәле Зоя, беренче көнне вәгъдә иткәнчә, жай белән генә ана дәрес бирә килде: хатын-кызны ничек танып белергә, алар белән ничек мөгамәлә итәргә, анын уй-теләкләрен ничек тоемларга, кай төшләрен үбәргә һәм назлап дәртен кузгатырга... Бүген шул дәресләрнен дәвамы булды...

Егет анын кабарынкы сусыл иреннәрен, йомшак муенын, ияк астын һәм колак артын, күкрәк уентысын һәм ими башларын берөзлексез үбә башлады. Хатын киерелеп-киерелеп куя, еш-еш сулыш ала, гәүдәсе өзлексез хәрәкәттә, куллары Габделнурның инбашларын, аркасын сыпыра, назлый, кисәк-кисәк ухылдап йә ыңгырашып, тырнап та ала... Ул егетне җиде катлы ләззәт күгенең соңгысына чөяргә теләгәндәй кылана: алар тирбәлгәндә панцирьлы сетка карават астындагы чемоданга тиеп-тиеп ала иде...

Аларның тәннәре дымланды, икесе дә тирләп чыктылар, ләкин бер-берен иркәләү, бер-беренә бәхетле мизгелләр бүләк итү теләге әле һаман бетмәгән, дәртләре сүрелмәгән иде... Ниһаять, икесе дә «эштән чыгып», бушанып калдылар һәм тар гына караватка чалкан яттылар...

—Сиңа минем белән рәхәтме?—дип сорады Зоя күзләрен ачмыйча гына ярым пышылдап.

—Әйе.

—Мин һәрвакыт сине шулай сөярмен... Хәзер, Валентина космоска очкач, безнең фабрика бөтен илгә билгеле. Бәлки тиздән фатир да бирерләр әле. Инженер-технолог итеп тә куймакчылар үземне,—диде хатын гомерендә беренче мәртәбә үз-үзен онытырдай исерткеч ләззәт татыган Габделнурның ялангач күкрәген, көчле беләкләрен сыйпап-назлап.—Мин сине яратам. Бик яратам! Гомер буе шулай яратыр идем...

Хатын, тәненең һәр күзәнәгеннән дәрт ташып торган хәлдә, янә егетнең куенына керде, бөтен барлыгы белән аңа бирелде...

Йомырканы кайсы төшеннән ватсаң да ярый, тәмле генә булсын, дисәләр дә, бу—кайда туры килсә шунда, аулаграк өйдә ятып яки ышыкта аягүрә генә, ашык-пошык, курка-өркә генә бер-береннән күңелен күрү түгел иде инде. Бүген Зояны бәхет басты: кемдер килеп чыгар яки күрер дип тә курыкмады, кабаланмады, бөтен шартын китереп, якын күреп йөргәне белән аулакта яратышты. Һәм ул, һичшиксез, чын мәгънәсендә канәгатьләнү алды, үзен хатын-кыз итеп тойды. Шул ук вакытта егеткә дә чын ләззәтнең ни-нәрсә икәнен төшендерде. Ярый ла кадерен белсә...

...Ләкин күп тә үтмәде...

Габделнур урта мәктәпкә, кичке әзерлек курсларына, йөри башлады. Моны белгәч Зоя аның алдагы планнары белән кызыксынды.

—Казан университетына, юрфакка керергә җыенам!—диде уенда мәкерфәлән булмаган риясыз егет беркөнне клубта очрашкач.

Бу сүзләрнең Зояга тәэсире ничек буласын, әлеге хәбәрне хатын ничек кабул итәсен, кыскасы, алдын-артын уйламаган иде ул...

—Ничек?!!

Бермәл аптырап, тораташтай катып калды Зоя. Ничек? Ул бит бу егеткә зур өметләр баглаган иде! Ярославльдә калыр, эшкә урнашыр, киләчәктә аның тормыш йөген тартыр дип уйлаган иде... Соңгы көннәрдә ул хакта конкрет сүз булмаса да, теге вакытта шәһәргә барып йөрүләре нәрсәгәдер өметләндерә сыман иде. Шулай ук барысы да әрәмгә китте микәнни?.. Ә бит үзе мыштым гына кирәген ала бирде... Ни аяныч, Зоя күз алдында торган кыйммәтле бәллүр вазаның—корган уй-планнарының, хыялларының—шушы секундта клуб идәненә төшеп чәлпәрәмә килүен аңлады. Ипле генә холыклы хатын шунда гомер кыланмаганны, кисәк дөртләп кабынды. Чөнки монда эш читләтеп кенә әйтүдән, ярарга тырышудан узган иде инде! Ул янәшә биюеннән туктады, түгәрәктән читкәрәк чыгып, диварга сөялде.

Аннары кинәт:

—Әйдә урамга!—диде бик нечкәртеп тормыйча һәм чыгу белән пырдымсызланып солдатка ябырылды.—Ярославльдә вуз беткәнмени сиңа? Шул сасы Казаныңда нием калган синең?.. Как сопли с пальца меня выкинуть

хочешь?.. Кирәк чакта әвәләдең дә...

Китте, китте тезеп... Хатынның борын яфраклары кинәйде, йөзеннән алсулыгы качты, егет соклана торган зәңгәр күзләреннән зәһәр очкыннар чәчрәгәндәй булды.

Габделнур, ни әйтергә белмичә, аңа карап катты да калды: бу соң улмы, аны яраткан кешеме?

Шулай да солдат сабырлыгын җуймады.

—Кызма әле,—диде ул Зояны җәлләп.—Ипләп кенә сөйләшик...

Хатын аны бүлдерде.

—Кирәгең бар иде, пеләшкә тарак кебек...

Һәм янә тәтелдәүгә күчте...

Бераздан, зиһене ачылып, үзенең чыгырдан чыгуын, ярсып китүен аңлап, әгәр һаман егетне битәрләсә төпсез чиләккә утырып калачагын сизенеп, хатын янадан элекке назлы Зояга әйләнде. Ләкин эш узган, егеткә аның чын йөзе ачылган, үзе әйтергә яратканча, поезд киткән иде инде...

Ялгызы гына өенә кайтып барышлый, Зоя үзенең күбәләктәй очынып йөргән гамьсез елларын исенә төшерде.

Яшьлегендә, каравыл ротасында хезмәт итүче бер Мәскәү егетенең тасма теленә ышанып, ул аның теләгенә каршы килә алмады. Тәҗрибәсезлеге аркасында (техникум бетерәсе елы иде) буйга да узды. Соңгы айларда кадерле кияү булып өйләренә килеп йөргән сержант, «сине килеп алырмын» дип, корсагы борынына җиткән Зояны тынычландыра-тынычландыра, китеп барса да, кабат хәрби шәһәрчектә мыегын да күрсәтмәде. Зояның, баласын кочаклап, балавыз сыгып утырган минутлары сәгатьләргә генә түгел, тәүлекләргә дә җыелгандыр. Үзенең йомшаклык күрсәтеп алдануына да, атасына кирәк булмаган бала табуына да үкенгән чаклары ай-һай күп булды ялгыз хатынның. Ләкин вакыт дигән дәва барысын да булмаса да, кешедәге байтак җөй-яраларны төзәтә икән. Сержант онытылды, аны башкалар алыштырды. Әмма... Сөткә авызың пешсә, суны да өреп кабарсың, дип әйтәләр әйтүен, ләкин ул көн үтсенгә генә очраша башлаган солдатка соңрак нык ияләште, үзенчә төрле планнар корды. Һәм менә аннан да колак кага ахрысы...

Зоя, подъездга кергәч, баскычка утырып язмышын каргый-каргый елады.

Алар кабат очрашмадылар. Зоя үзенә бер матросны ияләндерде, ә Габделнур бөтен күңелен хезмәткә, укуга салды.

Отделение командиры кайтып киткәч Лукъянчук дилбегәне ефрейтор Гаделжановка тоттырмакчы иде. Ләкин Габделнур, укуын сылтау итеп, отделение алудан баш тартты һәм, үз чиратында, Заранканы тәкъдим итте. Аңа шундук кече сержант дәрәҗәсе дә бирделәр. Шулай итеп Габделнур дусты кул астында хезмәт итә башлады.

Әти-әнисе, туганнары белән арада хатлар йөри. Менә ул тагын бер хат алды. Монысы бик ерактан—Владивостоктан, энесен армияга алганнар икән. “Абый, исәнме! Мин Владивосток якларына килеп эләктем, погранвойскага. Безнең часть Посьет дигән поселокта, Кытай белән Корея чигендә. Бер якта Япон дингезе икән. Монда гел таулар, аларны, сопка дип йөртәләр, урманнар калын. Дингездә безнең колак ишетмәгән кальмар, гребешки, йолдыз, омар күп ди. Аларны әле күргән юк, насыйп булса татып та карарбыз. Ә менә Татар өрәнгесе дигән агачны күрдем... Көннәр җылы, алай зарланырлык түгел. Хезмәт җинел булмас инде. Машинага утырсам гына. Ярар, дөнья күреп кайтырбыз. Старослужащийлар мактана: “Не каждому дано ходить по последнему метру родной земли”, диләр. Служба почетный инде анысы. Әлегә кыерсытмыйлар, без күбәү бит, район егетләре дә бар. Корал белән нәрәткә йөргәч, солдатлар тату яши. Элек, без бәләкәй чакта, хәтерлисеңдер, дөнья читенә барып, яр буенда аякны асылындырып утырсаные, дип хыяллана

идек. Менә теләккә ирештек. Мин хәзер шунда инде. Владивостокта булган егетләр: анда Казанский собор бар, диләр. Ул нәрсәдер, әле күргән юк. Ярар, кыскача сәлам хаты тәмам. Әтиләргә, абыйларга һәм апаларга да яздым. Әтиләргә юлдан да язып салганыем. Без поезд белән бик озак килдек бит."

Габделнур энесе өчен артык хәсрәтләнмәде, югалып калмас. Ә менә әнисе ничек түзә икән? Өченче малае хәрби хезмәттә бит! Әле уртанчысы кайтып житмәгән, инде төпчеген дә алганнар. Бер ана өчен күбрәккә китә шул. Сагынганда карарга янында бер баласы да юк ичмаса. Олы улы ешрак кайткалап китсә инде... Кызының, якын булса да, үз тормышы бар, ул да еш килəлмәс, кеше кешесе. Әнисенең үз балаларын ничек яратуын телдән әйткәне булмаса да, Габделнур моны һәрчак тоеп яшәде. Аларны бергә күрсә, аның йөзе тагын да нурлана, күнеле күтәрелә, хәтта үзалдына көйләп тә йөри башлый иде. Берчакны, Габделнур абыйсы белән ишегалдында сөйләшеп утырганда, әнисенең алар яныннан: "Ике каен янәшә, яфраклары шаулаша; ике туган очрашса, сандугачтай сайраша",—дип үтеп киткәне хәтерендә. "И газиз Әнкәйләр! Ходай Сезгә сабырлык бирсен!"

Энесеннән хат алганның өченче көнендә, декабрь ахырында, тагын янгын чыкты. Бу юлы авылда бер мунчага ут капты. Ләкин Лукъянчук егетләре эшне тиз тотты: мунча исән калды; өйгә һәм каралты-курага да утләргә ирек бирмәделәр; күршеләренә дә кайгы килмәде.

## XV

Авыл кешесе район үзәгенә килгәч нинди тойгылар кичерсә, Габделнур да Мәскәүгә килеп төшкәч шул халәттә иде. Ул инде Ленинградны да күрү бәхетенә ирешә, ә Мәскәүне әле—юк. Шуна күрә ул поездан төшеп өч вокзал мәйданына килеп чыккач, авызын ачып дигәндәй хәйран калды: мондагы иркенлек, матурлык, берөзлексез машина һәм трамвай-троллейбус агылышы, һич туктый белмәгән һәм әрле-бирле килүче халык ташкыны аның ушын алды. Әйе, авыз ачып карап торырлык иде шул! Кая карама—биек йортлар: очлы манаралы, шакмаклы, күп катлы, искеләре, яңалары, йөзләгән тәрәзә уелганнары... Ә инде Казан вокзалының бинасын күргәч, ул аптырауның соңгы чигенә житте: Сөембикә манарасын монда китереп утыртканнар түгелме соң?

—Гаделжанов, артка калма!

Габделнур туктап ук калган икән. Куып житте.

—Иптәш өлкән сержант!—диде ул аларны Мәскәүгә алып килүчегә.—Бу безнең Казандагы бер бинага охшаган!

—Булыр, булыр. Тик син бездән калма, адашырсың.

Ефрейтор Гаделжанов белән тагын бер өлкән матросны партиягә алырга тиешләр. Аларның часте турыдан-туры Мәскәүгә буйсына һәм үзәк политидарә дә биредә иде. Кандидатлыкка частьта гына кабул итсәләр, партия әгъзалыгына алу—Габделнур өчен истәлекле вакыйганың иң мөһим өлеше—Мәскәүдә икән. Аларны частьнең партком әгъзасы, тиешле срогын тутырганнан соң килешү нигезендә хәрби хезмәттә калган (солдат-матрос аларны «макаронник» дип кенә йөртә), утыз биш яшьләр тирәсендәге өлкән сержант Гигевич озата килде.

—Егетләр, әле тагын киләбезме-юкмы, әйдәгез, шәһәр карап йөрик,—диде Гигевич эш беткәч яшьләрне сөендереп.

Чиратсыз гына (кизү торучы милиционерлар рөхсәт итте) мавзолейга кереп, Ленин бабайның саргылт, әмма «нурлы» йөзен карап чыктылар. Ополчение оештырып, Мәскәүне поляк баскыннарыннан азат итәргә килгән Минин (Түбән Новгород халык ополчениесенә 1611 елның 2 мартында татар кенәзләре

һәм морзалары да килеп кушылган) һәм этник татар булган Пожарский һәйкәле янында фотога төштеләр. Кремльгә килгән туристларның игътибарын җәлеп итүче, Рәсәй империясенең зурлыгын, бөеклеген күрсәтүче, әмма бер тапкыр да атмаган Царь-пушканы һәм үз вазифасын үтәмәгән, чаң какмаган Царь-колоколны карап чыктылар. Кыскасы, авызларын ачып, башларын күтәреп, әледән-әле алан-йолан каранып, шактый озак тинтерәп йөрделәр.

Василий Блаженный соборы янында туристлар бар иде. Егетләр төркемнең артына килеп бастылар да, гидның аңлатуын тыңлап, тыныч кына басып тордылар. Ләкин экскурсоводның бер сүзенә Габделнур рәнжеде.

—Бу собор Казанны җиңү хөрмәтенә салынган,—диде төркем алдында басып торган, аларга карап сөйләүче ырмаулы күзлек кигән хатын.

Габделнур түзмәде. Чөнки техникумдагы тарих укытучысының сөйләгәннәре кылт итеп исенә төште.

—Гафу итегез, нинди җиңү хөрмәтенә?

Хатын, күзен дә йоммыйча:

—Мең биш йөз илле икенче елгы,—диде.

—Минем белүемчә, ул Казанны басып алу елы!—диде Габделнур аңа таба борылып караган туристларның барысы да ишетелерлек итеп.

—Барыбер түгелмени?—диде гид бирешергә теләмичә.

—Җиңү белән басып алу—икесе ике нәрсә!—диде Габделнур да үз сүзен сүз итәргә теләп.—Берлинда, Триптих паркында, совет солдатына һәйкәл куелган. Менә ул фашистик Германияне җиңү хөрмәтенә!

Туристлар, алар Мәскәү тирәсендәге берәр өлкәдән генә иде булса кирәк, башта таркалып калдылар, аннары шаулаша, ризасызлык белдерә башладылар. Өлкән сержант, шыпырт кына:

—Ефрейтор Гаделҗанов, бик эчкә кермә!—диде.—Әйдәгез, киттек.

Бераз дәшми бардылар. Белорус егете Гигевич Габделнурга астыртын гына күз салгач, әйтеп куйды.

—Син карап торуга гына гади икәнсең. Хәер, мин сине аңлыйм. Тик син яңадан бу хакта беркайчан да, бер җирдә дә авыз ачма. Кыен ашарсың! Чыпчык дип кенә әйтсәң дә, торна дип арттырырлар.

Алар белән янәшә атлаган озын буйлы өлкән матрос дәшмәде. Күрәсең, мие сыеграк һәм боларның сөйләшүенең мәгънәсе аңа барып җитми иде.

Частька кайткач хәрби тормыш элеккечә дәвам итте: тревогалар, өйрәнүләр, казармада уен-көлке сөйләшеп утыру, спорт ярышлары, плацта сафта йөрү, солдат тормышын төрләндерергә омтылу...

Шуның өстенә, үзләрендә хромка гына булганлыктан, көндезләрен клубка да сугылгалый һәм, онытып бетермәс өчен, берәр сәгать баянда уйнап кайта иде.

## XVI

...Казан аэропортында «кукурузник» дип йөртелгән ике канатлы җиңел самолет бераз гына җирдән җилдереп барды да, улый-үкерә һавага менеп тә китте. Зур шәһәрнең бихисап йортлары, шау-шулы урам-мәйданнары, аларны тутырып йөргән меңләгән кешеләре, армый-талмый килеп сарып йөрүче тыгын трамвай-троллейбуслары, автобуслары артта калды. Алда—иркенлек, зәңгәр күк йөзе, күпереп торган мамыктай аксыл болытлар һәм... туган як.

...Ул бәләкәй чакта ук утыртылган кыр ышыклау полосасындагы, шактый биек булып үскән өрәнге агачларындагы кошлар да солдат абыйларын сәламлиләр иде шикелле. Туган якның тымызык кына искән җылы җиле дә тәнне генә түгел, җанны да иркәли сыман... Кояшы да яктырак, болытлары да аграк, күге дә зәңгәррәк... Ә инде еракта шактый зур булып җәелеп утырган туган авылын һәм кайсында озын-озын эскертләр салынган,

кайсында рәт-рәт салам күбәләре тезелешкән, ә бер урында инде сөрелгән чем-кара туфраклы басу-кырларны, үз артларыннан тузан болыты иярпеп әкрен генә хәрәкәтләнүче комбайннарны, аларга таба барганда тәрәзә пыялаларында кояш нурлары чагылып киткән житез машиналарны күргәч, Габделнурның күнеле бөтенләй нечкәрде, күзләре дымланды... «Туган җирем! мин сине гомерем буе сагынып яшәдем!»...

Аргы басулар да, биргеләре дә, кыскасы, туган авылының һәр карыш җире таныш... Әнә авылга таба бер машина ипи төяп кайтып килә. Җыйнак кына машина, артык кумый да, ләкин әкрен дә кыймылдамый.

—Әти булса кирәк,—дип куйды егет.

...Габделнур бәләкәй капканы ачуга ук әнисен күрде. Бәрәнге һәм кар базлары, аларның бирге башындагы суган түтәле тәбәнәк коймa белән әйләндереп алынган иде. Кар базы турысында, агач келәткә хәтле, коймага терәп утын әрдәнәсе өелгән. Әнисе сул кулының беләгенә ашыкмыйча гына утын салып маташа. Күтәрә алган хәтле салды да, буш булмасын өчен уң кулына бер ярка тотып, ул капкага таба борылды һәм, чемоданын баскычта калдырып, тиз-тиз ана таба атлап килүче солдатны күрде. Улын танып, сүз әйтергә өлгергәнче, Габделнур, җайлап кына әнисенең кулыннан утыннарын алып, әрдәнә өстенә куйды. Шуннан соң гына кулын сузды.

—Әни, исәнме!

—Исәнме, улым! И балакаем, кайттыңмы?!

Габделнур тартынып кына әнисен кочаклагандай итте. Кайбер халыкларда кабул ителгәнчә лач-лоч үбешүне әйткән дә юк, хәтта кочаклавы да аркасыннан кагу гына иде. Кечкенәдән үк төчеләнүгә өйрәнмәгән, күнекмәгән бала да, аларны шулай тәрбия кылган ана да беренче карашка салкынча, корырак исәнләштеләр кебек тоелырга мөмкин иде. Ләкин ананың мөлдерәмә яшь тулы күз карашы, улының зур кулын үзенең кечкенә учларына алып каты итеп кысуында, аны сыпырып-сыйпап торуында шулкадәр наз, җылылык, көчле сагыну ярылып ята иде. Артык сүз, артык хәрәкәт һич кирәк түгел иде бу минутларда аларга ана белән баланың якынлыгын аңлатырга.

—Әни, исән-сау торасызмы?

Гөлзифа түти күз яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртте. Сулу алды. Шуннан соң гына әйтте.

—Ару әле, улым. Үзең исән генә кайтып җиттеңме? Бөтенләйгәме?

—Әле белмим, ничек булыр. Экзамен бирдек тә, таралыштык.

Габделнур әнисе кулыннан алып куйган утын агачларын үзенең беләгенә сала башлады.

—Улым, бигрәк күп төйисең,—диде әнисе.—Киемеңне пычратырсың. Кая, үзем күтәрим.

—Каккач бетә ул.

Тугыз-ун адымны алар янәшә атладылар: моннан өч ел элек улын күз яшьләре белән изге теләкләр теләп, солдатка озатып калган, аны көн аралаш төшләрендә күргән, бер көн дә уеннан чыгармыйча иртә-кич аның исәнлегенә дога кылган, хәзер менә улы янында ничектер тагын да кечерәеп калган ябык гәүдәле ана һәм, шактый дөнья күреп, дары иснәп, солдат шулпасы эчеп кайткан төз буйлы, таза җилкәле улы.

Әнисенең өстендә җиңнәрен сызганып куйган чуар ситсы күлмәк, алъяпкыч, башына ак яулык бәйләгән, аягында йон оекбаш белән кызыл эчле кара галош. Гадәти авыл киеме. Ләкин Габделнур өчен алар дөньяда иң затлы кием. Чөнки аларны әнисе кигән! Борынгы көмеш беләзек белән гәрәбә муенса да Габделнурга кечкенәдән таныш. Чигә чәчләре тагын да агара төшкән, ябык булса да йөзе түгәрәк, һәрчак нурлы, ягымлы.

Гөлзифа түти улының исән-имин кайтуына шөкранә кылып, сөенеп,

сокланып туя алмый. Улы—ыспай яшел киемнән, төймәләре август кояшында ялтырап тора, кызларныкыдай нечкә билен киң каеш белән буган, аның да аелында кояш нурлары уйный, башында козыреклы фуражка, аягында күн итек. Ана өчен ул һаман бала, йөрәк парәсе. Ә бит элеккегә караганда олыгаеп киткән; гәүдәгә төз күренсә дә йөзе ябык чырайлы: чип-чиста итеп кырынган, чәче дә артык житү түгел.

Габделнур әнисеннән күзен алмый, үзе сораштыра.

—Әти эштәме?

—Ие. Комбайннан ипи ташый.

—Әбиләр ни хәлдә?

—Алар да бер көе. Арждак әбиең үз өендә яшәп ята.

—Суны син илтәсенме?

—Ие.

—Апалар килгәлиме соң?

—Апаң—сирәк... Кыз баланың... Бәндәләргә—бәндә бит ул, кыз бала, мескенкәем... Кияү ике көнгә бер димәсән, керел чыга.

Әнисе дә сорауга күчте.

—Улым, абыең беләме синең кайтасын?

—Юк.

—Энең белән хат язышасызмы?

—Әйе.

Ишек төбендә Гөлзифа түти:

—Бир, улым, моннан үзем алып керим,—диде.

—Юк инде. Әнә чемоданны гына ал.

Барысы да таныш: сап-сары итеп юылган, буялмаган баскыч, кожаннар эленгән карангырак өйалды, сул якта чолан ишеге, унда—веранда, клеенка белән тышлап жылытылган өй ишеге... Габделнур ничек кенә тырышып иелсә дә бусаганы атлап кергәндә фуражкасы чак кына төшеп китмәде.

Утыннарын мич каршына куеп, ул ачык ишектән сак кына олы якка күз салды. Әбисе намазга утырган икән.

Ана улына дәште.

—Улым, өстеңне сал.

—Ярар.

Шулай дисә дә Габделнур кителен салмады, чөнки аның өстендә якасыз ак солдат күлмәге иде.

—Улым, утыр. Тәпи өсте торма.

Габделнур, күнеле нечкәреп, өй эчен—бәләкәй якны күздән кичерде: әнисе таш катыгы белән агарткан ап-ак мичне дә, тәрәзә каршындагы озын өстәлне дә, ике тәрәзә арасына эленгән, рамы бизәкле борынгы көзгене дә, стена буендагы, түшәк-ястыгы жыештырып-өеп куелган тимер караватны да, иске урындыкларны да (икесе—артсызлары өстәл астына этәрелгән). Бөтенесен хәтерли, һәрберсе үз урынында: матча кашагасы, сөлге-тастымаллар, юынгыч... Түшәмнең киң нарат такталары бераз түбән төшкәнме, әллә инде сап-сары итеп юылган идән сайгаклары чүт кенә өскә калыкканмы, һәрхәлдә, өй ничектер тәбәнәкләнеп калган шикелле иде. Әллә егет үзе үсеп киткәнме? Кечкенә чакта иске шкаф янына басып, аның почмагын пәке белән киртләп-киртләп куялар иде. Ул олы якта... Исән микән әле?..

Габделнур, өйалдына чыгып, итеген, фуражкасын салып керде. Ачык ишектән олы якка күз ташлады. Әбисе, намазын тәгәлләп, торып килә иде. Габделнур бусаганы атлап керде, аңа дәште.

—Әби, исәнме?!

Әбисе башта аптырабрак калды, күзләрен йомгалап алды, аннары, оныгын таныгач, йөзе ачылып китте.

—Ай Алла, кем бу, дип торам. Исәнме, улым, исәнме?!

Алар бик җылы күрештеләр, хәл-әхвәл сораштылар. Кызгылт-чуар француз яулык бәйләгән, озын күлмәк кигән, йөзен җыерчыклар яргалаган әбисенең яше шактый булса да әле гәүдәсен туры тота, ябык, үзе әйтмешли, чәүкә чукырлык та ите юк. Шулай да аның чирләп урын өстендә ятканын Габделнур хәтерләми. Әбисе белән күрше авыл урманнарына (үзләрендә урман түгел, бер агач та юк) чия, миләш җыярга барган чаклары исенә төште Габделнурның: терек-терек җәяү атлыйлар иде барганда да, кайтканда да... әбисе артыннан көчкә өлгереп. Әбисе мунча ярата иде. Хәзер дә шулай микән? Кайчагында көненә икешәр тапкыр да керә. Әнисенең, кием черетеп, дип сукранганы бар иде. Ике керүнең сәбәбе шул: күрше-күлән алар мунчасына яга да, карчык-корчык иптәшкә бер-берсен дәшә.

Габделнур кечкенә чагында әбисенең аны ләүкәгә сузып салып, ай-ваена карамыйча, акырта-бакырта каен себерке белән чапканын һич онытмый. Үсә төшкәч, егет өчен мунча яхшы гадәткә әйләнде.

Әбисе диванга утырды, солдат—артлы урындыкка. Ишек янындагы кыйбла як почмакта туку станы тора иде. Ул инде иске, кем әйтмешли, кадими заманыннан калган. Ләкин әле дә хезмәт итә икән: корылган, соса һәм кылыч-шүреләре үз урынында, аркау җепләре тартылган.

—Әле һаман палас сугасыңмыни, әби?—дип сорады оныгы станга таба ымлап.

—Тик торганчы,—диде әбисе, дисбесен тәрәзә төбенә куеп.—Идәнгә генә ул...

Чыннан да, идәнгә тар палас җәелгән—каты җептән—яна, ә әбисе йоклый торган караватның паласы—төрле төсләргә манылган йон җептән сугылганы иске—аңа таныш иде.

Туку станы янында, идәндә, каба, аңа йон бәйләп куелган, орчык кыстырылган.

Әбисе шушы авыл кызы. Аның өч апасы күрше авылларга кияүгә чыкканнар, ә абыйсы белән энесе читкә китмәгәннәр. Абыйсы беренче бөтендөнья сугышында немецләрнең газ атакасына эләгеп, сукыраеп кайта, инде вафат, энесе исән, Урта урамда яши, ул да сугышта булган, ләкин соңгысында.

Әбисе сигез бала таба, өчесе кечкенә чакта ук дөнья куя. Хәзерге көндә өч кызы һәм бер улы—Габделнурның атасы—исән. Ә аның энесе...

Оныгының уйларын белгәндәй, әбисе:

—Улым, Зыяфетдин абыеңны күрмәдеңме?—дип сорады.—Син ерак җирләрдә йөрдең бугай бит.

—Юк шул, әби, күрмәдем.

—Төшкә гел кайтыр төсле керә...—диде әбисе һәм үзалдына сөйләнеп алды.—Ай кайтсын, көн кайтсын, газиз бәбкәем кайтсын... И-и, кайтмас шул инде, кайтырлык җирләрдә түгелдер...

Әбисенең кече улы сугышта хәбәрсез югалган. «И әби, әле һаман көтәсең икән. Инде сугыш беткәнгә егерме ел була бит». Габделнур Зыяфетдин абыйсын белми. Карточкасын гына күргәне бар. Исталеккә калган. Чистай медицина училищесында бергә укыган иптәше белән төшкәннәр. Зыяфетдин үзенең абыйсына, ягъни Галләм абзыйга, тартымрак озынча йөзле, туры борынлы. Фотода ул житү чәчле, өстендә пиджак белән ак күлмәк һәм эре кыек сызыклы киң галстук, түшендә ниндидер значок. Ул сугышка киткәндә Габделнур әле тумаган да. Ә менә бабасы үлгәндә аңа ике яшь була.

Ике олау белән Чаллыдан кайткач, ул атларын да тугара алмыйча, хәлсезләнеп, өйгә кереп ята. Кулын чак кына кыймылдатып, агач кашыклар белән идәндә уйнап утырган Габделнурны үзенә чакыра... Боларны ул әнисе

сөйләве буенча гына белә. Әнисенең, бабаң белән, ягъни кайнатасы белән, сөйләшми идек, дип тә әйткәне бар. Әйе, элек килен балакай каенатадан гына түгел, анын абый-энеләреннән дә «тел яшергән». Хәзерге кайбер «отчаянный» киленнәр кебек пәрмә-пәр әйткәләшүне уйлаган кеше дә булмаган. Билгеле инде, каенанага да кадер-хөрмәт зур булган. «Киленкәе эштән кайта—Берлинны алган кебек, каенанасы дер калтырый—пленда калган кебек» дигән такмаза соңгы сугыштан соң гына чыккан булса кирәк.

«Бабай иртәрәк киткән шул, әле алтмышның өстенә генә чыккан була югыйсә»,—дип уйлады Габделнур.

Хәзерге алтмыш яшьлек кешеләр генә түгел, аннан өлкәнрәкләр дә сакал-мыек йөртми. Ә бабасы турында:

—Мин әткәйнең сакал-мыексыз чагын белмим,—ди торган иде Габделнурга әтисе.

Бабасы бик җор телле, шук кеше булган. Анын уң аягының бармаклары герман сугышында өзелгән, күн итек башына чүпрәк тыгып куя икән. Бервакыт, Чаллыдан кайтканда, каршыга очраган күрше авыл олаучылары белән, сүз иярә сүз чыгып, бәхәсләшә.

—Бөтен арбаларыгызның тәгәрмәчләрен аяк башыннан чыгарам. Түзәм.

—Юк, чыдый алмыйсың!—дип кызып китә тегеләр.—Үткәрсәң, бер литр спирт куябыз.

Аларның спирт заводыннан килүләре икән. Билгеле, «бик авырлык белән чыдый» карт һәм соңгы тәгәрмәч «аяк йөзен изеп» китүгә ухылдап җиргә ава...

Бәхәс димәктән, юлда андый хәлләр еш булгандыр, күрше авылның бер кешесе, бәхәсләшеп, икенче берәүнең күн итек башын олтаны-ние белән тешләп өзгән, дип сөйлиләр.

Икенче әбисе—әнисенең анасы—Урта урамда яши иде. Габделнур анын хакында да сораштырды.

—Кодагый әле исән генә йөреп тора, безгә дә килгәли, мине дә чәйгә чакыргалый,—диде әбисе күңеле булып.

Олы якта да әйбер-кара үз урынында, әллә ни үзгәреш юк: ишектән кергәч тә сул якта, караңгы стенага якынрак, калай белән тышланган түгәрәк мич, ике караватъ, түгәрәк өстәл тирәли берничә урындык, саргылт төстәге шифоньер. Өстәл өстендә зур гына радиоалгыч, патефон, янәшә—үтүк. Урам яктагы өч, верандага караган ике тәрәзәнең пәрдәләре ак, чигүле. Тәрәзә төпләрендә берничә төрле гөл чәчкә атып утыра. Ун телле тальян гармуны күренмәде. Шкафтадыр, мөгаен.

Әбисе белән бераз гәпләшеп утыргач, Габделнур бәләкәй якка чыкты. Ул арада әнисе самавырга су салды, йомырка тезде, капкачын япты да чыра белән ут тергезеп җибәрде, комфоркасын кигезеп күмер салды, торбасын мичтәге тишеккә тыкты...

Әнисенең кулларына карагач, Габделнурның исенә төште: бервакыт, келәттә лар кучергәндә, анын бер бармагы олы агач әрҗә астында калып, яньчелгән иде.

Әнисе ул чакта тыныч кына:

—Балалар, чак кына күтәрегез әле, кул кысылды,—диде.

Карасалар—яньчелгән икән, кара кан ага... Никадәр сабырлык биргән ана Ходай! Хәзер ни хәлдә икән бармагы? Икенче вакыт, бәрәңге базын саман кирпеч белән әйләндергәндә, башына кирпеч төшкән иде. Күпме эш эшләгән үз гомерендә бу бәләкәй, ләкин каты, нык, көчле куллар! Өйдәге эш, беркөн калмый йөргән колхоз эше... Эш... эш... Урагын да урган, чүбен дә утаган, бәрәңгесен дә казыган... Кем аларны санап бетергән дә, кем исәбен алган?!

—Улым, Мәһрүсә апаңнар ни хәлдә?

Сүз әнисенен Казанда яшәүче туганнан туган апасы хакында бара иде.

—Әйбәт кенә. Сәлам әйттеләр.

—Сәлам китерүенә рәхмәт. Кызы укыймы, эшлиме?

—Укый. Әле унбиштә генә бит.

—Мәһрүсә үзе чирләмиме соң?

—Буладыр инде. Ул вредный цехта эшләп пенсиягә иртә чыккан бит.

Габделнур чемоданыннан Мәһрүсә апасы җибәргән һәм үзе алып кайткан әз-мәз күчтәнәчләрен чыгарды, янә бер кат сәламнәрен ирештерде.

—И улым, рәхмәт инде,—диде Гөлфизә түти өстәл янында мәш килеп.— Син үзең безгә күчтәнәч. Бу юлы бик озак кайтмый тордың. Берчакны, мунча артында керләр элгәндә: «Әни!» дип эндәшкәнеңне ишеттем. Бик сагынганмындыр инде. Икенчеләй, чишмәгә суга барам сине уйлап. Кинәт: «Әни!» дигән тавыш килә. Як-ягыма каранам, үзем шикләнәм. Чишмә буенда утырып жыладым. «Юләрләнә күрмим тагы»,—дим үземә.

—Әни, алай бик еш уйлама инде,—диде Габделнур елмаеп.

—И улым, бала—бавыр ите, дип юкка гына әйтмәгәннәр инде. Бигрәк яшьли чыгып киттең шул.

—Әни, колхоз эшенә йөрисеңме соң?

—Йөрмәгән кая... Әле кичәле-бүгенле, башым авыртып торгач, сорап калганыем.

Бераздан Габделнур чемоданын верандага алып чыкты. Кайтканда чишмә буендагы болыннан өзеп алган, чалбар кесәсендәге «исле үлән»не чемодан төбендәге мактау грамоталары арасына кыстырып куйды, үзе уйланды. Әнисенә, алай бик еш уйлама, дисә дә, бер генә минутка аның хәленә кереп карады. Күбрәккә китә икән шул бер кешегә: әтисе өч ел сугышта булган, абыйсы тиешле срогын хезмәт итеп кайтты, Габделнур үзе әле бетермәгән, инде энекәше киткәнгә дә бер ел тула. Йөрәге генә чыдасын!..

Чәйгә утырганчы Габделнур «патшалар җәяү йөри торган җир»гә барып киләсе итте. Өйдән чыгуга ук биләмнән кайтып килүче песине күрде. Ул солдат абыйсына күтәрелеп бер карады да баскыч янына килеп утырды. "Актүш әрәм булган",—дип уфтанды, чөнки этнең үлеме турында хатта язганнар иде инде.

Каршыдагы бакчада, шомырт һәм миләш агачларында, чыпчыклар чыркылдаша, аларның бер төркем иптәшләре туры лапас өстендәге яңа кайткан саламны да сырып алган. Лапаста кызгылт төстәге бозау утлыктан нидер чемченә иде, ят абыйны күргәч, капка янына килеп, тәбәнәк койма өстеннән юеш борынын сузды. Аның аяк астында да, ишегалдында да тавыклар жим эзләп йөри, карт әтәч, башын горур тотып, аларны бөртек күбрәк жиргә чакыра. Тавыклар, генерал артыннан ияргән офицерлар шикелле, аның күз карашын тоеп, һәр хәрәкәтенә буйсынып, бөтен теләкләрен дә үтәргә әзер тора. Кое сиртмәсенә кунган саескан да, бу кем тагы монда тулгана, дигән сыман, Габделнурга карап алды. Солдат бакча капкасын ачып, эчкә үткәч, чиләге булмаса да, коега килә ахры бу, бәладән баш-аяк, диептер инде, озын койрыгын сузып, очып китте һәм келәт түбәсенә барып кунды.

Әбрәкәй кечерәеп, тараеп калган, кысан, баш тия—чак кына фуражкасы төшеп китмәде. Өч ел зур-зур гомуми бәдрәфләргә өйрәнгән кешегә монда бик жайсыз иде. Югыйсә, әллә ни үсмәде дә сыман, бер-ике сантиметрга гына. Алабугада укыганда гына өч елга егерме бер сантиметрга үскән иде.

Габделнур, арт капканы ачып, бәрәңге бакчасына күз салды. Өлгереп килүче бәрәңге сабаклары әле ямь-яшел. Күршеләрнең дә бәрәңгеләре унар шикелле. Бу жир гомер-гомергә аларны туендырды. Сугыштан соңгы ачлык елларны, яз көне черек бәрәңге жыяр иде халык, кабартма сыманрак итеп юка гына кәлжемә пешерер иде. Ләкин ул әллә ни туклыклы түгел иде шул.

Шуңа күрә дә халык арасында такмак йөри иде.

Кәлҗемә, кәлҗемә,
Нигә чәчәк атмыйсың?
Күпме генә ашасам да
Йөрәгемә ятмыйсың.

Сарай-чиннек артындагы бакчада карлыган куаклары куе, биек булып үскәннәр; аларны бәрәңге бакчасы ягыннан әйләндереп алган койма искергән, җепсәләре ярылган, муртайган, алыштырырга вакыт икән...

—Әти—берүзе, абый эштән бушый алмый торгандыр, энекәш—армияда,—дип куйды Габделнур кеше белән сөйләшкәндәй.—Менә мине дә, ай күрде кояш алды, диярлек кенә, берничә көн генә торам да китеп барам. Ярар, исән булсак, отпускыларда кайткаларбыз.

Мунча каршындагы куакларны аралап, бер-ике кура җиләге тапты. Баягы саескан мунча түбәсенә килеп кунган. Мунча ишегендә йозак-фәлән юк, келә урынына да бау бәйләнгән түгәрәк тимер кисәге генә тыгып куелган иде.

...Ашагач, Габделнур, рәхмәт, дип урыныннан күтәрелмәкче булган иде, аны әбисе туктатты.

—Улым, амин тотмадың бит.

Габделнур, гаеп эш өстендә тотылган кеше сыман, кыенсынып кына:

—Өч ел казармада яшәп, онытылган икән,—диде һәм, кул күтәреп, бит сыпырды.

Каенанасы олы якка палас сугарга чыгып киткәч, Гөлзифа түти улы янынарак утырды.

—Улым, син догалар беләдериең бит. Онытмадыңмы?

—Юк, әни,—диде Габделнур көлеп.—Сөйләп күрсәтимме? Әлпи, тиси, әнә бара бер песи, коерыгын кәкерәйткән, анасына кайтып әйткән...

—И улым...

—Ярар алайса, икенчеләрен укыйм. Әлхәм тәбәрәк, җилкәм тагарак, әлхәм шөкер, жилкәм чокыр. Кәлимәтен, таебатын, безнең әнкәй бай хатын, кесәсе тулы тәңкә, танавы тулы...

—И улым, алай мыскыл итмә инде. Мин бит сиңа «Әлхәм»не дә, «Колхуалла»ны да өйрәткәнием.

—Соң, аның боларын да син өйрәттең инде.

—Анысы шаярып кына бит аның. Без дә олылардан отып алганыек инде.

—Беләм, әни, берсен дә онытмадым. Тик аларны кеше алдында укып, дога кылып утырып булмый бит.

—Күңеленнән укып йөр белгәннәреңне, сине кеше тикшермәс, юлларың уң булыр. Кояш чыккан чакларда бисмилла әйт. Мин сезнең өчен көн дә теләк телим, балалар. Ходай рәхмәтеннән ташламасын. Тәннәрегезне тәмуг утларына хәрам кыл... Улым, бик ябык күренәсең.

—Безгә күп ашарга ярамый, фигура бозыла,—диде Габделнур елмаеп.—Әни, үзең әйтмешли, арык тәнем сау булсын.

—Тамагыңа аша, ач йөрмә. Ябыккансың. Син бәләкәй чакта түм-түгәрәк иең. Элек авылда түгәрәкләр эшләде бит. Түгәрәккә барыгыз, дип әйтеп йөриләр ие. Син шунда, мин үзем түгәрәк, без бармыйбыз, дип әйтә торганыең. Көлеп чыгып китәләр ие.

Тагын бераз сөйләшеп утыргач, Габделнур:

—Әни, мин келәт арасына барып кайтам,—диде.—Берочтан әбине дә күреп чыгармын.

—Рәхмәт, улым, бар, бар.

—Коедан су алып керәсе юкмы?

—Иренмәсәң, бер чиләк кенә керт. Чиләк өйалдында, каплап куйган.

—Беләм.

Дөресен генә әйткәндә, Гөлзифа түтигә әле су кирәкми иде. Шулай да улынын теләгенә каршы килмәде. Баласынын нинди дә булса эш эшләргә атлыгып торуы, әнисенең исә шуны башкарып чыгарга рөхсәт бирүе—икесенә дә рәхәт иде әлеге минутларда.

Габделнур су алып кергәндә әнисе өстәлдәге жилпучка он иләп бетергән дә, анын урынына куна тактасы куеп, камыр басарга әзерләнә иде.

—Әнә шунда идәнгә куй, улым,—диде ул.

Габделнур, чиләкне урнаштырып, мич артына күз салгач, үзалдына елмаеп куйды. Элек мич артында бауга тезелгән, кызлар чәче сыман үрелгән суган асылынып торыр, аралыкта лакан, тас һәм комган була иде. Авылнын бер кызы, күпмедер вакыт шәһәрдә яшәп, кунакка кайткач, зарланып әйткән, имеш: «Шушы авылга кайтсан, тас та кумган булыр инде». Кемгә ничек, ләкин Габделнурга балачак хатирәләренә чуму, кечкенәдән күреп үскән йорт җиһазлары арасында кайнашу—әйтеп бетергесез юаныч, күнел тынычлыгы бирә иде.

## XVII

Габделнур урамга чыкты. Иркенләп һава сулады. Кем әйтмешли, күкрәкләре киңәеп китте. Аһ, нинди рәхәт үз авылында, аунап-тәгәрәп үскән урамында!.. Үз яшьтәшләреннән генә дә унлап малай булгандыр; бер-ике яшькә олыраклар яки кечерәкләр жыелса, урам гөр килеп торыр иде җәен дә, кышын да... Әле бит малайлар янында кызлар да була... Хәзер инде урам тынычрак. Хәер, әнә бер төркем бала-чага чыр-чу килә, бер-икесе велосипедка атланган. Ерактарак өлкәннәр дә күренә: капка төбендә утыручы карт-коры, иңнәренә көянтә-чиләк асып суга баручы хатын-кыз... Этләр дә күзгә чалына—җанлы урам үзенең гадәти тормышы белән яши. Бакча эчләрендә алма һәм чия, урамда—өрәңге, тупыл һәм тирәк агачлары.

Әүмән-тәүмән килеп бер оя үрдәк су буеннан кайта. Габделнур үскәндә дә, хәзер дә алар гаиләсе үрдәк асрамады. Үрдәк, ни бирсәң дә һаман, вак, вак, дип зарлана, ә беришә әрсезе, бак-бак, өеңне сат, безне ашат, ди бит. Бәлки шуна күрәдер авыл халкы күбрәк каз тотты, әби-чәби гомергә болында, су буенда бәбкә саклады. Хәер, бер абзый үрдәк тә асрады асравын. Ләкин ул аларга тозлы су эчертә торган булган... су буеннан кайтмасыннар өчен.

Күркә асраучы да бар иде әле алар урамында. Ул йортнын хуҗасы Донбасстан кайткан шахтер иде. Алар энесе белән икәү эшләгәннәр. Энесе шахтада басылып үлгәч, аналары монысын кайтартты. «Хет берсе янымда булсын, исән калсын», дип әйткән. Хатыны, татар кызы булса да, шул якта туып үскәнлектән, татарча авырлык белән сөйләшә, ләкин авылча гади, җинел итеп түгел, ә һәр сүзен жиренә житкезергә тырышып әйтә иде. Теле йөгерек булмаса да, сөйләме матур. Үзе дә ул бик чибәр, пөхтә итеп киенеп йөри. Бәлки анын туган якларында күркә асрау гадәте булгандыр... “Сыкы белән күркә симерә”,—дип күркәләрен кышка кергәндә, сыкы төшкәч кенә суялар иде.

Күркә ул талый, кызыл киемле хатын-кызларга каныга. Хәер, каз да талый, бигрәк тә ата каз: чукып кына ала, сизми дә каласын. Күршедәге бер егет (яшьтәшләре инде армия хезмәтендә иде) Габделнурларга коега суга кергәндә, гел анын абыйсыннан яклау сорый иде.

—Ата казыгыз талый, ку әле!

Югыйсә, кулында чиләкләре бар, тибеп җибәрсә дә яки чыбык тотып керсә дә була. Күрәсен, кеше малына тияргә кулы күтәрелмәгәндер инде.

Габделнур, урамнан тыкрыкка борылганчы, чаттагы йортка кереп, анда яшәүче күрше карчыгынын хәлен белеп чыкты. Әле исән икән. Егет армияга

киткәндә бу әби, машинаны туктатып, аңа бер сум акча биргән иде. Өч ел буе шул исеннән чыкмады. Юкса, үз әбиләре дә бирде, әти-әнисе, туган-тумачасы да. Саубуллашырга дип кузовтан иелгән Габделнурның учына төрткән бер сумы гел хәтерендә сакланды.

Тыкрыкка борылды. Бәләкәй мотоциклга атланган бер үсмер исәнләшеп китте. Алда—унга-сулга ерак-еракларга сузылган Урта урам, аның артында тагын бер урам, анысы кыскарак. Бу авылның өч урамы да бер-беренә буйлай бара. Авыл башында буровой вышкасы, арырак икенчесе...

Тыкрыкның ике ягына да бәрәңге бакчасына мал кермәсен өчен сирәк киртә тотылган.

Кая гына караса да, кайдан гына барса да солдатның хәтеренә нидер төшә.

Әле бик бәләкәй иде Габделнур. Шушы тыкрыкта бер апага, сабый акылы белән аңламыйча, кушаматы белән эндәшкән. Соңыннан бу апа Гөлзифа түтигә (алар чордаш-ахирәтләр икән), и малай, гарьләндем дә соң, улың, исәнме, Женле түти, дип эндәште, дигән. Күрәсең, зиһене ачылган вакыт булгандыр, зиһене томаланган чакта аны исендә калдырып, күңеленә авыр алмас иде. Әнисе әрләп тә ташлаган иде Габделнурны.

Ә икенче вакыт, монысы бераз үсә төшкәч булды, ап-ак чиста киемнән—чигүле алъяпкыч, бәбәй итәкле күлмәк, тула оектан—йөрүче берәүгә:

—Исәнме, әби,—дигән иде.

Бала бит, каян белсен аның соңгы сүзе тегенең күңелен рәнҗетәсен.

—Фәлән нәрсәңә җон чыксын әле, аннан миңа, әби, диярсең,—дип, дулап китеп барган иде теге апа.

Хәзерге акылы белән уйлый Габделнур: күрәсең, ул «әби»гә әле кырык-кырык биш яшьләр тирәсе генә булгандыр, ире сугышта үлгәндер...

Сабый күңеле барысын да ничек нечкәртеп торсын да, кемнең нинди уй белән яшәгәнен каян белсен?! Аны өйрәткәннәр, колагына тукыганнар: үзеңнән олылар белән исәнләшеп үт! Һәм ул шулай итә дә, бетте-китте вәссәләм! Ә кайчагында синең бу «тырышлыгың» кемнедер кимсетү булып чыга, хәтерен калдыра икән.

Моннан, тыкрыктан караганда, агачлар арасына күмелеп утырган мәктәп тә күренә. Мәктәп ихатасын биек тупыл агачлары әйләндереп алган. Кайчандыр аларны Габделнурның абыйлары утырткан һәм тәрбияләп үстергән.

—Директор коштабак белән сыер тизәге алып килергә куша иде яна утырткан тупылларның кәүсәләрен сыларга,—дип сөйләгән иде абыйсы бервакыт.—Кәҗә ашаган җирен...

Анда җиде ел уку дәверендә Габделнур хәреф танырга өйрәнде, бик күп фәннәрне үзләштереп аң-белем алды; концерт-спектакльләрдә катнашты; әдәби кичәләр дә оештырдылар алар; мәктәп бакчасында эшләделәр; чаңгыга басып, турникта атынып, колгадан яки арканнан үрмәләп көч-куәтләрен арттырдылар, беләк мускулларын ныгыттылар; тәнәфесләрдә (кайчагында дәрестә дә) шаярдылар-шаулаштылар, мәктәптән кайтканда бер-берсен дөмбәсләп, кызып китеп сугыштылар да... Барысы да булды җиде елда. Саный китсән, аларның исәбе юк! Ләкин кайчагында шуклык кылулары, укытучыларны борчыган мәлләре дә бихисап булды. Хәзер менә шулар исенә төшеп, ниндидер сагыш, үкенү сыман нәрсә өскә калкып чыга.

Бервакыт, авылга буровой бригадасы килеп урнашкач, рус теле укытучысы, яшь кенә кыз, бер егет белән йөри башлады. Бала-чагадан яшереп буламыни андый хәлне? Бигрәк тә малай-шалайдан. Малайлар клубка кино карарга дип чыгалар. Алар билет алган кешеләр арасына кысылып яки алданрак керәләр дә, сәхнә астына үрмәләп, кино башланганчы шунда качып яталар. Анда рәхәт түгел: кысан, тынчу, кайчагында эче киткән берәр малайның

нәжесенә дә буялып чыгасын. Ә шулай да кино карыйсы килү теләге барысына да түзәргә мәҗбүр итә.

Ул көнне малайлар әле клуб тирәсендә йөриләр—ничек тә качып керергә исәп иде. Укытучы кыз белән «буровой» егет тә клубка киләләр икән, житмәсә, кычкырып сөйләшәләр. Шунда малайлар Шура апаларының тавышын аермачык ишеттеләр.

—Тише, тише, Николай, ученики есть.

Икенче көнне, рус теле дәресе башланыр алдыннан, Габделнур кара такта янына чыгып басты һәм ишектә маржа апалары күренүгә сөрән салды.

—Тише, тише, Николай, ученики жис!

Ул йөгереп барып партасына утырды.

Укытучы кып-кызыл булды, класс журналын һәм китап-дәфтәрләрен өстәлгә атып бәрде.

—Гаделзянов, выйди из класса!—дип кычкырды ул.

Габделнур чыгарга уйламады да. Шура апалары, озын аяклары белән олы-олы атлап, ул утырган парта янына килде. Тагын үзенен боерыгын кабатлады.

—Вон из класса!

Шушы укытучы аркасында урысча ярыйсы гына сукалый башлаган Габделнур:

—Не выйду!—диде һәм чытырдатып партага ябышты.

Янәшә утырган укучы кызны торгызды да, көчле, таза куллары белән укытучы калын такталардан эшләнгән авыр партаны бөтереп йөртә башлады. Ләкин бәләкәй малай бирешмәде. Ахырда, укытучы аны калдырып, такта янындагы өстәл артына утырып, елап жибәргәч, класстан чыгып ычкынды. Билгеле, соңыннан тәртип бозучыны директор чакыртты. Ә анысы, ир кеше, күп сөйләшеп, вакыт сарыф итеп мәшәкатьләнмәде, Габделнур бүлмәгә килеп керүгә яңагына чалтыратып та жибәрде: малайның күзеннән утлар күренде...

Икенче вакыт, малайлардан кайсыдыр шаярып утырганда укытучы апалары (кем икәне дә, нинди фәннән укытканы да хәтерендә түгел) бармак калынлыгы линейка белән тондырды. Сулагай кулдан чыгып очкан саллы линейка күршедәге бер гаепсез кызның танавына эләкте. Әйтерсең акыртып суялар: кызый чырулап, үкереп елап жибәрде; борыныннан гөжләп кан китте. Апалары йөгереп кенә чиләк белән су алып керде, юды, маңкасына тикле сөртте, юмалады—ике дәфтәр белән бер бозгыч биреп бәхилләтте.

Әйе, мөгаллимнәр дә бик «тәвәккәл»иде элек. Химия укытучысы, шаярып утырганыңны күрсә, дәшми-нитми генә килә дә, сөяк белән тиредән генә торган беләгеңне узып барышлый гына шундый итеп чеметә, астына жибәрердәй буласың. Ә математик абыйлары малайларның «мингерәү» башын йодрыгының чыгыбрак торган урта бармагы белән төя-төя «акыл бирә» иде: «Башыңны эшләт, ангыра бәрән, башыңны эшләтмәсәң, миең ачы катыкка әйләнер». География укытучысы гел колакларын бора торган иде. Малайлар жаен таптылар: аның дәресе алдыннан колак яфракларына каз мае сөртә торган булдылар...

Яманы да, күнелле мизгелләр дә, авыр чаклар да—барысы да булды жиде елда. «Балалык юләрлеге белән ачуыгызны чыгарып, кәефегезне жибәреп, рәнжеткән чакларыбыз өчен гафу итегез безне, хөрмәтле һәм кадерле (моны соңрак аңладык!) укытучы абый-апаларыбыз! Булдыра алсагыз, кичерегез эчкерсез, гади авыл балаларын!.. Без сезнең педагогика кысаларына сыймаган, кайчагында гел юктан гына артык уяулык, кирәкмәгән кырыслык күрсәтеп, безне кыерсытуларыгызны күптән кичердек инде... Без сезгә ачу сакламыйбыз...»

*Дәвамы киләсе санда*



Фәүзия
Солтан

# БАЛЛЫ МИЛӘШ ҺӘМ КОШ ҖЫРЫ

* * *

Дивардагы рәсемемнән
Миңа яшьлегем карый:
Җитди генә күз карашы
Киләчәгемне барлый...

Бик еракта калган инде
Чәчәкле унсигезем.
Суык баллаган миләштәй
Каршылыйм гомер көзен...

* * *

Көн ачылып китсен өчен
Бер елмаю җитә кебек:
Ул елмаю җирдән күккә
Алып менеп китәр кебек.

Кулларыңны иңгә куеп,
Бер карасаң күзләремә—
Басылыр күк ярсуым да,
Очкынланыр күзләрем дә...

Туры карап әйтсәм әгәр,
Ачуланма юкка, диеп:
Аңларсың да—елмаерсың,
Күзләремә карап, сөеп.

## Күңел назың

Тормыш юлың—ап-ак чәчләреңдә,
Күзләреңдә—үткән гомерең,
Көтмәгәндә әйткән җылы сүзең
Бәлзәм булып назлый күңелем.

...Хыянәтнең әче ярасыннан
Күмерләнгән йөрәк, каралган:
Кабат янар өчен ачкычы да—
Синең назың, алтын баганам...

Аңла мине, кайчак, ышанмыйча,
Кабындырсам йөрәк ярсуың:
Авыз пешкәч өреп эчәсең бит
Чишмәнең дә салкын саф суын...

Фәүзия СОЛТАН – *шагыйрә; «Учларымда җиләк», «Үзәк өзелгән чак» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

* * *

Ниләр көтә алда безне?
Тынгы бирми уй-хыяллар.
Алда—аласы биеклек,
Алда—менәсе кыялар.

Кыя-киртәләр үткәндә
Егылмаска, чүкмәскә,—дим.
Күңел очкынын сүндерми
Өметләрне өзмәскә!—дим.

...Язгы ташкын ярны яргалый.
Әче сүзләр йөрәк яралый.

## Кыйблага тугрылык

Яшәр өчен без килгәнбез икән—
Хәсрәтләрне күрми китмәбез.
Күк йөзендә сүнгән йолдызлардай
Берәм-берәм янып бетмәбез.

...Янган хисләрне без сүндермиек,
Яраларны кабат кузгатмыйк:
Яшәргә дип килгәч, дөньялыкта
Кыйблабызны гына югалтмыйк.

## Халәт

Диңгез тирәнлеген белеп булмый
Югарыдан гына таш ташлап...
Диңгезченең хәлен белер өчен
Үзең кара—диңгезләр айкап.

## Өмет гөле

Яран гөлем, нигә саргаясың?
Сагышларым синә күчтеме?
Сердәшем дә, күңел ачкычым да
Син идең бит. Шиңмә, түз инде!

Мин сөенеп, очынып йөргәндә
Бүләк булып чәчәк аттыңмы?
Моңланамын—яфракларың сары,
Хисләремне үзеңә алдыңмы?

Шау чәчәккә күмел әле, гөлем.
Тамырларың исән бит әле.
Чәчкәләрең белән сөендереп
Яшиселәр алда ич әле!

## Шулай булса иде...

Төшермәскә иде күңелләрне,
Сөю хисен саклап, гомергә
Язсын иде бару ахыргача,
Һәм барысын тигез бүлергә.

Сүрелмәсен иде янган күңел,
Бирешмәскә иде ваклыкка.
Борчымасын иде шикләнүләр,
Юл ачылсын иде хаклыкка...

Булсын иде безгә пакълек юлдаш
Атлаганда бергә янәшә...
Мәхәббәтне саклый күрегез, дип
Гүя безгә Ходай эндәшә.

## Кош җыры

Оя корып, оя үреп
Үткәрдем гомеремне...
Яңа Оя корам әле,
Искесен җимеримме?

Яннарымда гомер бергә
Кошчыкларым булырмы?
Канатларым, җитезләрем
Яңа Оя корырмы?

Яңа Оя үрдем, ләкин
Искесен җимермәдем.
Чүп-чарлардан аралдым,
Гөлләр белән бизәдем.

Үреп ясаган Оя́ма
Үтмәс һич салкын, яңгыр.
Туңдырмас көчле бураннар
Һәм җимермәс җил-давыл.



# Фәния Чанышева

## Туган көнем

Әниемнең теләп йөрегәнен
Ахыры алдан тоеп торганмын…
Арыш чәчеп, солы урагын да
Тәмамлагач кына туганмын

Кырда үткән минем туар көнем
Энҗергәчә зәңгәр иртәдән;
Алтын нурлар кунган күзләремә
Сары камыл, сары көлтәдән.

Кыр казлары бездән китәр мәлдә
Ырыс белән җиргә килгәнмен.
Нәкышьләре, сагышлары белән
Күңелемдә йөртәм көз ямен.

…Мин тугызның берсе булып үстем,
Мәхрүм түгел ләкин кадердән:
Кышкы кичләр, Тукай шигырьләре,
Күңел бәйрәмнәре хәтердә…

Әти, мин бит сиңа сыенып үттем
Яшел тасма—арба юлларын.
Җылы яңгыр, җәйгорларга[1] кушып,
Күңелең гәүһәрләрен җыйганмын.

Шуңадыр да серен белгәнмен бит
Бөре, яфрак, бәбәк, һәр гөлнең;
Кош сайраса, урман шауласа да
Җаным дертли, ярсый күңелем.

Сабый чакның нурлы утравында
Синең белән атлыйм тагын да.
Димәк, дәвам итә синең җырлар,
Шигъри рухың яши җанымда.

---

[1] Җәйгор—салават күпере.

Фәния ЧАНЫШЕВА—*шагыйрә; башкорт, татар телләрендә басылган берничә китап авторы. Башкортстанда яши.*

* * *

*Материя мин, җаным, аның бары*
*Уйлый, җырлый, сагына торганы.*
Х. Туфан

**Булды, хакыйкате артка чигеп,**
**Иңнәреңне басты ялганы,**
**Әрнүләрнең бардыр күңелеңдә**
**Мәңгелеккә торып калганы.**

**Булды карлы-бозлы коеннарның**
**Синә гына атап яуганы,**
**Сагышларның сары койганнары,**
**Кайгыларның йөрәк ярганы.**

**Тын кичләрдә ерак офыкларга**
**Карап күзләреңнең талганы,**
**Туган якка аккан болытларны,**
**Кыр казларын озатып калганың.**

**Бирешмәде ләкин шигъриятең,**
**Имин калды намус, вөҗданың,**
**Кайтарасы иде елларыңның**
**Дусларыңнан читтә узганын.**

**«Кер чайкаучы кызлар» исеменнән**
**Рәхмәт сина, олы туганым!**

## Тукай үзе тора шикелле

**Өздереп тә тартса Заһид агай[1]**
**«Зиләйлүк» кәй дигән бу көйне,**
**Шушы моңнан әсирләнгән Тукай**
**Үзе басып тора шикелле.**

**Өши сыман, тышта көзге җилләр**
**Тар-мар итә түбә саламын,**
**Кем утыртсын аны мич янына,**
**Кем назласын ятим баланы?**

**Хәтерлидер төсле сабый чагын,**
**Үксезлектә үткән язмышын,**
**Сары яфрак сыман сары йөзле**
**«Зиләйлүк» тәй кызның каргышын.**

**Истә калганнары бер-бер артлы**
**Күз алдыннан үтә тезелеп,**
**Барлый кебек моңлы сазы—кайчан,**
**Кайсы җирдә калган өзелеп.**

[1] Композитор Заһид Хәбибуллин.

**Өздереп лә тартса Заһид агай**
**«Зиләйлүк»тә дигән бу көйне,**
**Шушы моңнан әсирләнгән Тукай**
**Үзе басып тора шикелле.**

**Мәңгелеккә ашкан бу җырлардан**
**Күпме йөрәк әле җилкенер,**
**Ә бит үзе яздан, наздан мәхрүм**
**Яшен уты кебек бу гомер.**

*** * ***

**Борчымагыз әле, хәтерләүләр,**
**Ап-ак бүген Уфа урамы,**
**Әле генә яуган кар өстендә**
**Эзләремне салып узамын.**
**Сафлык били бөтен дөньямны!**

**...Ярым-ярты яктыртылган бүлмә,**
**Тышта шаша февраль бураны,**
**Урау юллар аша кайтып керден...**
**Ап-ак иде Уфа урамы.**
**Искә төшермәгез, хәтерләүләр,**
**Бер урауссыз юллар буламы?**

**...Әкияткә тиң Яңа ел кичендә**
**Сөюемне кушып җырладым,**
**Олы сөю яшерен була, диләр,**
**Боздым, ахры, әдәп-йоланы.**
**Сөюемне кушып җырладым.**

**...Ак бәс кигән иде шомырт, таллар.**
**Киемнәре челтәр, өр-яңа.**
**Томан аша бактым зәңгәр таңга,**
**Син утырып киткән юргага.**
**Томан аша бактым дөньяга!**

**Искән җилдәй бу гомер соң әллә**
**Сагышлардан гына торамы?**
**Язганнарым бары—үткәннәрнең**
**Күңелемә кунган тузаны.**

**Игәмәгез әле, хәтерләүләр,**
**Балкып ята гомер юлларым.**
**Ап-ак бүген Уфам урамы!**

*Хикәяләр конкурсына*



Искәндәр Сираҗи

# КҮКЛӘР НИКАХЫ

Яңгыр җирнең йөзен юа...

Эре-эре тамчылардан тукталыш ышыгында качып торган Йосыф хәзрәт үзенең чагыштыруына елмаеп куйды. Аңа бүген бар җиһан, бөтен кешеләр, хәтта менә бу барыр юлын бүлеп көтмәгәндә генә яшьнәп-күкрәп коя башлаган яңгыр да матур, Аллаһының инсаннарына кылган бер рәхмәте булып тоела. Аның бүген улы туды! Йосыфның әле аны күргәне дә юк, яңа гына телефоннан хәбәр иттеләр. Малай бит, малай—нәсел дәвамчысы!!! Ул гына түгел, табигать үзе дә гөнаһсыз сабыен гөселләнеп-пакьләнеп каршы ала сыман тоела аңа. Әнә бит, кала ничек аруланып калды: җыелып яткан бөтен чүп-чар күңелле генә җырлап каядыр ашыгучы гөрләвекләргә ияреп, агып китте, һавадан яңгыр, шәһәр сөреме белән моңарчы бер дә сизелмәгән ниндидер үләннәр исе килә. Ә яңгыр һаман ява да ява, гөрләвекләр ташкын булып зур елгаларга ургыла. Бу ташкынны машиналар да ерып бара алмый бугай—көткән автобусы һаман күренми. Кешеләр дә кайсы-кая ышыкларга кереп качышып беткән.

Җәйге җылы яңгырга йөзен куеп бер кыз бала гына бире атлый. Чәчләре буйлап су ага, күлмәге юешләнеп тәненә сыланган, ә ул туфлиләрен кулларына тоткан да шушы фани дөньяның иң бәхетле кешеседәй атлый бирә. Йөзендә шатлыклы елмаю. Йа, Раббым, нинди гүзәл манзара, нинди гүзәл кыз... Аның матурлыгын табигать үзе дә күрде—күк йөзе кинәт кенә ачылып аллы-гөлле салават күпере булып елмайды. Яңгыр гына туктамады, эре, җылы тамчылар сылукайның зифа буен, тулышкан күкрәкләрен назлады. Юк, яңгыр түгел, Җанәбелхак үзе үк яраткан бу гүзәллеккә сокланды, аңа йомшак тамчылар булып орынмый түзә алмады бугай...

Йосыф үзенең имам икәнен дә онытып, кызны тукталышка җиткәнче күзләп торды. Кыз үзенә карап торган егетне шунда гына абайлап алды, унайсызлануын яшерер өчен елмайгандай итте, йөзенә алсулык йөгерде. Бу елмаю Йосыфны әсир итте дә куйды. Сөбханалла, сөбханалла, фәрештәдер бу. Мондый самими елмаю җир кызында була алмас. Әнә, табигать тә үзенең тыйнаксызланып кызның сылу тәненә кагылуына оялды бугай, яңгыр ничек кисәк кенә башланып киткән булса, шулай кинәт туктады да...

Автобус килә. Раббым, бу кызныкы гына була күрмәсен, бир син Йосыфка тагын бер генә мизгел шушы матурлыкка сокланырга... Күкләр ирнең догасын ишетмәде ахры, кыз унайсызланыбрак, тәненә сыланган юеш күлмәген төзәтә-

төзәтә каршында ук ачылган ишеккә атлады. Йосыф, бу гүзәллектән аерылудан куркып, аның артыннан талпынды... Тукта, юләр, нишлисең син?! Синең бит бүген улың туды, бала тудыру йортында Ләйлә абыстаең көтеп ята, имам икәнеңне дә онытма... Автобус ирнең борын төбендә ишекләрен шапылдатып ябып китеп барды... Чү, әнә бит арткы тәрәзәдән ул карап тора, елмая, кулын болгый...

Йосыф автобусны борылышка кереп гаип булганчы күзләре белән озатып калды. Юк, көненә меңләгән кеше ташучы гап-гади автобус кына түгел бу—ул аның йөрәгенең бер кисәген алып китте, күңел түрендә бары тик кызның энҗедәй тешләрен җемелдәтеп соңгы елмаюы гына уелып калды. Кем булды ул гөл-чәчкәләргә тиң нәфис сылукай, исеме ничек? Гөл-чәчкә?.. Шулай булсын, Йосыф өчен ул юлында ялгыш кына очраган гүзәл Гөлчәчәк булып калсын... Әллә кайда гына күк күкрәде, күк йөзен бер мизгелгә яшен камчысы телеп узды, тагын яңгыр ява башлады. Тик бу инде элеккегесе кебек күңелле, җылы яңгыр түгел, әллә нинди шунда—эчпошыргыч...

* * *

Гөлчәчәк автобуска керде дә, тәненә сыланып торган, юешләнгәч үтә күренмәлегә әверелгән күлмәген тәртипкә керткән булып ирләрнең комсыз карашыннан кача-кача иң артка барып басты. Тукталыштан ана теге егет карап тора иде. Кыз бары шунда гына аңа игътибар беләнрәк карарга җөрьәт итте. Мөселман бугай—сакалын кыска гына итеп тигезләп кыркыган, муенына кадәр төймәләнгән кара костюмы да муллага охшатып тора, түбәтәе генә юк. Чибәр егет үзе, әкияттәге Йосыф кебек... Кыз автобустан күзен алмый карап торучы егеткә елмаеп кулын изәде, бер мизгелгә аның күзләрен күреп калды—әллә нинди моң-сагыш бар иде бу кара күзләрдә...

—Нәрсә терәлеп каттың, акчаңны түлә!

Кондуктор хатынның дорфа тавышы Гөлчәчәкне хыялый уйларыннан бүлдерде. Әллә кайда гына күк күкрәде, күк йөзен яшен камчысы телеп узды, кыз куркып куырылып килде, шунда ук егетнең моңсу кара күзләре исенә төште. Тик ул акчасын түләп тәрәзәгә янә караганда автобус тукталышы да, егет тә күздән югалган иде инде...

Урамда тагын яңгыр сибәли, тик бу инде элеккегесе кебек күңелле җылы яңгыр түгел, әллә нинди шунда—эчпошыргыч...

* * *

Йосыф үзенең бу очраклы гына күргән кызга карата күңелендә кузгалган ярсу хисләрен күптән хатын-кыз назы күрмәвенә юрады. Менә, озакламас, Ләйләсен, улын өенә алып кайтыр да, теге Чибәркәйнең энҗе тешләрен балкытып елмаюы онытылыр.

Юк, онытылмады, гел төшләренә кереп йөдәтте. Инде абыстай белән улын алып кайтканга да ике ай, ә елмаю һаман күңел түрендә ымсындыргыч бер сурәт булып саклана. Гөлчәчәк! Бу исемне исенә төшергән саен күз алдына күлмәге тәненә сыланган, кулына туфлиләрен тоткан, йөзен җәйге җылы яңгырга куйган кыз күз алдына килә дә баса. Йосыфның бөтен тәнен ниндидер ярсулы ялкын, дәрт биләп ала... Ләйлә абыстай моны угыл тапкан өчен хәзрәтенең үзенә рәхмәте дип кабул итә.

—Әттәсе, болай кылансаң, тагын берне алып кайтабыз бит...

Иренең соңгы арада ачылып китеп сөйләшми башлавын да, вакытлы-вакытсыз каядыр чыгып китүен дә уйламый абыстай. Ул хәзер ата кеше, җитдиләнергә вакыт, көн-төн хатыны белән ләчтит сатып утырмас бит инде... Әнә, тагын каядыр җыена. Ярар, иреннән эшенә тыкшыну мөселман хатынына

килешми, теләсә, үзе әйтер әле...

Йосыф бик теләсә дә әйтә алмас иде. Нәрсә дисен ул хәләленә? Синең янга бала тудыру йортына барышлый гөл-чәчәкләргә тиң сылу кыз очраттым, шул гүзәл хәзер төшләренә кереп йөдәтә, дисенме? Әле бу төнне дә төшендә күрде ул аны. Теге автобус тукталышында басып тора имеш, Йосыфны чакыра. Барырга кирәк, бәлки бу төше юш килер. Инде ничә тапкыр аяклары үзләреннән-үзләре шул якка атлады, тыелып калды. Юк, имам булган кешегә нindидер бер кызны эзләп шәһәр буйлап кангырап йөрү килешмәс... Әллә соң имамлык юлын сайлап ялгыштымы Йосыф? Аңа бит әле егерме биш яшь кенә, кордашларының күбесе өйләнмәгән дә, кызлар белән типтереп яшиләр. Ул да йөрер иде шулар белән кәеф-сафа корып, мәчеткә картайгач та барып була ла... Әстәгъфируллаһи Тәгалә! Әллә нинди көфер уйларга кертә бу кызый хәзрәтне. Юк, тагын бер генә, читтән генә булса да күрәсе иде шуны, бәлки йөрәгендәге ялкыны басылыр, болай ук төшләренә кереп йөдәтмәс иде. Ул аңа сүз дә катмас, Аллам сакласын, аның бит гаиләсе бар...

Автобуслар тукталышка киләләр дә китәләр, киләләр дә китәләр, кемнәрдер төшеп кала, кемнәрдер китә, һәркем үз эше белән мәшгуль—ике көнлек фани дөнья эше белән... Йосыф уйларына чумган, үзе текәлеп-текәлеп автобустан төшүче кызларны күзәтә. Аңа инде ничәмә-ничә кыз елмайды, тик аларның мең елмаюы да Гөлчәчәгенең энҗе тешләрен бер җемелдәтеп алуына тормый шул. Ә Гөлчәчәк һаман күренми, төше юш килмәде... Намаз вакыты кереп килә, мәчеткә барырга кирәк. Башкача монда килеп йөрмәс инде ул. Бәлки теге чибәр кыз да бу тирәдә яшәмидер, ялгыш кына килеп чыккан булгандыр, бүтән беркайчан килмәс тә... Бәлки ул бөтенләй башка шәһәрдән кунакка гына килгән булгандыр, инде кайтып киткәндер...

Бу уйларыннан Йосыфның тәне эсселе-суыклы булып китте—ул аны башка беркайчан да күрмәс микәнни?..

* * *

Әллә нәрсә булды әле соңгы араларда яшь хәзрәткә. Элегрәк намазга алданрак килеп, Ибраһим мәзин белән озаклап сөйләшеп, чәй эчеп утыра иде. Бүген, әнә, сәламен генә ыргытты да, җавабын да көтеп тормастан, үз бүлмәсенә кереп китте. Абыстайның хәл-әхвәлен белешсәң дә «әлхәмделиллаһ, бихәер»дән башка сүз ишетмәссең. Әллә инде аралары бозылып киттеме, бәби алып кайткач бичәсе хәзрәткә көн күрсәтмиме? Юк, алай булмас, Ләйлә абыстайны бишектән үк белә Ибраһим бабай, бик әдәпле, тәүфикълы бала булып үсте. Монда башка сәбәп бар... Нинди сәбәп икән ул имамның намазын ук ялгыштырырлык? Белергә, вакытында чарасын күрергә кирәк. Югыйсә, яшь хәзрәтнең мәхәллә картлары алдында абруе төшүе ихтимал, инде болай да чыш-пышлар башланды... Әнә, үзе дә чалма-чапанын киеп чыгып килә, азан әйтергә кирәк.

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр...

Ибраһим мәзиннең әле дә булса яңгыравыклы аһәнен җуймаган тавышы мәхәллә каргаларын урыннарыннан кубарга, дәррәү күтәрелеп тынычрак урынга очып китәргә мәҗбүр итте. Көз җитә, ояларында балалары барында азаннан куркып очып китми алар. Хәзер һәр тавышка канат җилпергә генә торалар, балаларын очарга өйрәтәләр... Озакламас, мәчеткә дә җәй кояшында чуен кебек каралып беткән малайлар, ап-ак шәл-яулыкларына төренгән әби-апалар, яшь кызлар кереп тулыр. Быел көздән мәдрәсә ачып җибәрергә ниятли Йосыф хәзрәт. Мәчетнең икенче катында махсус бүлмәләр дә әзер. Аннан соң инде шәһәр буйлап һәр үткән-сүткән кызыйга текәлеп карап Гөлчәчәген эзләргә вакыты калмас. Тапса хәзер табып, күзләрен тутырып бер карап калырга кирәк... Әстәгъфирулла тәүбә... Әллә нишләтте бу кыз,

каргага гына карасан да башка ул килеп керә. Әле кайчан диген—һәр мөэмин-мөселман өчен изге булган азан вакытында...

Йосыф үзе күнегелгән гадәте буенча гына намаз хәрәкәтләрен кабатлый—әле сәҗдәгә китә, җәлсәгә утыра, кыямга баса. ...Сәмигаллаһу лимән хәмидаһ... Үзенен күз алдында Гөлчәчәкнең элекке тешләрен балкытып елмаюы. Юк, табарга кирәк, күрергә...

...Әссәламе галәйкүм вә рәхмәтуллаһ...

Намазын тәмамлап ун ягына сәлам биргән җирдән катып калды имам. Автобуска кереп барышлый шулай уң җилкәсе аша караганда күреп калды бит ул аны бүген! Тукталышка таба шул, үзе килә иде бит, танымады гына!..

Башларын борып катып калган картларнын берсе түземсезләнеп тамак кырып алды, Йосыфны уйларыннан бүлеп чынбарлыкка кайтарды—намазны тәмамларга кирәк...

...Әссәламе галәйкүм вә рәхмәтуллаһ...

Ялгышты хәзрәт, ялгышты—намаздан соң тиз генә мәчеттән чыгып китте. Алай ярамый, картлар белән бераз бакый дөнья хакында сөйләшеп утырырга кирәк иде. Гомерләре буе гөнаһ җыйган карт-коры үлемнән курка, аларны Аллаһынын фазыйләтләрен сөйләп, кылган гөнаһларынын һичшиксез ярлыканачагына инандырып кайтарырга иде дә бит, юк, китте. Юл уңае гына Ибраһим мәзингә сүз катты.

—Ибраһим бабай, икенде белән ахшамны үзең генә укытырсың инде, эшем бар...

Эшем бар, имеш. Элек болай кыланмый, картлар белән сөйләшеп утыра иде. Шуңа яраттылар да үзен. Бүген, әнә, канәгатьсезлекләре чырайларына чыккан, барысы да мулланын сәлам биреп катып калуын сөйлиләр. Бу, тәмуг утының газапларыннан куркучы карт-корыга ирек куйсаң, әллә нинди гайбәтләр таратырлар. Ярар, Ибраһим яшь хәзрәтне бөхтан сүздән коткарыр, икенде дән соң гайбәт өчен Аллаһынын җәзасы турында вәгазь сөйләп алыр... Ә хәзрәтнен нишләп йөргәнен белергә кирәк, белергә...

* * *

Әй, бу монсу кара күзләр... Тагын күпме төшләренә кереп йөдәтер икән алар Гөлчәчәкне? Университетка керү имтиханнары тапшырып йөреп онытылып торгандай булганнар иде, тагын искә төштеләр. Әбисе мәчеттән кайтып исенә төшерде. Әй, мактады инде Әминә әби яшь хәзрәтне. Үзе матур, үзе яшь-яшь, үзе бик тә гыйлем икән. Исеме Йосыф ди... Шунда ук Гөлчәчәкнең күз алдына автобус тукталышында басып калган егетнең монсу кара күзләре килеп басты. Бу караш та наз да, ялвару да, моң да, тагын аңлатып бетерә алмаслык әллә ниләр бар. Шул булырга тиеш. Исеме дә Йосыф... Тукта, ә кем әле тукталыштагы егетнен исемен Йосыф диде?! Ул аны әкияти Йосыфка тиңләп үзе генә шулай атады түгелме соң? Бәлки ул бөтенләй мулла да түгелдер әле, бу тирәдә яшәмидер дә, башка шәһәрдән кунакка гына килгәндер дә, инде күптән кайтып та киткәндер. Гөлчәчәк аны башка беркайчан да күрмәс тә... Юк, юк, күрәчәк—шул ул! Иләсләнгән күңелгә нидер җитми, әллә нәрсә генә эшлисе килә шунда. Ни икәнен генә үзе дә белми кыз.

—Әбием, миңа догалар өйрәт әле.

Өйрәтмиме соң, рәхәтләнеп өйрәтә. Әллә соң, Аллаһының рәхмәте, үсеп буй җиткән оныгы иман юлына кереп барамы? Югыйсә, соңгы араларда Әминә әби ирләрнең ушын алырдай чибәр кыз булып өлгергән Гөлчәчәккә карап шөбһәләнә дә башлаган иде—Аллам сакласын, дөньяның кеме юк, башын әйләндереп харап итеп китүләре бар. Догалар өйрәнеп дин юлына кереп китсә, яулык та бөркәнеп җибәрсә, тәмам кайгысы бетәсе икән

карчыкның. Әнә бит, оныгы бүген дә тәрәзәдән мәчет ягына карап тора, бер алып барып кайтасы булыр үзен.

* * *

Азан тавышына тупылларга кунаклаган каргалар дәррәү күтәрелеп очып киттеләр. Нигә куркырга инде, мәзиннен тавышы бер дә ямьсез түгел югыйсә... Йосыф та, әнә теге манарасы күренеп торган мәчеттә намазга әзерләнеп йөри микән? Хәзер инде Гөлчәчәк тәгаен белә, шул мәчеттә имам ул. Беренче тапкыр очрашкан автобус тукталышында күрде дә үзен бүген. Йосыфы каядыр еракка карый-карый автобуска кереп бара иде, Гөлчәчәкне күрмәде. Әллә күреп тә танымадымы?

Бер мизгелгә кызның зиһене ачылып киткәндәй булды—ә ни өчен танырга тиеш әле ул аны? Алар бит очраклы гына күрештеләр дә аерылыштылар, бер-берсенә сүз дә катмадылар... Ник соң әле ул бу хакта монарчы бер дә уйлап карамаган? Бу ачышыннан Гөлчәчәккә ямансу булып китте, көне буе үзенә урын таба алмый йөрде. Юк, юк, Йосыф аны танырга тиеш иде, күрмәде генә ул. Теге чакта Гөлчәчәк автобус тәрәзәсеннән аның күзләрен күрде, бу караш китмә, кал дип ялвара иде. Ул аны анламады гына...

Башта һаман шул Йосыф кына. Каян гына килеп очрады да, каян гына болай күнеленә кереп калды соң әле бу моңсу карашлы егет?! Ник бимазалый ул Гөлчәчәкне?! Алар бит хәтта таныш та түгел...

Кыз инде ничәнче көн үз-үзен битәрли, кемгәдер ачуы чыга, кемгә икәнен үзе дә тәгаен генә әйтә алмый. Йосыфкамы? Юк, ник ачулансын ул аны! Ярый әле әбисе сөендерде. Быел көздән мәчеттә ял көннәрне хатын-кызлар өчен мәдрәсә эшләячәк икән, яшь хәзрәт үзе укытачак ди... Йосыф укытачак! Бара Гөлчәчәк бу мәдрәсәгә, бара! Университетка бармаса бармый, мәдрәсәгә йөриячәк, тизрәк көз генә җитсен!

* * *

Вакытны җил белән, аткан ук белән тинли шагыйрьләр,—имеш, тиз үтә. Үтми шул! Вакыт—ташбака ул!

Гөлчәчәк соңгы атнаны уздыра алмый иза чигә. Әле мәдрәсәгә барасы кулмәген алып үтүкли, әле инде йөз дә беренче кат яулыгын барлап куя. Изелгән-йомарланган җирләре юкмы? Йосыф унмаган кызый икән дияр тагын...

Менә якшәмбе дә житте, Гөлчәчәк әбисен култыклап каушаудан буыннары йомшарган аягы белән мәчет бусагасыннан атлап керде... Керде дә, чак авып китмәде—ишек төбендә үк аның Йосыфы басып тора бит! Бу очрашуны көткән иде ул, тик шулай да әзер түгел икән. Гөлчәчәк аны барысы да җыелып беткәч класска керүче укытучы сыманрак күзаллаган иде. Ә ул үзе чалма-чапаннан, барысын да ишек катында ук каршы алып тора. Йосыф та аны таныды бугай, каршына бер адым ясагандай итенде дә, туктап калды... Әллә соң ул ялгышты гынамы?

* * *

Ул килгән, Гөлчәчәге килгән, мәдрәсәдә укыячак! Йосыф хәзрәтнен күнелендә фәрештәләр тәкъбир әйтә... Тукта, нәрсә дип сөенә соң әле ул? Үзе имам, үзе өйләнгән—улы Сөләйман белән Ләйләсен онытып җибәрә түгелме? Юк, хискә артык бирелеп китмәскә кирәк. Ул бит кызны күрергә генә теләде. Менә инде морадына иреште, житте, тынычланырга вакыт. Тик дәрес узасы бүлмәгә килеп керүгә Йосыф үз-үзенә биргән сүзен онытты, Гөлчәчәкне күреп бер мәл чибәрлегенә сокланып карап торды. Йа, Хода...

Болай ярамый бит инде, дәресне ничек тә башларга кирәк.

—Әссәламегаләйкүм... Мин сезгә ял көннәрендә дин сабагы бирәчәкмен...

Нәрсә сөйли ул, беренче дәресне болай башлыйлар мыни? Башта танышырга, исемнәрен сорарга кирәк бит...

Әбиләр, төрле яшьләрдәге хатыннар, кызлар нәкъ мәктәптәгечә торып басып исем-фамилиясен әйтә, Йосыф дәфтәренә яза бара, һәркайсын исендә калдырырга тырыша. Әнә аның Гөлчәчәге утыра. Кызык, аның исеме ничек икән? Ул бит аны гөл-чәчәкләргә тиңләп үзе генә шулай атады...

—Гөлчәчәк... Хафизова...

Сөбханалла, Гөлчәчәк! Йосыф ялгышмаган, Аллаһының рәхмәте... Ә тавышы нинди матур—чишмә челтерәве кебек, мондый тавыш хур кызларында гына буладыр. Тыңлыйсы да тыңлыйсы иде шуны...

—Гөлчәчәк, нинди Коръән сүрәләре беләсең... беләсез?

Хәзрәтнең үзенә болай мөрәҗәгать итүенә кыз уңайсызланып кызарып чыкты—әле башкалар белән танышып та бетермәде бит, тагын уңлап кеше бар.

Йосыф та үзенең хатасын аңлады бугай.

—Ярый, син... сез исегезгә төшерә торыгыз, танышуны дәвам итик...

Хатын-кызларның белгәннәрен укып күрсәтүен азан бүлдерде. Йосыф хәзрәт мәчетнең беренче катына төшеп китте, талибәләр намазны аның колонкалардан ишетелгән тавышына ияреп шушында гына укырга тиеш икән. Арадан белгәнрәге егермеләп хатын-кызны кыйблага каратып тезеп бастырды, алгы сафта намаз тәртибен белүчеләр, арттагылар аларга ияреп укырга тиеш булып чыкты.

...Аллаһу әкбәр... Аллаһу әкбәр...

Бу Йосыфның тавышы микрофон аша бигрәк матур яңгырый... Үзе дә матур...

Гөлчәчәктә намаз кайгысы юк, ул Йосыфын уйлый. Өйләнгән кеше түгелме икән ул? Юк, өйләнмәгәндер, балдагы юк бит...

...Аллаһу әкбәр... Аллаһу әкбәр...

Башкаларга ияреп Гөлчәчәк тә сәҗдәгә китә, ә күз алдында Йосыф күзләре. Хәзер ул да шулай маңгае белән намазлыкка елышты микән? Кыз мәчет сурәте төшерелгән намазлыктан егетнең җылысын тойгандай булып китә, әйтерсең ул аның күкрәгенә кереп сыенган...

Йосыф күңелennән Коръән сүрәләрен укый, күз алдында Гөлчәчәк. Йа Раббым, нинди гүзәл...

...Аллаһу әкбәр... Аллаһу әкбәр...

Ул да хәзер нәкъ аның кебек үк сәҗдәгә киткәндер, матур ак маңгаен намазлыкка салгандыр... Йосыф үзенең маңгаенда Гөлчәчәкнең җылысын тойгандай була, иреннәр үзләреннән-үзләре намазлыкка үрелә...

Кхым!!! Кемдер тамак кыра, сәҗдә озаккарак сузылды бугай...

Аллаһу әкбәр...

* * *

Тәки белде бит яшь хәзрәтнең ник үзгәргәнен Ибраһим бабай, белде. Гашыйк булган икән бит ул. Хәзер инде кемгә икәнен дә чамалады—теге күптән түгел генә шәһәр читендәге йортка күчеп килгән Әминә карчыкның оныгына. Бүген иртән әбисе белән житәкләшеп мәчеткә килеп кергәч ничек талпынып куйды хәзрәтебез! Кыз да аңа тартылды бугай... Чибәр шул, каһәр, яшь чагын булса үзен дә гашыйк булып куярлык. Әй, яшьлек, җыен юк-бар өчен янып-көеп йөрүләр... Кай чагында шул юк-бар дигәнен әллә нинди юләрлекләр эшләтеп куя, хәзрәткә күз-колак булыбрак торырга кирәк—абыстае, улы барын онытмасын. Бер көнне Ләйләне мәчеткә чакырырга

кирәк булыр әле, күрсен яшь кызый абыстайны. Акыллы бала булса үзе аңлар, араларына кермәс...

Инде дүрт ай узды, Гөлчәчәк һәр дәрескә ашкынып, сабырсызланып бара. Атна буе иләсләнеп йөри, Йосыфы белән очрашу мизгелләрен күз алдына китерә. Менә-менә бу атнаны нидер булыр, хәзрәт үзенең гыйшкын белдерер кебек тоела кызга. Юк, берни әйтмәде, сиздермәде... Яратмый ул Гөлчәчәкне, башка хатын-кызлар кебек үк бер талибәсе итеп кенә карый! Әллә сукырмы ул, Гөлчәчәкнең мәдрәсәгә бары аны күрү өчен генә йөрүен белмиме?! Бәлки бу атнаны берәр сүз катар, берәр ым гына булса да кагар... Аңа бит күп кирәкми, Йосыфының үзен сөюен генә белү дә бик җиткән!

Кыз үз мәхәббәтеннән үзе исереп, билгесезлектән каңгырып йөри. Их, Йосыфның үзен сөюенә бер генә дәлиле булса икән! Бәлки бу атнаны бер-бер хәбәр бирер, барырга кирәк, барырга...

Иа, Хода! Ничек түзәргә бу йөрәкнең януларына?! Әнә генә бит ул, күзләрен тутырып аңа карап утыра, сабак тыңлый. Ничек аңа сөюен белдерергә?! Әгәр ул аңламаса, Йосыф хәзрәт кул салды дип тавыш чыгарса нишләр? Юк, имам кешегә яшь кызга гыйшык сүзе сөйләп йөрү килешмәс, иләс-миләс шагыйрь түгел лә ул. Булсын иде Йосыфның бер кечкенә генә дәлиле, кыз үзе сиздерсен иде сөюен—ике дә уйламый алдына егылыр, синнән башка яши алмыйм дияр иде. Юк шул, сиздерми, Гөлчәчәк аңа бары укытучысы итеп кенә карый. Ярый, югары уку йортларында кышкы каникуллар җитеп килә, бу вакытта дәресләрне көн саен куярга кирәк булыр. Бәлки әле шул арада берәр җае чыгар, аңлашырлар...

Бүгенге дәресләр дә тәмам. Йосыф тагын бер ым да какмады, кал димәде. Гөлчәчәк иң соңгы булып чыгу ягына юнәлде—бәлки әле туктатыр, берәр сүз әйтер. Юк шул, дәшми, аңа ияреп баскычтан төшеп бара... Ул шундый якын. Капланырга иде күкрәгенә, мин сине сөям дип кычкырырга иде бер—ярамый, әллә нәрсә уйлар, азгын дияр. Мулла бит ул, аныкын белмәссең...

Менә генә бит, якында гына—кулыңны суз да кочып ал, битләреннән, күзләреннән үбә-үбә сөюеңне аңлат кына лабаса—юк, ярамый... Йосыф Гөлчәчәк белән янәшә атлый, йөрәгендә вулкан, тыеп торыр хәл юк. Әллә соң... Чү, Сөләйман белән Ләйлә абыстае килгән, нәрсә калган аларга монда?

Инде тәвәккәлләдем дигәндә генә хәләле белән улын күреп хәзрәт бер мәлгә каушап туктап калды, аннары яннарына атлады.

—Менә, әттәсе, без дә килдек әле, сине күрәсебез килде. Ибраһим бабай да Сөләйманны күрәсем килә дип шалтыраткан иде...

Йосыф абыстаен тыңламый да, аның үз уйлары. Хәзер Гөлчәчәк аның өйләнгәнен, улы барын белде, мәхәббәтен аңлатып тормаса да була—барыбер кире кагар, азгын мулла дияр. Барысы да чәлпәрәмә килде. Ә бит Йосыф башта кызга гыйшкын аңлатырга, әгәр ул каршы булмаса гына гаиләсе барын хәбәр итәргә уйлаган иде. Мөселманнар бит алар, дүрт хатын да хәләл, мәхәббәтләре булса җаен табарлар иде әле...

* * *

Ул өйләнгән, аның улы бар! Йа Хода! Нәрсәгә өметләнде ул, юләр кызый?! Әлбәттә Йосыф аны ярата алмый, бары укучысы дип кенә белә... Гөлчәчәк бүтән мәдрәсәгә бармам, аны онытырмын дигән иде дә, юк шул, оныта алмады, ике атна түзде дә, тагын килде. Бүгеннән аның каникуллары башланды, җомга булса да дәресләр узачак...

Ибраһим бабай сәлам биреп баскычтан икенче катка менеп баручы Гөлчәчәкне кызганып карап калды. Йөзе сулып калган балакайның, төннәр буе мендәрен кочаклап елап чыккан ахры, күзләре кызарып, шешенеп киткән. Ике атна килмәгәч, инде уйлаган эше унды, кызны да, хәзрәтен дә коткардым

дип куанган иде, юк икән шул, иртәрәк шатланган. Бу икенең инде ниндидер юк-бар киртәләр алдында гына туктап калырлыгы калмаган. Бүген башка укучылары да юк бит әле анын, берүзе генә килде, икәүдән-икәү калачаклар... Раббым, бу балаларны гөнаһ эшләрдән үзең сакла...

Ишектән килеп кергән Гөлчәчәкне күргәч Йосыф хәзрәт сөенергә дә, көенергә дә белмәде. Ул инде анын килеренә өметен өзгән иде. Ә ул килгән, тагын да матураеп килгән.

—Узыгыз, Гөлчәчәк туташ, утырыгыз, дәресне башлыйбыз. Бүген башка беркем дә килмәс инде.

Корырак чыкты бугай, үпкәләмәсен тагын.

—Әйдәгез, Гөлчәчәк, барлык белгән Коръән сүрәләрен укып чыгыгыз әле...

Кыз күзләрен йома төшеп беравык тын торды да, укый башлады. Нинди тавыш, нинди йөз чалымнары! Йосыф кызны күзәтә. Йа Раббым, сабырлык бир!

Кыз сүрәләрне байтак белә булып чыкты, җомга намазына чакырган азан яңгырамаса, тагын укыйсы иде әле. Үз гомерендә беренче тапкыр азан Йосыфнын ачуын чыгарды—сөеклесенен тавышыннан мәхрүм итә бит! Азан тәмамлангач та башка вакыттагы кебек михрабына ашыкмады хәзрәт, әйтелмәгән сүзе кала бит! Хәзер үк әйтеп калса гына инде, башка вакытта мондый мөмкинлек булмавы да бар.

—Гөлчәчәк...

—Йосыф...

Сүзләр кирәкми, сүзләр артык! Ике гашыйк бер-берсенә омтылды. Бу мизгелдә аларны туктатырдай көч җир йөзендә генә түгел, күкләрдә дә юк иде бугай. Ләйлә абыстай, улы Сөләйман, Шәригать—барысы да бер-берсенең кочагында онытылды, иреннәр белән иреннәр кавышты, куллар белән куллар, йөрәк белән йөрәк... Ник шунда бөтен дөньясы аларга каршы чыкмый, ник бөтен җир йөзен туфан басмый—аларга барыбер. Алар сөя, сөелә, алар бәхетле! Йа, Раббым, рәхмәт сина бу гөнаһлы бәхетең өчен!

Дүрт рәкәгать сөннәт намазы да укылды, ә хәзрәт һаман күренми. Картлар үзара гәпләшә, имамның тәкәллефсезлеген тикшерә башладылар. Тирәнгә киткәнче Йосыфны чакырып килергә кирәк. Ибраһим бабай мәдрәсә бүлмәсенең ишеге төбенә килгәндә үк барысын да аңлаган иде инде. Шулай да күнелендә бер өмет чаткысы калган—бәлки гөнаһына кермәгәннәрдер әле... Юк шул, еланнардай бер-берсенә сарылганнар, дөньяларын онытканнар. Раббым, үзең ярлыка бу бәндәләреңне, үзең күкләрдә никаһын кыл! Синең ихтыярыңнан башка бу җирдә бер генә эш тә кылынмас...

Ибраһим бабай тавыш чыгармаска тырышып кына йозагында калган ачкычны борып бикләде дә, кесәсенә салып михрабка юнәлде. Бүлдермәс ул яшьләрне, алар тырыштылар, карыштылар—күкләрнең ихтыяры шулдыр күрәсең. Җомганы ул үзе генә үткәрер...

## Габдрахман Минский

# АНА МӘХӘББӘТЕ

Аларның бер дә балалары булмады.

Озак көттеләр алар. Бу көтү елларында балага булган мәхәббәтләре үскәннән-үсте. Әгәр була калса, баланы ничек сөеп, күз алмасы кебек кадерләп тәрбия итәчәкләрен бер-берсенә сөйләп хыялландылар алар. Балага күп төрле һөнәр сайлап та уйлаштылар: музыка остасы, очучы, доктор, балерина, җырчы, шуның ише тагы бик күп, бик күп һөнәр өйрәтергә булдылар. Аларның балалары һәрнәрсәне бик тиз үзләштерүчән, кыю һәм житез булыр төсле тоелды үзләренә.

Бала турында сүз кузгалганда, я урамда бала ияртkән ананы күргәндә, театр-киноларда ана белән бала темасына спектакль, фильмнар караганда, хисләрен уртаклашкандай бер-берсенә карап елмаештылар.

Бер генә кич бала турында сөйләшми калынса, нәрсәдер житми төсле, киче дә бик күнелсез кебек күренде аларга.

Бүгенге кичне дә сүзләре баладан башланып китте. Табигый, әлбәттә, сүзне хатыны башлады:

—Сиңа сөйләмәгәнмен икән, бик кызык бер хәл булып алды бит әле: трамвай көтәбез, бала күтәргән бер хатын да бар. Шундый матур баласы, шундый тере! Ә мин шул хатын артында басып торам. Менә бервакыт баланың күзләре миңа төште... Әй жаныкаем, яна очарга әзерләнгән кошчык кебек кулларын җилпеп-җилпеп куя. Мин елмайдым. Елмаймый буламы соң! «Кил, кил» дигәнчәрәк итеп, кулларым белән чакырган идем, килә бит, көчәнә-көчәнә әнисе кулыннан ычкынырга тели. Миңа килә, имеш...

—Сабый ул. Аның өчен һәрбер елмаеп караган хатын—ана. Синең аңа булган мәхәббәтеңне сизә ул,—дип куйды ире.

Чынлап та шулай бит! Менә хәзер биш-алты айлык кына сабый аның кулында булсынчы. Ул бит аны, һичшиксез, үз анасы дип белер иде. Үсеп теле ачыла башлагач та, «әнием» дияр иде. Дияр иде, дияр иде...

Кинәт аның бу уйлары яна бер фикерне тудырды һәм шул минуттан аның бу фикере яңа кабынган йолдыздай яктырып яна да башлады. Ул бу фикерен иренә сөйләмәкче дә иде, әмма хәзергә сөйләмәскә булды.

Икенче көнне, үзенең кая барасын беркемгә белдермичә генә, ул өеннән чыгып китте. Ярты сәгать чамасы трамвайда баргач та, бер чатта төште. Аның каршысында мәрмәр баганалы ак таш йорт. Ул ишекне ачып эчкә керде. Кием элгечтә торучы хатыннан: «Баш врачны күреп буламы?»—дип сорады. Ана ак халат бирделәр. Ялтырап торган баскычлардан югары катка менеп китте.

Баш врач мөлаем гына, җыерчыксыз түгәрәк йөзле, тулы гына бер хатын икән. Ул килүченең тавышында яңгыраган үтенечне тиз ишетеп алды. Ә

килүче исә, каршысында тынлап утырган баш врачка, иң якын кешесенә серен сөйләгәндәй итеп, чишелгәннән-чишелә барып сөйләде:

—Икебез дә бала яратабыз. Тормышыбыз да яхшы. Тик бер чите генә китек—балабыз юк. Әгәр дә дүрт-биш айлык булса, мин бернәрсәгә карамастан алыр идем. Ана үз анасы булып тәрбия бирер идем... Ышаныгыз, чын күнелдән сөйлим мин сезгә...

—Ышанам, ышанам... Аңлыйм мин сезне. Ләкин нишләмәк кирәк. Сез теләгән бала бездә юк шул. Гомумән, хәзер анасыз калган бала табу кыен. Ә сезгә, шулай шул, яшь бала, әле белештерми торган яшьтәге бала кирәк.

Баш врачның теләктәшлеге аңа дәрт кенә өстәде.

—Ничек яхшы булыр иде! Бәлки, яңа тапкан аналар арасында ризалык бирүчеләр бардыр?

—Авызыгызны да ачмагыз! Ана үз баласын бирә микән! Үтте инде, үтте ул заманнар!

Кичәге шатлыклы уйлар, дулкынландыргыч хыяллар бер секунд эчендә юк булдылар. Бу йортка ул зур өметләр белән килгән иде бит...

Менә баш врач нәрсәнедер хәтерләгәнсыман аңа карап торгач:

—Туктагыз әле, нишләп сез олырак яшьтәге бала алырга теләмисез?—диде һәм аның җавабын да көтмичә сөйләп китте:—Беләсезме, бездә бер кыз бала үсә. Ул хәзер дүрт яшькә житте инде. Аның анасы үлгән. Кызчык безнең тәрбиядә. Атасы күренмәс булды. Бар инде ул, бар жансыз аталар, бар әле бездә. Ә кызый бик әйбәт кенә...

—Дүрт яшьтә дисез бит, ике яшендә булсын иде, ичмасам, хәзер бит ул миңа үз итеп карамас шул?!

Кинәт баш врач, аның сөйләп бетерүен дә көтмичә, башында бер уй туганын сиздереп елмайды да бүлмәдән чыгып та китте.

Ул ялгызы калды. Күзләре ишеккә төбәлделәр. Әллә инде баш врач, аны бик аңлап алгач, берәр яңа туган бала карарга дип киттеме икән? Сабырсызлык белән көтә башлады ул.

Озак та үтмәде, ниндидер бер шаянның коридор идәнен шакылдата-шакылдата чабып килүе ишетелде. Менә ишек тә ачылды. Чабып бер кызчык килеп керде.

—Әнкәй!—диде кызчык һәм бүлмәдә мөлдерәп көтеп утырган хатынга ташланды. Коча-коча куенына сыенды. Бу хәлдән хатын аптырап калды.

Ә кызчык исә:

—Син минем әнием, име, минем әнием? Мин сине көтәм-көтәм... Мин елыйм да, миңа: «Тиздән әниең килер»,—дип әйтәләр. Килдеңме, әнием, килдеңме?—дип сөйләнергә, үпкәләгән булып авызын турсайтып зарланырга да башлады. Шатлыгы ташуыннан нишләргә белмәгән хатын кызны күтәреп кочагына алуын сизми дә калды.

—Кызым минем, газизем минем...

Ана белән бала—ике көчле сагыну бергә очраштылар. Алар бит икесе дә бер-берсен бик тилмереп көттеләр: кызчык үзенең анасын, ә ана үзенең баласын. Шундый зарыгып көттеләр алар бу көнне!

Өстәле янында елмаеп баш врач басып тора. Хатынның күзләре аңа төште, һәм ул бу гаҗәп вакыйгага җавап эзләгән төсле карады аңа. Баш врач бер сүз дә әйтмичә ишарә генә ясады: «Тукта, сабыр ит». Кызчык һаман сөйләнде:

—Әнием, хәзер өйгә кайтабызмы? Син минсез китмә, мин уенчыкларымны гына алып киләм,—диде һәм чаба-чаба чыгып та китте. Шул вакытта баш врач сүз башлады:

—Ике ел инде ул бездә тәрбияләнә. Бик иркә, назлы кыз үзе. Кайчакларда шулай анасын сагынып елый башласа, без аны: «Елама, әниең тиздән килер»,—дип юата тордык. Бала шул, тиз гадәтләнде. Ике ел инде менә анасын көтә. Тәҗрибә уңышлы чыкты. Мин хәзер аның янына барып: «Әниең килде, сине көтеп утыра»,—дигән идем, сикереп торды да уенчыкларын калдырып сезнең янга чапты. Менә күрдегезме, ул үзе сезгә беренче булып «әнием» диде.

—Минем кызым, минем кызым ул. Җаным-тәнем белән үземнеке итеп сизәм мин аны!—диде хатын.

* * *

Аларны озата чыктылар.

Балалар йорты хезмәткәрләренең барысы да ана белән баланың шатлыгын уртаклашып, зур капкага тикле аларны озата килделәр. Ә кызчык, анасының кулыннан җибәрмәслек итеп кысып тоткан да, куанычын эченә сыйдыра алмыйча атлый.

Кызчык Ләлә исемле иде. Хатынга аның кәгазьләрен бирделәр. Эшне ничек рәсмиләштерү юлларын өйрәттеләр. Барлык ак халатлылар аларны күздән югалтканчы озатып калдылар.

Ана белән кыз өйләренә кайтып җиткәннәрен сизмәделәр дә. Ишектән атлап кергәндә, алардан да бәхетле кеше юк иде. Ләлә бер минут эчендә бөтен өйне йөгереп чыкты. Төрле сорауларын бер-бер артлы яудырып кына торды.

—Әнием, син мина яңа күлмәк алырсыңмы?

—Алырмын, кызым, алырмын, ике күзем.

—Ә минем әтием кая?

—Әтиең хәзер кайтыр, кызым, әйдә әле без аны балконга чыгып каршы алыйк.

Алар балконга чыктылар һәм әтиләрен көттеләр, озак та үтмәде, «әти» дә күренде.

—Әнә, әтиең кайта!—диде ана. Ләлә кулларын болгый-болгый кычкырырга тотынды:

—Әткәй, әткәй, тиз кайт, без сине көтәбез! Ләкин «әти» кеше бу тавышны игътибарсыз калдырды.

Бәлки, ишетмәгәндер? Ишетсә дә, ничек итеп инде мондый тансык сүзне аңар кычкыралар дип уйлый алсын ул? Ләләгә бу ошамады. Нишләп әтисе аны күрергә теләми икән? Шундый әти буламыни?

—Әтием, әтием!—дип кычкырды Ләлә.

Бу юлы «әти» аптырабрак калды. Аптырамаслык та түгел: бу бит аларның балконы, әйе, әйе. Әнә балконда аның хатыны. Ә хатыны янында бер кыз бала күренә. Шул кыз бала аңа кычкыра түгелме? Әйе, әйе. Аңа кычкыра. «Әтием, әтием!»—дип кычкыра.

Озак та үтмәде, Ләлә әтисенә каршы йөгереп тә чыкты һәм чабып килеп аның тез башларын кочаклады. Әти булырга тиешле кеше әле һаман да аптырауда иде. Чарасыздан ул үзенә сарылган кызчыкны кулына күтәрде. Шаян Ләлә, шуны гына көткән төсле, аның битеннән чүпелдәтеп үбеп тә алды. Аптыраган «әти» шатлыгын йота-йота:

—Кызым, каян гына килеп чыктың әле син?—диюен белми дә калды.

—Мине әнием алып кайтты. Ә син минаниләр алып кайттың?

—Хәзер, кызым, хәзер, күз нурым...

Алар өйгә керделәр. Өй эче зур бер бәйрәм көнендәге кебек ямьле иде. Әйе, зур бәйрәм иде бу! Һәм бәйрәм озакка сузылды. Ләлә ниләр генә эшләп күрсәтмәде: җырлады да, биеде дә. «Петушок»ны да сөйләде. Үзенең зур үсүе белән мактанырга теләп диваннан идәнгә дә сикерде. Ниһаять, уйный-уйный арып-талгач, йомшак урын өстенә авып йокыга китте...

Алар озак вакыт Ләлә янында утырдылар. Баланың һәрбер сулыш алуын тыңлаган төсле, тын гына ана карап тордылар. Ә аннары бер-берсенә карап елмаештылар. Хәзер инде бу елмаю артында теге, узган көннәрдәгедәй яшеренеп яткан хәсрәтнең эзе дә калмаган иде...

## ИСКӘРМӘ

Язучы Габдрахман Минскийның тууына 100 ел уңаеннан журналыбыз битләрендә автор турында беркадәр мәгълүмат бирергә булдык.

Габдрахман Минский 1906 елның 29 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә дөньяга килә. Бер яше тулыр-тулмаста ул ятим кала, үги әтисе тәрбиясендә үсә. Шулай да җәдит мәдрәсәсендә, аннары татар совет мәктәбендә белем ала.

1926 елда Г. Минский Казанга килә һәм театр техникумына укырга аяк баса. Ул яшь чагыннан ук алга, зур максатларга омтылучан була, актив һәм ашкынулы тормыш белән яши. Хикәяләр һәм пьесалар яза. Аларның берничәсе хәтта татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә куела. Аннары тимер-мәгъдән төбәге Урал, Чиләбе шәһәре, трактор заводы төзелеше, газета редакциясендә эшләү...

Соңрак, Мәскәүдә Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтын тәмамлагач, Баку шәһәрендә киностудиянең сценарий бүлегендә консультант була. Аның сценарийлары буенча шул елларда «Артем авазы», «Ватан улы» һәм башка нәфис фильмнар эшләнә.

Гыйбрәтле хәл: Бакуда фильмнар куйдырган бу татар егете нишләп татар фильмнары иҗат итмәде икән? Хәер, 1941 елда аны Ватан сугышына алалар, иҗади өзеклек килеп чыгуын чамалау бер дә кыен түгел. Керчь ярымутравында барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша ул, контузия ала. Госпитальдә дәваланып чыкканнан соң 1946 елга кадәр чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Тагын Баку тарта аны, 1952 елда гына Г. Минский Казанга кайтып төпләнә. Татарның үз киностудиясе юк, ул чакларда Мәскәүгә, КПСС ҮК ка ялварулар файдасыз, билгеле. Менә шуңа күрә аның кинодраматургия жанрыннан китүен аңлап та була.

Менә шуңа күрә булса кирәк, тормышның утларын-суларын кичкән әдип повесть һәм хикәяләр яза. Аның «Яшенле яңгыр» повестен яңадан укып карарга, бәлки, бүгенге күзлектән карап бәяләргә кирәктер. Чөнки анда беренче империалистик сугыш һәм революция еллары, татарлар язмышы тасвирлана.

Г. Минский–Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Гадел Кутуй белән якыннан аралашкан, аларның хәер-фатихасын алган язучы. Ул болар хакында «Замандашларым» дигән җыентыгында бик матур истәлекләр язып калдырды.

Ул җәмәгать эшләрендә дә бик актив катнаша, «Казан утлары» журналының редколлегия члены, язучылар союзы каршындагы партоешма секретаре булып та эшли.

Габдрахман Минский 1983 елның мартында Казан шәһәрендә вафат була.

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

## Тарих мәгънәсе

*«Падишаһ, мәрхәмәт күрсәтеп, кешеләрне араламасын, бер-берсеннән аермасын иде, боярларга да дворяннарга һәм бояр балаларына да безгә хезмәт итүче кеше балаларына: кайберләрен кире какмасын да кайберләрен кабул итсен иде... Теләсә кемне сайлап алудан һәм безгә кирәкмәгәннәрен кабул итүдән туктасын иде, һәм падишаһ аларны кире җибәрүне безгә калдырсын иде... һәм безгә килергә теләгәннәрне падишаһ, мәрхәмәтеннән аермыйча, бездән чакыртып алырга кушмасын иде; ә бездән китеп сиңа, падишаһ, үтенеч белән килгәннәрне, бездән китәргә теләгәннәрне син кабул итмәсәң иде».*

*Явыз Иванның бөек кенәз Симеон Бекбулатовичка үтенечнамәсе. 1575 елның 30 октябре.*

Рус һәм татар тарихы гына үзара тыгыз бәйләнгән дию аз булыр иде, татар факторыннан башка бөтендөнья тарихын да аңлау мөмкин түгел. Урта гасырлар картасында Европа бер бәләкәй ярымутрау гына, калганнары бар да Татар җире: Кытай Тартар иле, Бәйсез Тартар иле, Дала яисә Нугай Тартар иле, Мәскәү Тартар иле, Кече яисә Кырым Тартар иле. 1348 елда билгесез испан авторы тарафыннан язылган «Libro del Conoscimento»дан («Гыйлем китабы») күренүенчә, Тартар иле барлык җирләрнең чиреген тәшкил иткән, чөнки аңа Азиянең яртысы кергән, ә Азия ул заманнарда бөтен җирләрнең яртысы дип саналган.

Европалы күзлегеннән караганда, бер дә юкка өрәм булып үзләштерелми яткан зур-зур җирләр татар рухының серлелеген барлыкка китергән дә инде. Татарлар иксез-чиксез һәм уңдырышсыз кебек тоелган далалардан кинәт кенә килеп чыкканнар да, башкалар җанында борчу калдырып, шулай ук тиз генә юк та булганнар, император Фридрих II сүзләренчә, «җил-давылдай», ә замандашлары Маттеус Паризензис әйтмешли, «Ходайның ачу тулы яшене шикелле». Алар кышын да, җәен дә пәйда булганнар. Кышкы суыктан да, комлы чүлдән дә, елга-сулардан да, урман-таулардан да куркып тормаганнар. Иң атаклы рыцарьларның армияләрен тар-мар китергән халык җылы, тыныч шәһәрләрдә гомер сөргән европалылар күңелендә өркү уяткан.

Татар җире үзеннән вакыт-вакыт, тарихчылар шәрехләвенчә[61],—җимергеч, ә минемчә, иҗтиһадлы энергия ташкыны чыгарган. Татар җире—татар рухы кебек үк серле, кетелмәгән һәм фараз ителмәслек бер нәрсә ул.

[61] Н. Я. Данилевский һуннарны, монголларны һәм төркиләрне тарихның тискәре иҗатчыларына керткән.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 7-8 саннарында.*

«Рус рухы» яисә «рус гаярьлеге»—инглиз, алман, француз характерына аваздаш гыйбарәләр. «Татар гаярьлеге» дип халык алдында кычкырып әйтеп карагыз менә. Бу Чыңгыз ханны терелтергә өндәү сыман яңгыраячак.

Бүгенге көндә «татар феномены»н аңлатып биргән аналитик хезмәтләр табуы бик кыен. Ул башка парадигмада булып чыга, аны аңларга яки анда иҗади башлангыч күрергә һәм бөтендөнья цивилизациясенә кертергә омтылуга караганда, кыргыйлык дип, антидөнья дип атау җиңелрәк бит. Башка халыклар хакында олы-олы хезмәтләр язылган булса да, төрки-татар культурасы турында иң тулы, иң тарихи хезмәттә дә берни таба алмыйсың. Хәтта төрки дөньяда да һуннар, Төрки каганатлары, Дәште кыпчак, төрки-татар ханлыклары хакындагы белемнәр өстән-өстән генә. Безнең балалар Чингачгукның кем икәнен, индеецларның делавар яки могикан кабиләләре турында шундук сөйләп бирәчәкләр, ә менә океан арьягында түгел, элек үзенең газиз Татарстанындагы Актаныш районында яшәгән найман яисә кераит кабиләләре турында берни дә белмиләр. Татарлар темасын өйрәнгәндә евроцентризм ише кузаллаулар аеруча комачаулый. Цивилизация һәм татарлар тарихи әдәбиятта—бер казанга сыймаган тәкә башлары шикелле.

В. О. Ключевский язганча, «Көньяк рус далалары—ерткыч күчмә халыкларның сыену урыннары».[62] С. Ф. Платонов та «кыргый азиат күчмә халыкларын»[63] искә ала. В. С. Соловьев күчмә халыкларны яисә татарларны, «ерткыч урдалылар» дип атап, һәрчак алар хакында «дала кыргыйлары» дип кенә яза, шул ук вакытта ул славяннарны һәм русларны европалылар яисә «Россия рәвешле Европа» дип атый, гәрчә ул заманда Россия дә Россия булып җитешмәгән генә түгел, Европаны да һичничек мәдәни һәм психологик берәмлек дип атап булмый, ул бары географик төшенчә генә, ә менә Хәзәр һәм Болгар дәүләтләре, Дәште кыпчак җирләре славяннарның төньяк җирләренә яисә хәтта Киев һәм башка территорияләргә караганда да алданрак һәм яхшырак үзләштерелгән була. Х гасыр төркиләре-болгарлары, бигрәк тә Алтын Урда дәвере татарлары Русьның төньягындагы «аю өннәре»ндә көн итүче руслар белән чагыштырганда чын европалылар булганнар. С. М. Соловьев варварлар җәмгыятендә хөкем сөргән канга-кан үче рудименты хакында үзе үк искә ала, мәсәлән, Ольганың ире өчен үч алуын тасвирлый, ул моны мәрхәмәтле гамәл дәрәҗәсенә күтәрә: «газизе өчен үч алу батырлыкка тиң», «дини бурыч, тәкъвалык бурычы».[64] Ул заманда җинаять рәнҗетү дип саналган һәм рәнҗетелгән кемсә үзе яки аның нәселе бу рәнҗеш өчен үч алырга тиеш булган,—дип яза С.Ф.Платонов.—Кешене кенәз түгел, үз туганнары яклаган, әгәр берәүне үтерсәләр, аның өчен атасы, ир туганнары, агай-энеләре «үч алган».[65] Үз нәселыруыннан куылган кеше яклаучысыз калган, аны «эт урынына үтерергә» мөмкин саналган. Канга-кан үче җәмгыять үсешенең иң түбән баскычларына хас икәнлеге барыбызга да мәгълүм.

Яңа эра башында татарлар гына түгел, хәтта һуннар да канга-кан үче кагыйдәләре буенча түгел, законнарга буйсынып яшәгәннәр.

Х йөздә русларның викинглардан аермасы аз булган, чынлыкта руслар үзләре үк викинглар булганнар да инде. Святослав Византия императорының тынычлык турындагы тәкъдимнәренә болай дип җавап бирә: «Русь—үз кул көче белән тамак туйдыручы кәнлекчеләр түгел ул». Алар күршеләрендәге халыкларны талыйлар һәм алардан җыеп алынган байлык бәрабәренә көн итәләр. Алар гадәти елга юлбасарлары булалар. Һәм инде соңрак XII гасырда Мстислав Новгород гаскәрен җыя һәм «Чуд җирләренә басып керә, аларны яндырып бетерә, гади халыкны әсирлеккә ала һәм терлек-туарны талап алып, өенә җиңүче булып, дан-шөһрәт казанып кайтып керә». «Язын ул дружинасы белән бергә яңадан уйлана башлый: тагын кая яу чабарга? Аннары үзенең кияве,

62 В. О. Ключевский. Сочинения. Т.Y. - М., 1989, с. 56.

63 С. Ф. Платонов. Полный курс лекций по русской истории. - М., 2004, с. 58. 64С. М. Соловьев. Сочинения. Книга I...., сс 147-148.

65 С. Ф. Платонов. Полный курс лекций по русской истории. - М., 2004, сс.92-93.

Полоцк кенәзе Всеславка яу чабарга була».[66] Бу—гадәти варвар, аның турында С. М. Соловьев үзе үк болай дип яза: «данлы, әмма файдасыз батырлыклар белән атаклы кенәз, иске, Көньяк Русьның булдыксызлыгын, киләчәк дәүләт үсешенә сәләтсезлеген күрсәткән кенәз».[67] Тәгәл генә әйткәндә, Мстислав батырлыклары белән түгел, талаулары белән данлыклы. Азиатлар ул заманда югарырак культурага һәм әхлакка ия булганнар. Әмма шулай да татарлар—һичшиксез варварлар, ә руслар тарихларының башыннан ук цивилизацияле булганнар дигән стереотип яшәп килә.

Арнольд Тойнби үзенең «Тарихка төшену» дигән күренекле хезмәтендә мөмкин булган барлык цивилизацияләрне дә тасвирлый, аларны төрле сыйфатлары буенча классификацияләп чыга, әмма анда төрки-татар цивилизациясенә урын табылмаган, чөнки Көнбатыш галиме фикеренчә, татарларны цивилизация төшенчәсе белән янәшә куеп булмый, ул бөек төрки империяләргә хәтта иң борынгы (реликт) җәмгыятьләр арасында да урын бирмәгән. Ә бит бу сәхифәләрне дә тарихтан аерырга ярамый, һәркем майя яисә ацтек кабиләләрен яки хәтта Пасха утравыннан юкка чыккан халык цивилизацияләрен белә, ә татар тарихы, татар культурасы белән бик сирәк белгечләр генә шөгыльләнә, А. Тойнби язганча: «Көнбатыш диңгезчеләре ачканчы Пасха утравы күршеләреннән аерым яши һәм алар белән бәйләнештә булмый. Әмма андагы «таш балбаллар» җир йөзеннән юкка чыккан цивилизация булганлыкны аңлата, күрәсең».[68] Пасха утравы турындагы барлык фикерләүләр күзаллауларга корылган, әмма бу фикерләр ачык һәм тәгәл булган очракта да әллә кайда Тын океандагы бу утрауның бөтендөнья тарихына йогынтысы юк—кешеләр шушы утрауда үз көннәрен үзләре күргәннәр, йөзләгән еллар дәвамында Евразия тарихын барлыкка китерүче Чыңгыз ханга һәм татарларга исә тарихи хезмәтләрдә урын җитми калган. Моны ничек аңлатырга соң? Европа тарихчылары өчен татарлар—антидөнья. Алар, дала, күчмә халыклар факторына, татар-монголлар факторына, исемнәрен атамыйча гына, вакыйгаларга һәм халыкларга әйләнә-тирә басымы буларак кына мөрәҗәгать итәләр. А. Тойнби болай дип яза: «Казаклар рус православиесенең Евразия күчмә халыкларына каршы торучы чик сакчылары булдылар».[69] Һәм аннары, казакларны төре йөртүчеләрнең рыцарь ордены белән чагыштырып, даладагыларга каршы торучы культура, цивилизация буларак чагылдыра. Моннан да уңышсызрак чагыштыруны уйлап табарга да мөмкин түгел. «Казак» төрки телдә элек-электән «ирекле кеше» дигәнне аңлата, ул ханнар хакимиятенә буйсынмый, бер катламга да керми, гадәттә, берәрсен талар өчен далага китә. Нинди рыцарь булсын инде ул! Соңыннан гына алар хан яки атаман сайлап куялар һәм оешкан көчкә әвереләләр. Идел һәм Дон елгасы буйларында йөргән казакларга килгәндә исә, гәрчә А. Тойнби сокланып язса да, алар—ушкуйниклар, ягъни елга юлбасарлары булганнар. Казакларда иҗтимагый тормыш үсеш алгач, алар Россиягә килеп кушылганнар. «Дала» белән «көрәш»тә аларның бертөрле дә тарихи роле булмаган, аларның ниндидер күчмә халыкларны мифик җиңүләрен күчмә халыклар дөньясының таркалуы белән аңлатып була. Әмма бу сюжет тарихчыларның евроцентристик менталитеты күзлегеннән караганда гаять кызыклы. Алар фикеренчә «татарлар» һәм цивилизация, «татарлар» һәм культура төшенчәләрен янәшә куярга ярамый. Татарлар тарихы—капма-каршы дөнья ул, анда халыкларның үз исеме юк, аларны күчмәләр, варварлар, кыргыйлар дип кенә атыйлар. Бу антидөньяны аңлатып та, аңлап та, кабул итеп тә булмый. Ул тышкы тирәлек кебек, ягъни А.Тойнби сүзләренчә, ул «басым ясау стимулы», кояштагы таплар сыман, без аларны күрмибез, әмма алар китергән зыянны тоябыз.

---

[66] С. М. Соловьев. Сочинения. Книга 1.... с. 578.
[67] С. М. Соловьев. Сочинения. Книга 1.... с. 606.
[68] А. Дж. Тойнби. Постижение истории. -М., 1991, с. 23.
[69] А. Дж.Тойнби. Постижение истории..., с. 140.

Рус язучыларының һәм философларының рәсми тарих язмалары белән күзләре шулкадәр томаланган була ки, алар хәтта аермачык нәрсәләрне белергә дә, күрергә дә теләмиләр. Алар Александр Македонский, Юлий Цезарь, Наполеон, Бисмаркларның максатлары турында фикер йөртәләр , Борынгы Мисыр, Борынгы Кытай турында сөйлиләр, әмма Чыңгыз ханны белергә дә теләмиләр, ә аның каны, өлешчә генә булса да, аларның үзләрендә дә бар лабаса. Бу—антидөнья, ул күзгә күренми, аның яшәргә хокукы юк. Ходай язмасын! Наполеонга сокланып, ул кылган гамәлләрнең һәм русларның аны җиңүенең әһәмиятен аңлап, шулар хакында сөйләү хәерлерәк. Татарлар исә булмаган. Вәссәлам!

Чын тарих исә башканы күрсәтә. Төркиләр Бөек Даланың гаять зур территорияләрен дә, елга үзәннәрен дә үзләштерүгә байтак өлеш кертәләр. Алар хәрби сәнгатьне генә түгел, терлекчелек, игенчелек, шәһәр төзелеше культурасын да үстерәләр. Цивилизацияне коммуникация чараларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Коммуникация чаралары исә урта гасырларда төркиләрдә югары үсеш ала. Төрки-татар дәүләт структуралары урта гасырлар өчен үрнәк була, хәзерге Россияне дә, бүгенге Төркияне дә һәм башка илләрне дә алардан гайре күз алдына китерүе кыен. Дөнья йөзендә шулкадәр империяләр һәм милли дәүләтләр төзегән халыклар бик аз.

*И вечный бой! Покой нам только снится*
*Сквозь кровь и пыль...*
*Летит, летит степная кобылица*
*И мнет ковыль...*

*И нет конца! Мелькают версты, кручи...*
*Останови!*
*Идут, идут испуганные тучи,*
*Закат в крови!*

*Закат в крови! Из сердца кровь струится!*
*Плачь, сердце, плачь...*
*Покоя нет! Степная кобылица*
*Несется вскачь!*

Александр Блок. «На поле Куликовом».
1908 елның 7 июне.

Ни өчен соң бөек төрки-татар цивилизациясе тарих күләгәсендә калган? Ни өчен соң кайбер илләр алга китә дә, икенчеләре юкка чыга? Моны техника прогрессына, географик урынга, бүтән факторларга сылтап була. Әмма тарихның юнәлешен билгеләүче тагын бер критерий бар бит. Иммануил Кант раславынча: «Дөнья тарихы—ул бары тик Ирекне аңлау прогрессы». Тарихның иң ахыргы мәгънәсе азатлыкны арттыру. Кеше ирекен арттырган цивилизацияләр генә яшәп калганнар һәм алга киткәннәр. Башкаларның язмышы реликт цивилизацияләрнең язмышын кабатлый. Ирек ул ахыр чиктә икътисади һәм техник үсешне аңлата. Тиран һәм деспот режимнар да билгеле бер чорда хәрби яисә икътисади өстенлекләргә ирешкәннәр, әмма озак дәверләр масштабында караганда сәяси ирек рух үсешен билгели, ә ирекле рух фән, техника ачышларына китерә, илләрнең һәм халыкларның үзара ярышына этәргеч була. Үзгәртеп коручан рух белем һәм ихтыяр таләп итә. Бу гомер бакый шулай булган. «Ирек,—дип яза Джон Стюарт Милль,—һәртөрле алга китешнең бердәнбер хаклы һәм үзгәрмәс чыганагы ул: ирек булган җирдә күпме индивидуум булса, алга китешнең бер-берсенә бәйсез үзәкләре дә шулкадәр үк булырга мөмкин. Хәер, прогрессив принцип нинди генә чагылыш тапса да—ирек яратумы яки алга китешне яратумы—һәр очракта гореф-гадәтләрнең өстенлегенә каршы тора һәм ул кешеләрне шушы изүдән коткарырга омтылу-

ны күз алдында тота. Кешелек тарихының бөтен галәмәте дә шушы принцип белән гореф-гадәт арасындагы көрәштән гыйбарәт. Дөресен генә әйткәндә, дөньяның күп кенә өлеше гореф-гадәт чиктән тыш хакимлек иткәнгә күрә тарихсыз калган».[70]

Татар дәүләтләренең дә язмышы сәяси һәм икътисади ирек кысалары белән билгеләнә. Алар төрле һөнәрләргә, фәннәргә, рухи ирек үсешенә этәргеч биргән заманнарда җәмгыять алга киткән, хәрби сәнгать тиңдәшсез, дәүләт идарәсе нәтиҗәле, финанслар системасы камил булган. Биләмәләрне арттырган вакытта иске формаларны үзгәрешсез калдыру зыянга эшли башлаган. Җәмгыять зуррак һәм катлаулырак булган саен, аның сәяси оешуының нәтиҗәлелеге мөһимрәк була бара. Алтын Урда Урта гасырлар азагында үзенә ярашлы сәяси формалар таба алмаган. Ул корылтай һәм дүрт бәк системасы рәвешендә сайлаулар системасына якынайган, әмма дан-шөһрәткә омтылучы дала юлбашчыларын сәяси системага кертеп җибәрерлек адым ясарга өлгерми калган. Азатлыкка омтылу хисе татарларда бик үзенчәлекле чагылыш тапкан: казаклар—ирекле кешеләр барлыкка килгән. Әмма аларның далага—үзүзен югалта баручы цивилизациягә китүләре тарихи драмага әверелгән, гәрчә даланың күчмәлек демократиясе үзенә тартып торса да.

Алтын Урданың зәгыйфьләнә баруы цивилизацияләрнең котылгысыз бәрелешеннән килеп чыга. Техник яктан Европадан яки Русьтан сизелерлек артта калу да күзәтелми, Урда гаскәрләре өр-яңа идеяләрне үзләштергәннәр һәм үзләренең атлы гаскәр тактикасына кертә белгәннәр. Мәсәлән, алар, бәләкәй тупларны иярнең ике ягына бәйләп, атта барганда ук дошманга ядрә яудырганнар. Рус елъязмаларында Болгар тирәсендәге яу турында искә алуларда «кайберләре безнең гаскәрләрне өркетеп, шәһәрдән күк күкрәттеләр», диелә, ягъни туплардан атканнар. Цивилизацияләр арасындагы эчке конфликттан җәмгыятьнең көче кими бара. Европа инде авыл хуҗалыгы белән ныклап шөгыльләнә, кайбер илләр сәнәгатьне үстерүгә дә ирешә, татарлар исә берьюлы ике цивилизация вәкилләре булалар: күчмә тормыш һәм дә игенчелек. Урда эчендәге бу көрәштән яңа тәртипләр яклы булган урдалыларны үз якларына аударган руслар җиңүче булып чыга. Шулай итеп, Алтын Урданың үзендәге ике цивилизация конкуренциясе әкренләп Урданың аерым өлешләрен үз эченә алган, яңартылган Русь конкуренциясенә әверелә. Әгәр дә Аксак Тимер Идел буе шәһәрләрен яндырып чыкмаган булса, Сарай, Болгар яисә Үкәк (хәзерге Саратов) башлап йөрүчеләр булыр иде. Рус шәһәрләрен Аксак Тимернең җимергеч явыннан урманнар саклап, коткарып кала.

Алтын Урда күчмәләр культурасының азагын—кояш баешын аеруча төгәл чагылдыра һәм анда цивилизацияләр конфликты фаҗигале төсмер ала—тарих шушы культура рәвешендә үзенең гаять мәгърур сәхифәләре белән хушлаша. Алтын Урдадан соң булган ханлыклар сәяси һәм иҗтимагый тормышка яңа элементлар кертә алмыйлар, алар, элеккеге гореф-гадәтләрне ныгытып, иске тәҗрибәне генә кабатлыйлар, менә шул аларның язмышын хәл итә дә инде.

*Умчались, пропали без вѣсти*
*Степныхъ кобылицъ табуны,*
*Развязаны дикіе страсти*
*Подъ игомъ ущербной луны.*

*И я съ вѣковою тоскою,*
*Какъ волкъ подъ ущербной луной,*
*Не знаю, что дѣлать съ собою,*
*Куда мнѣ летѣть за тобой!*

[70] Джон Стюарт Милль. О свободе. - С-Петербург, 1900, сс.138-139.

*Я слушаю рокоты сечи*
*И трубные крики татар,*
*Я вижу над Русью далече*
*Широкий и тихий пожар.*

Александр Блок. «На поле Куликовом».
1908 елның 31 июле.

Игенчелек строе һәм православиенең үтеп керүчән роле рус кенәзлекләрен күтәрү факторлары була, әмма Мәскәү сәяси ирекләрне арттыруга омтылыш ясамый, ул хәтта сәяси культурага башбаштаклык кертә, бу рус дәүләтен баштан ук кимчелекле итә. Опричнина исә рус дәүләтенең бөтен дәверендә иң начар уйлап табуларның берсе була. Ермак Себерне буйсындыручы буларак мөгълүм, әмма ул тормышын ушкуйник буларак башлап җибәрә. Аннан аермалы буларак, Чыңгыз хан нойоннары «Бөек Яса» кануннарына буйсынганнар. Явыз Иван, Петр I кебек үк, законлы кагыйдәләргә караганда үз капризларын ешрак үти. Без—шул заманнардан калган җимешләрнең ачысын татучылар. Ни өчен болай килеп чыкканына мең төрле сылтау табып була, әмма Явыз Иван, Петр I, Сталин кебек кеше иреген чикләүләрне берничек тә аклап булмый, чөнки тарихның төп мәгънәсе—кешенең иреген арттыруда. «Кешелекнең бөтен тарихы ул индивидуальләшүнең өзлексез процессыннан һәм шуның белән бергә ирек кебек факторның әһәмиятен арттырудан гыйбарәт,—дип яза Эрих Фромм.—Иреккә омтылыш метафизик көч түгел, аны табигать законнары белән дә аңлату мөмкин түгел; индивидуальләшүнең һәм мәдәни аң үсешенең кире кайтарылмас процессларының котылгысыз нәтиҗәсеннән гыйбарәт. Авторитар көчләр иреккә омтылуны китереп чыгаручы төп факторларны юк итә алмыйлар; шулай ук аларның шушы шартларның нәтиҗәсе булган ирекке омтылуны да юкка чыгарырга хәлләреннән килми».[71]

Тарих—ул башбаштаклыкны чикләү аша ирекләрне арттыру. Менә нәкъ шул халык рухын үстерергә ярдәм итә дә инде, ә халык рухы исә ирекле фикер йөртү бәрабәренә яңа идеяләр таба. Гадәти хокуклар урынына—законнар, кан-га-кан үче урынына—суд, парламент белән чикләнгән корольләр хакимияте, монархияне алмаштыручы демократия, механик күпчелек диктатурасы урынына алга киткән демократия—бөтендөнья тарихында башбаштаклыкны җиңү баскычлары шулар. Башбаштаклыкны чикләү халыкның рухын тарихи иҗат өчен азат итә. Нинди генә сәбәпләргә нигезләнмәсен—авторитаризм, деспотизм, тиранлык, ирек чикләүнең теләсә нинди рәвеше тарихи аклаудан мәхрүм. Кирәклеккә сылтап каты куллы хакимият урнаштыруны да аңлатып була, җәмгыятьнең бүтән чарасы юк иде дип тә «дәлилләп» була, әмма бу очракта илнең һәм җәмгыятьнең «запас юлда» калуын көт тә тор һәм, шушы тупыйктан чыгып, алга киткән халыкларны куып тоту аеруча кыен булачак.

Иректән башка идеяләр, оригиналь хәл итүләр конкуренциясе мөмкин түгел, ә яңа идеяләрдән башка җәмгыять таркала башлый. Җәмгыятьнең күптөрлелек палитрасы гореф-гадәтләр, конформизм басымы астында калып, кимсетелгән, чикләнгән, мескен кешеләр үстерәчәк, гарип җаннар тудырачак. Вильгельм Гумбольт фикеренчә, кешелек үсеше өчен ике шарт зарур: ирек һәм күптөрлелек. Шуңа күрә дә Европа, борынгы цивилизацияләрдән узып китеп, йөзләгән еллар буена алга бара, чөнки ул ирекләрне бертуктаусыз арттыра һәм мәдәниятләр төрлелеген саклап килә. Индивидуумнар, сыйныфлар һәм халыклар конкуренциясе өзлексез, даими прогрессны тәэмин итә.

Гадәттә кешеләр үз фикерләрен башкаларга тагарга омтыла, ә кулында хакимият тә булса—ул аларны бөтен җәмгыятькә тагарга тырыша, һәм шул ук вакытта алар җәмгыять үсешенең нindидер идеаль моделе булуга ышаналар һәм нәкъ менә үзләрен шул модель ияләре дип атыйлар. Тарихның нindидер ахыр максаты бар дип исәпләү—хата фикер. «Шулай ук барлык бәндәләргә

[71] Эрих Фромм. Бегство от свободы. - Минск, 2004, с.305.

дә, кая гына булсалар да, котылу алып килерлек бердәнбер хакыйкать доктринасы, табигый хокуктан яисә изге китаптагы вәхиләрдән йә даһи кешенең күрәзәләреннән, йә гади кешеләрнең табигый акылыннан, йә кешелек дөньясына идарә итәргә куелган галим-утилитаристлар элитасының исәпләп чыгаруларыннан торган доктрина турындагы төшенчә дә шулай ук хата фикер».[72] Беркем дә иң олы хакыйкатьне белә алмый һәм бирәүнең дә үз доктринасын җәмгыятьнең бердәнбер моделе буларак башкаларга көчләп тагарга хакы юк. Дж. С. Милль исәпләвенчә, «башкалар уйлавынча, теге яисә бу гамәлне башкару дөресрәк яки мактаулырак булуга карап, беркемнең дә индивидуумны теге яки бу гамәлне кылырга яки кылмаска мәҗбүр итәргә хакы юк».[73] Карлейль бу хакта болайрак фикер йөртә: «Адәм актыкларын теләсә нинди юллар белән рәтлерәк итү, дуңгызларны яхшырак итү гөнаһ,имеш...». Бу ике карашта да чын либерализм белән, Николай Бухарин сүзе белән әйткәндә, кешеләрне бары тик «кеше материалы» гына дип санаганнарның бөтен кешелеккә үз фикерләрен тагучы доктриналары арасындагы аерма чагыла да инде. Көчләп тагылган бәхет бәхет түгел инде ул. «Беркем дә мине үзе аңлаганча бәхетле итә алмый,—ди Иммануил Кант.—Патернализм—күз алдына китерергә мөмкин булган иң олы деспотизм ул». Кешеләрдән алар үзләре ирешә алмаганны әвәләү, үзләренә ни кирәген һәм үзләре өчен нәрсә яхшы икәнлеген дә аңламаган кешеләр көтүеннән рөхсәт яисә ризалык сорап тормау—диктаторның мантыйгы менә шундый. Ул кешеләрнең күбесе традицияләргә таянып яши дип раслый, шуңа күрә дә үз режимын «бик кирәкле» дип аталучы ниятләре белән аклый, әмма шул ук вакытта кешеләргә, тышкы, ялтыравык холык-тәртип үрнәкләрен көчләп тагып, аларны үсеш мөмкинлекләреннән мәхрүм итә ала.

Огюст Конт болай дип сорый торган булган: «Әгәр без химиядә яисә биологиядә фикер ирегең рөхсәт итмибез икән, ни өчен без аны әхлак яисә сәясәттә рөхсәт итәргә тиеш?» Мондый мантыйк беренче карашка гына ышандыра. Чынлыкта исә иҗтимагый тормыш табигатьтән тамырдан аерылып тора. Анда кырыс детерминизм юк. Тарих субъекты, табигать, ландшафт, климат теге яки бу хайванның (мәсәлән, дөя яисә атның) яшәеше этник, физиологик һәм башка факторларны билгеләгән кебек үк, шул дәрәҗәдә үк тарихи законнарны да билгели. Әхлакый нормалар, аларны сайлап алу һәм аларның нәтиҗәләрен бәхәссез һәм объектив факторлар. Иммануил Кант исәпләвенчә, тышкы дөнья белән идарә итүче законнар барлык нәрсәләрне дә идарә итсә, әхлакның җир йөзендә эзе дә калмас иде. Иҗтимагый тормыш очраклы хәлләр белән билгеләнмәгәнгә күрә, әхлакый җаваплылык яшәп килә, димәк, сайлау ирегә дә, гамәл ирегә дә бар. Мондый очракта сайлау ирегә мөмкинлеге тарихи үсешне билгеләүче төшенчәләрнең берсенә әверелә. Кеше белән табигатьнең һәм башка кешеләрнең үзара йогынтысында яңа бер нәрсә барлыкка килә һәм мондый яңалык—кешеләргә аеруча хас үзенчәлек. Тормыш бит ул—төгәлләнмәгән, даими рәвештә үзгәреп торучан, көтелмәгән бер нәрсә. Кешеләрне яхшылыкны яманлыктан аера белү сәләте кеше итә, шуңа да ирек бәһасез була. Кеше әйләнә-тирә табигатьтән өстенлек итүе белән дә, фикерләвенең рациональлеге белән генә түгел, сайлау һәм эксперимент ирегә белән дә аерылып тора. Төгәл детерминизм юк икән, иҗтимагый корылышның идеаль моделе төшенчәсе дә үз асылын югалта, диктатураны аклау да үзеннән-үзе юкка чыга. Хакыйкать иректә һәм азат бит.

Либераллар мәгърифәтнең иксез-чиксез көченә һәм әхлакның бөтен кешеләрне бай һәм тигез итә алуына ышанганнар. Социалистлар икътисади ресурсларны контрольдә тотуга һәм бүлешүгә ышанганнар. Идеяләр ярышында беренчеләре җиңеп чыккан. Социализм да, авторитаризмның башка рәвешләре дә һәрьяклап җиңелүгә дучар булды. Д. С. Милльнең «Ирек турында» дигән кечкенә генә брошюрасында—сэр Ричард Ливингстон сүзләренчә «бөек юка китапчыкта» кеше ирегә турындагы идеяләрнең иң яхшысы бәян ителгән.

[72] Исайя Берлин. Четыре эссе о свободе. - Лондон, 1992, с. 324.

[73] Джон Стюарт Милль. О свободе..., с. 17.

Либерализм турында шуннан соңгы барлык хезмәтләр теге яки бу рәвешле Дж. С. Милль фикерләре тирәсендә бөтерелә. Шул ук 1859 елда Карл Маркс-ның «Сәяси икътисадны тәнкыйтьләү» китабы дөнья күрә, анда тарихны материалистик аңлау нигезләре бәян ителә. XX гасыр буеннан-буена либераль идеяләрнең марксизм белән көрәшенә әверелә һәм социалистик дөньяны тарихи мәгънәсезлеккә китерә.

Бүген иң йогынтылы концепцияләрнең барысы да, аермалары күплегенә карамастан, либерализм идеяләренә таяналар. Либерализм заманнары тәмамланды дип белдерүче сәясәтчеләр дә бар, билгеле. Эммануэль Валлерстайн: «Бүген либерализм үз мантыйгыннан үзе аптырашта. Ул кеше хокукларының законлылыгын һәм аз-азлап кына булса да халыкларның хокуклары законлылыгын раславын дәвам итә. Ул хокукларның тулы күләмдә үтәлмәячәген белсә дә, һаман шуларны раслый. Бу торган саен кыенлаша. Ә, кем әйтмешли, Сцилла белән Харибда арасына кысылган либераллар, күпчелеге—консерваторларга, бик азы гына радикалларга әверелеп чын йөзен ача бара».[74] Либералларны болай бәяләү идеологиянең үзен инкяр итү түгел, билгеле, монда хәзерге дөньядагы сәяси, хәтта партиячел юнәлеш буенча тәнкыйть ясала. Либерализм идея агымы буларак үзенең әһәмиятен саклап кала һәм өлегә кадәр кешелек дөньясының шуннан да йогынтылырак, шуннан да универсальрәк нәрсә уйлап тапканы юк әле.

Либерализм, иҗтимагый тормышның минималь таләпләренә каршы килмәгән хәлдә, мөмкин кадәр тыкшынмауны таләп итә. Әмма шәхси ирек башкалар ирегеп дә чикләмәскә тиеш бит. Ирек ул без үзебез урнаштырган законга буйсынуны күз алдында тота. Локк әйтүенчә: «Закон булмаган җирдә ирек тә юк», чөнки әйбәт законнар, гадәттә, җәмгыять файдасына эшли.

Ирек тотрыклылык, бердәмлек, туганлык кебек бүтән кыйммәтләрне гамәлгә ашыруга да каршы килергә мөмкин. Ярлы-ябагайга ирек турында гәп сату көлке, анда корсак кайгысы, аның өчен итек-кәвеш Шекспирдан мөһимрәк, әмма сәяси ирекләре булмаган җәмгыятьнең, нефть ятмалары булмаса, баю мөмкинлеге юк. Томас Гоббс фикеренчә, кешеләр өчен иң кыйммәте, иң кирәклесе—куркынычсызлык, имин тормыш. Кешелек дөньясының күпчелеге рәхәт тормыш, иминлек, дан-дәрәҗә, хакимият, киләчәк тормышта бүләкләүләр хакына ирегеп корбан итәргә әзер, әмма бу җәмгыятьнең кеше ирегеп арттыру ягына таба юнәлешен үзгәртми.

Иҗтимагый система гадел һәм әхлакый җәмгыять төзү өчен алшарт ролен үтәүче ирек урнаштыру белән генә шөгыльләнми, әгәр бер халыкның яки бер социаль катламның ирегә икенче бер халыкның яисә сыйныфның хөрчелегенә бәйле икән, мондый җәмгыять гаделсез һәм әхлаксыз җәмгыять була. Чынлыкта исә, Исайя Берлин язганча, «хокукый ирекләр кешеләрне рәхимсез эксплуатацияләү, кансызлык һәм гаделсезлек белән янәшә хөкем сөрә алмый».[75] Ирекле базар асылда кешенең төп хокукларын тупас бозуларга, гаделсезлеккә китерә, берәүләрне икенче берәүләр тарафыннан эксплуатацияләүгә этәрә, җәмгыятьне байларга һәм ярлыларга бүлгәли. Ирекле базар да, сайлаулар процедурасы буларак, демократия дә ирек белән гаделлеккә тәңгәл түгел.

Механик күпчелек ихтыяры булган очракта демократия дә, диктатура кебек үк, гаделсезлеккә китерергә мөмкин. Демос, ягъни Борынгы Афина халкы закон чыгару, суд һәм хәтта башкарма хакимиятне дә үз кулына алган. Ул заман философиясе афиналыларны, дәүләт законыннан да өстен закон юк һәм закон чыгаручы законның үзеннән дә өстен, дип өйрәткән. Демосны тотып торырлык көч булмаган, димәк, тотып торырлык бурычлар да булмаган, закон чыгаручылар, үзләре урнаштырган законнардан гайре, бернинди законнарга да бәйле булмаганнар, һәм Афина халкы тиранга әверелә барган, ә аның демократик дәүләте борынгы греклардан чыккан акыл ияләре каргышына тап була.

[74] Эммануэль Валлерстайн. После либерализма. - М., 2003, с. 154.

[75] Исайя Берлин. Четыре эссе..., с. 56.

Афиналылар Сократны бәйсез фикер йөрткән өчен үтерәләр. Бу стройны Аристотель охлократия, ягъни котырган гавам хакимияте дип атый. Чирек гасырдан соң афиналылар кеше ирегең, гаделлекне һәм закон алдындагы тигезлекне гамәлгә ашыру өчен демократия шул ук дәрәҗәдә үк үзен дә чикләргә тиеш, ә үткән заманда олигархия дә үзен шулай ук чикләргә тиеш булганлыгын аңлыйлар. «Азчылык изүендә яшәү коточкыч,—дип яза лорд Актон,—әмма күпчелек изүендә яшәү тагын да куркынычрак. Массалар ниндидер яшерен энергетик куәткә ия һәм ул тышка бәреп чыкса, азчылык аңа бик сирәк очракта гына каршы тора алачак. Бөтен бер халыкның үзхакимлеге ихтыярына нәрсә каршы торырга мөмкин соң? Монда үтенү-ялвару да, елау-кызгандыру да, хатагөнаһларыңны тану да ярдәм итми, бердәнбер юл—хыянәт кенә кала».[76]—Лорд Актон бу сүзләрне әйткәндә фашизмның коточкыч галәмәтләрен күз алдына китерү дә кыен булган. Гитлер хакимияткә демократик юл белән килә, аны сайлап куялар. Механик күпчелек демократиясенә таянучы, иҗтимагый катламнарның һәм мәдәниятләрнең күптөрлелеген искә алмаган иҗтимагый строй хакимиятне үз кулына туплаган бер кеше диктатурасы кебек үк куркыныч тиранлыкка әверелә. Мэдисонга атаган хатларының берсендә Джефферсон болай дип яза: «Хәзер дә һәм тагын күп еллар дәвамында да иң зур афәт закон чыгаручылар тиранлыгы булачак әле». Җәмгыятьтә беркем дә җимерә алмаслык ирек чикләре хөкем сөрергә тиеш. Һәр кешенең, һәр халыкның, һәр дәүләтнең үз суверенлыгы чикләре булырга тиеш. «Абсолют суверенлык доктринасы үзеннән-үзе тиранлык ул».[77] Ирек кешеләр белән идарә итүче затның яисә органның (алар нинди генә идеалларга таянса да) хакимиятен чикләүгә бәйле. Әгәр мине игелекле максатлар өчен дип мәҗбүрлиләр икән, димәк, минем ирегем кысыла.

Россия өчен тарихи сабак дигән нәрсә юк бит. Ул бүген дә кеше ирегең чикләүче доктрина әзерләп маташа. Дәүләт Думасы 2004 елгы сайлаулардан соң механик күпчелек тиранлыгына әверелде, закон чыгаручылар Конституциядән, җәмгыятьтән дә өстен була башладылар, алар үз суверенлыкларының җәмгыять алдындагы җаваплылыклары белән чикләнгәнлеген оныттылар. Бернәрсә белән дә чикләнмәгән суверенлык җәмгыять өчен куркыныч нәрсә ул. Суверенлык хакимият тармаклары, территорияләр һәм шушы илдә яшәүче халыклар арасында бүленергә тиеш. Шул очракта гына демократия кеше ирегең тәэмин итәчәк. «Дәүләтнең ирекләлеген раслаучы иң ышанычлы күрсәткеч—азчылыкның иминлек дәрәҗәсе».[78] Демократия һәм тигезлек хакына, Алекис де Токвиль сүзләренчә, күп кенә кешеләр еш кына «күндәм сарыкларга» әвереләләр, алар арасындагы «уртакул кешеләр күмәклеге» аерым кешеләрнең үзләренә генә хас сыйфатларын һәм индивидуаль талантларны юк итә. Механик күпчелек демократиясенә каршы дәва монархиядә дә, социализмда да түгел, ә бәлки демократиянең үзенең либерализмга таба күбрәк авышуында. «Ирек ул югарырак сәяси максатка ирешү чарасы түгел. Ул үзе—иң югары сәяси максат».[79]

*Дәвамы киләсе санда.*

---

[76] Лорд Актон. Очерки становления свободы. - Лондон, 1992, с. 46.
[77] Исайя Берлин. Четыре эссе..., с. 292.
[78] Лорд Актон. Очерки становления свободы..., с. 37.
[79] Лорд Актон. Очерки становления свободы..., с.58.

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТАЛАК*** *г.* — Хатын аеру. *"Талак кылу, ирекка җибәрү* мәгънәсендәге "талакун" сүзеннән.

"Талак кылучы ир *талик* дип, ә ирелнән аерылган хатын *талика* дип атала. *Митлак* — Талак кылучы (кушамат). Аллаһы Үзе рөхсәт иткән нәрсәләр арасында талак Аллаһ сөймәгән гамәлләрдән исәпләнә. Шуңа күрә талакны булдырмый калу өчен барлык мөмкинлекләрдән файдалану зарур. Коръән-Кәримнең "Хатыннар" сүрәсендә 128 нче аятьтә болай диелә: "Әгәр бер хатын иренең бизгәнен яки талак кылырга теләгәнен сизсә, бу хатын белән иренең арасын төзәтеп дуслаштыруда гөнаһ юктыр. Килешү, гафу итешү аерылышудан хәерле." ("Коръән тәфсире" буенча.)

Талак формуласының ир тарафыннан ничә тапкыр әйтелүенә карап, кире кайтарылышлы һәм кире кайтаргысыз талак төрләре булган.

Талак сүзен өч тапкыр кабатлаудан соң талак кире кайтаргысыз булып исәпләнгән. Ләкин әлеге формуланы куллануда гарәпләр әлләниндй нечкәлекләр уйлап чыгарганнар. Мәс., "Синең муеныңда бау", "Алжир шәһәрендә ничә чирәп булса, мин синең белән шулар санынча аерылам" дип әйтү "өчле талак" исәбенә кертелгән, ә "Син минем хатыным түгел инде", "Син үз иркеңдә" дип әйтү бер тапкыр кабатланган формула булып исәпләнгән. "Син яртылаш аерылган һәм тагын өчтән бер өлешкә талак кылынган" дигән гыйбарә исә, мондагы өлешләрнең арифметик суммасы хәтта бер бөтенгә тулмаса да, ике тапкырлы талакка бәрабәр дип аңлатылган.

Тагын кара: ***ТАЛАКИ БАИН, ТАЛАКИ ГАЙРЕ РАҖИГА, ТАЛАКИ РАҖИГА, ЗИҺАР.***

***ТАЛИР ТӘҢКӘ*** — Екатерина II патшалык иткән дәвердә йөргән бер сумлык көмеш акча. XVIII гасырда немец дәүләтләрендә сугылган *талер* 3 маркага тигез булган. Атама *"йохимсталер"* сүзенең икенче өлешеннән килеп чыккан. Русларда бу акчаны *"ефимка"* дип атаганнар. Хәзерге *"доллар"* сүзе дә шушы "талер"га барып тоташа, ягъни хәзерге вакытта "каты валюта" символлары булып киткән "доллар" белән "марка" арасында тарихи тугандашлык бар икән.

Татарда көмеш "талер"ны чулпыга тага торган булганнар ("талир тәңкә"), ә егетләр күзләре төшкән кызларга шушындый "талер"ны бүләк итеп җибәргәннәр.

***ТАЛЛАҺИ*** — Алла исеме белән ант итү сүзе. "Орфографик сүзлек"тә ымлык дип искәртелгән. Чыннан да, ул *"билләһи"*, *"валлаһи"* сүзләренә ияреп кенә йөри шикелле.

***ТАМГА*** *тар.* — **1**.Терлеккә булган хокукны раслаучы тавро, билге; мөһер яки аның басмасы; хан мөһере сугылган ярлык; гер яки бизмәнгә куелган тамга (ул аларның дөреслеген белдергән). // *Нишанлык тамгасы* — мөһер, хан мөһере. *Ал тамга* — олы хан мөһере.

"Тамга" термины беренче тапкыр борынгы төрки һәм борынгы уйгур язма чыганакларында телгә алына. XIII гасырда мөһер мәгънәсендәге бу сүз чыңгызилар дәүләтләрендә киң таралыш ала. Хан тамгасы (ярлык) гадәттә як-яклары 5,5 см дан

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

алып 15 см га кадәр булган дүрткел формада була. Аның легендасы девиздан, хан исеменең эпитетыннан, тамга хуҗасының исеменнән, патшалык итүче нәселнең гербыннан торган. Тамга алтын, ал һәм зәңгәр төсләрдәге буяу белән басылган.

Тагын кара: ***СӘХИБГӘРӘЙ ХАН ЯРЛЫГЫ.***

**2.** Монголлар тарафыннан сәүдәдән, һөнәрчелектән һәм эшмәкәрлектән алына торган җыемны (пошлина) да тамга яки тамга малы дип атаганнар. Кайбер чыганаклар буенча, "тамга" сүзе Болгарда пристань мәгънәсендә дә йөргән. Русча "таможня" сүзе дә шуннан.

*//Нәсел тамгасы*-теге яки бу кешенең яки гаиләнең мал-туарга һәм кайбер мөлкәткә салына торган тамгасы. XIX гасырның икенче яртысында да әле татарларның 60% ы кул куйганда шундый нәсел тамгасыннан файдаланган. Мондый тамгаларның өчпочмаклы *өзәңге* рәвешендәгеләре (төрле вариацияләр белән), *кабырга, капка, бoҗра* дип аталганнары һ.б. булган.

***ТАМГА МАЛЫ*** *тар.* – Читтән керә һәм читкә чыга торган товарларга тамга сугып җыела торган салым, пошлина. Рус телендәге *таможня* сүзе дә шуннан килеп чыккан.

***ТАМГА ҖЫЮ*** *тар.* – Электә бер кешене авыл кешесе исәбенә кертү яисә авылдан куганда тавыш бирү нәтиҗәсен ачыклау. Бу вакытта күбәүләр үзләренең нәсел тамгасын салып тавыш биргәннәр.

***ТАНӘСУХ*** *г.* – Җанның берәүдән икенче берәүгә (кешегә, хайванга, кайчагында хәтта үсемлеккә яки үле табигатьтәге берәр нәрсәгә) күчүе, *метемпсихоз* (русча-*переселение душ*). Метемпсихоз идеясе Һиндстандагы фәлсәфи-дини традицияләрдә (брәһманизмда, һиндуизмда, буддизмда) аеруча зур үсеш алган. Җанның шушылай күчешенә беренче нәүбәттә шигый мәзһәбләре, шул исәптән исмәгыйлийәләр, нусайрийәләр, друзлар һ.б. ышана. Исмәгыйлийәләр, мәсәлән, кеше үзенең искергән киемен алмаштырган кебек, җан да үзенең сурәтен (тәнне) алмаштыра дип ышаналар. Сөнни галимнәре исә танәсухны гадәттән тыш бидгать нәрсә дип карыйлар.

Метемпсихоз турындагы барлык тәгълиматлар да теге яки бу затның язмышы фәкать аның үзенә генә, аның элекке тормышларында кылган гамәлләренә генә бәйле дип саныйлар.

Метемпсихоз асылда дөньядагы бөтен явызлыкны, социаль тигезсезлекне, һәртөрле золымны да аклый, чөнки аларны элекке тормышлардагы яманлыкларның нәтиҗәсе дип карый.

Ә татар телендәге *сын битләү* сүзе сынын, төсен алыштыру, кыяфәт төрләндерү мәгънәсендә йөри, ягъни русча *перевоплощение* сүзенә (реинкарнация) тәңгәл.

Танәсух сүзенең икенче мәгънәсе – "илаһи рух"ның җир йөзендә таралып, төрле затларга бүленеп урнашуы. Мондый тәгълимат шигыйчылыкның аеруча радикаль тармакларында үстерелгән, алар үзләренең "сайланмыш" затларына (шигый имамнарына) "илаһи нур" яки "илаһи орлык" күчкән була дип ышанганнар.

***ТАҢ СУЫ*** – Им-томчылар сары төшеп авырган яки күз тигән кешене дәвалаганда файдалана торган иртәнге чык. Авылдагы берәр изге чишмә суын да таң суы сыйфатында кулланганнар. Шифалы суны кыйблага карап аккан чишмә яки инештән таң вакытында алып кайта торган булганнар. *//Таң суы ала бер әби. Таң намазын укып, тәһарәтләнеп төшә Иделгә. Әле җиргә якты төшмәгән була, кояш тумаган була. Догасын укып су ала, шул су белән чәйкәндерә. Өч чәршәмбе таң алдында су алып, шул таң суында коендырырга кирәк.* "Гомернең өч туе" китабы буенча (Ф.С.Баязитова).

***ТАПЧАН*** *бор.төр.* – Яту урыны, караватъ. Рус теленә дә кергән төшенчә ("лежанка" мәгънәсендә). Р.Әхмәтьянов бу сүзне кытай телендәге *тао чаң* сүзе белән янәшә карый. Ләкин Мәхмүд Кашгарый "тапчан" сүзен "өчаяклы аскуйма, биек куаклардан йөзем җыю өчен кулланылган" дип аңлата.

***ТАРХАН*** *тар.* — Борынгы төрки дәүләтләрендә һәм хәзәр каһанлыгында феодалның титулы — берәүгә дә буйсынмыйча, үз иркендә яшәүче мәгънәсендә. Болгар һәм Казан ханлыкларында салымнан азат ителгән түрә. Тархан бик зур тугыз җинаяте өчен җаваплылыкка тартылмаган, аның балалары һәм оныклары тугыз буынга кадәр салым түләмәгәннәр. Тархан хатынына "тарым" дип олылап дәшкәннәр. Җир биләүчеләр арасында тарханлык, мәсәлән, чуашларда да таралган була.

Урта Идел буенда һәм Себердә Тархан исемендәге торак пунктлар бар. // *Тарханлык грамотасы* — тархан хокуклары бирә торган ярлык.

***ТАТАР АУ ЭТЕ*** — Кострома ау эте (гончая). Көнчыгыш Европага татарлар алып килгән ау (эзәрлекләүче) этләренең иң саф токымы. А.П.Сабанеев рус аучыларының "бурзайлар белән киек эзәрлекләү сунарын һичшиксез татарлардан алган" булулары турында яза. Бу токым Ярославль-Кострома төбәгендә әсир төшкән татар кенәзләрен һәм морзаларын күчереп утыртканнан соң тарала.

***ТАТАР ТЕЛЕ*** — Төрки телләрнең болгар-кыпчак төркеменә керә. Гомумән, татар теле борынгы кыпчак теле нигезендә формалашкан дип карала. Татар теле аглютинатив тел, аңа сингармонизм хас.

Татар телендә өч диалект бар, болар көнбатыш (мишәр), урта һәм көнчыгыш диалектлары. Ана телебезнең нигезен тәшкил иткән урта диалект вәкилләрен казан татарлары дип атыйлар. Ул түбәндәге сөйләшләрне колачлый: казан арты сөйләшләре (дөбьяз, мамадыш, балтач, лаеш, бәрәңге сөйләшләре); тау ягы сөйләшләре (норлат, кама тамагы, тархан сөйләшләре); керәшен сөйләшләре (казан арты, түбән кама, подберезье, нагайбәк сөйләшләре), минзәлә, бөре (Башкортстан), нократ-глазов (Киров өлкәсе, Удмуртия), пермь (Пермь өлкәсе), камышлы (Самара өлкәсе), касыйм, бастан (Рязань өлкәсе), каргалы, абдуллино (Оренбург өлкәсе), златоуст, тепекәй, турбаслы (Үзәк Башкортстан), эчкен (Чиләбе өлкәсе) сөйләшләре (тел белгече Дөррия Рамазанова буенча). Болардан тыш, Әстерхан татарлары теле бар, анысы нугай теле нигезендә формалашкан. Төрки телләрдән башкорт теле татар теленә аеруча якын, ә Кырым татарлары теле — шактый ерак.

Берләшкән Милләтләр оешмасының тел комиссиясе татар телен дөньяның теләсә кайсы почмагында аңлашып була торган 14 телнең берсе дип игълан итте. Чыннан да, әйтик, төрек теле төрки телләр арасында иң күп таралганы булса да, ул гомум төрки типтан ераграк тора, ә татар телендә тугандаш телләр белән уртак тамыр сүзләр проценты күбрәк. Татар теле лексикасында Якын Көнчыгыш (гарәп-фарсы һәм, димәк, борынгы шумер һәм Мисыр) сүзләре, Европа-рус телләреннән алынмалар һәм Ерак Көнчыгыш-Кытай эзләре бар. Гарәп һәм фарсы алынмалары татар телендә гамәли лексиканың өчтән берен алып тора, Көнбатыш Европа һәм рус сүзләре исә 10-15 процент тәшкил итә. Соңгы вакытларда рус алынмаларын гарәп-фарсы сүзләре һәм гомум төрки тамырлы сүзләр кысрыклавы сизелә. Бу процесс тагы да дәвам иткән очракта уртаклык индексы тагы да югарырак булачак дип көтәргә була. Әмма яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыкмаска, төрек теленең XX гасырда ясалма сүзләр хисабына сикерешле үзгәрүе аркасында килеп чыккан катлаулануларны булдырмау, өлкән буынның яшь буынны аңламый башлавын кисәтү чарасын күрергә һәм уртаклык индексын киметмәскә тырышырга кирәк, чөнки татар телен әлеге 14 тел исәбенә керткән күрсәткеч — нәкъ менә шушы уртаклык.

1992 елның июлендә "Татарстан халыклары телләре турында" Татарстан Законы кабул ителде. Шул ук елны татар теленең рус теле белән бер үк дәрәҗәдә Татарстан дәүләте теле булуы конституциядә беркетелде. 1994 елда "Татарстан республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан республикасы дәүләт программасы" Югары Совет тарафыннан расланды. Телләр Законы нигезендә 2002 елдан Татарстандагы һәр хезмәткәр мәҗбүри рәвештә татарча да, русча да белергә тиеш.

Соңгы елларда татар орфографиясе мәсьәләсе кабат игътибар үзәгендә тора. Латинча хоруфатка күчү перспективасы өметле булса да, аның конкрет формасы хәл ителеп бетмәгән, чөнки бер төркем галимнәр төрек алфавитына нигезләнеп төзегән хәрефләр

системасы күбәүләрдә ризасызлык уята, алар 1939 елгы латин алфавитын кайтару кирәк дип саныйлар. Ләкин ул алфавитның да кимчелекләре күп — аңарда аерым авазларның график бирелеше латинчадан аерыла (мәс., *у*, *ь* хәрефләре).

Тагын шунысы кызык, күренекле татар галиме һәм сәясәтчесе Садрый Максудиның кызы *Адилә Айда* (Төркия) фикеренчә, борынгы этруск халкы әлифбасын *турсакалар* яки *пеласклар* (этрускларның әлгәрләре) Урта Азиядән Италиягә алып килгәннәр. Шушы иске төрки әлифба әкренләп латин әлифбасы булып үзгәргән. Әгәр дә галимәнең фаразлары дөрескә чыкса, төркиләрнең латин әлифбасына кайтуы асылына кайту шикелле вакыйга булачак.

***ТАТАРЧА АЙ ИСЕМНӘРЕ*** — Халык телендә элек кулланылган ай исемнәре:

1) *Нәүруз ае* — беренче ай, март ахыры-апрель башлары.

2) *Яз ае* — апрель ("Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә апрель ае булып *"сәвер"* ае да теркәлгән).

3) *Сабан ае* — май.

4) *Җәй ае* — июнь (*билек ае* яки *чертмә ае* да шушы чорга карый дип уйлыйбыз; ләкин "Татар теленең диалектологик сүзлегендә" билек ае — "борынгы җирле календарь буенча бишенче ай", ә җәй ае — "борынгы җирле календарьда елның өченче ае" диелгән). Халыкта тагын *"Тын ай"* дигән төшенчә дә булган, ул җәен эш булмаган айга туры килгән һәм җомгаларның берсендә яшь-җилкенчәк сахрага чыгып "Аргамак уены" (соңыннан "Кызлар уены" дип атала башлый) үткәргәннәр. Ихтимал, *"уен өсте"* дигән төшенчә шушы вакытка карый торгандыр;

5) *Чиллә ае* — иң эссе вакыт, июль (Г.М.Дәүләтшин төзегән чагыштырма таблицадагы *печән ае* да шушы чорга карый дип уйлыйбыз). Минзәлә сөйләшендә июль аен *әсәт* дип тә атыйлар ("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969).

6) *Урак ае* — августларга туры килә ("Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә — "борынгы җирле календарьда елның дүртенче ае").

7) Ындыр ае, ашлык сугу ае-сентябрь.

8) *Келәү ае, корбан (йолык) китерү ае* — октябрь (ләкин Ислам дине кабул ителгәннән соң корбан ае дип һиҗри *зөлхиҗҗә* аен атый башлаганнар).

9) *Кыш ае* — ноябрь ("Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә *кашыс ае* — ноябрь башында була торган салкын вакыт, кыш башы).

10) *Олы кырлач (агам кырлач)* — кышның иң салкын айларыннан берсе: декабрь (*раштуа ае* шушы айның ахырына карый дип уйлыйбыз; дөрес, "Татарча-русча сүзлек"тә (1966) "олы кырлач" гыйнварга туры килә дигән фикергә тап булабыз). "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1969) агам кырлач — декабрь аенда һәм гыйнвар башында була торган салкыннар. Чулым татарларында *кырлач ай* — "буранлы ай" мәгънәсенә ия икән. Нәкый Исәнбәттә ("Идегәй" дастанында да) декабрь мәгънәсендә *каңтар* сүзе очрый.

М.С.Глуховның "Tatarica" энциклопедиясендә керәшеннәрдә борын-борынгыдан ай-кояш календаре кулланылуы турында әйтелә һәм ай елын кояш хәрәкәте белән яраклаштыру өчен календарьга өстәмә унөченче ай кертелүе искәртелә. М.С.Глухов язганча, алар (?) *Агаем кырлач ае* һәм *Энем кырлач ае* дип аталганнар икән. Шунысы кызык, Бируни сүзләренә караганда, борынгы гарәпләр дә һиҗрәткә кадәр ике йөз ел чамасы элек үзләренең ай исәбендәге елларына яһүдиләрдән айлар өстәргә өйрәнгәннәр, ягъни үзләренең елы белән Кояш елы арасындагы вакыт аермасы бер айга тулгач, елларына шул артык вакытны өсти башлаганнар. Өстәмә ай *"наси"* дип аталган (*әйям әс-наси*-өстәмә көннәр). Нәтиҗәдә үзенә бер төрле Ай-Кояш календаре килеп чыккан.

11) *Кече кырлач (энем кырлач)* — кышның иң салкын айларыннан икенчесе — гыйнвар (дөрес, "Татарча-русча сүзлек"тә (1966) "кече кырлач" февраль аена туры килә дип күрсәтелгән). "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1969) кече кырлач — гыйнвар һәм февраль айларында була торган салкыннар.

12) *Буш ай* — якынча февраль ("Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә буш ай — борынгы җирле календарь буенча җиденче ай дип күрсәтелгән).

Г.М.Дәүләтшин, төрле чыганакларга таянып, тагын *Чәк аен* да аерып күрсәтә (корбан китерү ае), ләкин, ихтимал, ул ай *Келәү ае* белән берләшкән булгандыр. Дәүләтшин

төзегән чагыштырма таблицада җәй һәм печән айлары арасында *билек* яки *чертмә ае* да теркәлгән. Халык телендә тагын *күке ае* дигән төшенчә дә бар, ул беренче мәртәбә күке кычкырган айга карата (апрель ахыры) әйтелә. Борынгы болгар календарендә *соң яз* дигән ай хәзерге майга туры килгән дигән фикер бар. Февраль-мартны *акман-токман* дип атаганнар.

Авыл халкы хезмәт эшчәнлегенә бәйле атамалар да кулланган ("сабан-сука өсте", "чәчү өсте", "печән өсте"/"болын өсте", "урак өсте", "урман өсте" һ.б. Боларда "өсте" сүзе "ае" мәгънәсендә килә).

Чагыштыру өчен төрки табигый календарьдагы ай исемнәрен китерәбез: Нәүруз (22 мартта башланган), Кәккүк (22 апрельдә башланган), Мамыр (22 майда башланган), Маусем (22 июньдә башланган), Яз-тукхан (22 июльдә башланган), Тамыз (22 августта башланган; сәрйани календарьда бишенче ай-тәммуз аеның июльгә туры килүен әйтеп китик), Кыр куйык (22 сентябрьдә башланган; казакълар күйек ае/киек ае дип тә атаганнар), Казан (22 октябрьдә башланган), Караса (22 ноябрьдә башланган), Йыл тукхан (22 декабрьдә башланган), Кантар (22 гыйнварда башланган), Акпан (22 февральдә башланган). "Башкортостан. Краткая энциклопедия" бүлешмәсендә башкортларда йөргән табигый календарьдагы ай исемнәре шушы ук тәртиптә санаганда түбәндәгечә күрсәтелә: Буранай, Алагай, Һабанай, Хотай, Майай, Урагай, Харыса, Караса, Кырпагай, Акъюлай, Һыугай, Шакай.

Ел фасылларының татарча исемнәренә килгәндә, кайбер тел галимнәре "җәй" сүзе "җәю"–"җәелү" фигыленә бәйле, "көз" исә "көзән" (кысылу) дигән сүз белән тамырдаш, "кыш"–"кысу"–"кысылу"га, "яз" исә "язылу" фигыленә "тарта" дип исәплиләр. Бу фикер бәхәсле, әлбәттә.

***ТӘГАЛӘ*** *г.* – 1.Бөек булу, югары булу. //*Тәгали*–югарылану, бөекләнү. *Күңел шулардан тәгалине тели.* Җамал Вәлиди. 2.Бөекләрнең бөеге, бөек һәм югары булган Аллаһ. //*Тәгалаллаh* (Сәйф Сараида, Әхмәт Ясәвидә очрый). *Аллаhы Тәгалә. Хак Тәгалә.*

***ТӘГИН***–Төрки каһанлыкларда каһан улларының титулы ("Древне-тюркский словарь"да–"хан гаиләсендәге кече әгъзаларның исеменә кушып әйтелә торган титул"). Хәзәр каһанлыгында һәм огузлар, сәлҗүкләр, караханидлар дәүләтләрендә (VIII-XII гасырлар) хан һәм гаскәри аксөякләрнең варислары да шушы титулны йөрткән. XIII гасырга аны оглан, солтан титуллары алмаштыра. *Тәгин/тәгин* терминының күплек саны шәкеле–*тәгит* сүзе хәзерге татар телендә *егет* рәвешендә яңгырый һәм күрше фин-угор телләренә дә кергән (Р.Әхмәтьянов). Рус телендәге *джигит, джигитовка* сүзләре дә шушы тамырдан.

***ТӘГЪЗИЯ, ТӘГЪЗИЙӘ*** *г.* – 1.Үлгән кешенең якыннарын юату, кайгыларын уртаклашу, сабыр булырга өндәү. //*һәм дә Петербургтан да бик күп җәмгыятьләр тарафыннан тәгъзиягә бик күп кешеләр килгәннәр иде.* Г.Исхакый. Тәгъзия итү. Тәгъзия кылу. 2.Шигыйларда өченче шигый имамы Хөсәен истәлегенә багышланган дини мистерия. Мөхәррәмнең баштагы ун көнендә мәчетләр каршында, үзенә бер төрле сәхнәдә уздырыла. Тәгъзийә мулланың (рауза укучының–раузаханның) вәгазе белән башлана, аннары малайлар хоры вәгазьне җыр белән йомгаклый. Хор җырлаганда тамашачылар каршыннан синәзаннар (күкрәкләрен йодрык белән төючеләр) һәм сәнкзаннар (күкрәкләрен таш белән төючеләр) уза. Тәгъзийәдә катнашучылар имам Хөсәен тормышыннан төрле сәхифәләрне һәм аның 680 елда мөхәррәмнең 10 сында Кәрбәла янында ничек һәлак булуын сурәтләп күрсәтәләр. Сөйләм телендә шигырь итеп язылган текстны да актерлар яттан сөйләмиләр, бәлки кәгазьдән укыйлар, шуның белән үзләренең актер гына булуларын билгертәләр. Ләкин тамашачылар барыбер бик нык тәэсирләнәләр һәм кайчагында, кызрачланып, тискәре каһарманнарга таш атып, аларны сәхнәдән куып ук төшерәләр.

Тагын кара: ***ГАШУРӘ***.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Тәлгат
Галиуллин,

Фәрит
Йосыпов

## ДАСТАН ЭЗЛӘРЕННӘН...

Флора Әхмәтова-Урманче — «Казан утлары», «Сөембикә», «Мәдәни жомга» кебек басмаларда еш күренә торган исем. Укучыларның күбесе бу затның Себердә яшәүче милләттәшләребез вәкиле, рәсем сәнгатендә поэзиядә Тукай, прозада Исхакый, музыкада Сәйдәш, театрда Г. Кариев кебек бөеклектә торган Бакый Урманченең турылыклы хәләл жефете, уртак улларының анасы,бөек рәссамның ижатын замандашларына житкерү, рухын киләчәк буынга индерү нияте белән яшәүче шәхес икәненнән хәбәрдар түгелдер дә, бәлки. Туган ягы Тубыл якларыннан аны аспирантурага үзе дә шул тарафларда туып-ускән күренекле фольклорчы Хәмит Ярми чакырып алды. Үткән гасырның алтмышынчы еллары башында Тел, әдәбият һәм тарих институтында (ул чордагы исеме) каратут йөзле, килешле гәүдәле, беренче мәлдә горур һәм тәкәббер күренгән кыз пәйда булды. Рус һәм дөнья әдәбиятларын яхшы белүе, татар халык ижаты гәүһәрләренә гашыйк булуы, Себер кинлекләрендә генә туа алган дастаннарга мөкиббән китүе белән таң калдырды. Фольклорның асылын аңлау өчен күңел байлыгы, кешелеклелек, гомум культура, халык тарихын белү, шигъри жан кирәк дисәк, аларның барысы да Флора туташка хас иде. Беренче мәлне дуслары, туганнары булмау сәбәпле моңсуланып, борынын салындырып йөргән чаклары да булгандыр. Мәгәр ул тиз аралашучан, тыңлаучан, аңлаучан холкы белән Казанда якын арада үз кеше булып китте.



*Бакый ага Урманче һәм Флора ханым Кама Тамагы (Чулмантамак) буенда. 1986 ел.*

Без Саратов далалары, Омск сазлары арасында урнашкан татар авыллары халкы телен һәм фольклорын Флора Әхмәтова-Урманче белән бергәләп әле бүгенгедәй

генә өйрәнеп, Биктимер, Яковлевка, Үләнкүл, Көмешле сәхнәләрендә концертлар ясап йөри идек сыман. Флораның киң күңелле холкын, оештыру сәләтен экспедицияләр вакытында тирәнрәк аңладык. Беребез аның белән бер көнне диярлек 1968 елда кандидатлык диссертациябезне яклады. Шуннан, башкорт дуслар әйтмешли, Флора ханым «көйәүгә сыкты», кияүнен дә ниндие - бөек рәссам Бакый ага Урманче иде. Гарәп графикасын өйрәнү теләге аны Бакый абый алып барган курска юлыктыра һәм, озак та үтми, без аларның өйләнешеп, бергә торуларының шаһите булып киттек. Гаилә кешесе булып киткәннән соң да ул фәнни эзләнүләрен, энә белән «кое казуын» ташламый. Флора инде хәзергесе көндә уннан артык китап, газит-журнал, фәнни җыентыкларда өч йөзгә якын фәнни һәм популяр мәкаләләр бастырып, әле дә фәнгә, мәдәнияткә хезмәт итеп килә. Шигърияте, моңлы халык иҗаты әсәрләре белән эш иткәнгәме, Флора ханымның тикшеренү алымнары, тел-стиль үзенчәлекләре дә мактауга лаек: төртелми-бәрелми, үзе белән ихлас сөйләшкән-сөхбәтләшкәндәй укыйсың аның язмаларын.

Аның халкыбыз иҗатында көрәш-эпос жанрлары — бәет һәм дастаннарны өйрәнүгә батырларча керешүенә сокланып, беренче тапкыр дастаннар җыентыгы чыгуы (1984) унае белән Гамил ага Афзалның: «Без — дастанлы халык!» дип горурланып Флора Әхмәтовага махсус шигырь багышлавын, шагыйрь Рәдиф Гаташның тоташ мәдхиядәй анализ ясавын, филология фәннәре докторы хаҗия Айсылу ханым Садекова, Рәшит әфәнде Ягъфәрләрнең төпле бәяләмә багышлауларын да искә алып, без монографик пландагы ике җыентыгы хакында сүз алып бармакчы булабыз.

Бәетләрне без, татар халкы тарихының сәнгатьле, шигъри елъязмасы, дип атыйбыз. Чөнки аның тематик колачы күк гөмбәзебездәй чикләрне, офыкларны белми диярлек: бер яктан, ул — халык үткән тарихи юлны киң һәм тирән чагылдырган, үткәнгә кешелек идеалыннан, акыл, хис тәҗрибәсеннән якын килеп, олы язмышлы шәхесләрнең фани дөньяны ташлап китүенә ихлас үкенечен белдергән жанр. Икенче яктан, бәет — иң гади, әмма берәр фаҗигагә юлыккан шәхес язмышына, бик гадәти күренгән вакыйгаларга да игътибарлы. Шунда ук халык вәкиле тормышының тискәре якларын да күз уңыннан төшерми, эчтәлек белән шәкелнең тәңгәл килмәвен күреп, сизеп ала, төрттереп, көлеп, чеметеп куярга да онытмый. Һөҗүи әсәрләрдә бәетнең жанр сыйфатлары, шигъри төзелеше, строфа, рифма, сынландыру кебек хасиятләре яхшы саклана.

Бу фикерләрне Ф. Әхмәтова-Урманченың XXI гасыр башында ук «Раннур» нәшриятендә дөнья күргән, классик татар бәетләрен эченә алган «Татар эпосы. Бәетләр» җыентыгында һәм аның саллы, әтрафлы кереш мәкаләсендә укырга була. Бу жанр җәүһәрләрен, ул эчтәлекләреннән чыгып, өч бүлектә карый: шәхси фаҗига бәетләре, һөҗүи бәетләр, иҗтимагый бәетләр. Мондый бүленеш ышандыра. Элегрәк «тарихи бәетләр» буларак каралган «Пугачев бәете», «Салават бәете», «Аксак Тимер бәете» кебек әсәрләр, шәхси фаҗига бәетләре бүген дә өйрәнеләләр, чөнки халык иҗаты әсәрләре тарихны эзмә-эз, төп-төгәл чагылдыруга дәгъва итми, унай яисә тискәре гамәлләрне үз җилкәләренә алган затлар язмышы аша чагылдыра. Бәет халыкның менталитетын, аң үсеше дәрәҗәсен аңлап, киләчәге өчен җан аткан Сөембикә, Акмулла, Тукай кебек олы язмышлы шәхесләр турында уйлана, аларның фани дөньяны вакытсыз ташлап китүләрен милләт хәсрәте-кайгысы дәрәҗәсенә күтәрә, шул ноктада индивидуальләштерү белән киң гомумиләштерү бергә кушылып китә. Тарихи алгарышны масса, гавам түгел, ә шуннан үсеп чыккан, үзенә чаклы ирешелгәннәрне үзләштереп, киләчәкне күрү сәләтенә ия, табигатьтән илаһи куәт алган аерым кешеләр әйдәп бара. Халык шул хакыйкатьне күптәннән аңлаган.

*Булды мәрхүм шагыйрь Тукай, чәчә-чәчә нурларын,*
*Китте Тукай бу дөньядан безгә биреп җырларын.*
*Бик аз вакыт эчендә нык танытты ул үзен,*
*Белделәр барча галәмнәр Тукайның әйткән сүзен.*
(«Тукай бәете»)

Бәет жанрының шактый тулы бу тупланмасы академик басмага дәгъва итми. Күп санлы вариантлар бирелмәгән, (әйтик, бик борынгы «Сак-Сок» бәетенең генә дистәләрчә вариантлары мәгълүм ), төрле кешеләрдән язып, күчереп алынган нөсхәләр китерелми, искәрмәләр бары тик Шәһри Болгарга, Тукай намена багышланган бәетләргә генә ясала. Әмма бу җыентык соңгысы булмас. Һәр чорда бу изге эшкә фидакарь милләтпәрвәрләр, халык язмышына, сүзгә гашыйк затлар алына торды. XX гасыр дәвамында бу жанрнын Х. Бәдигый, Г. Толымбай, Х. Ярми, И. Надиров, Ф. Әхмәтова, Р. Ягъфәров, А .Садекова кебек төрле буын фольклорчылары, бәетләрне туплап, сүз башлары язып, аларны халыкка кайтару хәстәрен күрә торулары мактауга лаек.

Әлеге җыентыкка килсәк, кереш мәкаләнең төпле, тирән эчтәлекле, гыйльми яктан уйланылган, бай фәнни җөмләдән икәнен янәдән искәртәсе килә. Автор төрле чорда бәетне өйрәнгән татар, урыс, хәтта чит ил галимнәренең жанрга биргән бәяләренә, аның тирәсендә хәзерге көнгәчә барган бәхәсләргә кин туктала һәм, теоретик-гыйльми эзләнүләрне дәвам итеп, үз карашын, жанрны яңачарак бәяләргә омтылышын калкытып та куя.

Бәетләрне Ф. Әхмәтова-Урманче «Татар эпосы» дип атый һәм керештә ул атамага караган фикерләрен дәлилле исбатлый. Шиксез: эчтәлек киңлеге, мәгънә тирәнлеге, вакыйгаларны инләү куәте җәһәтеннән иҗтимагый бәетләре дә, шәхси фаҗига бәетләрдә — эпос таләпләренә җавап бирәләр.

Эпос төшенчәсенең әле бит әдәбият белемендә яшәп килгән мәгънәсе, кулланылыш даирәсе дә бар. Л. Толстой, А. Толстой, М. Горький, М. Шолохов, М. Әмир, И. Гази кебек әдипләрнең берничә томнан торган киң колачлы әсәрләрен «эпос» дип атау очрый. Аларда сөйләүче, гадәттә, бәеттәге кебек үк, үтеп киткән хәлләргә бәя бирә, искә төшерә, хикәяләү катламын үзара сөйләшүләр (диалог), эчке сөйләм (монолог) белән тулыландыра. Фольклорчы Флора ханым уйлана, эзләнә, нәзари фикер, заманча атама-бәяләрне халык иҗаты үрнәкләренә үлчәп карый.

Бәет жанрының килеп чыгуы, яшәеше, сүнү, сүрелү тарихы белән таныштырганда, галимә үз элгәрләренең гыйльми эзләнүләренә игътибарлы вә ихтирамлы. Ул аларның фәнни карашлары белән тыйнак кына фикер алышып, остазыбыз Хәмит Ярминең «атлап үтмә, таптап үт» дигән васыятен дә истә тотып, күрәсең, төпле анализлар ясый, кайбер фикерләрне баштанаяк та әйләндереп куйгалый. Әйтик, моңарчы елау-сыктау, үлем-китем, кайгы-хәсрәт дәрьясы дип каралган бәетләрне Ф. Әхмәтова башкачарак бәяли, жанр хәрәкәтендә үзгәрәк чагылыш — яңгырашлар күрә. Бәет үзәгендә яткан үлем вакыйгасы — үзе тормышка гимн, аннан аерылу фаҗигасе якты дөньяда яшәү кыйммәтен, гамәл-фигыль гүзәллеген раслау икәнне исбатлый. Моны ул, фольклористикабызда беренче буларак, орхон-енисей язмалары үзенчәлекләрен гамәлгә кертеп ачыклый.

Сан ягыннан күп булмаган милләтләрдә бәет кебек жанрлар җәмгыятьне алга этәрердәй көчле шәхесләр фаҗигасен үзәккә ала, шул нигездә дөньяга килә. Милләтнең куәсен, аң үсеше дәрәҗәсен, цивилизациясен саклау ихтыяжы белән аңлатыла бәет жанрына хас бу үзенчәлек. Чыннан да, мич башыннан егылып төшеп, үз үгезе сөзеп, яисә исереп үлгән берәүгә дә багышлап бәет чыгарылмый. Шул ук вакытта бәет, тарихта зур эз калдырмаган шәхесләргә багышлап иҗат ителеп, бөекләрне халык шигъриятеннән читкә калдырырга да мөмкин.

«Суга баткан Гайшә», «Янып үлгән ике шәкерт», Сабан туенда аттан егылып үлгән кешеләр хакында вә гайре бәетләр, классикабызга әверелеп, татар тормышы манзараларын, этнографик күренеш-үзенчәлекләрне, йорт-җир, тормышын тасвирлау белән бергә, гаилә тоткасы хатын-кыз, көчлеләр, батырлар югалуына, фаҗигагә юлыгуына аһ итә, чаң кага.

Исламга хәтле цивилизация җимеше икәнe ярылып яткан «Сак-Сок» бәетенең йөзләрдән бер генә варианты алынса да, ул примитив «борынгылык»ка кайтарылып, архетип образ буларак кына каралмый. Ф. Әхмәтова-Урманче татар халык иҗатының бу шаһ әсәрендә үтә-күренмәле гадилек белән гасырлар төпкеленнән килгән саф, камил сурәтләр аша хәзерге татар тормышына да ятышып торган әдәп-

әхлак кануннары ятканны дәлилле күрсәтә: бала, ана каргышы аркасында кошка әйләнеп, куркыныч, ят атмосферада кала («йөрәгем ярылды зур имән аугач»), өй-йорт кешелекле жылысын жуя, ата-ана теленнән яза. Төзәтеп булмаслык ачы хәсрәт коллизиясен үз эченә алып, якты дөньяга көчле рух, иман, өмет белән өретелгән бәет туа. Бу коточкыч аерылу фажигасен һәм көен рәссам Бакый ага Урманче, «Баллада» дип атап, фантастик жете, куе буяулар белән тау-ташлар, кара урманнар, парлы жанварлар арасында күгәреп таң атуын көткән, ләкин бер-берсе белән дә кавыша алмаучы канатлы вә кәләпүшле ике бала, хәсрәтле ата белән ана кайгысын үзенең гүзәл панносында сурәтли. Әсәрнең рәссам башкаруындагы драматизм белән сугарылган бәет көе дөрес-тәгаен нотага салынып, «Сак-Сок» дигән махсус җыентыкта да басылды. (Ш. Шәрифуллин). Ә балачагында әтисе моңлануыннан откан бу кыйсса мотивларына таянып, рәссам-график И. Урманче әр-яңа сәнгать төре — мультфильмда «Баранкин, кеше бул» дигән әсәр иҗат итте. Көе, сүзләре тәмам онытылса, инде бәет риваять төренә күчә. Шуңлыктан эпос буларак ныгу дәверендә бәетләр риваять, мөнәҗәт, илаһи жыр, назым, әрбагый, касыйдә исемнәре белән дә йөртелгәннәр. Әмма эпосларга хас вакыйгалылык, бәян итү, тарихилык, эзлеклелек, фажиганең күзенә карап тасвирлау саклана.

Әле генә булып узган фажигаи хәлләр эзеннән көчле хисси (экспрессияле) рухны сүзләргә күчереп кую бәет жанрын язма әдәбияткә якынайта. Шуңа нигезләнеп, Ф. Әхмәтова бәет жанрын, тулаем дәвамлы бер эпопея итеп карау белән бергә, шәхси һәм ижтимагый вакыйгалылык принцибында төркемли. Ул бәетләрне бер яктан эпос, ягъни тормыш һәм көрәш поэзиясе буларак таныта, икенче яктан, жанрны үз эчендә төркемләү бөтенләй янача принципларга корылган. Бик борынгы заманнардан бу көнгә хәтле килә торган шәхси фажига бәетләре тезелеп, бер якта калсалар, сугыш бәетләре, жир, ирек, дин өчен, ягъни ижтимагый көрәш бәетләре, үзләреннән-үзләре икенче якка торып баса. Әдәбияттәге антропологик һәм ижтимагый принципка якын бу бүленешкә һөҗүи бәетләр дә кереп урнаша. Билгеле булганча, бәетләрнең бу төрен Г. Тукай да таныган.

Шулай итеп, Ф. Әхмәтова-Урманче бәетләрне төркемләү мәсьәләсендә үзенә күрә бер ачыш ясаган. Дөрес фәнни төркемләү табылмаса, фәндә үсеш, прогресс була алмый. Халкыбызның бу бай мирасын мөстәкыйль туплау, эпос гыйлемен һәм әдәбият белемен тирәнтен өйрәнү аңа «Бәетләр — татар эпосы» дигән гыйбарәне әйтү мөмкинлеген биргән. Дөрес, яңа «Янып үлүче»ләр, «Суга батучы», «Өшеп үлүчеләр», операция өстәлендә гомере киселгән вә гайреләр хакындагы бәетләрдә әлләни алга китеш юк, шигърият рухы жемелдәми, күбесе элеккеге, инде уңган, иске киемнәргә төренгән. Әфган, Чечня сугышларына карата да бәет чыгарылмый хәзер, солдат аналары гына һәлак булган улларына сагышлы шигырьләрен багышлый.

Әйе, бәетләр — татар халкының күнел тарихы, күнел кайтавазы. Олы тарихтан, табигатебездән көч кодрәт алган күңел ярсуын шигърият кенә тулы чагылдыра ала. Бәет ул — тарихның тере аңы, халык язмышында бөреләнгән жимеше. «Бу бит бәет. Түгел тәсбих. Тулган эчләр бушасын», яисә «Кайчан чыгып бер күрербез Руссия каласыны?», — дип инәлгән, үзләрен Рус иле белән бер бөтен итеп күрүдән гайрене башларына да китермәүче исемсез патриотларның төрле вакытта ижат ителгән көрәш поэзиясендә каршы як әһелләре — десятник, сотник, сотский, сельский, становой, судебный, стражник, урядник, староста, түрә, глава, генерал, губернатор, ак патша, солдат, казак, каравыл, верховой, команда, суктыручы, зинданда тотучылар, писарь, пристав, окружный, волостной, землемер, полковник, начальник...

Болар — халкыбызның көндәлек гомер торышына, кан саркыган ярасына тоз сибеп торучы жан ияләре, ачыктан-ачык тискәре персонажлар. Алар китергән тән вә жан жәрәхәтләрен «чи тиреләр ябынып» та дәвалый халкыбыз, авызыннан кара кан килсә дә сер бирми, баш та күтәрә. Гасырлар дәвамында көрәшә-көрәшә көлгә-күмергә әйләнми, киресенчә, үсә, үрчи, янара. Аның азатлык даулавы башка халыклар эпосындагы кебек кемнәрдер игосыннан изелеп, жылау-сыкрау түгел. Шулай ук һай-һайлап, чит илләрне басып алуга өндәүнең эзе дә юк татар эпосында.

«Күрше хакы— Тәңре хакы» дип, килешү, түзү, чыдау, сабырлык моңы ул көрәштә.

Коръәндә «Кеше гомере буена үзен үлемгә әзерләргә тиеш» диелгән. Бәетләрне бер-берсе белән бәйләүче, кешене тормышка да, теге дөнья хозурларына да әзерләүче төп көч, юнәлеш шунда түгелме?

*Нух та үткән дөньядан...*
*Кара да үткән дөньядан,*
*Күп тә үткән дөньядан,*
*Аз да үткән дөньядан,*
*Бары да үткән дөньядан.*

Хәзерге фольклористикада, күптән түгел фанидан киткән милләттәшебез олуг галим Әдһәм Рәхим улы Тенишев житәкләгән «Евразия халыклары эпосы» дигән Сериядә эпос жанры «дөньяда этнос яшәешен» ачу жанры, дип билгеләнә (В. Гацак). Бәетләр янына «Татар эпосы. Дастаннар» дигән китабын да чыгарып (Казан: «Раннур» нәшрияты, 2004), Флора ханым Әхмәтова татар этносының бу дөньядагы хәятын тасвирлаган әсәрләр тупланмасын да бирде. Тупланмага фатиха рецензиясен дә Әдһәм ага Тенишев язып калдырган.

Татар «Дастаннар»ы жыентыгын, шулай ук «Бәетләр»е белән беррәттән, фольклорчы Ф. Әхмәтова беренче мәртәбә 20 ел элек, соңыннан Тукай премиясенә лаек булган 12 томлы «Татар халык ижаты» тупланмасында бастырып чыгарган иде. Әле ул заман үзе дә бик кырыс: «бу әйбер бармый, тегесе ярамый» дип, ничә кылилләк аша уздырылган дастаннар арасында «Идегәй» телгә дә алынмаган иде. 650 битле бу жыентыкның 100 битеннән артыгын әлеге шаукымлы әсәр алып тора. Аның да жыелма дигән (сводный), ягъни халык ижатын әдәби ижатка күчергән, шуның өчен башкае зинданда черетелгән галим һәм шагыйрь Нигъмәт Хәким (1889—1937) әсәре беренче мәртәбә якты дөнья күрде. Шундый ук жыелма әсәр буларак, тик башка төрки халыклар ижатыннан 34 вариантка таянып ижат ителгән, әмма 1940 елда ук дөнья күргән «Идегәй» — Нәкый ага Исәнбәт ижаты да китерелә, монда. Ә инде «Идегәй»нең 1872 елда академик В. Радлов тарафыннан Себер татарлары авызыннан язып алынган 3 вариантын кертеп, аларның кайчандыр Идел ярлары чичәннәре тарафыннан, тарихи Идегәй үзе исән вакытта ук ижат ителгән әсәр язмага күчүен дәлилле тасвирлый Ф. Әхмәтова.

Себер чичәннәре үз тарихларыннан дастан нигезенә яткан «Караца», «Купланды», «Хужаш», «Би Агыш», «Хәлмәт мәргән», «Тәвеш мәргән», «Бурихан» вә гайреләр — ярылып яткан тарихи жыр да, мөнәжәт, балладалар белән дә якын мөнәсәбәтләрен вак кына хәрефләр белән язылган искәрмә-шәрехләрдә— монографик ачышлар рәтеннән күрәбез бу китапта.

Тарихта урыны жуелмас ачышларның берсе — шулай ук «Татар тарихы. Дастаннар» китабы биләмәсе. 1970 елларда В. Радлов эзләреннән 100 ел узганнан соң йөреп, Ф.Әхмәтова нәкъ академик язып алган дастаннарны көйләре белән магнитофонга төшереп калган. Аларны Н. Әлмиева, З. Сәйдәшева. Е. Смирнова кебек музыка галимнәре һәм А. Ключарев, Р. Еникиевлар кебек композиторлар нотага салганнарын жыеп, бу китапка туплаган. Хәзер шуларга таянып, композиторлар яңа Себер сюиталарын ижат итә, зур музыкаль әсәрләр яза.

Дастаннарның мең ярым еллар элекке гарәп цивилизациясеннән килгән, төрле төрки халыклар, шул исәптән себер татарлары шивәсеннән дүрт меңгә якын сүзгә аңлатма да китерелә бу китапта.

Рәссамнар тарафыннан дастаннарга иллюстрацияләр бирү мөмкинлеге ачылгач, «Туктамыш», «Коркот», «Сөембикә», «Бәлкыйс» кебек әсәрләр үрнәкләрен Бакый ага Урманче ижатыннан да күрәбез бу китапта. Мең елдан артык тарихлы «Ләйлә-Мәжнүн» дастаны шигырьләрен бүгенге көн теленә күчерүен игътибарга алып, рәссамның татар әдәбиятындагы урынын күрсәтеп үтү жаен да таба Флора ханым үзенең китабында.

«Мәңгелек сәнгать әсәре «Ләйлә-Мәжнүн» шигырьләрен хәзерге телгә күчергәндә рәссам Б. Урманчены татар кульязмасындагы фажигаи фикер тетрәндерде: дөнья

культурасында иң ярсу мәхәббәт символы Мәҗнүн көчләре сынган! Тереклек шәмгы Сүнмәстән әүвәл бер генә мәртәбә булса да җанашын күрергә ашкынган, әмма морадына ирешкәч, үзендә җан әсәре калмаган. Җансыз сурәт булып, мәгъшукасы аягы астында тузан булып таралуга риза һәм... югала. Мәхәббәте өчен Мәҗнүннән ким көч-гамәл куймый көрәшкән нәзберек зат Ләйлә мондый финал көтмәгәнгә, бердән сүнә, тиз үк дөньядан да китә».

Табигый, әмма фаҗигаи халәт. Татар мәхәббәт дастаннарының азагы бәхетле тәмамланырга тиешлеләре дә фаҗига рәвешендә тәгәлләнүенең бер мисалы бу. Дастан каһарманнары булачак мәгъшукаларын төштә күреп, яисә ярәшелгән кызы турында читтән ишетеп, аны эзләү, табуга, димәк, гаилә кору, ыру-кавемне үрчетү, илне ыгыту кебек изге ниятләр белән башлый гомерен. Алар башта алыплар хикәятләрендәгечә зур батырлыклар эшли: Мәҗнүн дә үз кул-аягына кигән тимер чылбырны «җеп кебек өзә», Таһир да дошманнарын «кыяр кебек турый», башкалар да «кара чебен шикелле килгән дошман гаскәрен чапкан печән кеби аударып кына бара» һ. б. Әмма ахырда җинә алмас дошманнарына үз коралларын тапшыртып, алардан башларын кистерәләр. Бу бик борынгы дастаннардан килә торган мотив. Дастаннарда әлеге корал, «Сак-Сок»лардан килгән дәһшәтле сурәт-символ — «тимер ук» сыйфатында мәгъшукалар Бәдигыльҗамал, Баянсылу, Зөһрә вә гайреләр күкрәгенә кереп, аларны да ахирәткә юнәлтә, җан тәслим кылдыра.

Татар халык дастаннарының эчтәлеге, образлар галереясе, сурәтләү байлыклары бетмәс-төкәнмәс. Аларның көчен, тарихи мәгънәсен аңлау өчен күп буыннар хезмәте кирәк булыр. Бу юлда Флора Әхмәтова-Урманче эшчәнлеге мактауга һәм хуплауга лаеклы.

Хәзерге көндә фольклорчы, филология фәннәре кандидаты, ТФА Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺСИ өлкән фәнни хезмәткәре, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре һәм Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Флора ханым Әхмәтова бүгенге көнгә Бакый Урманче иҗатына багышлап өч альбом чыгаруын, «Бакый Урманче мәкаләләре һәм истәлекләре», «Бакый Урманче турында истәлекләр һәм мәкаләләр» дигән ике зур җыентык, «Урманче һәм Тукай», «Урманче иҗатында костюм», «Бакый Урманче шигырьләре» кебек китапларын нәшриятка әзерләп, В. Радловның Себер фольклоры томын русчага тәрҗемә итүен, консерваториядә җыр җыентыклары әзерләвен билдереп, аңа озын гомер, зур уңышлар теләп калабыз!

*Алхәбәр*

# БЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР... КИТАП БУЛЫР

«Сүнмәс утлар балкышы» — «Казан утлары» редакциясендә әзерләнгән китап шулай дип атала. Журналыбызның тәп-тәгәл мең санының куе сайланмасы, каймагы бу. Татар тарихын, милләт язмышын чагылдырган, 7 бүлектән торган ошбу китап күләм ягыннан да, эчтәлек ягыннан да саллы. Анда хикәяләр, шигырьләр, мәкаләләр, документлар, истәлекләр, хатлар, юлъязмалар, хәбәрләр, көндәлек язмалары, юмор-сатира әсәрләре — җәмгысе 250 ләп каләм эше керде.

Китап журнал редакциясендә сатылачак.

*Карл Фуксның тууына 230 ел*

# КЕШЕЛЕКЛЕ, МӘГЪРИФӘТЛЕ ШӘХЕС

Безгә кадәр кемнәр, нинди затлар гына туып-яшәп китмәгән дә, нинди генә рухи байлыклар, якты истәлекләр калдырмаган бу дөньяда!

Талантлы галим, гуманист, Казан университетында иң беренчеләрдән саналган профессор, врач Карл Федорович Фуксның биографиясен, купкырлы фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген, гаилә хәлен, зыялы һәм гади кешеләр белән дә бертигез аралаша белүдәге сокландыргыч яшәү рәвешен күздән кичердем дә (аның хакында дистәләгән мәкаләләр, китаплар язылган) ирексездән әнә шулай дип уйлап куйдым.

Аз да түгел, күп тә түгел: 70 ел гомерен яшәп кала һәм шуның 40 елдан артыгын фәнгә, бер дә курыкмыйча әйтеп була — татар дөньясына, Казан каласына, аның кешеләренә багышлый.



Милләте ягыннан — немец, ләкин мәркәзебез Казанда яшәгәнгә күрәме, ул шәһәрне һәм татарларны бигрәк тә үз күрә, якын итә. Аның Печән базарына (хәзерге Париж урамы) еш баруы, татарлар белән аралашуы күп истәлекләрдә бәян ителә. Һәм юкка түгел: әле хәзер дә фәнни кыйммәтен югалтмаган «Казан шәһәренең кыскача тарихы», «Рамазан», «Корбан», «Сабан», «Татарның Жыен бәйрәме» кебек хезмәтләре күп яктан игътибарга, хөрмәткә лаек.

Аны Казанда гына түгел, бөтен Европада диярлек яхшы белгәннәр. Төрле һөнәрләреннән тыш, ул әле атаклы библиофил (китапханә остасы) да булган: өендә аның татар һәм урыс телләрендә бик күп кульязмалар сакланган. Казандагы 1842 елгы көчле янгын вакытында ул үзенең төрледән-төрле коллекцияләрен (натуралист, биолог, минераллар белгече һ. б.) ярдәмчеләреннән башка берүзе ташый һәм сәламәтлегенә шактый зыян китерә.

Фото яисә рәсемнәрдә сакланып калган сурәтенә карап, аның кемлеген төсмерләп карыйк әле. Бөдрә чәчләр, киң маңгай, кыйгач кара кашлар, көләч һәм кешелекле йөз карашы, утыртма якалы һәм шул заман кешеләренә хас рәсми киемнәр, орден һәм медальоннар... Кыскасы, аның йөз-кыяфәтеннән акыл һәм зыялылык бөркелеп тора. Ә тормышта һәм кешеләр белән аралашудагы төс-кыяфәтен, житди көләчлеген вакыт галиҗанабләре генә яхшы хәтерләп калгандыр, мөгаен.

Бу кешенең талантына сокланмый мөмкин түгел. Урыс һәм татар телендәге кульязмаларны бөртекләп җыйган бу шәхес юкка гына полиглот, ягъни бик күп телләрне белүче галим булмагандыр: ул, немец һәм урыс телләреннән тыш, шуның өстәмәсенә инглиз, француз, итальян, латин, грек, гарәп, төрек һәм әлбәттә, татар телендә бик иркен сөйләшә белгән.

Һөнәре буенча врач-медик булса да, К. Фукс тарих, этнография, үзе яшәгән төбәкнең гореф-гадәтләре белән якыннан кызыксына, фәнни хезмәтләр язып калдыра. Аны хәтта татарларның берничә хатын белән ничек яшәүләре дә кызыксындыра, гаҗәпләндерә, ул моның сәбәпләрен эзли һәм үзенең күзәтүләреннән уңай нәтиҗә ясый.

Аның дуслары, танышлары — барысы да тарихи шәхесләр. Менә шуларның кайберләрен булса да искә төшереп китик булмаса.

Ибраһимов Николай Мисаилович — университеттта эшләүче галим һәм шагыйрь, «Ватаныбыз әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте»н оештыручы. Аның халыкта кин таралган «Во поле березонька стояла...» дигән җырның авторы икәнлеген дә искә төшерик. Карл Фуксның хатыны Александра Андреевна, урта кулрак булса да, шигырьләр яза. Менә шуларның өендә озак еллар буена әлеге җәмгыятьнең әдәби кичәләре еш үткәрелә. Фукслар йорты үзенә күрә иң популяр әдәби салон ролен уйный. Пугачев бунты турында материаллар җыйнау өчен Казанга килгән Александр Пушкинның бу йортка тәүлек чамасы тукталуы бер дә гаҗәп түгел, алга табарак без моны күпмедер тәфсилләп китәрбез.

Ибраһимовның шәкерте, аннары инде танылган язучыга әверелгән Сергей Аксаковның истәлекләрендә мондый юллар бар: «Мин аның балкып-нурланып торган татар күзләрен мәңге онытасым юк... Укытучымны мин үлеп яраттым, чынлыкта ул мине олы юлга этәрүчем булды». Язмыш аяусыз: Н. Ибраһимов 40 яшендә чахоткадан үлә...

Фуксның Казандагы тагын бер якын дусты, фикердәше — мөгаллим, татар теле белгече Ибраһим Хәлфин. Алар бергәләп, кулга-кул тотынышып дигәндәй, татар, гарәп, төрек телендәге кульязмаларны җыялар, университет китапханәсен баеталар. Бу урында Карл Фуксның дүрт ел буе университет ректоры булып эшләвен дә билгеләп китик.

Пушкинның Казанга килүе зур вакыйга була. Шагыйрь Е. Баратынский К. Фукс турында «гаҗәеп кеше» дип сөйләп кенә калмый, аларны таныштыра, кунакка алып бара. Фуксның истәлекләренә караганда, алар «ярты сәгать эчендә диярлек күптәнге танышлар кебек дуслашып-аңлашып та өлгерәләр». Фукс чәй эчеп утырган араларда Пугачевның ничек итеп Казанны алуы турында ишеткән-белгәннәрен сөйли. Шахмат уйнарга да вакыт табалар...

Бу мәҗлестә, шәһәрнең күренекле байтак шәхесләре белән бергә, университет ректоры Н. Лобачевский да катнаша. Бер истәлекче болай яза: «Без Фукслар өендә әдәби кичәдә булдык. Лобачевский Фукс ханымның язган шигырьләрен укыды һәм берничә тапкыр кычкырып көлеп тә җибәрде...» Лобачевскийның бу өйдә еш булганлыгын, Пушкин килгән вакыттагы кичәгә юкка гына чакырылмавын чамалау бер дә кыен түгел.

1833 елның 8 сентябрендә, Казаннан китәр алдыннан, Пушкин хатыны Наталья Николаевнага хат юллый: «Мин Казанда бишесеннән... Биредә мин героемның замандашлары — картлар белән аралаштым, шәһәр читләрен йөреп чыктым, сугыш булган урыннарны карадым, сораштым, язып алдым — һәм бу якларга килүемнең тикмәгә булмавыннан бик канәгатьмен».

Пушкин өлешен тәмамлап, Карл Фукс образына тагын берничә штрихны өстәп китәсе килә. Шәһәрнең югары катлау кешеләреннән күпләре өнәмәсә дә, Фукс даими яшәү урыны итеп Татар бистәсен сайлый, хәзерге Киров һәм Галиәсгар Камал урамнары чатында өй сатып ала, шул тирәдә яшәүче татар халкы белән якыннан аралаша, гореф-гадәтләрен өйрәнә, оста табиб буларак, аларны карусыз дәвалый. Атаклы Печән базарына еш йөрергә яратканлыгын да менә шулардан аңлап була.

1829 елны бөтен Идел буен чолгап алган ваба (холера) эпидемиясе вакытында ул, Лобачевский белән берлектә, бу афәткә каршы көрәштә гражданлык батырлыгы күрсәтә һәм халык арасында зур популярлык казана. Кыскасы, Казан губерниясе аның «икенче Ватанына» әверелә.

Карл Фукс Россия биләмәсендәге башка милләт вәкилләрен көчләп «урыслаштыру» сәясәтен хупламый, шуна күрә дә ул татар халкы тарихын, аның гореф-гадәтләрен өйрәнә, алга сөрә. Халыкны, туган телне фәкать мәгърифәт кенә саклап калачагын ул дөрес аңлаган һәм менә шуңа күрә гомерен, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген шушы максатка багышлаган.

**Рашат НИЗАМИ**

# ЯҢА ИШАН ОНЫГЫ

Туксанынчы еллар реформасыннан соң иҗтимагый тормышның асты-өскә килде: иптәшләр әфәндегә әйләнде, суллар унга каерды, урындагылар центрист булды, астагылар өскә менде, югарыдагылар түбәнгә тәгәрәде, атеистлар руханилар ягына күчте, дөнья базары фәнни коммунизмлы сыйнфый дошманын танып үз канаты астына алды...

Илдәге сәяси үзгәрешләргә, демократик борылышларга, дингә карата хөрмәт артуга бик сөенгән кешеләрнең берсе, мөгаен, Атилла Расих булгандыр. Туган көненнән алып өлкән яшькә җиткәнче, «Ишан оныгы», «Мулла малае» дигән ярлыктан котыла алмаган язучы, фани гомеренең соңгы биш-алты елын гына булса да мәхдүмлеге белән горурланып яшәп калгандыр.

Сүз иреге, фикер төрлелеге һәм иҗади хөрриятнең барыбер киләсен алдан ук сизенгәнме—А. Расих «Елларны чигерсәм» дигән истәлек трилогиясенең беренче кисәген 1983 елда ук язып, «эшен бетереп» куйган. Язган, ләкин мөхәррирләргә күрсәтмәгән, үз вакыты җиткәнне көткән. Һәм «Ишан оныгы» бары тик 1993 елда, яңа шартларда гына, «Казан утлары» журналында басылып чыга алган.

Рәсүлевләр шаҗәрәсендәге ике мәхдүмлек Атилла Расихның алдагы тормышында һәм иҗатында гел чагылыш таба. Аның ике туган елы бар: берсе—1915, китапларга язылганы—1916. Туган җирен Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәре (элеккеге Оренбург губернасы) дип беләбез, ә чынлыкта исә ул Төркиянең Истанбул каласында туган. Һуннарның явыз императоры хөрмәтенә Атилла кушсалар да, әнисенең уе башкача була—Төркиядәге кендек әбисе Расиха хөрмәтенә малаен Расих дип атауларын тели. Авыл хуҗалыгы институтына укырга керә, ветеринария институтын тәмамлый. Үзе—гыйльми хезмәткәр, үзе—профессионал язучы. Романнарының берсе—«Ике буйдак». Кыскасы, Атилла Расихның язмышы куш чикләвек кебек.

Бүгенге яшь укучы алдына: «Кем соң ул, Атилла Расих?»—дигән сорау куярга ашыкмыйча, язучының берничә күләмле әсәрен санап китү бик тә урынлы булыр: «Дустым Мансур» (1955), «Язгы авазлар» (1963), «Ике буйдак» (1965), «Ямашев» (1968), «Каһарманнар юлы» (1972) романнары, хәрби-патриотик юнәлештә язылган күп санлы маҗаралы һәм дә лирик повестьлары... Аның төп әсәрләре һәммәсе дә русчага тулаем тәрҗемә ителгән.

Хөрриятнең әдәби мохиткә алып килгән әхлакый чирләреннән берсе—китапка битарафлык дибез. Үз чорында тәнкыйтьчеләр А. Расих иҗатына игътибарсыз калган дип әйтеп булмый. Р. Сверигин, Ф. Миннуллин, И. Нуруллин, Р. Мостафин, Ф. Мусиннар аның хакында күләмле рецензияләр, китабына кереш сүзләр язганнар. Бүгенге таләп белән өйрәнсәк тә әсәрләрен укыла торган китаплар шүрлегендә күрербез.

Хезмәт юлын Вахитов исемендәге комбинатта гади эшче булып башлаган, гыйльми иҗат белән матур әдәбиятны икедән үреп барган, биографик трилогиясе диссидентлык рәнжеше белән сугарылган, биш еллык сугышта җиңеп орден-медальләр белән кайткан да, илле елдан соң нәкъ Бөек Җиңү бәйрәме көнендә вафат булган кешелекле язучының шәхси тормышы аеруча кызыксыну уята. Шуңа күрә, әлеге язмада романнарының эчтәлеген сөйләп, идея-сюжетына тирән анализ ясап А. Расих иҗатын укучы күңеленә кодалауны максат итеп куймадык. Таләпчән укучы үзен кызыксындырырлык авторларны сайлый белә ул. Безнең уебыз, дистәләп роман һәм тагын шулчаклы повестьны мирас итеп калдырган олы шәхеснең портретын, иҗади йөзен гәүдәләндерү иде.

Без, инде ир уртасы яшенә җиткәннәр, аны бик һәйбәт хәтерлибез. Ә XX гасыр

азагында каләм тибрәтә башлаган яңа буын авторлар А. Расихны без сөйләгәннәргә таянып кына күз алдына китерә алырлармы? Һәрхәлдә, киткәннәрне искә алу изге гамәл—язучы исемен язучы саклый, кирәксә эзләп таба, күтәрә, белмәгәннәр өчен холкын-фигылен, портретын сөйләп калдыра.

Портрет димәктән, һәр рәссам аны үзенчә шәрехли. Кемдер үз героеның әвәл чәчен ясый, кемдер исә авыз-борыныннан, йә иякләреннән ясый башлый.

Атилла Расих әдәби геройларын тасвирлаганда палитрага буяуларны саран өсти, сурәтләү чараларына манылган бизәкләр белән чуарламый, гади укучы күзенә күренерлек итеп кенә тасвирлый. Хатын-кыз персонажлары—зур күзле, озын керфекле, куе кара чәчле; ә ирләре куе чәчен артка тараган, уртачадан калкурак буйлы, туры карашлы, түгәрәк йөзле булырга мөмкин.

Язучының үзенә килгәндә: култыклаучан чәчен артка сыпырып куйган булыр, зур, төзек йөзле, киң иякле, каш кадәрле генә мыек йөртер, зур төзек йөзенә күрә калын гәрәбә кысалы күзлек кияр, кеше алдында киң маңгаена җыерчык чыгармас, гадел, әмма үтәли күз карашларына тотылсаң, онытылган гөнаһларың искә төшеп, вөҗдан газабы кичерә башлыйсың. Гәүдәгә шагыйрьләр Нури Арслан белән Зәки Нуридан чак кына кайтыш, әгәр җыелыш бетеп таралышыр вакыт житкәч урыныннан торып басса, проза секциясенә килгән язучылар аның янында кечерәеп калгандай була торган иде. Шушындый эре сөякле шәхеснең чамасыз юашлыгы аның гәүдә зурлыгына тәңгәл килми иде бугай. Ул сүгенә белмәде, кычкырып сөйләшкәнен дә хәтерләмим, тәмәке тартмады, хәмер капмады, туташларга кызыкмады—кыскасы, нәселле мөгаллимнәр баласы: Зәйнулла ишан оныгы, Кадыйр мулла малае, укытучы Зәйтүнәнең сөекле улы. Укырга барсаң да, өенә кайтсаң да—мәктәп.



Әнисе укытучы булып эшләгән Шәле авылына язгы-кышкы каникулларга кайтса да, кайнатасының туган авылы Пәрәүдә җәйге елларын үткәрсә дә, хәтта бишьеллык сугыш афәтен кичсә дә, Атилла Расих һәрвакыт тәртипле, ягымлы, мөләем, самими булып кала алган. Яшәү тирәлегенең кырыслыгына бирешмәгән. Яшәү тирәлеге итеп, «Ишан оныгы»ннан бер өзек китереп үтү урынлы булыр.

«Шәле Татарстандагы иң караңгы авылларның берсе дисәм дә, шәт ялгышмам. Аның халкы ифрат артта калган, әдәпсез, усал. Ирләре генә түгел, анда хатын-кызлар да оятсыз сүзләр кыстырып сөйләшә. Кеше үтереш, талаш анда еш кабатлана торган хәл. Әни шундый авылда укытты. Алай гына да түгел, ул анда колхоз төзү эшендә шул шомлы авыр көннәрдә тырышып, актив катнашып йөрде».[1]

Инкыйлап кичергән җөмһүриятебезнең кулаклар бәйге тоткан иң зур авылына скрипка күтәреп кайтып кергән Атилланың балачак хатирәләрен сызып ташларлык дәлилләр табалмабыз. Гәрчә, әлеге китабының ахырына житәрәк, А. Расих бу авыл хакында тагын да иркенләбрәк яза. Шәлегә сөенә-сөенә кайтулары, кибет тавында чана шуулары, бала итәкле чуар күлмәк кигән кызларны кич утырганда скрипкага биетүләре, әнисе янында үткән жылы, тук көннәре язучының күңелендә матур бизәк булып саклана. А. Расихның хатирәләрен Шәле төбәге тарихына теркәгәндә тагын бер детальне онытмаска иде, язучы «Питрәч» сүзенең этимологиясенә үзенчә яңалык өсти. Монарчы: йә кеше исеме, йә бәлки «Пестрый» (чуар) халык яшәгәнгә шулай аталгандыр дигән версияләргә бөтенләй башкача килә: Питрәч—күәстә калган камырдан пешкән кечкенә ипи, ди ул. Якташларыбыз адресына әйтелгән яманлауны оныттырырлык ачыш бу.

[1] А. Расих. Ишан оныгы. ТКН. 1996 ел. 10 бит.

Авыллар турындагы өстәмәләр язмабызга һич артык түгел, бактың исә язучы гел әнисе йогынтысында үсә. Һәм әнисе кайда—Атилла Расих шунда. Моңа табигый хәл итеп кенә карау җитми. Эш шунда ки, Рәсүлевләр гаиләсе рәсми яктан бөтен булып исәпләнсә дә, чынлыкта исә язучының әтисе тору урынын еш алыштырып гел читтә яши. Ишан малае—Кадыйр мулла репрессиягә эләгеп, алты ел «утырып» чыкканнан соң, хатынының һәм улының киләчәген мөмкин кадәр керсез саклар өчен әле Әстерханда, әле Төркиядә, йә Уфада «югалып» тора, гаиләгә хәленнән килгәнчә почта аша ярдәм итә. Бары тик гомеренең соңгы көннәрендә генә гаиләсенә кайтып егыла. Инквизиция яна корбаннар эзләп мавыкса да иселәрен дә онытмый. Кадыйр—элеккеге Указлы мулла—Казанда тыныч яшәр өчен дингә каршы чыгышлар ясарга мәҗбүр була.

А. Расихның әдәбиятка хирыслыгы кайсы яктан килә дигәндә... Әтисе, Истанбулда өч ел укып, төрек лицеен тәмамлаган. Гомер буе диярлек бер пьеса язган, әмма улының сүзләре белән әйткәндә, тик очлап кына чыга алмаган...

Язучы буларак формалашуында әнисе Зәйтүнәнең йогынтысы искиткеч зур. Ул, укытучы буларак, малаен әдәби мөхиткә алып керә. Өйдә кычкырып шигырь уку, әдәбиятка гашыйк шәхесләр белән еш аралашу, өй түрендә Г. Тукай портретын саклау—болар берсе дә эзсез югалмый. Атилла Расих, күп очракта, дөньяга әнисенең күзләре белән карый, әйтер сүзен аның кинәш-нәсихәтләре белән аялый, әдәби коллизияләрне чишкәндә «әнием»нәрчә ягымлы булып кала.

Әнисе Атилла Расихның сугыштан язган 127 хатын саклый. Солдат хатлары беренче җөмләсеннән ахырынача сентименталь проза рәвешендә бара. «Сөекле әнием!», «Кыйммәтле әнием!» дип башлана да «Йөзеңнән үбеп, улың» дип тәмамлана. Бу сүзләр язучының персонажлары сөйләмендә дә еш кулланыш таба. «Әни малае»ның стиле хәтта сугыш чорында, ут эчендә язылган хикәяләрдә дә сизелә.

Разведка ротасына яшь кыз Наилә Ихсанова килеп төшә («Сагынылган мәхәббәт»). Өлкән лейтенант Ильяс разведчик кызга шундук гашыйк була. Ләкин, ротаның командиры буларак, Наиләгә карата үзенең хөрмәтен сиздерергә теләми. Эшкә зыян килер дип курка. Әлбәттә, «эш» дип автор бу очракта сугышны әйтә.

Инде тагын бер мисал.

Дүрт ел сугышып, хатыны һәм ике баласы янына исән-имин кайтып төшкән Габдрахман күрешүнең беренче төнендә нишли дисез?!. Бүлмәдә ут сүнгәч, сугыш кырларында ятып калган дуслары алдындагы бурычлары турында уйланып, хатыны Нәфисәнең йокыга киткәнен көтеп ята. Таң атканчы уйланып яткач, ниһаять йокыга киткән Нәфисәнең маңгаеннан үбеп ала да күрше бүлмәгә кереп комод тартмасыннан сугышка чаклы эшләгән заводтагы сызымнарны эзләргә керешә... («Беренче көн»).

Иҗатын укыгач автордан ерагаясың, биографиясен өйрәнгәч якынаясың. Гомумән, Атилла Расихның романнарын кулына алганчы әвәл аның биографик трилогиясен укып чыгарга кирәктер. «Елларны чигерсәм» трилогиясе язучының бөтен иҗатына алтын ачкыч булып тора.

Әнисе, кышкы озын кичләрдә Хөсәен Ямашев турында хатирәләр сөйләп, Атилла Расихта беренче татар большевигының язмышына карата зур кызыксыну уята. Телгә алынган Шәле авылы колхозы шул вакытлардан бирле революционер М. Вахитов исемен йөрткән, бәлки бу да укытучы Зәйтүнә өчен сүз башы була алгандыр. Ни генә димә, Атилла Расих «Хөсәен Ямашев» дигән тарихи роман өчен трилогиялек материал җыеп өлгерә.

Ветеринария институтында кандидатлык диссертациясе яклый алган четерекле язмышлы Атилланың әдәбият белән җитди шөгыльләнәсен аңлаган Зәйтүнә ханым. Һәм улы өчен иркенләп истәлекләр язып калдырган. Алга таба бу истәлекләр язучының өстәл китабына әверелә, ни генә язса да өстәмә мәгълүмат чыганагы була. Әлеге истәлекләрдә күпләргә таныш—Тукай һәм Зәйтүнә мөнәсәбәтләре шактый зур урын алган.

1907 елда, үндүрт яшьлек Зәйтүнә, Шакир абыйсына ияреп, Троицкидан Казанга күчеп килә. Бу—Тукайның Уральскидан Казанга килгән еллары. Казанга бераз

иялəшкəч, Зəйтүнə туганнан-туган сеңлесе Шəмсениса белəн «Əл-Ислах» редакциясе каршыннан үтеп йөрилəр. Аларны ачык тəрəзəдəн Фатих Əмирхан күреп ала. Бер мəлне ул: «Иртəгə безгə Тукай килə, сез дə килегез»,—дип кызларны кунакка чакыра. Тукай белəн еш күрешүлəр заяга үтми. Ф. Əмирхан белəн Шəмсениса, Тукай белəн Зəйтүнə арасында серле дуслык урнаша. Шигъри кичəлəр, концерт-тамашалар, редакциядə кəрт уйнаулар яшьлəрне шактый якынайта. Тик, 1908 елда Зəйтүнə, яшəү шартларын яхшырту йөзеннəн, əнисе белəн Чистайга күчеп китə. Анда да Тукайдан сəламнəр ирешə тора. Хəтта Чистайга гастрольгə килгəн «Сəйяр» труппасы спектаклендə сөйгəн кызы өчен контрамаркалар да җибəрə. Лəкин кавышу турында сүз чыкмый, киресенчə, Тукайның авыруы көчəйгəн саен, аралары ерагая. Биш ел көтеп тə өмете өзелгəн мəхəббəттəн, шагыйрьнең Зəйтүнəгə багышлап язылган шигыре генə туып кала. Егерме яшен мөлдерəмə тутырган кызны Зəйнулла ишан улына димлилəр. Кадыйр мулла хатыны булгач та əле Зəйтүнə, Атилласын ияртеп, Тукай каберенə зыярат кылырга йөри.

Əни кеше язучы Атилла Расих өчен махсус язып калдырган истəлеклəрендə Тукай илə булган мөнəсəбəте хакында, кеше кулына элəгүдəн курыкмыйча һəм олы улыннан тартынмыйча, бөтен нечкəлеклəренə кадəр əйтеп сала алмагандыр əлбəттə. Монысы мөһим дə түгел. Ин мөһиме—шушы гамьдə, Тукай рəсеме астында үскəн Атилла Расих килəчəктə Г. Тукай исемендəге дəүлəт премиясенə лаек булачак.

Гаилəм тук яшəсен өчен аспирантурага кердем, гыйльми эш белəн шөгыльлəнəм дип җае килгəндə акланырга яратса да, чынлыкта, ул фронттан кайткач иҗат газапларына тулаем чума, томаланып яза башлый. Əтисе өчен эзəрлеклəүлəрдəн аны үзе тудырган «дөрес» əсəрлəре саклап кала.

Гаделлек һəм социалистик казанышлар өчен җан атып яшəгəн А. Расихның мактаулы сыйфатларына зыян китермичə генə аның бер матур ялганын да ачып салыйк.

1934 елны, Казанның авыл хуҗалыгы институтына укырга керер өчен анкета тутырганда, ул үзенең социаль чыгышын мулла малае дип түгел, ə хезмəткəр гаилəсендə тудым дип яза. «Теге-бу» оешмалар моны бер ел укыгач кына сизеп алалар һəм Атилла Рəсүлевне институттан куалар. Егет үҗəтлек күрсəтə, Мəскəүгə барып Җир эшлəре комитеты (Наркомзем) комиссиясенə ярдəм сорап мөрəҗəгать итə. Əлеге комиссия, тартып-сузып йөри торгач, əтилəренең аерым яшəвен, Атилланың русча шəп белүен, аның хикəялəр авторы булуын исəпкə алып, совет югары уку йортларында алга таба укуын дəвам итəргə рөхсəт бирə. Күрəсең, колхозлашу еллары түгəрəклəнеп килə, кулаклар, алпавытлар һəм муллалар токымын җəберлəү планы үтəлгəн булгандыр инде.

Əгəр Атилла Рəсүлевнең метрикəсенə, 1915 елның 16 сентябрендə Төркиянең Истанбул каласында туган, дип тə язылган булса язучыбызны нинди язмыш көткəнен күз алдына китерүе кыен түгел. Шуна күрə дə ул, рəсми гомерен бер елга кыскартып, 1916 елның 16 сентябрендə, Оренбург губернасының Троицк шəһəрендə туган булып теркəлгəн. Бу төгəлсезлек—ничарадан-бичара кебек килеп чыккан чара гына.

«Яшьлек эзлəрем» дигəн китабына (ТКН, 1976) кереш сүз язганда күренекле филолог, əдəбият галиме Флүн Мусин да А. Расихның туган елын төзəтелмəгəн килеш бирə. Димəк, бу икенче чынбарлыкка язучылар да инанган һəм хəтта Атилла агай үзе дə ышанырга дучар ителгəн.

Икеле-микеле җəмгыятьтə иҗат интеллигенциясе һəрдаим икелəнеп яшəргə мəҗбүр... Ишан оныгы, мулла малае, кызыл комиссарлар тарафыннан эзəрлеклəнгəн А. Расих: большевик-революционерларга мəдхия булырдай «Хөсəен Ямашев», «Каһарманнар юлы» романнарын сөенə-сөенə яза; беренче бишьеллык филакарьлəренə дан җырлап «Дустым Мансур» романын тудыра; Сталин исемен байрак итеп фронтка китə; совет солдаты образын идеальлəштереп повестьлар, хикəялəр бастыра; сугыштан соң ачлы-туклы яшəп, девальвациялəрдəн алданып, бер тиенсез калган килеш сугыштан соңгы чорларда колхоз тормышын, яңа чор председательлəрне күтəреп «Язгы авазлар» романын иҗат итə. Язучының эчке капма-каршылыгы, рухи ризасызлыгы, туктаусыз икелəнүлəре һəр яңа əсəрендə конфликт

киеренкелеген көчәйтә. Бу халәт «Ике буйдак» романында аеруча нык сизелә.

Авторның романнары мөхәррирләр кулына элэгү белән журнал редакциясе, нәшрият һәм каләмдәшләре арасында зур бәхәсләр тудыра. Романнар кульязма килеш кулдан-кулга йөри, кире борыла, кат-кат эшләтелә, төзәтелә. Редакция таләпләрен санга сукмаганы өчен, язучылар союзы идарәсе: «Совет әдәбияты» журналы прозаик А. Расихның кульязмаларын алмаска хокуклы»—дигән карар да чыгара (1951). Ахырдан язучы: мин бит кульязмаларымны кат-кат эшкәртәм, редакция әйткәннәрне төгәл үтим, дип, аңлатып шикаятьләр язарга мәҗбүр була. Редакцияләрдә эшләп карамаган, көннәр буе утырып башка авторларның кульязмаларын төзәтмәгән һәр язучыга хас үпкәләүләр, интригалар бу.

Шулай да Татар совет язучысы Атилла Расихның барлык романнары «Казан утлары» журналында «Совет әдәбияты» чорыннан ук басыла килгән. Аларны заманында Абдулла Гомәр, Гариф Гобәй, Гомәр Бәширов, Газый Кашшаф кебек язучыларыбыз редакцияләгән. КПССның Татарстан өлкә комитеты да аның иҗатын таныган. Партия члены булмаса да аңа диссертацияләр якларга ирек биргәннәр, китапларын күпләп чыгарганнар, Язучылар союзының идарәсенә сайлаганнар. Кабул итү комиссиясе әгъзасы итеп билгеләгәннәр, проза секциясе җитәкчесе итеп калдырганнар. Тукай премиясен дә ул Г. Афзал, Т. Миннуллин, И. Юзеевлардан соң, әмма Ә. Еники, А. Гыйләҗевләрдән алданрак алган.

Гомер юлына: НЭП, колхозлашу, шәхес культы, Бөек Ватан сугышы, Чирәм жир, БАМ, үзгәртеп кору чорларын сыйдырган Ишан оныгы, мулла малае, фронтовик язучы Атилла Расихның тормышы һәм иҗат портреты белән хәлкадәр таныштык. Инде әсәрләрен тагын бер кат укып карардай чак җитте.

**Камил КӘРИМОВ**

## Киләсе санда укыгыз

«Казан утлары»ның 10 нчы саны укучыларыбызны түбәндәге әсәрләр белән сөендерергә җыена.

Чәчмә әсәрләр бүлегендә **Фоат Садриевның** «Бәхетсезләр бәхете», **Рәфкать Кәраминең** «Олы юл да сикәлтәле» романнарының дәвамы, **Рауль Мирхәйдәровның** «Үзем хөкем итәм» исемле романының башы һәм яшь язучы **Нурисә Габдуллинаның** «Сихри төн» хикәясе урын алган.

Поэзия яратучылар исә **Мөдәррис Әгъләм**, **Марсель Галиевның** төрле елларда язылган иң әйбәт шигъри бәйләмнәре белән бәррәттән, **Айрат Суфияров**, **Гайсә Гатауллин**, **Наилә Миңнехановаларның** яңа шигырьләре белән дә таныша алачак.

Сәнгать бүлеге **Юныс Сафиуллинның** сәхнә легендалары—Галия Кайбицкая, Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллиналар турындагы «Сәхнәбезнең өч йолдызы» исемле язмасын һәм **Земфира Сәйдәшеваның** композитор Шамил Тимербулатов хакындагы «Чын татарча милли көй» исемле мәкаләсен тәкъдим итә.

**Рафаэль Хәкимнең** төрки-татар цивилизациясе хакындагы «Татар рухы» исемле публицистик язмасы, **Адлер Тимергалинның** «Миллият сүзлеге», **Фирдәвес Гарипованың** «Авылларыбыз тарихы»; «Татар энциклопедиясе битләреннән», **Фаяз Хуҗинның** «Алабугага ничә яшь?» исемле фәнни мәкаләсе дә укучыларыбыз күңеленә хуш килер дип ышанабыз.

Фәридә
Хәсәнова

# «МИН ЕЛМАЕП КЫНА ДӨНЬЯ ҮЗГӘРЕРМЕ?»

## (БҮГЕНГЕ ШИГЪРИЯТТӘ ЗАМАН ЧАЛЫМНАРЫ)

*Гармония юк шул бу Җирдә,*
*Мин тәртипкә салам дөньяны*
*Тик, кызганыч, бары шигырьдә...*

И.Юзеев

Әдәбият тормышны, чынбарлыкны образлы чагылдыруның бер төре булганлыктан, хәзерге заман, базар темасына язылган әсәрләр саны да арта бара. Бүгенге «залиманә зәһәр заманнарда» (З.Мансуровның шигъри табышы ) язылган берничә әсәрнең исемнәренә генә игътибар итик.

Х.Әюпнең шәхси кичерешләрне заманның иҗтимагый фикере, әхлакый проблемалары белән тыгыз бәйләнештә бирергә омтылган «Базарлар», Л.Шагыйрьҗанның «Дөнья базары яхут яңа «Америка фаҗигасе» дип аталган публицистик поэмасы һәм базарны Тукай кебек язарга өйрәтә торган мәктәп итеп сурәтләгән «Чык базарга» шигыре, Г.Моратның тормышта һәркемнең үз бизмәне, үз хакы дип раслаган «Кара базар», А.П.Чехов геройларын хәтерләтеп сатулашкан ике агае белән истә калган «Тукталышлар» һ.б. шигырьләр... Р.Харисның хәзерге заманга җыйнама сурәт булган «Чехов базары» поэмасы.

Алда исемнәре аталган әсәрләр—соңгы еллар җимешләре. Шулай да сүзне әле «үзгәртеп кору» дигән заманнар башланганчы ук М.Әгъләм тарафыннан язылган (1972–1985) «Тукайдан хатлар» поэмасыннан башлап җибәрәсе килә. Шагыйрь анда «Мин әле кая барам?» дигән сорау куйган иде. Әлеге сораунын, соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрдә еш кабатланып, яңадан-яңа әсәрләр тууга сәбәпче булып торганы сизелә. М.Әгъләм болай язган иде:

*Бара шагыйрь,*
*Азык бетә, диме, язарына—*
*Һәрбер шагыйрь үзенең гомерендә*
*Юлыгачак Печән базарына.*

Дөрестән дә, әдәбият галиме Н.Хисамов билгеләп үткәнчә, «базар татар өчен куркыныч түгел». Шулай ук яңалык та түгел. Соңгы унъеллыкларда җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне юкка гына «үткәнгә яңадан кайту» дип атамыйлар. Татар шагыйрьләренең базар темасына мөрәҗәгать итүенә Н.Хисамов болай карый: «Тормыш үзгәрешләренә үтә сизгер татар шигърияте базарга да үзенең мөнәсәбәтен ачыклап килә. Сәүдәгә, кәсәбәчелеккә әзерләнмәгән иҗат кешесенә аның бик күп авыр яклары китереп сукты. Шунлыктан, әлеге шартларны каһәрләүдән алып, комик күренешләргә һәм бу процессны гәүдәләндерүче сәясәткә карата саркастик мөнәсәбәткә чаклы киң аның бәя диапазоны. Хәлбуки яңа иҗтимагый һәм икътисадый чынбарлык зарури рәвештә үзенә юл яра һәм аның ихтыяры тыелгысыз».

Базар турында әсәрләр туу белән бергә базар шартларының үзенә генә хас булган

лексикасы да барлыкка килә. Шулай да татар шагыйрьләрендә базарның аерылгысыз терминнары: бизнес, биржа, брокер, банкрот, маркетинг, менеджмент, инфляция һ.б. шунын ише сүзләр еш очрый дип әйтеп булмый. Мондый халыкара терминнар әдәби әсәрдә сәнгатьлелек тудыруга ярдәм итмиләр, күрәсен. Шунысын да билгеләп үтү дөрес булыр: күрсәтелгән терминнар аңлата торган төшенчәләр әсәрләрнең эчтәлегенә салынган. Шагыйрьләр шартлы алымнар, читләтеп әйтү, сүзнең көчерелмә мәгънәсе аша базар шартларында да уңышлы әдәби әсәрләр тудыруга ирешәләр.

Базар—ижтимагый тигезсезлекнең иң югары чагылышы. Р.Харис «Чехов базары»нда мәсьәләнең нәкъ менә шул ягына басым ясый да:

*—Бетсен налог инспекциясе,*
*Һәм яшәсен Чехов базары!*

*...Дәүләт кызык: рәтләп акча бирми,*
*Ә салымны шәпләп түләтә.*

Бу поэма персонажлары ачыктан-ачык дәүләтнең салым сәясәте белән килешмәүләрен белдерсәләр, И.Юзеев «Иякләштек» (1995) шигырендә «туган җирен ташлап киткән качакка ияләшкән кебек үк, налог йә ясакка ияләштек», дип яза. Бу ияләшү төшенчәсенең шәхес өчен яшәү принцибына («Йом күзенне, күрмә күпне, бул тыныч...») ук әйләнүен әрнү белән билгеләп үтә.

Шулай да шагыйрьнең лирик герое заманның һәр тискәре күренешен кабул итә, килешә дип нәтиҗә ясау дөрес булмас иде. 1991 елда язылган «Без» шигыре алда әйтелгән фикерне раслап тора:

*Кагылмагыз... Безме! Без ул—*
*Яралы юлбарыслар...*

«Яралы юлбарыс» образын Әхсән Баян иҗатыннан да табарга була. Ул да илдәге ялгышларның сәбәбе тәкъдирнең үзе белән үк килгәндер дигән нәтиҗә ясый. Шагыйрь жаны бәргәләнә, хакыйкать эзли, ләкин табасына ышанмый. Ә.Баян кешеләр арасында ышаныч кимүне урманнарда арткан агулы гөмбәләр саны белән бәйли. Кешеләрдә зәһәрлек арту гөмбәләргә күчте, бу табигать ялгышымы, әллә Тәнре каргышымы? дигән мәгънәдәге соравын куя да сораучының портретын икенче бер шигырендә («Аңларсыз», 1992) болай тасвирлый:

*Мин—иманлы, мин горурмын,*
*Дансыз, малсыз... чалбарсыз...*

Шигырьләрендә шагыйрь үзеннән соң килгән буын һәм заман турында болай яза:

*Безнең буын шулай кыюсызрак*
*Булып чыкты. Ә сез? Булдырдыгыз!*
*Шау-гөр килеп, уздыгыз да безне,—*
*Бөеклеккә, әллә бөлгенлеккә?—*
*Ыргылдыгыз.*
*Булдырдыгыз!*

Шагыйрь әлеге шигырендә әйтергә теләгән фикерен, логик дәлилләрен укучының аңына, йөрәгенә тәэсир итәрлек сүзләр һәм алымнар (риторик сорау, укучыга турыдан-туры мөрәҗәгать итү) белән аңлатып биргән.

Ә.Баянның зур тәэсир көченә ия булган шигырьләреннән берсе «Дөньяны мин үзгәртергә килдем» (1993) дип атала.

*Дөньяны мин үзгәртергә килдем.*
*Башлык булыр, дидем, җирдә хаклык.*

*Хак бәхетне һичкем алмас тартып,*
*Рәнҗетәлмәс һичкем көчсезне—*
*Өлкәннәрне, толны, үксезне.*

Лирик геройның шигырьдә хаклыкны яклый алмавы күренә. Шигырь тулысынча экзистенциализм рухында язылган. Тормышны үзгәртергә дип омтылган затның көче, өмете бетеп, ахыр чиктә заман аның үзен үк үзгәртүгә ирешә. Үзгәргән затның портреты дөрестән дә «яралы юлбарыс»ны хәтерләтә:

*Тормыш түгел, сатыш, тартыш монда.*
*Алдау, талау—иң зур акыл көче.*
*Үз җиремдә—мин ят, мин чит кеше,*
*Тик күзәтеп утырам базарны,*
*Күлмәк ертып, бәйлим ярамны.*

Хәзерге шигърияттә шагыйрьләр, заман күренешләрен сурәтләп, төрле конфликтларга игътибар итәләр. Чөнки кеше үзе үк—төрле каршылыкларның берлеге, анда һәрвакыт рухи омтылыш һәм матди теләкләр арасында киеренке көрәш бара, кайсы сыйфат җинә, кеше шул юлдан китә.

Каршылыкларның берсе—халык һәм заман каршылыгы. Заманны тасвирлаган берничә шигырьгә игътибар итик. Әйтик, шагыйрь Р.Харис:

*Яңа заман килә. Килә җәя җәеп.*
*Күзебезгә терәп ата бик күп гаеп.*
*Урамнарда йөри күпме тере мәет,*
*Берсенә дә чыкканы юк моңлы бәет.*

Тагын Г.Афзалның «Яңа заман» шигыренә игътибар итик. Шигырьдәге хис үткәннәрне сагынудан башлана. Чабаталы, комганлы, уразалы, иманлы заманнан көлгән вакытлар искә төшә. Соңга таба кеше «Алла сакласын» дип, һәркемнән шикләнеп авызын йома торган заманга килеп керә... Ә бүгенге заман сайрашырга да гөрләшергә, ирек биргән битарафлык заман... Шигырьдә нечкә ирония сизелеп тора. Чыннан да, бер караганда кешегә ирек бирелгән кебек. Ләкин битараф кешегә ул ирек нәрсәгә? Җитмәсә, ул битараф кеше әле «Кызыл хөрәсән» колхозының бер әгъзасы да булса? Г.Афзал шигырьләрендә дәүләт сәясәтен алдау белән талауга кайтарып калдыру, заманны «этлек» һәм «чүплек» рифмалашкан төшенчәләр аша күрсәтү белән дә очрашырга мөмкин. Ә менә «Заман» шигырендә Г.Афзал заманны җанлы әңгәмәдәш дәрәҗәсенә күтәрә. Аны матур, әмма үзе нәфис сүзгә ышанмый; аң-белемгә юмарт булса да, хискә саран; исәп-хисап алга киткән, танышларының кадерен табыш белән билгели торган; романтизмы артка чиккән соры җанлы, усал күзле, коры сүзле ялгыз кеше образы белән тиңләштерә. Шагыйрьнең заман темасын күтәргән шигырьләре шактый. Шуларның берсе булган «Хәбәрдарлык заманы»нда ул телевизордан илдә яки дөньяда барган һәр яңалыкны, фактны күрсәтү, карау мөмкинлеге белән генә чикләнмичә, «начальниклар ни әйтер дип, телне тешләп тормыйк инде» дигән мәгънәдә дә аңларга кирәклегенә басым ясый. Ә икенче бер шигырендә ул, кешенең алтмыш еллык тормыш тәҗрибәсенең ялган булуын аңлавын хәбәр итә. Дәрдмәнднең «Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан, Түгел бал корты мин—чагып елаткан» дигән шигырь юлларын искә төшерә.

Илгә демократия җилләре китергән яңалыклар драматизмы темасын Әхмәт Гадел тагын да кискенләштерә.

*Кем гаепле - безме, заманмы?*
*Кем уятты бездә ямanны?*
*Кем торгызды авыр чакларны?*
*Кем күрсәтте кискен чатларны?*

*Ул елларның ялгыш эшләре*
*Ни эшләтте безне? Нишләдек?*
*Кем гаепле? Безме? Заманмы?*
*Кайсы өстен: хаклык? Ялганмы?*

Шигырьдә лирик геройның трагизмы да күренеп тора. «Бар дошманны жиндек» дип расласа да, ул «җыналмадык тик үзебезне» дигән нәтиҗәгә килә. Россия өчен хас булган «Кем гаепле?» дигән мәңгелек сорау аны соңгы юлга да озатыр кебек тоела. Ә.Гадел башка шигырьләрендә дә әлеге сорауга кайта-кайта мөрәҗәгать итә. Кешеләрне һәр гамәл өчен җавап бирергә чакыра. Шул рәвешчә, аның шигырьләрендә тәрбияви як көчәеп китә. Ә бу күренеш, билгеле булганча, әдәби әсәрнең эстетик көчен киметә төшә.

Гәрәй Рәхимнең «Заман» шигыре дә, заманны ачыклый, образ тудыра торган күпсанлы сурәтләү чаралары булуга да карамастан, укучы күз алдында романтик күренешләр тудыра алмый. Шигырьдә Заман һәм Вакыт «үз братын төп башына утырта торган» дәгъвалы, чуалчык, норсыз, котсыз, әхлагы китеп, тәртибе беткән чор итеп сурәтләнә. Әлеге шигырьдә көлү дә, яшь аралаш елау, гаҗизлек хисләре дә бар. Әлеге хисләр Дәрдмәндтә башкачарак чагылыш тапкан иде: «Бертуганың чит тибәдер, дәүләт тигез булмаса. Ана сөтен айры имә, Бала игез булмаса».

Базар мөнәсәбәтләре әдәбиятта махсус лексика да тудыра икән. Газинур Морат «шагыйрь базары» һәм «шигырь базары» метафораларын 1992 елда ук кертеп җибәргән иде. Шагыйрьнең яңа гына чыккан «Төнге әверелеш» китабында әлеге темага кагылышлы шигырьләрне тагын да табарга була. Мәсәлән, «Китап базары». Дәрдмәнднең «Кил ки зарым! Юк язарым, Чөн кабул итми базар...» юлларын эпиграф итеп алган бу шигырьдә татар китабының бәясе турында сүз алып барыла. Шагыйрь татар китабының чорма, архив, сандык төпләрендә посып яткан вакытларын искә төшерә, учак-учак янган китаплар да калкып чыга. Шигырьгә каләм ияләренең китап чыгару өчен спонсорлар эзләве дә килеп кергәч, Тукай искә төшә: «Ә Тукайга байлар үзе түләгән». Базарда китап сатучы агайлар белән гәп куерта башласаң, алар көлә генә: «Сезгәме соң Тукай кебек язу, кит әле!». «Татар китабы базарда түгел, базада аунап ята шул»,—дип уфтана автор. Базар агайларының Ги де Мопассан, Маркиз де Сад китапларын гына сатуы сәбәпләрен ачыклауны автор укучының үзенә калдыра. Шулай да шигырьнең яшерен мәгънәсендә җавап табылганлыгы сизелеп тора. Әйе, әлеге шигыре белән Г.Морат бүгенге көндә килеп туган кискен проблемаларның берсе—татар китабын тарату, китап сәүдәсе кебек мәсьәләләрне әдәби яссылыкта күтәреп чыга. Рухи хәзинәне халыкка җиткерүнең ныклы системасын, китапка дәүләтчә мөнәсәбәт булдырырга чакыра. Проблема хәл ителмәгән очракта, халыкны китапсыз калдыру—аны тарих битеннән сызып ташлау белән бер кебек дигән фикер әйтелә. Шагыйрьләрне генә түгел, шигырь укучыларны да әдәби әсәрләргә куела торган югары таләпләр планкасын төшермәскә чакыра.

Ә менә «Талчук» шигыре үзенең әдәби-эстетик вазыйфасы белән алдагыларыннан аерылыбрак тора. Шагыйрь Г.Морат Дәрдмәнд кебек («Урамнан һәм базардан чүплә сүзне...»), язарына азык эзләп, базарга чыгып китә. Әмма дөнья базары булса да, анда язарга азык табылмый, чөнки лирик герой фикеренчә, һәр нәрсә үз-үзеннән кыйммәт хакка сатыла. Шул вакытта бүгенге базар мөнәсәбәтләренең тагын бер күренеше—реклама ялтырап ала. «Бәхет сатам, үз бәясенә!»—дип, кулына тутык дага тоткан бөкре бер карт аваз сала: аның товарына чират тезелә. Шулай итеп шартлы алым лирик геройның проблемасын чишәргә ярдәм итә. Төн уртасында килгән илһам исә аңа яңа шигъри бәйләмнәр китерә. Шул рәвешчә Т.Кампанелланың «Киләчәктә дөнья белән шагыйрьләр идарә итәр»,—дигән фикеренә таба бер адым ясала. Шагыйрь, халыкның «дага бәхет, байлык китерә» дип ышануына нигезләнеп, кызыклы шигырь тудыруга ирешкән.

Г.Моратның «Юл чатындагы кибет» шигыре дә шул тематиканың дәвамы дип әйтсәк ялгышмабыз. Шигырьдән аңлашылган төп фикер болай яңгырый: «Акылсызлар акыл сата монда, акыллылар—акылсызлык».

Шагыйрьнең һәрбер шигыре укучы алдына сиздермичә генә мәңгелек сорау куя.

Әлеге сорау Россия халкы өчен яналык түгел: «Кем гаепле?» һәм «Нәрсә эшләргә?». Г.Морат әлеге җыентыкта тупланган әсәрләренең проблемасын, идея эчтәлеген бер шигырь аша да аеруча калку җиткерә. Ул шигырь «Сәяси сорау» дип исемләнгән.

*Һәрбер ялган*
*Дөрес булып*
*Күренә генә.*
*Ялганга ышанмый*
*Халык—*
*Күнегә генә.*
*Ник ялган, алайса,*
*Илнең*
*Түренә менә?..*

Ә менә Р.Фәйзуллинда әлеге проблема башка төрле чишелеш ала. 1985 елда язылган «Тордым басып Кама ярында» шигырендә ул Балык Бистәсе пристаненың Мәкәрҗә ярминкәсе кебек шаулап торган чакларын сагына. Пароходлар туктый торган пристаньның күпләр өчен озату, ә яшьләргә шигырь уку урыны булуын искә төшерә. Ә бүгенге көндә елга ярларының гына түгел, кешеләрнең дә үзгәрүенә игътибар юнәлтеп, хәтергә кереп кала торган чын шигъри юллар иҗат итә:

*Нуры азрак хәзер күзләрнең,*
*Чынлыгы ким әйткән сүзләрнең...*

Иҗтимагый-сәяси темага язылган шигырьләрдә хакыйкать һәм ялган кебек төшенчәләргә шагыйрьләрнең бик сизгер булулары күренә. Аларның күбесе әлеге проблеманы «балык башыннан чери» дигән принциптан чыгып чишәргә алына. Мәсьәләгә Р.Фәйзуллин кебек, «заманалар менгә әйләнсә дә, фидакарьләр һәрчак табыла» диючеләр дә бар. Битарафлар сафы соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрдә кимеп бара сыман.

Ялган төшенчәсенә Ф.Яруллин да бик сизгер. Ул әлеге бер сүз нигезендә кабатлау һәм градация, әлеге сүзнең көчерелмә мәгънәсе аша дүрт строфалы шигырь яза. И.Юзеев, Г.Афзал, Ш.Галиев һ.б. шагыйрьләр иҗатында күзәтелгән заман күренешен ул капма-каршы яссылыкта сурәтли. Шигырьдә ул болай яңгырый:

*Ялганнар, ялганнар, ялганнар...*
*Үзгәрә дисәк тә заманнар—*
*Юк, заман үзгәрми, бары тик*
*Үзгәрә, яңара ялганнар.* (1994)

Хакыйкать төшенчәсен Г.Морат иҗтимагый, сәяси планда караса, шагыйрә Нәҗибә Сафина «җиргә төшерә». Хәйләләү, хәйләләп кешенең нәрсәсен дә булса алу; ялганлау, ялган сөйләү; ялган сөйләп кешене ялгыштыру, ялгыш фикергә китерү, ялганга ышандыру; кызыктыру, саташтыру, ялгыштыру, башкача булып күренү яки ишетелү; вәгъдә бозу, хыянәт итү; ялгышу кебек мәгънәләргә ия булган «алдау» төшенчәсен һәм ул сүз китереп чыгарган хисне шигырь нигезенә сала. Шулай итеп, «Табигать тә әгәр алдаса...» шигырендә гади татар хатыны хисләрен сурәтли. Лирик герой дәүләт, хөкүмәт, мөдир, нәшрият, мөхәррир алдауларына күнеккән инде. Ул аны шулай тиеш дип кабул итә. Барысы да алдый: хәтта халал ир дә, урам чатларындагы хәерчеләр дә. Банкир да кредит бирәм дип алдый, майсыз сөт белән майсыз май да ашап алданабыз. Шулай да шигырьләге лирик геройның иҗтимагый, сәяси, икътисадый пландагы алдауларга исе китми дип ышанырга була. Градация алымы белән барып, шагыйрә әлеге каршылыкның югары ноктасына җитә: Кеше—Табигать каршылыгы. Ләкин Табигать алдаса—ана күнегеп булмый икән. Май аенда көз килүне күнел кутәрә алмый. Май җылысы сизелмәсә, унбишенче числоларда алмагач чәчәк атмаса, тупыл яфрак ярмаса—йөзләргә сары чыга. Шулай да шагыйрә ахырда Табигать бу Заманнан үрнәк алмас әле дигән ышаныч калдыра.

Шагыйрә Н.Сафина алдау мәсьәләсен дәвам итеп, туган тел һәм татар телен дәүләт теле итеп күрәсе килү проблемасын «Әллә төш, әллә өн» шигырендә күтәрә. Лирик герой ялгыш кына чит илгә барып чыга. Китмән торкан бер кешене күргәч, аны татардыр дип уйлап сүз ката. Аның «Мин дә татармын, су бир, үләм»,—дигән үтенеченә каршы тегесе, авызын ачып, телен күрсәтергә куша. «Татар булсаң, синең авызда ике тел булырга тиеш»,—ди. Ләкин авызда сынар өтек тел генә күренә. Уянып киткәч, лирик герой бик унайсызлана. Өнендә аңа мәҗбүри рәвештә (алдап) икенче телне куярга киләләр. Шул рәвешчә автор татар теленең кулланылыш дәрәҗәсен, әһәмиятен арттыру бурычын шартлы алымнар ярдәмендә һәм сәнгатьчә нәфислек белән укучының аңына сеңдерә.

«Алдау-алдану» төшенчәләренә Зөлфәтнең карашы үзенчә. Башка шагыйрьләрнең лирик герое алдауны авыр кичерә. Гадәттә, ул үзе гадел кеше булып, дәүләт яки кешенең алдаганын күзәтеп тора, бәяли, йә алдауны кисәтә торган зат итеп сурәтләнә. Ә менә Зөлфәттә башкача:

*Күреп, аңлап, тоеп яшәдем мин—*
*Ялган белән тулды һәр төбәк.*
*Алдаучысы булган яшәештә*
*Алданучы булган—мин кирәк.*

Шулай да шагыйрьнең лирик герое беркатлы дип уйлау дөрес булмас иде. «Шик» дип исемләнгән шигырендә лирик герой «тууым да минем ялган икән, ялган икән минем туган ил» дип белдергәннән соң, язмышы турында уйлана, «бөҗәкләр дә үз дигәнчә яши» дип өзгәләнә.

Алдау кебек төшенчәгә И.Юзеев башкача якын килә. Аның лирик герое, «гомер буе бәхет килер» дип алданып яши-яши гомер азагына якынлаша. Ахырда шундый нәтиҗәгә килә: «ышанмый да, алданмый да» башлый. Икенче бер шигырендә ул («Бурлаклар», 1995) үз халәтен акчарлакларның ачы авазын тыңлап барган мәңгелек бурлакка тиңләсә, өченче бер шигырендә («Олы җанлы шагыйрь-әдипләргә...», 1995) олы җанлы әдипләрнең, хакыйкатьне төшендерә алмый, йә Тукай кебек яшьли гүргә, йә Исхакый кебек чит илгә китеп барырга мәҗбүр булуын әйтә. Шигырьдән аңлашылган төп фикерне болай аңлатып булыр иде: халык шагыйрьләре, язучыларына кадер-хөрмәт алар исән чакта ук күрсәтелсен. Әлеге проблема башка шигырьләрдә дә («Ул даһины исән вакытында...», 1995) дәвамын таба. И.Юзеев аларда ачынып шундый сорау куя: «җылы караш ташка ник кирәк?».

Р.Харисның заман темасына кагылышлы «Лирик сәүдәгәр» исемле шигыренә игътибар юнәлтик. Әсәрнең исемендәге эпитеты үзе үк гаҗәпкә калдыра. Татар әдәбиятында сәүдәгәрлекне шулай яратып, лирик сәүдәгәр дип атаган башка шагыйрь күренми. Әлеге шигырьдән сәнгатьнең, әдәбиятның көче нечкәлектә икәнлеге калку чагылып тора. Гадәттә бездә сәүдәгәр йә комсыз, йә бай, йә алдакчы булып сурәтләнә. Ә биредә шагыйрь, шушы ике сүзнең көтелмәгән янәшәлегеннән файдаланып, яңа образ ясый алган. Лирик сәүдәгәрнең сата торган товары да үзенчәлекле: төнге урмандагы агачларның шәүләләрен тәкъдим итә ул. Менә «төбендә бер хатынның бер ир иннәренә куанычлы яше түгелгән» төз нарат; әнә, сөялеп, горур сөйгәне яшь егеткә «мин синеке була алмам» дигән ап-ак каен; арырак нәфис миләш, юкә, имән... Ләкин сатып алучылар гына күренми. Шулай да лирик сәүдәгәр уфтанмый, күпме кадерле хатирә үзенә калды бит. Кирәк чакта ул аларны файдалана яки бүләк итә алачак.

Хәзерге әдәбиятта базар темасына язылган шигырьләрдән яңалыгы белән аерылып торган тагын бер шигырь бар. Ул да булса Марат Закирның «Базар читендә бер карт» шигыре. «Ап-ак кәфендәй бер карт» базар читендә, елмаеп, юк кына бәягә үзенең гомер буенча туплаган хәләл малын—«алтындай хаталар»ын сата. Шагыйрьнең «Бәһа» шигыре дә кешене уйланырга мәҗбүр итә торган рухта язылган: «Бүгенге бәһаләргә киләчәк заман үзе бәһа куяр».

М.Закир шигырьләрендә, новелладагы кебек, фикернең кинәт кенә үзгәреп, бөтенләй көтелмәгән чишелеш алуы күзәтелә, шулай ук әйтеп бетермәү көчле. «Хәер соранучы» шундый шигырьләрдән берсе. Шигырьдән аңлашылган төп мәгънә аның исеменә үк чыгарылган.

Ә менә Л.Шагыйрьҗан «Чык базарга» шигырендә заман базарын тарих, сәнгать, тормыш итеп сурәтләгәннән соң гына «сәясәткә бирә». Базарны ул җыенга тинли— уенны базар үлчәвенә салып сөйләргә кирәк. Базар бер үк вакытта юмарт та, саран да, чөнки анда берсе җан азыгы эзләсә, икенчесенә мал кирәк. Базардан ул фәлсәфә ала, аны тормыш сәхнәсе итеп күз алдына китереп, бер үк вакытта үзе тамашачы һәм катнашучыга да әверелә.

Хәзерге заман татар поэзиясендә базар темасын чагылдырган әсәрләр күпләп языла. Шагыйрь Харрас Әюпнең дә «Базарлар» дип исемләнгән публицистик поэмасы бар. Әсәрдә лирик персонаж базарга болай гына, бабайлардан калган бер гадәт буенча, бер йомышсыз, ил хәлен белер өчен генә чыга. Поэманың композициясе дә базарны хәтерләтә. Аның беренче һәм соңгы бүлекләре бару-кайту булса, төп өлеш төрле базар исемнәре белән аталган. Мәсәлән, «Колхоз базары», «Печән базары», «Әмәкәй базары», «Болгар базары», «Коллар базары», «Кошлар базары», «Сорочи базары» һәм «Дөнья базары». Шагыйрь аларда базарның кеше тормышына басым ясавына ачынып яза. Нигә киресенчә түгел соравы куела. Лирик герой базар кыйммәт булса да, ил каршында адәм баласының арзан торуы сәбәпләрен эзли-эзли, Иске Казандагы Печән базарына килеп чыга. Тукайның «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына ишарә итеп, шагыйрь бүгенге заман базарын күрсә, ничек көләр икән дип уйлана. Шагыйрь Ибн Фадлан, Мәрҗани язып калдырган базарлар белән бүгенге базар арасындагы аерманың сәбәпләре турында да уйлана. Хәзерге базарларда чит ил товарларын сату өстенлек алса, борынгы базарларда Византия, Кытай һ.б. дәүләтләр үзләре бездән әйбер алырга килгәннәр. Болгарның затлы күн һәм мехларын күреп кенә кайту да кыйммәт торган. Әлеге мәгълүматларны белгәннән соң лирик персонажга, Колхоз базарына барып, бәрәңгегә чират тору авыр бер газапка әйләнә... Нәтиҗәдә шәхес рухи кыйммәтләр белән матди дөнья арасында бәргәләнүгә дучар ителә.

«Коллар базары» дип исемләнгән бүлекне әрнемичә укып чыгып булмый. Халык, милләт, туган тел дип борчылмаган күндәм халыкның ни кушсалар шуны эшләргә әзер торуын Х.Әюп «конституцион богау» дигән метафора белән сурәтли. Менә охшаш сәяси метафора Р.Хариста «федераль кыршау» дип бирелә. Нәтиҗәдә иҗтимагый-сәяси лириканың лексикасы яңа образ-сурәтләр белән дә баетыла бара. Дөрестән дә, Х.Әюп язганча, базарда:

*Бары да үтә, үтә—ни сатасың,*
*Илен сата кеше, телен сата,*
*Күз дә йоммый сата үз атасын...*

Башка шигырьләрендә шагыйрь бүгенге көндә кеше өчен табынырлык кыйммәтләр калды микән дип уйлана.

*Кая таба карап табыныйм соң?—*
*Дүрт ягым да минем кыйбла,—ди ул.*

Шулай да җавап бар шигырьдә: кыйбланың да кыйбласы булырлык як—ул кеше, шәхес. Ә икенче бер шигырьдә (Ул шигырь «Өч кенә сүз» дип атала) алда куелган мәсьәләне чишә торган шәхес үзе үк күрсәтелә:

*Бер ишеләр яратылган базар өчен,*
*Икенчеләр яратылган азар өчен,*
*Өченчеләр яратылган илдәгенең*
*Бөтенесен бәйнә-бәйнә язар өчен.*

Әмма шагыйрь иҗатында әхлаксыз гамәлләр кылган затның үкенүе, уйлануы очрамый, бары тик әлеге күренешләрне лирик геройның читтән күзәтеп, бәяләп торуы гына бар.

Базар темасын Рөстәм Мингалим дә читләтеп үтми. Аның «Синең базар» исемле шигыре бар. Бу әсәрне милләтен сатучыны фаш итәр өчен язганын шагыйрь үзе үк

әйтеп куйган. Әйбәт эшкә керер, дан-дәрәҗә алыр, кәеф-сафа сөрер, түш киереп йөреп, гел базарда калыр өчен халкын сатар...

Әлеге шигырьләрне укып чыккач, күңелдә авыр бер хис кала. Дөрес, әлеге хис яңа түгел. XX йөз башында Сәгыйть Сүнчәләй дә «Һәр кеше үксез, күңелсез, һәр кеше—дөнья колы», дип язган иде. Соңгы еллар шигъриятендә лирик герой яшәешне күзәтүче, аның камил булмавыннан ризасыз, ялгыз шәхес кебек аңлашыла. Р.Фәйзуллинның «хакыйкатькә тирән кергән саен, кеше күп чак кала шул ялгыз» сүзләре искә төшә. Билгеле, әлеге шигырьләрдә хис-кичереш түгел, фикер-мөнәсәбәт алда торганлыгы күренә. Алда мисалга китерелгән шигырьләрдә иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи проблемалар күтәрелә, тормыш-яшәеш кануннарына мөнәсәбәтле уйланулар үзәккә куела. Лирик герой башкаларга үз фикерен җиткерүче, юл күрсәтүче кебек аңлашыла. Кеше, үзе дөрес түгел дип тапкан яшәеш кануннары белән каршылыкка кереп, аны чишү юлларын шул кануннарның үзеннән эзли. Кайбер шигырьләрдә сурәтләнә торган күренешләр бүгенге белән киләчәкнең өметсезлеген, чарасызлыгын ассызыкласа да, Р.Фәйзуллинда өметкә урын кала:

*«Дөнья усал-фәлән...»,—диеп,*
*Кан елау яхшы түгел!*
*Бөтен искән җилләр дә бит*
*Гел генә каршы түгел.*

Биредә ирексездән Дәрдмәнднең «Илдә бер дуст булмаса гәр, Ил бөтен дошман түгел», дип язган юллары искә төшә.

Ә менә Р.Харис яңа заманны яңа гасыр белән бәйләп сурәтли. «Үле хыял, сынык өмет, сәрхуш әхлак яңа гасыр аяк баскан бусагада», дип яза шагыйрь. Яңа заман темасына багышланган шигырьләр Р.Харис иҗатында шактый күзәтелә. «Башны учка куйдырырлык гаҗәеп бер заман бу» шигырендә ул болай язган иде:

*Кемдер әрли, кемдер мактый: бик тәэсирле заман бу,*
*Кешелекнең бик күп чире ачылып киткән заман бу.*

Ләкин шагыйрь заманга гел тискәре бәя бирә икән дип уйлау дөрес булмас иде. Нәкъ менә әле телгә алган шигырендә ул «көрәшче йөрәкләргә таман килгән», «миләргә өр-яңа сырлар уйдырырлык заман бу» дип билгеләп үтә.

Наис Гамбәр үз вакытында, шигырьнең эстетик категорияләр белән эш итүен билгеләп, «шигырь сөңге яки ук очына манылган зәһәр агу булудан бигрәк, агукайтаргыч булып тора. Һәрхәлдә шулай булырга тиеш»,—дип язган иде.

Ә менә хәзерге байтак шигырьләрне укыганда, еш кына «ук очына манылган зәһәр агу» белән очрашырга туры килә. Күрәсең, җыелган проблемаларның кискенлеге шагыйрьләрдән дә кырыслык һәм кыскалык таләп итәдер. Үз вакытында Дәрдмәнд тә, аеруча кискен итеп, «Нә алтын белгә балчык бу замана, Белалмыйм: кемгә тансык бу замана?» дип язган иде. Заманның кеше алдына куйган проблемалары җыелмасы М.Мирзаның «Мәңгелек сорау» дип исемләнгән нибары дүртьюллык шигырендә чагыла:

*Гел яңаны эзләп табабызмы,*
*Табып югалттыкмы күптәннән?*
*Киләчәккә таба барабызмы,*
*Кайтып киләбезме үткәннән?*

М.Мирзаның «мыскалын да сатып ваклап, мыскыл иткән заман»га (төгәл һәм уңышлы әйтелгән образлы сурәт) куйган сораулары икенче бер шигырендә, катгый таләпкә үк әйләнеп, болай яңгырый:

*Җавап тотар заман җитте*
*Бүген сиңа, замана.*

Шәхеснен җаваплылыгы белән бәйле булган ирек төшенчәсе турында уйланганда Зөлфәт Хәким сүзләре искә төшә: «Кеше тугач ук гаделсезлек дөньясында яши башлый. Бәлки, бу иң зур гаделсезлектер. Дөньяга килгән бала инде ул туганчы ук башка кешеләр тарафыннан уйлап чыгарылган кануннар, аңа кадәр яшәүчеләр урнаштырган тәртипләр буенча яшәргә дучар ителә. Һәрбер инсан үзеннән алданрак туучыларга бар иткән мохиткә килеп эләгә. Һәм, ниһаять, кеше анарчы төзелгән ил-көндә яшәргә мәҗбүр. Шуңа күрә барлык кылган эшләре, гамәлгә ашкан уй-ниятләре өчен кеше берүзе генә җавап тотарга тиеш түгел».

Күренекле драматург шәхеснең кылган гамәлләре өчен җаваплы булу бурычын юкка чыгарып, шәхескә фәлсәфә фәне тарафыннан бирелгән билгеләмәгә күпмедер күләмдә зыян сала. Ләкин аның шигырьләрендә гаделсезлеккә, ялганга кеше, шәхес түгел, ә менә бөтенләй җансыз предметлар каршы чыга. Әйтик, «Иске радио» шигыре. Чоланда эче куыш, тузан баскан иске радио тора. Ул инде сөйләми. Сәбәбе: бәлки, ялгызлыктан, бәлки, акылын җуйганнандыр. Шулай да шигырьдән аңлашылган төп фикер шундый: кеше күзенә күренмәсен дип, үрмәкүч пәрәвезе астында яшеренергә теләгән бу радио күп еллар буе ялган сөйләүдән туйганга дәшми. Ә икенче бер шигырьдәге («Өй янында гарип тал агачы») гарип тал агачы, кояш баегач, намаз укыган кебек була. Таң атып, җил исеп киткәч, шыгырдый башлый. Аның шыгырдавы әсәрдә тормыш авырлыгыннан зарлану булып ишетелә.

Шулай да З.Хәкимнең «Ала алмады» шигыренә аерым игътибарны юнәлтәсе килә. Укучы күз алдына шундый күренеш тәкъдим ителә. Вокзал. Автобус килеп туктый. Ишегенә халык өелә. Тавыш куба, этеш-төртеш, сүгенү китә. Беркем дә чигенергә теләми. Читтә медальләр таккан, ботинкасы «авызын ачкан» бер бабай гына автобус янына якын килергә кыймый. Җыелган халык утырып китә. Бабай кала. Сугыш ветеранының шул минуттагы хәле шигырьнең соңгы ике юлында болай янгырый:

*Яуда шәһәрләрне алган кеше*
*Автобусны «ала» алмады.*

Ш. Галиев тә шигырьләрендә заманга үзенчә бәя бирә. Сибгат Хәким «КамАЗ белән намаз гына рифмалашмый калган заман» дип атаган чор турында Ш.Галиев «бер очы—күктә, бер очы—чүптә», ди. Шагыйрь фикеренчә, заман кешеләрнең акылына да үзгәреш кертте: акыл ни чик белмәс, ни шик белмәскә әйләнеп, өстән генә карап үткәнгә бәя бирә башлады. Ә менә Р.Фәйзуллин «Безнең көннәргә бер штрих» шигырендә кеше шәхесенә хас булган тагын бер социаль проблеманы—физик гариплеккә дучар булган кеше язмышына игътибар итә:

*Базарның чатында угрылар*
*гармунын алдылар сукырның.*

Дөрестән дә, халык шагыйренең чыннан да ил гаме белән яшәвен раслап торган шигъри юллар бу. «Шагыйрьнең «суырылган теш хәлендә карт-коры ветераннар» дигән образлы юллары укучы күңеленә авыр тәэсир итә. Картлык темасын шагыйрь җиңелчә юмор белән үткәреп җибәрергә дә омтылыш ясый, ләкин барыбер котылгысыз драматизмны юкка чыгара алмый:

*Син күргәндә яшен инде үлгән була.*
*Без күргәнне Яшьлек күптән күргән була...*
*Эч пошырып янда: «мин яшьмен» дип,*
*Маймылланып, Картлык йөргән була... (1995)*

Базар темасын Ш.Галиев тә читләтеп үтми. Бер шигырендә ул авызын ачса, үпкәсе күренергә торган сатучы ханымның базарда эшли башлагач, алтынга батып, теше дә күренмәвен бәян итсә, икенче бер шигырендә базарның баерга да, бөлергә дә ярдәм итә торган тотрыксыз урын булуына басым ясый. Шигырьдә аерым кеше,

дәүләт, олигархлар караклыгы арасында параллель үткәрелә. Дөрес, шагыйрь аларны «яратып», «данлы бурлар» дип атый.

Караклык темасын сурәтләү Роберт Миннуллин иҗатында чын эстетик кануннарны исәпкә алып башкарыла.

*Кеше төсле яшим дисәң,*
*Карак булырга кирәк!*
*Кирәк, ләкин азрак кына*
*Саграк булырга кирәк!*

Шагыйрьнең «Шулай булырга кирәк!» шигыре нечкә юморга корылган. Шигырьдә лирик герой, заманны, тормышны күзәтеп, үзенчә нәтиҗә ясый. Аныңча, бу тормышта кешегә усал, әрсез, гамьсез, кырыс, моңсыз, комсыз кебек сыйфатларга ия булырга кирәк. Шагыйрь бер яктан укучыны юмор аша тискәре сыйфатларга ия булырга чакыра кебек, ләкин шигырьдән анлашылган фикер киресенчә килеп чыга. Р.Миннуллин ирония аша бөтенләй икенче мәгънә килеп чыгарлык оста шигырь тудыра алган.

Рафис Корбан иҗатында да «Базар» дип аталган шигырь бар. Ш.Галиевтә социаль проблемалар текст эченә яшереп, турыдан-туры әйтмичә бирелсә, Р.Корбан «туры» юлны сайлаган. Ул базар мөнәсәбәтләрен «базар баткагы» дип атап, һәр нәрсәнең дә сатылуын, чыгарып сатар малы, сатып алыр акчасы булмаган кешенең ачка үләргә хөкем ителүен билгеләп үтә. Базар чорында яшәүнең өч кенә төрле юлы калганлыгын күрсәтә: «кем намусын, кем тәнен сата, йә булмаса теләнеп яши».

Ә менә Р.Низами шигырьләрендә чор «җитмеш җиде катлы иләк аша узгармакта безне бу заман» дип атала. Шагыйрь «Кая таба оча бу заман?» дип сорый да:

*Хакыйкатьнең хакыйкатен эзлим:*
*Нәрсә соң ул—Туу, Яшәү, Үлем?*
*Ак һәм кара төсләр уртасыннан*
*Җавап табу кирәк миңа бүген!—*

дигән төгәл, катгый максат куя. Шунысы кызыклы: бу «хакыйкатьнең хакыйкате»н эзләү башка шигырьләрдә дә дәвам итә.

Р.Низаминың «Тормыш трамвае» җыентыгына кергән шигырьләрендә эстетик сурәтлелекнең көчле булуы сизелә. Шагыйрьнең «Бүген» дип аталган шигырендә башкаларның аһ-зарын да ишетә-күрә һәм бәяли алган көчле шәхес «карап тора». Шигырьдә социаль, әхлакый проблемалар да күтәрелгән. Әмма кемгәдер рәнҗү, үпкә хисләре сизелми. Икенче бер шигырьдә Р.Низами шәхси проблемаларны елмаеп кына да уздырып җибәрергә тырыша:

*Үз-үземнән сорау алам бүген:*
*Мин елмаеп кына*
*Яхшырырмы дөнья, үзгәрерме?*
*Үзгәрер!*
*Шулай җавап бирә күзләрең...*
*Һәм яктырып китә көзләрем.*

Татар шагыйрьләренең соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрен карап чыккач, ышанып, шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек туа: дөрестән дә, «шагыйрь иңнәрендә ил гаме». Ләкин, И.Юзеев билгеләп үткәнчә, гармониягә шигырьдә генә ирешеп була шул...

Рауза
Солтанова

# ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ РӘССАМЫ

Галиәсгар Камал драматург кына түгел, күренекле театр эшлеклесе дә булган. Беренче рәссам Сабит Яхшыбаев та театрда анын тырышлыгы белән эшли башлый. Әлеге рәссам турында беренче мәкаләне дә Г. Камал яза[1]. Яна төр татар шрифтларын булдыруда да анын өлеше шактый зур. Ул ясаган утызлап төрдәге татар шрифтларынын егермедән артыгы И. Харитонов типографиясендә китап басуда файдаланылган[2]. Татар театры афишаларынын графика, плакат сәнгатендә мөстәкыйль жанрга әйләнеп китүе шулай ук Г. Камал исеме белән бәйле. Афишаларны типографиядә бастырмаска, ә кулдан эшләргә тырышканнар, дип искә ала Л. Аитов. Гарәп каллиграфиясен осталарча куллана белгән Г. Камал, улы Әнәс белән бергәләп, һәр спектакльгә 40-50шәр афиша ясый торган булган. Болар—гади шрифтлар белән язылган афишалар гына түгел, Г. Камалнын иллюстрацияләре, рәсемнәре белән бизәлгән чын сәнгать әсәрләре дәрәжәсендәгеләр. Авторнын үз бенефисы афишалары аеруча матур булган. Каллиграф-һөнәрмәнд буларак, Г. Камал төрле типтагы һәм үлчәмдәге шрифтларны оста итеп декоратив бизәкләр белән берләштерә белгән. Мисал өчен 1914 елнын 22 декабрендә Яңа клубта куелган "Уйнаш", 1916 елнын 5 августында куелган "Кечкенә сугыш" ("Маленькая война"), "Жилкуарлар" ("Ветряные") ("нәсх" стилендә) спектакльләре турындагы афишаларны күрсәтергә була. Бүгенге көндә алар барысы да Татарстан Республикасынын Милли музеенда саклана.

Татар бизәкләре традицияләренә һәм гарәп язуына таянып, Г. Камал хәрефнен эстетик тәэсирен үстерергә омтылган, анын төрледән-төрле сәнгати мөмкинлекләрен кулланган.

Чынлыкта татар театрынын ин беренче рәссамы булган Г. Камалга сәхнә костюмнары турында да кайгыртырга туры килгән. Кием (камзул, казаки, читек, чапан, чалма) эзләп, актерлар белән бергә ул ярминкәләрдә йөргән, тапмаганда, таныш байларына мөрәҗәгать иткән.

Драматург татар спектакльләрен бизәүгә һөнәри якын килергә кирәклеген яхшы анлаган. Үзенен "Ачлык кушты" пьесасын куярга берничә кат талпынып караса да, кирәкле декорацияләр юклыктан куя алмый калуы турында яза Г. Камал. Клуб идарәсенә декорацияләр ясату турында үтенеч белән кат-кат мөрәҗәгать итеп карый, тик үтенече кире кагыла, шулай итеп, спектакль куелмый кала. Г. Камал татар театрына рәссам табу мәсьәләсенә бик житди карый. И. Харитоновнын наширлек эшчәнлегенә 40 ел тулуга әзерлек барган көннәрдә татар рәссамына ихтыяж мәсьәләсе инде катгый итеп күтәрелә.

Мөселман матбугаты берәр сәләтле укучыны сәнгать училищесына җибәрергә карар итә һәм стипендия дә билгели. Җәмәгатьчелектән акча жыярга да омтылып

[1] Камал Г. Мөселман рәссам // Г. Камал. Әсәрләр.—Казан, 1961.–Т.2.–246-248 бб.
[2] Каримуллин А. Татарская книга. Татарское книжное издательство.–1974.–С.52

карыйлар. "Йолдыз" газетасы идарәсе 50 сум бирә, мона өстәп "Вакыт" газетасы редакциясе дә шундый ук сумма күчерә. "Матбугат тарихы" китабы нәшер ителеп сатылгач, "Сабак" китапханәсе дә беркадәр ярдәм күрсәтергә вәгъдә бирә. Шуна да карамастан, Г. Камал бик ачынып, кирәкле сумманы җыеп бетереп булмавы турында яза. Һәм укырга җибәрердәй мөселман баласы да табылмый.

Ниһаять, 1912 елның августында Казанга 22 яшьлек Сабит Яхшыбаев килә. Ул Г. Камалга шагыйрь Дәрдемәнднең егетне сәнгать училищесына урнаштырырыга ярдәм итүен сорап язган хатын-юлламасын тапшыра.

Татар театрының беренче рәссамы турында без нәрсәләр беләбез соң?

Сабит Габделбасыйр улы Яхшыбаев 1890 елда Оренбур өлкәсе Югары Урал өязенең Суер авылында (хәзер Башкортстанның *Учали* районы Суяргол авылы) туа. Авыл мәдрәсәсен һәм шәһәр мәктәбенең 6 сыйныфын тәмамлый. Укыган чакта ук ул рәсем ясауга һәвәслеге белән аерылып тора, аны яратып "художник малай" дип йөртәләр. Ясаган рәсемнәрен сыйныф бүлмәләренә элеп куя торган булалар. Югары сыйныфта чакта укытучысы аңардан үз яшьтәшләренә рәсем дәресләре бирергә мөмкинлек тудыра. Мәктәпне бетергәч, ул *Авзяно-Петровский* заводында, аннары *Тамян-Танговор* ширкәтенең алтын приискасында машинист ярдәмчесе булып эшли. Яхшыбаев үзенең беренче "картина"ларын контора коймаларына күмер белән яза иде, дип искә ала дусты Х. Әмиров. Прискaның югары белемле хуҗасы шагыйрь Дәрдемәнд яшь рәссамның сәләтен күреп ала һәм аны Г. Камал янына җибәрә. Рәхмәт йөзеннән Сабит ана үзенең пейзажларын бүләк итеп калдыра: аларның берсендә—Исмәкәй авылы янындагы Биштәк тавы, икенчесендә—Кургашлы елгасы тамагы һәм яр буенда балык тотып утыручы Ярмәс карт, өченчесендә прискaның шахталары сурәтләнгән була.

Яхшыбаев Казанга килгәндә инде сәнгать мәктәбенә кабул итү тәмамланган була, шунлыктан ана түләүсез дәресләргә йөрергә тәкъдим итәләр.

Яшь рәссам "Ялт-Йолт" журналында реклама мәкаләләренә иллюстрацияләр дә бастыра, ә ясаган картиналарын "Йолдыз" газетасы редакциясендә җыеп бара. Б. Урманче истәлекләреннән күренгәнчә, 1912 елны Шәрык клубында ике рәссамның зур булмаган күргәзмәсе оештырыла, аларның берсе Яхшыбаев була. Ул ватман кәгазенә күмер белән ясалган берничә портрет тәкъдим итә. Искиткеч җинеллек белән һәм шул ук вакытта натурага бик ошатып язылган сурәтләр рәссамның сәләтен ачык күрсәтә һәм тамашачыны үзенә җәлеп итә.

Спектакльләрне профессиональ бизәүнең кирәклеген тирәнтен аңлаган Г. Кариев, Г. Камал тәкъдиме буенча, С. Яхшыбаевны рәссам итеп театрга эшкә ала. Шулай итеп, Кариевның труппасына Яхшыбаев килгәч, дежур декорацияләрдән котылып, һәр спектакльгә аерым декорацияләр ясау мөмкинлеге ачыла. Спектакльләрдән кергән табыш декорацияләр ясауга, костюмнар һәм бутафория цехларын, чәчтарашханә оештыруга һәм кинәйтүгә тотыла башлый. Бөтен истәлекләрдә Яхшыбаевның бик күп спектакльләргә рәсем ясаганы әйтелсә дә, гадәттә, Г. Камалның "Банкрот", "Безнең шәһәрнең серләре" һәм Ф. Әмирханның "Тигезсезләр"е генә мисалга китерелә.

Кызганычка каршы, эскизлар сакланмаган шул. Х. Гобәйдуллин хезмәтләрендә "Тигезсезләр" спектакле декорацияләренең фотокүчермәләре бар[3]. Х. Гобәйдуллинның диссертациясенә кушымтада "Сәйяр" труппасы 1912 елның ноябрендә куйган "Банкрот" сатирик комедиясе декорациясенең график эскизы фотосурәте дә урнаштырылган.

Өч актта да вакыйга Сиражетдин бай Туктагаев йортының кунак бүлмәсендә бара. XX гасырның 10 нчы еллары өчен гадәти булган бүлмәгә җиһазлар катгый симметрияле итеп урнаштырылган: идәндә зур келәм, уртада—эскәтер җәелгән түгәрәк өстәл, унда—тәрәзә, сулда—ишек. Сул як стена буенда диван, аның өстендә милли бизәкләр төшерелгән келәм һәм зур сәгать эленеп тора. Почмакта—сандык, өстенә патефон куелган комод. Турыпочмаклык рәвешендәге шамаил дә шунда эленгән. Уртага авыр калын чаршау белән капланган зур гына ишек

[3] Х. Губайдуллин. Татарский театр дооктябрьского периода: дис. канд. искусствоведения.

ясалган. Бу бизәлештә тирән реализм һәм тормышчанлык сизелеп тора.

Тикшеренүчеләр фикеренчә, нәкъ менә типиклык, таныш вәзгыять режиссер Г. Кариевка спектакльдә сөйләнгән вакыйганы төрле яклап ачарга ярдәм иткән дә инде.

"Банкрот"нын декорациясен янадан торгызу сәхнә жиһазланышын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Спектакльдә катнашкан кешеләр сөйләвенә караганда, "Банкрот"нын бизәлеше аннан алдарак куелган спектакльләрнекеннән әйбәтрәк булган. Шәрык клубынын сәхнә мәйданчыгы С. Яхшыбаевка бик иркенәеп китәргә ирек бирмәсә дә, ул спектакльне зур зәвык белән һәм татар интерьерын яхшы белеп бизәгән. Артистлар: "Барысы да үз урынында иде, шулай булу актерларга бик булышты",—дип юкка сөйләмиләр соныннан.

Ф. Әмирханнын "Тигезсезләр"ен галимнәр революциягә кадәрге татар театрындагы сәхнә сәнгатенен иң югарыгы ноктасы дип саныйлар[1]. Әйтергә кирәк, татар театры өчен бу постановка, Чеховнын катлаулы психологик драматургиясен куярга әзерләнгәндә, үзенчәлекле бер мәктәп булып хезмәт иткән.

Автор ремаркаларына төгәл нигезләнеп, С. Яхшыбаев I актта купец Сафый Насыйбуллиннын бай, заманча жиһазландырылган өч стеналы павильон рәвешендәге бүлмәсен ясый алган. Сәхнә киңлегенең чишелеше "Банкрот"тан европа тибындагы интерьер детальләренен күплеге белән аерыла.

Алгы планда сулда диван, арырак—яшькелт төстәге бәрхет пәрдәләр эленгән ишек, камин, анын өстендә сәгать, ә янында ике кәнәфи. Уртада ишек, ишектән уң якта пианино, анын ике ягында да—зур-зур тропик үсемлекләр, пальма утыртылган чүлмәкләр. Уң яктагы ике тәрәзә арасында язу өстәле тора, диварда—фотосурәтләр. Бүлмәнен нәкъ уртасында бәрхет эскәтер ябылган кечерәк кенә өстәл һәм ике урындык тора. Идәнгә палас җәелгән. "Бүлмәдәге жиһазлар йорт хуҗасынын шамаилле һәм өстенә граммофон куелган комодлы гади татар бае гына булмыйча, тышкы кыяфәте белән генә булса да үз катлавыннан шактый алга киткән бай икәнлеген күрсәтә".

Персонажларнын характер үсеше иң беренче тапкыр шушы спектакльдә сәхнә пространствосынын чишелеше аша күрсәтелә. Бөтен гомере бүе баеп китү турында хыялланган Гомәр, ниһаять, үз дигәненә ирешә, зур буржуага әверелә: үзенең оптика фирмасы эшен җәйгә сала, әтисенен мануфактура кибете дә аңа мирас булып кала. II актта вакыйга бакчада бара. Тамашачы күз алдына сәхнәнен яртысын биләп торучы карт агачларнын җәелгән ябалдашлары астындагы ике дача йорты килеп баса. Сул якта алгы планда—Насыйбуллиннар йортынын террасасы, арттарак күршеләре—студент Габдулла гаиләсенен дачасы. Террасага өстәлләр һәм үреп эшләнгән урындыклар урнаштырылган. Алгы якта—чәчәкләр. "Бөтен нәрсәдә—ак ком түшәлгән сукмакларда, утыргычларда, төрле жиргә куелган таганнарда—чын хуҗа кулы сизелеп тора".

Беренче тапкыр режиссер һәм рәссам тарафыннан спектакльне утлар белән белән бизәүгә, төсләргә игътибар ителә. Сәхнә бизәлешендә яшел төс өстенлек итә. Ләкин вакыйга җәй башында барганда (II актта) төсләр ачыграк, ә III актта төсләр көзгә тартым. Табигать картинасына тавышлар өстәмәсе дә кушыла. Кичке вакыйгаларны тасвирлаганда сәхнәгә тулы айдан төшкәндәй яшькелт-сары нурлар җибәрелә. Өйләрнен тәрәзәсеннән яктылык сирпелә. Агачлардан төшкән күләгәләр белән кушылып, алар нинди дер серле, шомлы атмосфера барлыкка китерәләр. Вакыт-вакыт бакчада ял итеп йөрүче кешеләрнен сөйләшкән тавышлары, коры яфраклар кыштырдавы, төнге кошлар сайравы ишетелгәләп куя.

Персонажларның киеме аларнын нинди катлаудан булуына тәңгәлләштереп эшләнсә дә, рәссамнын вакыйгаларга ирония белән каравы сизелеп тора. Сафый Насыйбуллин европача, ләкин искергән мода белән киенгән. Ә анын улы өстендә

[1] Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» спектакленең өч акты фотосурәтләре «Аң» журналының 1915 ел, N 4 санында басылып чыккан (28 февраль, 78, 79, 82 бб.) Х. Гобәйдуллин «Казан утлары» журналында күчереп бастырган. — 1966. — N 3. — 111б.

иң модалы кием булса да, башында, һәрвакыттагыча, кәләпүш. Гомәр Иманскийның тышкы ялтыравыгы аның күңел бушлыгын, бөтен көчен байлык туплауга юнәлткән яшь кешенең рухи ярлылыгын ачып бирә.

Безнең карашыбызча, бу спектакльдә беренче тапкыр, пространство чишелешендәге тормышчанлыкка карамастан, костюмнар чишелешендә тирән мәгънәле, тәэсирле, символлаштыру дәрәҗәсендәге образлылыкка ирешкәннәр.

Бөтен персонажлар ел фасылына һәм һава торышына карап киенгән булсалар да, аларның киемнәре төс һәм тегелеш ягыннан бик төрле. Автор һәм сәхнәләштерүчеләр уенча, Рокыя белән Сөләйманның ак костюмнары аларның мөнәсәбәтендәге сафлыкны, хисләренең тапланмаганлыгын гәүдәләндерә.

Татар театры турында күп рецензияләр язган тәнкыйтьче, сәхнә сәнгатен тирәнтен белүче, татар матди мәдәнияте белгече Г. Кәрам да "Тигезсезләр" спектакленә югары бәя бирә. "Бу яңа тамашаны карарга шәһәребезнең барлык бөек ислам җәмгыяте, зыялылар, яшьләр һәм укучылар килде. ... Театрдан һәммәсе дә канәгать булып, спектакльдән алган гүзәл тәэсирләр белән таралдылар. Чыннан да, фәкыйрь костюмнардан, сәхнәдәге ямьсез җиһаздан, бигрәк тә мең кат кабатланган, сагышлы, килде-китте фәлсәфә сатулардан туеп беткән халкыбыз өчен үзенең гүзәл образлары, сәламәт һәм саф фикерләре белән бу нечкә пьеса чын мәгънәсендә сюрприз булды..."

Шулай итеп, Яхшыбаев килгәч, татар спектакльләре режиссерның ниятенә тәңгәл килә торган үзенчәлекле профессиональ бизәлеш алганнар.

С. Яхшыбаевның эшләрендә кайбер житешсезлекләр булуга да карамастан (сәхнә пространствосы чишелешендәге күзгә ташланып торган бертөрлелек, фронталь планлаштыруның өстенлек итүе, спектакльдән спектакльгә интерьер детальләренең кабатлануы), бу—татар театры спектакльләрен профессиональ бизәүдә беренче адымнар була. С. Яхшыбаев татар театрына МХАТ тарафыннан ачылган һәм расланган импрессионистик сәхнә чараларын кертә.

Кызганычка каршы, рәссам буларак Сабит Яхшыбаев турында без аз беләбез. Ул бераз беркатлырак, тик ихласлыгы белән тәэсир итә торган, халыкчан самимилек белән башкарылган композицияләр һәм портретлар язган ("Авыл", "Татар крестьян хатыны", "Татар ире", «Ызба»). Ике картинасын Третьяков галереясенә жибәргәнлеге һәм аларның фондка кабул ителүе турындагы мәгълүмат әлегә расланмады. Галиәсгар Камал, Габдулла Кариевларның 1914 елда язылган портретлары исә сакланган. С. Яхшыбаев үз вакыты өчен тәҗрибәсез рәссам булса да, аның рәсемнәренең уңай яклары бар. Әйтергә кирәк, ул үз сәнгатенең төп нигезен—сурәтне яхшы белә. Г. Камал портреты аның үзенә бик нык охшашлыгы белән гажәпләндерә. Мөгаен, рәссам, портрет язганда, Камалның матбугатта еш күренгән фототсурәтеннән файдалангандыр. Драматург зәңгәр пәрдә фонында бәйрәмчә киемнән сурәтләнгән. Йөзе аеруча төгәллек белән эшләнгән. Нәзакәтле күркәм чырае—үз дәрәҗәсен һәм җәмгыятьтәге урынының әһәмиятен белүче кешенеке икәнлеген ассызыклый. Фотосы белән чагыштырганда рәсемдәге портреты хисчәнрәк, драматургның кеше хәленә керә белүче, ярдәмчел холкына тәңгәлрәк килеп чыккан.

1920—1930 елларда С. Яхшыбаев үз язмышын Башкортстан белән бәйли. 1920 ел башында, Стәрлетамак башкорт драма театры оешкач, аны В. Мортазин-Иманский труппага рәссам итеп чакыра. Мортазин-Иманский һәм Яхшыбаевның иҗади дуслыгы аларның "Сәйяр" труппасында бергә эшләгән елларында ук башланган була, алга таба да бергәләшеп эшләүләре яшь башкорт театрының үсешенә этәргеч бирә. Ф. Бурнашның Мортазин-Иманский тарафыннан куелган һәм Яхшыбаев бизәгән "Таһир-Зөһрә" спектакленең фотосы сакланып калган. Сурәттәге артистлар әле костюмнарын да салмаган, гримнарын да сөртмәгән. Алар арасында Таһир киемендәге Мортазин-Иманский да бар[5].

Безгә Яхшыбаевның башкорт сәхнәсендә Д. Юлтыйның "Кара кол",

---

[5] Гобәйдуллин Х. Халык артисты В. Мортазин-Иманский // Кызыл таң (Уфа). – 1970. – 15 декабрь.

М. Буранголовның "Ашказар", М. Фәйзинең "Галиябану", Ф. Бурнашның "Таһир-Зөһрә", Х. Ибраһимовның "Башмагым" спектакльләрен бизәгәнлеген ачыклау мөмкин булды. Кызганыч, декорацияләрнең эскизлары сакланмаган.

Театр белгече Л. Фәрзетдинова үзенең кандидатлык диссертациясендә, оешкан елларында башкорт театрында куелган этнографик мелодрамаларны анализлап, аларга "чынбарлыкны анализлап мәшәкатьләнмәгән" примитив эстетика ("беркатлы реализм") хас булганлыгын искәртә. Бу спектакльләр гомеренең күп өлешен табигать кочагында үткәргән "халыкның эстетик аңында тормыш-көнкүреш традицияләренә бәйле рәвештә формалашкан калыпка юнәлтелгән". Күп очракта декорацияләр арткы пландагы тиешле пейзаж сурәтләнгән пәрдәдән, тукымага рәсем итеп яки аппликация рәвешендә ясалган агач ябалдашларыннан торган. Сәхнәгә бик күп әйбер куела торган булган: бизәкле паласлар, чаршаулар, чәчәкле мендәрләр, комганнар, ләгәннәр һ. б. Бу гадәти таныш тирәлек тормыштагыча булсын өчен киемнәр дә, өйдәге савыт-саба да кешеләрдән җыелган. Рәссамның бурычы башкорт мәдәниятенең милли үзенчәлекләрен ассызыклап күрсәтә торган типик әйберләрне сайлап алу булган.

1922 елны Яхшыбаев күпмедер вакыт Х. Ямашев исемендәге мәктәптә рәсем дәресләре укыткан[6]. Татар театр белгече Х. Гобәйдуллинга анарда бер кыш укып калырга насыйп булган. Яхшыбаевның "тыйнаклыгы һәм педагогик такты искиткеч тәэсир калдырды",—дип искә ала ул.

Осталыгын камилләштерү омтылышы рәссамны Казан сәнгать училищесына алып килә. Ләкин, тормышының авыр булуы аркасында, ул укуын дәвам итә алмый. Яхшыбаев Уфага әйләнеп кайта һәм кабаттан театрда эшли башлый. Гомеренең калган елларын рәссам-декоратор хезмәтенә багышлый. Кызганыч, ул бик иртә дөньядан китә (1930 елның 14 июлендә вафат була).

XX гасырның унынчы еллары башында татар профессиональ декорация сәнгатенең тууы С. Яхшыбаев исеме белән бәйле. Аны башкорт театрының да беренче рәссамы дип санарга тулы нигез бар.

[6] Х. Гобәйдуллин. С. Яхшыбаев // Казан утлары. – 1966. – 111 б.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кәче

Кәче авылы Арча районында, район үзәге Арча шәһәреннән 6 чакрымда, тимер юл станциясе Кәчедән—1, Казан шәһәреннән 61 чакрым ераклыкта утырган.

Кәче атамасы тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш искә алына.

Кәче авылы Казан ханлыгы чорындагы авыллар исемлегенә кергән. Кәче авылы зиратында XVI йөзгә караган кабер ташы билгеле.

XVIII йөздә Кәче авылында 213 йомышлы, 1 керәшен татары булуы мәгълүм. А. Артемьев җыеп бастырып чыгарган җыентыкта (1866 ел) Казансу ярындагы Кәче авылындагы 171 хуҗалыкта 590 ир-ат һәм 583 хатын-кыз яшәгәнлеге, 2 мәчет булуы әйтелә. Н. Вечеслав хезмәтендә (1878 ел) Кәче авылындагы 168 хуҗалыкта 695 ир-ат һәм 589 хатын-кыз яшәгәнлеге күрсәтелә, авылда бер агач мәчет һәм гыйбадәт кыла торган йорт була. 1885 елда И. А. Износков Кәче авылы турында болай яза: «Казансу ярына, Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан Кәче авылының 216 хуҗалыгында 662 ир-ат һәм 745 хатын-кыз исәпләнгән. Алар барысы да ислам дине тотканнар һәм Кәче авылы җәмгыятенә кергәннәр. Тормышлары уртача булган. Умартачылык, балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр. Авылда мәчет булган, су тегермәне эшләгән. К. П. Берстель хезмәтендә (1908) Кәче авылында барлыгы 1723 татар кешесе яши дип күрсәтелә.

Наҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, Кәче авылы халкы күршедәге Өчиле, Бирәзәбаш, Урта Бирәзә, Зур Бирәзә, Югары Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә һәм Кукчә Бирәзә халкы белән июль башында Кукчә җыены бәйрәм иткән. Бу җыен икенче төрле Кыр җыены дип тә йөртелә.

Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтендә Кәче авылының бер күренекле дин әһеле турында мондый юллар бар: «Мелла Габделвәли бине әл-Вәлид бине Максуд бине... әл-Кәчеви җаһи-диндар, бик игътибарлы, тәзек фикерле, яхшы табигатьле, туры сүзле һәм укымышлы кеше иде. Хаҗ кылып хөрмәт казанды. Чыгышы белән Наласа авылыннан. Наласа имамы Мөхәммәд Әминнән белем алды. Алдан күрүчәнлеге белән, китаплар тикшерү, хакыйкатьне эзләүдә көчле фикерле булуы һәм эшчәнлеге белән аерылып тора иде. Мелла Әбденнасыйр әл-Курсавиның дусларыннан булды. Күп заман имамлык кылып, Кәче авылында вафат булды».

Кәче атамасы нәрсә аңлата?

Бабайлар авылларының барлыкка килүен болай сөйлиләр. Авыл уртасыннан Казансу елгасы ага һәм аның бер ягын Аръяк, икенчесен Биръяк дип атыйлар. Элекке заманнарда аръякта, тау битендә чирмешләр яшәгән, ә бирге якта куе урман булган. Татарлар аргы якта чирмешләрне кысрыклый башлагач, алар бу урынны ташлап икенче җиргә китеп төпләнәләр. Шулай да авылда өч чирмеш гаиләсе яшәп кала. Алар татарлар белән аралашып көн итәләр. Өч чирмешнең берсе Качыйм кушаматын йөрткән. Бу качыйм сүзе авыл исеме булып киткән, имеш. Халык этимологиясе шушындый. Зуп-зур татар авылына исемне чирмеш (мари) бирдеме икән? Безнең халык авыллары атамасын төркидән эзләми, нигәдер мари, удмурт, мордва телләреннән чыгарырга ярата.

Авыл үзенә исем итеп төрки кабилә-кавем атамасы булган кәче сүзен (этнонимын) алган.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 6 санында.*

Кәче авылы матур җирдә урнашкан. Аның бер ягы тау битендә, икенче ягы тигезлектә утыра. Казансу яры буйларында зур-зур таллар үсә. Поездан төшүгә уң якта яңа йортлар тезелеп киткән. Әле берничә ел эчендә үсеп чыккан йортлар болар. Аны халык яшьләр бистәсе дип йөртә, чөнки бу җиргә яшьләр олылардан аерылып башка чыгалар.

Сул яктагы басу Хәким басуы дип йөртелә. Ул басу Хәким бабайныкы булган. Хәким басуы бетүгә болын башлана. Болын Корыч дип йөртелә. Монда элек су эчендә камыш үскән калку түмгәкләр булган. Хәзер алар кечерәеп калган. Казансуның су коена торган бер яры бик текә булып тора. Шуңа ул Текә туры дип атала. Су коенучылар шуннан сикерергә яраталар.

Якын тирәләрдәге елгалардан күренеклеләре түбәндәгеләр: Дөм-дөм – коры елга. Елга бусагалы, шарлавыклы. Язгы ташу вакытларында, көчле яңгырдан соң суның ташып, бәргәләнеп агуы авылга ишетелеп тора. Шуңа күрә аны авыл халкы Дөм-дөм дип атаган да. Кына елгасы корып бетү алдында. Бу елганың югары башында бик матур болынлыклар бар, анда бик күп төрле кыр чәчәкләре үскән. Авыл халкы монда ел саен печән чапкан. Шунлыктан халык болынны гөлгә тиңләп Кына исеме биргән дип сөйлиләр. Ташлы елгада язгы ташудан соң бик күп таш актарылып чыга. Аннан халык үзенә кирәк кадәр таш җыя. Елгалардан башка тагын күл, чишмәләр, болыннар һәм аерым урын исемнәре дә очрый. Мүкле күлдән авыл халкы өй күтәрү өчен мүк җыеп китә торган булган. Аның мүге бик яхшы исәптә йөргән. Миләш күленең тирәягында элек миләш үскән. Исемен дә ул миләшкә мөнәсәбәтле рәвештә алган. Кызганыч, хәзер күл янында бер генә миләш агачы да күренми. Дими күле буенда Динмөхәммәт исемле бер байның басуы булган. Динмөхәммәт басуында урнашканга күрә халык, исемне кыскартып, күлне Дими күле дип йөрткән. Тугыз чишмә. Яр буенда тугыз чишмә бәреп чыккан, янында гына күл дә булган. Элекке вакытларда күлдә кыр үрдәкләре һәм кыр казлары бәпкә чыгарганнар. Карамау һәм чистартмау сәбәпле бу чишмәләрнең барысы да ябылган, бары тик берсе генә сакланып калган, ләкин хәзер анысы да бик хәлсез генә ага. Ә күл бөтенләй беткән. Хәзер монда көтү йөри.

Хәсәншәех дип аталган урында изгеләр кабере бар. Бу урын авылның борынгы нигезе дип, ягъни Кәче авылы башта шунда булган дип тә әйтәләр. Һәр ел саен июнь аенда авыл картлары, кешеләрдән акча җыеп, сарык сатып алалар һәм, шунда корбан чалып намаз укыйлар. Ул көнне авылның бөтен халкы бу урынга җыела. Авыл халкының бу гадәте борын заманнардан килә.

Ике басу урамы – шулай ук борынгы атама. Югарыда әйтелгәнчә, Кәче авылы хәзер Хәсәншәех җире дип йөртелгән урында була, ә авылның хәзерге урынында урман үскән. Менә шул урманны кисеп, иген игү өчен монда беренче басу ясаганнар. Бүген бу урында авылның бер урамы.

Авылда йортлар матур, чөнки балта осталары алтын куллы. Рәдиф һәм Булат Мөхәммәтшиннәр, Марат Мөхәммәтҗанов, Солтан Әхмәтҗанов – авылның хөрмәтле кешеләре.

Сабир Бәкиров, Дәүли Закиров, Фаил Гобәев җәй көне чишмә-кизләүләрне чистартып торалар, яңа улаклар ясыйлар, кыш көне бозларын чабалар. Авыл халкы аларга да рәхмәтле. Халыкның тормышы әйбәт. Кәче киләчәккә ныклы адымнар белән бара.

Авылда 300гә якын хуҗалык бар. Анда урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы, китапханә, кибет эшли.

Кәче халкы авыл зиратын карап һәм тәрбияләп, чистартып тора. Дин тотучы кешеләр өчен мәчет ачылган.

## Күгәй

Татарстанның Тау ягы дип аталган төбәгендәге атамалар күп катламлы. Анда болгар, бәҗәнәк, угыз, кыпчак, нугай һәм башка катламнарга мөнәсәбәтле атамалар очрый. Бу төбәктә шулай ук чувашлар, мордва-каратайлар, удмуртлар яшиләр. Төбәк топонимиясе катлаулы һәм кызыклы. Шушы җәһәттән караганда, Зеленодол районында урнашкан Күгәй авылы атамасы игътибарны җәлеп итә. Авыл тимер юл станциясе Албабадан – 8, район үзәге Зеленодол шәһәреннән 35 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи чыганакларда да искә алына. А. Артемьев китабында (1866 ел) да Күгәй теркәлгән. Аның 117 хуҗалыгында 314 ир-ат һәм 287 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет булган. К. П. Берстель китабыннан күренгәнчә (1908 ел), авылда

барлыгы 1405 татар кешесе яшәгән.

Авыл табигатьнең матур җиренә, су-инешләр, чишмә-кизләү һәм күлләргә бай урында утырган. Халык хәтерендә төрле легенда-риваятьләр, мәзәкләр һәм сөйләкләр сакланып калган.

Күгәй авылы оешу турында шушындый хикәят сөйлиләр: «Безнең бабайлар Казаннан Мәрәҗән би дигән су буена күчкәннәр. Казан би бабай Мәрәҗән су буеннан Урман тавы астына бик матур кизләү янына күчкән. Зиратлары Әрә суы артында калган. Ул кизләү яныннан Чуваш юлы дигән юл уза. Бу юлдан Буа ягы чувашлары Казанга йөргәннәр. Әрә суы буендагы тауга менеп карасалар, урман эчендә төтен күрәләр. Елгага төшеп карасалар, йомычкалар агып килгәнне күрәләр һәм, анда нинди кешеләр яши икән дип, барып карыйлар. Андагы кешеләрдән кемнәр булуын сорыйлар. Тегеләре, без — мукшылар, диләр. Күги биләр: «Сез нигә безнең җиргә урнаштыгыз, китегез», — диләр. Ләкин мукшылар арасында татарлар да була, алар чукынмас өчен мукшылар арасында яшеренгән булалар. Ә мукшылар ул вакытта чукынган булалар инде. Ләкин алар китмиләр, ничектер Күги би авылына кушылып китәләр».

«Күгәй» дигән сүз ни аңлата соң?

Атаманың барлыкка килүен нугай кавем-кабиләләренең бер этнонимы «күгәй»гә бәйләп ачыклап була. Х. Альбиковның «Шура» журналында урнаштырылган «Кирәкле үтенечкә җавап» дигән мәкаләсендә нугай кабиләләреннән күгеш, күгәй һәм айдар телгә алына. Атамалары бу этнонимга нигезләнеп ясалган авыллар Зеленодол районында бер-берсенә якын гына утырганнар, бер оя тәшкил итәләр. Күгеш авылы янында Күгәй һәм Айдар авыллары урнашкан. Диалектологлар язуына караганда, бу төбәктәге халык сөйләшендә нугай теле үзенчәлекләре ачык чагыла. Күгеш, Айдар, Күгәй һәм Бакырчы авыллары «Йуа җыены» дип аталган җыен бәйрәмен дә бергәләшеп үткәргәннәр. Бу да аларның кардәшлегенә бер дәлил булып тора. Һәр авылның үз тарихы, йола-кануннары булган кебек, Күгәй авылы да тарихтан, гореф-гадәтләрдән мәхрүм түгел. Киресенчә, үткәне матур, традицияләргә бай. Халыкта үткәннәр турында төрле риваять-легендалар сакланган. Авылда Йуа җыены үткәрә башлауның да үз тарихы бар икән. Күгәй авылы оешкач, бәйрәм итүне чираттан уздырганнар: бүген берәүдә, иртәгә икенче хуҗалыкта, өченче көн тагын яңа хуҗалыкта ашап-эчеп күңел ачканнар. Бу эшне тәртиптә тоту өчен, агач таякка киртләр киртләп барганнар. Таяк авылга бер генә икән. Язгы кыр эшләре башланганчы шулай бәйрәм иткәннәр. Язгы сукага төшәр алдыннан авылның егетләре, бергә җыйналып таякны авылдан ерак кырга, илтеп ташлаганнар. Бу җир хәзер дә «Сөрән ташлаган җир» дип йөртелә. Икенче язда яңа таяк алганнар, бәйрәм итүне яңадан башлаганнар. Менә шушындый тәртиптәге бәйрәм йоласын һәм таягын «Сөрән» дип атаганнар.

Авыл үскән, зурайган, болай чиратлы күңел ачу йоласы уңайсыз була башлаган. Авыл халкы сөйләшеп, килешеп, Мулла иле халкыннан бәйрәм йоласы сатып алырга ниятләгән. Бу вакытта Мулла иле авылында ике бәйрәм булган: берсе — «Юа бәйрәме», икенчесе — «Тикен бәйрәме».

Моның өчен бер төркем ирләр, атлар җигеп, мичкә белән сыра алып барып, Мулла иле халкын сыйлаганнар һәм Күгәйгә кунакка чакырганнар. Бергә сөйләшкәннән соң, Юа бәйрәмен Күгәйгә сатарга булганнар. Шуннан бирле Мулла иле авылында — Тикен, ә Күгәйдә Юа җыены үткәрәләр икән. Бу җыенны үткәрүдә тагын Айдар, Күгеш һәм Бакырчы авыллары да катнашкан.

Элек Күгәйдә «Аргамак уены» дип йөртелгән уен булган. Соңыннанрак аны «Кызлар уены» дип йөртә башлаганнар. «Тын ай»да, ягъни эш булмаган вакытта, җомга көн көндез Әрә суының аргы ягына чыгып уйнаганнар. Уйнап-җырлап гармуннар белән күңел ачканнар. «Бу уенны, — дип сөйли Зиннәтулла абзый, — нигездә, яшь-җилкәнчелек уйнаган».

Авыл атамалары булып ныгып калган этнонимнар татар шәҗәрәләрендә кеше исемнәре буларак та кулланыла. Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» (Казан, 1991) исемле китабында «Күгәй би шәҗәрәсе» турында сүз алып барыла. Шәҗәрә үз эченә ундүрт буынны ала. Хронологик чикләре ягыннан караганда, XV – XX гасырларны колачлый.

Шәҗәрәнең телдән сөйләнә торган легендасы Айдар авылының кульязма тарихы

белән тәңгәл килә икән. Шәҗәрәнең умыртка сөяге түбәндәге буыннардан гыйбарәт: Казан бик – Күгәй бик – Исәнбулат – Сөләйман – Акбатыр – Зәйни – Әхмәди – Солтан – Әмир – Хәйбулла – Әдиятулла (1885 – 1975) – Хатип (1929 елда туган) – Рифат.

Нәселнең килеп чыгышы турындагы риваятькә караганда, Казан җимерелгән вакытларда дүрт агай-эне Әрә суы буйларына килеп утыра. Олы агаларының исеме Күгәй би булып, калганнары Күгеш би, Айдар би һәм Ислам би дип исемләнгән. Туганнарның һәрберсе үз исемендә берәр авыл нигезләгән.

Күгәй авылының урамнары җыен дип атала икән (Югары җыен, Урта җыен һ. б.). Илһам ага Күгәй авылы морзалар, казаклар, мукшылардан һәм татарлардан оешкан дип сөйли.

Бу тирәләрдә элек урманнар шаулап үскән. Шул заманнардан калган шаһитларның берсе – Каенсар аланы. Исемнәреннән үк күренгәнчә, аланлык каен урманы эчендә булган. Шунда ук Алан урманы, Күгәй урманы, Чуваш юлы урманнары... Һәрберсенең исеме бар, исеменең үз тарихы бар. Менә бусы чуваш авылына бара торган юл өстендә урнашканга Чуваш юлы урманы дип аталган. Менә бусын янган аланнар дип йөртәләр икән. Халык монда килеп утыргач, җирне урманнан чистартып, басу ясарга туры килгән. Ышна берәмлеге кергән топонимнар, урманны яндырып яисә агачларны кисеп, төпләп ышна басуы ачу белән бәйләнешле. Илһам ага сөйләвенә караганда, менә бу ышна чокыры буенда мукшы нәселләре яшәгән. Аларның кайберләре күчеп киткән, ә кайберләре исламга чыккан. Авылда әле дә мукшы нәселләре бар икән.

Авыл эчендәге һәм авыл янындагы зиратларда каберләр өстенә куелган ташлардагы язулар һәм зират исемнәре дә – тарихның җанлы шаһитлары. Нарат өсте дип йөртелә торган зиратта Күги би җирләнгән дип сөйлиләр. Морза башы урамы янындагы күптәнге иске зиратта ваба чиреннән һәм гомумән, фаҗигале үлем, ягъни үз үлеме белән үлмәгән кешеләрне аерым җирли торган булганнар. Хәзер ул зиратка җирләмиләр. Югары баш зираты – зур зират. Бакырчы өстендә яхшылар зираты бар. Казаклар зираты исә Морзалар зираты белән катнашып киткән. Морзалар зираты безне борынгы заманнарга кайтара. Югарыда без диалектолог-галимнәрнең бу тирәдәге халык сөйләшендә нугай халкы теленә хас үзенчәлекләр ачуын әйткән идек. Морзалар зираты атамасы аерым игътибарга лаек. Морзалар дип татарларның һәм нугай кабилә-кавемнәренең аксөякләрен, ягъни югары катлау вәкилләрен атаганнар. Бу зират шуларга нисбәтән барлыкка килгән дә инде. Күгәйнең бер урамы Морза башы дип аталып йөртелгәнне дә искә төшерергә кирәк. Исеме Казандагы манарага бирелгән Сөембикә (Сөенбикә) нугай морзасы Йосыфның яраткан кызы була. Борынгы Казандагы Нугай капкасы, җөмһүриятебез җирендә, халыклар күңелендә сакланып калган Нугай юлы, Нугай тавы, Нугай сукмаклары һ. б. топонимнар барысы да нугайларга мөнәсәбәтле.

Күгәй басуында Алып чабатасын каккан тау да бар. Ул Бүре базы чокыры буена урнашкан. Күгәй басуында элекке кыр исемнәре дә шактый. Ул кырларда киндер, арыш, бодай, карабодай һ. б. культуралы үсемлекләр игелгән. Киндерне күгәйлеләр күп итеп иккәннәр. Онын тартканнар, маен ясаганнар, сүс алганнар. Башсыз киндерне баса дигәннәр, аның ярмасы булмаган. Илһам ага «Күгәйләр киндер орлыгы» дип аталган бер мәзәкчә сөйли. Күгәй егетләре армиягә барганда, ипи белән киндер орлыгы оны ашап утыралар икән. Шул вакыт, ашап бетерергә ирек бирмичә, аларны алып киткәннәр. Шунда бер егет: «Их, киндер орлыгы да калды, ашап бетерә алмадым», – дип әйткән, имеш. Шуннан соң күгәйләргә: «Тешеңне чистарт әле, тешеңә киндер орлыгы сыланган», – диләр икән.

Авылның аксакаллары сөйләвенә караганда, Күгәй авылына эш белән Каюм Насыйри килгән, аннары ул Корбаш дигән чуваш авылына киткән. Бу авыл электә мөселман авылы булган икән.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# В

**ВАЙНЕР** Борис Гиршевич (псевд. Сулимов) (25.1.1948, Сахалин өлкәсе, Курил р-ны Буревестник пос.), язучы, тәрҗемәче. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1970). 1975-78 елларда күптиражлы «Калининец» г-тасында, 1978-90 да «Вечерняя Казань» г-тасында эшли, 1993-96 да «Барабашка», 1996 дан «Зонтик» балалар ж-лы баш мөхәррире. Шигырьләрен «Весёлые картинки», «Крокодил», «Огонёк», «Аврора» (С.-Петербург) ж-лларында, «Литературная газета»да бастыра. Балалар өчен язылган «Нинди көн бүген!» («Что за день сегодня!», 1982), «Без Барбос белән» («Мы с Барбосом», 1987), «Бармалейны саклагыз» («Берегите Бармалея», 1998), «Тамчы да куркыныч түгел» («Ни капельки не страшно», 2001) шигъри җыентыклары, «Көзгедәгечә» («Зеркальный вариант», 1983), «Вак-төяк күңелсезлекләр» («Мелкие неприятности», 1989) юмористик хикәяләр җыентыклары авторы. Инглиз теленнән рус теленә Э.Блайтон, Д.Джекобс, Р.Брэдбери, Д.Раскин әсәрләрен, татар теленнән М.Җәлил, Г.Бәширов, Н.Арсланов, К.Булатова, Р.Миңнуллин әсәрләрен тәрҗемә итте. Ш.Галиевнең «Куян менгән түтәлгә» («Заяц на грядке», Г.-Х.Андерсен исем. халыкара диплом, 1982) китабы тәрҗемәчеләренең берсе. Курчак театры өчен пьесалар, сценарийлар, җыр текстлары авторы.

**ВАСЫЙӘТНАМӘ** (гарәп. васыйәт, фарсы - намә - язу, китап), язма рәвештә бирелгән 1) хокукый документ; 2) татар әдәбиятында эпистоляр жанр төре; каләм иясенең киләчәк буыннарга, шәкертләргә теләк-үгенечләрен, үгет-нәсыйхәтләрен белдергән язма (кайбер очракларда шигъри формада). Татар әдәбиятында аеруча билгеләре: «Галикәй Аталык васыйәтнамәсе» (1639), «Кишбикә Бикәч васыйәтнамәсе» (1660), «Гаделшаһ бине Габдулла васыйәтнамәсе» (1788).

Әд.: Шәрипов Ә.М. XVIII йөз әдәбиятының кайбер жанрлары (Сәяхәтнамә һәм васыйәтнамә) // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 нчы китап; Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI-XVIII вв. К., 1990.

**ВАФАИ** (15 йөз), Урта Азиядә яшәгән шагыйрь. Төрки телдә язган. Ислам дине нигезләрен шигъри юлларда аңлаткан «Рәүнәкыль-ислам» («Ислам нуры», 1464-65) исемле үгет-нәсыйхәт поэмасының авторы. Алланың һәм пәйгамбәрләрнең сыйфатларына дан җырлау б-н бергә, шагыйрь белемгә омтылуны, гыйлемлекне мактый. Поэма, кульъязма нөсхәләрендә киң таралып, 1850 елдан башлап Казанда күп мәртәбәләр нәшер ителгән һәм мәдрәсәләрдә дәреслек китабы буларак файдаланылган. Әсәрнең кульъязма нөсхәләре С.-Петербург, Казан, Уфа шәһәрләре китапханәләрендә саклана. Поэма татар суфи шагыйрьләрнең (Мәүла Колый, Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки һ.б.) иҗатларына зур йогынты ясаган. «Рәүнәкыль-ислам» поэмасының тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнгән Гали Рәхим татар халкында ислам дине, шәригать кануннарының тирән урнашуында бу әсәрнең зур тәрбияви роле булганлыгын искәртә.

Әд.: Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. Борыңгы дәвер. К., 1923; Абилов Ш. Вафаи турында // Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том; Самойлович А.Н. Очерки по истории туркменской литературы // Туркмения. Л., 1929. Т. 1; Хрестоматия по литературе народов СССР. М., 1959.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ВАХИТ** (Вахитов) Касыйм Мисбах улы (16.3.1916, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Әлшәй р-ны Нигъмәтулла а. -

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынnан басылып килә.*

4.10.1942), шагыйрь. 1935 тә Дәүләкән пед. техникумын тәмамлап, авыл мәктәбендә мөгаллимлек итә. 1941 дә Казан пед. ин-тын тәмамлый. Матбугат битләрендә («Кызыл Татарстан» г-тасы, «Совет әдәбияты», «Чаян», «Азат хатын» ж-ллары) шигырьләре 1932 елдан күренә башлый. Алар «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Очкыннар» (1940), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961), «Утлы еллар поэзиясе» (1972) коллектив җыентыкларга керәләр. В. үзен поэзиянең төрле жанрларында сынап карый: «Сөйләнмәгән әкият» поэмасы, «Егет турында баллада», юмористик шигырьләр һ.б. иҗат итә. Үзе теләп Бөек Ватан сугышы фронтына китә, Сталинград тирәсендә барган сугышта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**ВАХИТ** (Вахитов) Хәй (Габделхәй) Каюм улы (20.12.1918, Казан губ., Казан өязе Мәмдәл а. - 7.7.1978, Казан), драматург, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968, 1978). Бөек Ватан сугышында катнаша, хәрби разведчик була. Казан консерваториясен тәмамлый (1951). 1951-55 елларда Лаеш р-ны Татар Сараланы авылында «Яңа алан» к-зы партия оешмасы секретаре. 1956-58 дә Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларда укый. 1937 елда «Канлы куллар», «Соры кортлар» исемле беренче пьесалары басыла, 1939 да «Дулкыннар» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә. 1960 елда Татар акад. театрында куелган яшьләр турындагы «Беренче мәхәббәт» драмасы В.га зур абруй китерә һәм ул Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә (1961) лаек була. В. үзенең пьесаларында әдәп-әхлак проблемаларын күтәрә, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне яктырта. Төп геройлары - тормышта үз көчләренә таянып, максатларына ирешергә омтылучы яшь кешеләр. «Рәхим итегез!» (1963; 1961 дә сәхнәләштерелә), «Кайда соң син?» (1964; 1963 тә сәхнәләштерелә), «Карлыгач канат кага» (1965; 1964 тә сәхнәләштерелә), «Соңгы хат» (1966; 1966 да сәхнәләштерелә), «Күк капусы ачылса» ( 1973; 1967 дә сәхнәләштерелә) пьесалары шундыйлардан. Фәлсәфи-психологик пландагы «Туй алдыннан» (1969 да сәхнәләштерелә) драмасы тамашачыларда зур кызыксыну уята. Тәрбия мәсьәләсе, яшьләрнең әхлакый йөзе, аларның өлкәннәргә карата мөнәсәбәте, мәхәббәт һәм тугрылык кебек проблемалар В.ның «Мәхәббәтең чын булса» (1976; русчага тәрҗемәсе «Если любовь настоящая», М., 1979; 1972 дә сәхнәләштерелә) драмасында үзәк урынны алып тора. В. татар опера сәнгатен үстерүгә дә зур өлеш кертә. Ул «Самат» (1957; Х.Вәлиуллин муз.), «Җиһангир» (1976; Р.Гобәйдуллин муз.), «Дим буенда» (1965; Х.Вәлиуллин муз.) һәм «Мәхәббәт җыры» (1971; С.Садыйкова һәм Р.Гобәйдуллин муз.), «Кияүләр» (1972; С.Садыйкова һәм Р. Гобәйдуллин муз.) операларының либреттолары авторы.

Әсәр.: Күк капусы ачылса. Пьесалар. К., 1973; Яшьлек юллары. Пьесалар. К., 1978; Пьесалар. К., 1984.

Әд.: Кумысников Х. Он поёт молодость // Советская Татария. 1968. 20 дек.; Гыйззәт Б. Хәй Вахит һәм аның геройлары // Казан утлары. 1978. N12; Әхмәдуллин А. Драматургның үсү юлы // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Шул ук. Яңалык нәрсәдә иде? // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993.

**ВӘДҮТ М.** (чын фам. һәм исеме Мифтахов Вәдүт Кәшшаф улы) (20.11.1915, Уфа губ., Минзәлә өязе Яхшы Каран а. - 30.3.1942, Тула өлкәсе Рыдань а.), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939) урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. Әсәрләре 1930 еллар уртасыннан басыла башлый. Шигырьләре «Чәчәк атабыз» (1937), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Ватан өчен» (1941) исемле коллектив җыентыкларга кертелә. 1939 елда аның «Шигырьләр» җыентыгы дөнья күрә. Аерым шигырьләре сугыштан соң басылып чыккан «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле коллектив җыентыкларда урын ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. Тула янындагы сугышта һәлак була.

Әд.: Давыдов Ә. Мәңге яшь // Социалистик Татарстан. 1965. 21 нояб.; Рахман Р. Очкын оча // Ватаным Татарстан. 1995. 2 дек.

**ВӘЗИЕВА** Җамал Гали кызы (24.10.1907, Вятка губ., Алабуга өязе Сала-

гыш а. - 17.12.1989, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1950). 1928 елда Алабуга пед. техникумын тәмамлый. 1931 дән Казан вет. ин-тында, 1935 тән Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре 19-20 йөз татар әдәбияты тарихына, балалар әдәбиятына, татар әдәбиятын укыту методикасына карый. Мәктәптә әдәбият укыту программасы һәм уку ярдәмлекләре авторларының берсе.

Хезм.: Татар әдәбияты. XX йөз (1917 нче елга кадәр): Дәреслек-хрестоматия. К., 1947 (автордаш); Татар әдәбияты. XX йөз: Дәреслек-хрестоматия: 2 кис. К., 1954 (автордаш).

Әд.: Ибраһимова Ф. Укытучы бәхете // Азат хатын. 1987. N 10.

**ВӘЗИРЕВ** Нәҗафбәк Фәтхгалибәк оглы (5.2.1854, Шуша ш., Елизаветополь губ., хәзер Әзәрбайҗан Респ-касы - 9.7.1926, Баку), әзәрбайҗан драматургы. Әзәрбайҗан әдәбиятында реалистик трагедия жанрын нигезләүче һәм әзәрбайҗан театрын оештыручыларның берсе. 15 драма әсәре авторы. Ялган банкрот булып кыланучы карт бер сәүдәгәр-хаҗиның уналты яшьлек кызга өйләнергә тырышып йөрүе турында язылган «Тымызык яңгыр астыннан чыгып, яшенле яңгыр астына» (1895) пьесасы татар драматургиясендә Г.Камалны «Банкрот», Ш.Камалны «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедияләрен иҗат итәргә дәртләндергәндер дип уйларга нигез бар. В.нең кан үче алу кебек иске гореф-гадәтләрне тәнкыйтъ иткән «Мосыйбәте Фәхреддин» («Фәхреддиннең кайгысы», 1896) трагедиясе исә 1907 елда Гыймад Нугайбәк тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, татар театр труппаларының репертуарында ныклы урын ала һәм Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләрендә күп мәртәбәләр сәхнәдә уйнала. 1907-17 еллар арасында татар көндәлек матбугатында бу әсәр турында, аның сәхнәгә куелышы һәм авторының иҗат эшчәнлеге хакында бик күп мәкаләләр басылган.

Әсәрләре: Избранные произведения. Баку, 1958.

Әд.: Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Караев Я. Этапы азербайджанского реализма. Баку, 1983; Гаджиев А. Азербайджанский реализм. Баку, 1984.

*Р.К.Ганиева.*

**ВӘЛИ** (Вәлимөхәммәтев) Лотфи Вәлимөхәммәт улы (1910, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Кушнаренко р-ны Илек а. — 1943), шагыйрь. 1929 дан Мәскәүдә яши, пролетар язучылар ассоциясенең татар секциясе эшендә катнаша. Әсәрләре 1930 еллар башында «Эшче» г-тасында, «Октябрь баласы», «Ударниклар» ж-лларында басыла башлый. Беренче «Чакыру» (1932, М.Җәлил кереш сүзе б-н) җыентыгына кергән шигырьләрендә хезмәткә дан җырлый. Аерым шигырьләре «Каләмле ударниклар» (1932), «Туган ил» (1938) альманахларына кертелә. 1941 елның җәендә Бөек Ватан сугышына китә. Шигырьләрен һәм очеркларын фронт газеталарында һәм «Совет әдәбияты» ж-лында бастыра. 1943 тә фронтта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**ВӘЛИ** (Вәлиев) Хәйретдин (1893-1969), әдәбият тәнкыйтьчесе. Г.Тукай («Поэмалар шагыйре»), Г.Кутуй («Футурист шагыйрь»), Г.Ибраһимов («Галимҗан Ибраһимовның әдәби үсүе») иҗатларына багышланган беренче мәкаләләр 1920 елларда «Кызыл Татарстан» г-тасында, «Безнең юл» ж-лында һ.б.да басыла. Г.Нигъмәти, Ш.Сәттаров хезмәтләренә рецензияләр яза, публицистик мәкаләләр бастыра. «Әдәби типлар механизмы» (1929) китабы әдәби типлар, аларның характеры һәм структура үзенчәлекләренә багышлана. «Татар шигыре төзелеше» (1929) китабында шигырь төзелешенә киң анализ бирелә.

**ВӘЛИ** (Вәлиев) Ярулла Вәлиулла улы (1879, Бикморза а., Буа ө., Сембер губ. - 1937), язучы, драматург. Сәүдәгәр гаиләсендә тәрбияләнеп үсә. Дәрдемәнднең кияве. 1906 елдан «Вакыт» г-тасында эшли, 1917-18 дә баш мөхәррир. Егерменче еллар ахырында Оренбургтан Уфага күчеп килә, бухгалтер булып эшли. «Мәңгелек мәчет» (1901), «Әфиун» (1906), «Җанлы җеназа» (1907), «Ахырзаман бәласе» (1907), «Урман әүлиясы» (1907) хикәяләре, «Оят, яки Күз яше» (1902; сәхнәдә уйналуы 1907), «Ачлык кушты» (1908; сәхнәдә уйналуы 1911) пьесалары авторы. Пьесалары, бигрәк тә «Ачлык

кушты» драмасы үз вакытында «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» театр труппалары тарафыннан кат-кат сәхнәгә куелганнар. Репрессияләр чоры корбаны.

Әд.: Хәмидуллин Л. «Ачык фикерле зат...» Катапта: Ак төннәр хәтере. К., 2002. - 86-91 бб.

**ВӘЛИЕВ** Диас Назыйх улы (1.7.1938, Арча р-ны Казанбаш а.), язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981, 1983). Рус телендә яза. Казан ун-тының геол. ф-тын (1962), М.Горький исем. әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларын (1975, Мәскәү) тәмамлый. Геолог буларак Удмуртиядә, Киров өлкәсендә, Көньяк Уралда, Кемерово өлкәсендә эшли. 1966-72 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр. Беренче фәлсәфи-лирик хикәяләре 1959 да «Молодая гвардия», «Смена», «Сельская молодёжь» ж-лларында басыла. В. таланты бигрәк тә драматургия өлкәсендә ачыла. Беренче «»Намус хөкеме» («Суд совести», икенче исеме «Охота к умножению», 1971) драмасы зыялылар һәм хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрнең җитди әхлакый-этик проблемаларын күтәрә. «Гомер бүләк итәм» («Дарю тебе жизнь», 1972, ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1976) исемле трагедия-хроникасы аеруча зур уңыш казана. Пьеса Казан Зур драма театрында, М.Н.Ермолова исем. Мәскәү драма театрында һәм тагын илебезнең 50 дән артык театрларында уйнала. «Диалоглар» («Диалоги», 1976), «Казан-су аръягы пәйгамбәре» («Пророк из казанского заречья», 1977), «Казан университеты» («Казанский университет», икенче исеме «1887», 1979), «Кеше эзлим» («Ищу человека», 1985) һ.б. пьесалары Казан, Мәскәү, Ташкент, Минск һ.б. шәһәрләрнең профессиональ сәхнәләрендә уңыш белән барды. Аерым пьесалары татар телендә басылу һәм куелудан тыш белорус, украин, чех, болгар, әзербайҗан телләренә һ.б. тәрҗемә ителә. В. 1973, 1979, 1981 елларда өч мәртәбә Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз милли драматургия конкурсларында лауреат исемен алды. Проза әсәрләрендә В. фәлсәфи мәсьәләләргә зур игътибар бирә. «Картлар, ир-атлар, малайлар» («Старики, мужчины, мальчишки», 1975), «Әйләнә дөнья, әйләнә» («По вечному кругу», 1981), «Таш кискече тавышы» («Стук резца по камню», 1988), «Дон Жуан портреты» («Портрет Дон Жуана», 2003) китапларында автор тормышның фәлсәфи нигезләренә, әхлак мәсьәләләренә, кеше тормышының мәгънәсе проблемаларына аеруча зур игътибар бирә. «Астраль мәхәббәт» («Астральная любовь», 1999) романында реаль, романтик һәм мистик планнар тыгыз үрелеп бара. «Тәңрегә ышану» («Уверенность в Невидимом», т.1-2, 2002) китабына кергән «Бер кеше хакыйкате, яки Өстеналлага таба юл» («Истина одного человека, или Путь к Сверхбогу», 1993) әсәрендә, «Өченче кеше, яки Фәрештә» («Третий человек, или Небожитель», 1994) дигән роман-эсседа, «Барлыгы һәм берлеге турында уйланулар» («Мысли о Едином», ....) фәлсәфи язмаларында автор фәлсәфи яктан яңа дин, Өстеналла дине концепциясен тудыра. В. фикеренчә, төп дөньяви диннәр әкренләп саегып, бетүгә йөз тоталар һәм алар урынына яңа, барлык расалар һәм милләтләр кешеләрен берләштергән бөтендөнья дине килергә тиеш. Соңгы елларда язылган «Мөртәд, яки Голгофага чират» («Изгой, или Очередь на Голгофу», 1996), «Мин» («Я», 1999) проза әсәрләренә дә фәлсәфи киеренкелек хас.

Әд.: Галеев Б. Неверующий Диас // Литературное обозрение. 1989. N 4; Миндубаев Ж. Один под огнём // Литературная газета. 1991. 11 дек.; Диас Валеев - анализ творчества. К., 1996.

*Р.Ә.Мостафин.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Роза Хәлиуллинага 75 яшь

1931 елның 14 июнендә Актаныш районының Әҗәкүл авылында дөньяга килгән Розага тормышта күп һөнәрләр үзләштерергә туры килә. Гомуми белем мәктәбендә җиде класс тәмамлагач, Такталачык шифаханәсе каршында ачылган алты айлык курсларда укып, 1948 елга кадәр шул шифаханәдә күз авырулары буенча шәфкать туташы булып эшли. 1948 елда Казанга килеп, җиңел промышленность профессиональ техник училищесында оператор һөнәрен үзләштерә, кичке мәктәптә укып урта белем ала. 1952—1956 елларда исә медицина училищесын тәмамлап, төрле медицина оешмаларында эшли, төп хезмәтеннән аерылмыйча Казан медицина институтында укый.



1978 елдан—профессиональ язучылык хезмәтендә. Роза Хәлиуллина үзен шигърияткә соңлабрак килүче шагыйрә дип саный. Ул иҗат эше белән 1960 елларда шөгыльләнә башлый. Республикабыз матбугат битләрендә дөнья күргән шигырьләрен, (аеруча «Каенана» поэмасын «Казан утлары», 1977, № 10), «Бөрлегәнгә медаль», «Беренче карлыгачлар», «Чүкеч—нәни булышчы», «Агыйдел—аккош иле» һ. б. китапларын укучылар яратып кабул итә.

Роза Хәлиуллинаның иҗатына фәлсәфилек хас. Аның шигырьләре тормышчан, драматик характерда.

«Матурлык, шигърият, яшәү нәрсә ул?»—дигән сорауга Роза Хәлиуллина юбилей уңае белән чыккан бер әңгәмәсендә: «Матурлык ул—ихлас бирелеп эшләгән эшең булу. Шигърият ул—дөнья. Яшәү ул—ипекәй»,—дип җавап бирә.

Тормышта авырлыклар күп күреп, үзенең урынын шигърияттә тапкан, гомер юлының мәгълүм бер чорына килеп керүче шагыйрәнең әлеге сүзләрендә, әлбәттә, хаклык зур.

## Мидхәт Миншинга 70 яшь

Укучылар аны тавышыннан таный. Ул Татарстан радиосының үз хәбәрчесе, мөхәррире, өлкән мөхәррире, бүлек мөдире һәм баш мөхәррире булып кырык елдан артык бертоташтан эшли.



Мидхәт Миншин (Миншин Миннехәт Мөхәммәтша улы) 1936 елның 26 сентябрендә, Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылында туган. Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, прозаиклар Вакыйф Нуруллин белән Әхәт Сафиуллиннар аның авылдашлары. Мидхәт Миншин да кечкенәдән шигырьләр яза, радиожурналист булып эшләгән чорларда да хикәяләр һәм повестьлар язу белән мавыга.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган чакларда ук шигырьләре «Үсү юлы» альманахында, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында, «Беренче үрентеләр» җыентыгында басыла. Композиторларыбыз Р. Яхин, С. Садыйкова, Ә. Бакиров, Л. Батыр-Болгари, Ә. Шәрәфиев, Р. Кәлимуллиннар игътибар итеп, җырга салынган шигырьләре дә бар. Бүгенгесе көндә ул яңа повестьлар өстендә эшли.

Мидхәт Миншин «Васыять» (1979), «Башаклар жырлый» (1982) китаплары авторы. Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.

## Илдар Низамовка 70 яшь

Илдар Мәлик улы Низамов 1936 елның 3 сентябрендә Татарстанның Арча районы Олы Бәрәзә авылында укытучы гаиләсендә туган. Балалык, мәктәп еллары шул районның Чишмәле-Сап авылында үтә. 1951—1955 елларда Казан елга техникумында укый. Аны тәмамлагач, Агыйдел елга пароходчылыгына штурман итеп жибәрелә, аннан Совет Армиясенә алына. 1957 елда, Ерак Көнчыгышта солдат хезмәтен тутырып кайткач, ул янә Агыйдел елга пароходчылыгында техник, инженер-диспетчер булып эшли башлый. 1960 елда аны Уфада татарча чыга торган республика газетасы «Кызыл таң» редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп чакыралар. Шунда эшләгән чорда, хезмәтеннән аерылмыйча укып, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый.



1968 елда И. Низамов Казанга күчеп килә һәм 1974 елга кадәр «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә башта әдәби хезмәткәр, аннан бүлек мөдире вазифаларын башкара, ә 1976 елдан Татарстан китап нәшриятында политик әдәбият редакциясе мөдире булып эшли.

Әдәби ижат эше белән И. Низамов Казан елга техникумында укыган елларында кызыксына башлый, актив рәвештә «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәккә йөри. Беренче әдәби парчалары, очерклары да шул газета битләрендә дөнья күрә, аннан ул күмәк жыентыкларда, журналларда басыла башлый. Кыска әдәби парчалардан торган беренче китабы 1970 елда чыга. Хәзер ул — күп санлы китаплар авторы. Алар арасында «Дәрья күзе», «Өмет» кебек повестьлар да, «Куллар жылысы», «Иллә мин дә сандугач», «И туган тел» кебек жыентыклары да бар.

И. Низамов тел белеме буенча фәнни тикшеренү юнәлешендә дә нәтижәле эш алып бара. Ул «Матбугатның тәэсирле сүзе» дигән монографик хезмәт язды һәм шул темага кандидатлык, аннары докторлык диссертациясе яклады. Соңгы елларда ул татар теленең дәүләт теле хәленә үстерү юнәлешендә радиода һәм матбугатта актив эш алып бара.

И. Низамов 1960 елдан — СССР Журналистлар союзы, ә 1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Юбилярларны ихластан котлыйбыз! Аларга саулык, яңа ижат уңышлары телибез.*

**Редакция**

## Идрис Туктарның тууына 110 ел

1896 елның 20 сентябрендә Башкортстанның Булышлы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган Идрис ун яше тулгач алтын приискасында кара эшче булып эшли башлый. Чөнки жирсезлектән, фәкыйрьлектән тәмам интеккән әтисе гаиләсен алып Урал якларына барып урнашырга мәжбүр була.

Аң-белемгә омтылу көчле булган Идрис Кучкардагы өч класслы рус мәктәбендә, аннары Уфага барып дүрт класслы училищега укырга керә.

1915 елның көзендә патша армиясенә алынган егеткә әле февраль революциясенә кадәр фронт авырлыкларын күрергә туры килә. Бары тик патша төшерелгәч кенә ул фронтны ташлап янадан Кучкарга кайта һәм китапханәдә эшли башлый.

1920-22 елларда төзелеп килүче совет хөкүмәтен саклауда катнаша. Колчакка каршы өндәү эшләре алып баруда гаепләнеп аклар төрмәсендә дә утырып чыга. Бөек Ватан сугышы башлангач—1943 елны Идрис—солдат янәдән кулына мылтык ала. Аңа кадәр исә төрле газета-журналларда эшли, Казан дәүләт педагогия институты тәмамлый (1932-1936), Зеленодольск шәһәрендә рабфакта һәм ФЗУда укый, 1943 елда исә фронтка китә.

Сугыштан соң ике ел Киевта яши, биредә дә укытучы, китапханәче эшләрен дәвам иттерә. 1947 елда янәдән Зеленодольск шәһәренә кайтып төпләнә.

Кулына каләм алып, язучылык хезмәтенә керешкәндә Идрис Туктар инде бай тормыш тәҗрибәсенә ия була. Аның «Партизаннар» исемле беренче әсәре 1929 елда Мәскәүдә басылып чыга.

Ул төрле жанрларда ижат итә.

Шигырь, фельетон—берсе дә аның игътибарыннан читтә калмый. Бераздан исә прозага гына күчеп, хикәяләр, әкиятләр, повестьлар язуга күңел куя. Аның «Гыйльметдин солдат вакыйгасы», «Хәсән солдатның үлеме», «Бала туыы», «Үлем эшелоны» һ. б. хикәяләре аерым китап булып дөнья күрә.

Күп еллар шахтерлар арасында яшәп, аларның тормышларын якыннан белүенең нәтиҗәсе булып дөньяга «81 нче штольня» исемле повесте туа. Бу—әдәбиятта татар шахтерларының катлаулы тормышын киң яктырткан беренче әсәр була. Язучының шулай ук «Ике егет» исемле романы да игътибарга лаек. Аларга матбугатта зур бәя бирелә.

Идрис Туктар балалар әдәбиятында да яратып ижат итә. Ул үзенең «Нәни хикәяләр», «Жир жиләге», «Тамчылар», «Батырлыкта—матурлык», «Авыр аяк» һ. б. күп кенә әсәрләрен нәниләргә атап яза. Алар да Идрис Туктарга хас булганча ягымлы юмор белән сугарылган, гади, аңлаешлы тел белән язылган.

Аның шулай ук тәржемә өлкәсендә дә мәгълүм хезмәтләре бар. Куприның «Ак Пудель», Ликстановның «Малышок», Волошинның «Кузнецк жире» әсәрләре аның тәржемәсендә татар укучыларына барып ирешә.

Ул 1934 елдан бирле СССР Язучылар берлеге әгъзасы була. Идрис Туктаров 1982 елның 20 октябрендә сиксән жиденче яшендә Зеленодольск шәһәрендә вафат була.

## Әзһәр Габидинең тууына 80 ел

Ул чор кешеләренең күбесенә хас булганча Әзһәр Габиди язмышы да фронт юллары белән бәйле. 1926 елның сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында туган яшүсмергә Ерак Көнчыгыш фронтларында катнашырга, берничә тапкыр авыр контузияләр алырга туры килә. Әмма сугышның аянычлы-фаҗигале еллары аны тупасландырмый, киресенчә, тормышка башка яктан карарга мөмкинлеген ача, чыныктыра, инде өлгергән ир-егет ясый: «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле беренче шигырьләр китабы басыла. Сугыштан исән-имин кайтып туган ягында татар теле-әдәбияты, тарих укыткан Әзһәр аганың әдәбиятка мәхәббәте тагы да арта, башкарган хезмәте балалар дөньясы белән бәйле булгангамы (үзе дә алты бала атасы), аның бер-бер артлы нәниләргә язган «Без—яз дуслары», «Тапкырҗан табышмаклары» исемле китаплары чыга. Зурлар өчен лирик-фәлсәфи китапларыннан «Таң сәгате» (1994), «Урман читендәге наратлар без» (1997), «Күзгә барлау» (1999)—Әзһәр Габиди иҗатының асылын билгеләүче әсәрләр. Шулай ук аның «Их, кайтса иде егет чагым» җырын (Р. Курамшин көе) әле күпләребез хәтерлидер.

Әзһәр Габиди иҗатында игътибарга лаек тагын бер өлкә—аның чын күңелдән яратып, каләмдәшләренең иҗатларына карата язылган мәкаләләре. Шагыйрь биредә дә шигырьләрендәге кебек ихласлыгы, самимилеге белән ачыла. Әдәбияттагы хезмәтләре өчен ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Әлмәтнең Р. Төхфәтуллин исемендәге әдәби премиясенә лаек була. Вафатыннан соң туган авылы мәктәбенә шагыйрьнең үз исеме бирелүе дә Әзһәр Габидиның татар әдәбиятында мәгълүм бер урын тотканлыгын күрсәтә.

Ул 2001 елның 22 августында вафат булды.

♣

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Рәдиф
Сәгъди

# ШИКЛЕ МАШИНА

ШАЯН ХИКӘЯ

Авыл урамыннан ыжгырып килүче «Жигули» күренде. Кемнендер алаколалы мәчесе, машинадан өркеп, ямьсез итеп мыраулап, капка төбендә үсеп утырган йөз яшьлек талга сикерде. Реактив самолет кебек өскә ыргылды ул.

Агачның ин очына менеп җиткәч кенә, яфрак арасыннан сак кына башын тыгып, аска күз салды. Ә анда... Кинәт кенә тормозга басудан чыелдап шуып барып туктаган көпчәкләрдән көйгән резина исе таралды. Әллә кем булып киерелеп йөрүче кызыл кикрикле кара әтәч зур канәгатьсезлек күрсәтте бу хәлгә. Машина ягына карап «кырт-кырт» килеп, аяклары белән тыпырдап алгач, канатларын җәеп, тавык-бичәләренә кереп китәргә әмер бирде. Капка төбендә күрше йорт тавыклары гына «безгә нишләргә соң?» дигәндәй, аптырап басып калды. Әтәч, тагын бер кыртлап алгач, башы белән ымлап: «әйдәгез, сезгә урын җитәр» дип куйды. Күрше тавыклары да әтәч артыннан ыргылды. Агач башындагы мәче генә ишек алдына кереп качкан тавыклардан көнләшеп калды. Бераздан койманың эчке ягыннан гайрәтләнеп аваз салган әтәч тавышы янгырап куйды: «Кикрикүк!»

Машина ишеге ачылган тавыш мәченең бөтен игътибарын яңадан үзенә тартты. Аннан ачуыннан бүрткән, юка иреннәре кысылып каткан участок милициясе Миңлегаяз Фаязович үзе килеп чыкмасынмы?! Аның бу кыяфәтен күргә үк мәчене яңадан курку алды. «Сулаганымны гына ишетә күрмәсен тагын», — диеп тынын кысты. Кысмыйча кая барасың, бөтен тирә-як сәрхушләренең, вак-төяк каракларның котын алып торучы милиционер үзе басып торсын әле! Ачкычлар бәйләмен кулы белән эшлекле болгап, милиция тирә-якны күзәтте. Әтәч белән тавыклар кереп качкан йортның урта тәрәзәсе ачык икәнлегең шәйләп:

— Сәрвәрия әби! Сәрвәрия әби, син кайда? — дип кычкырды. Озакламый татарчалап бәйләгән яулыгы эченә керми калган чәчләрен җыештыргалап, мөлаем йөзле, ачык чырайлы, күзләреннән хәйлә чаткылары сибелеп торучы йөз-йөз илле яшьләр тирәсендәге тере генә бер карчык пәйда булды.

— Тавыкларымның котын очырып кем йөри дисәм, Миңлегаяз улым, син икәнсең.

—Отставить, Сәрвәрия әби! Юк-бар сүз сөйләшеп торырга вакытым юк!

—Ни булды соң, Гаяз энем?

—И все таки син мина шуны әйт әле! Әнә теге «семерка»ны тыкрыкта кем калдырып китте?!

—Кем дип әйтим икән соң, улым... Танымадым үзләрен, ахры, безнең авылныкылар түгелдер. Бик ашыгалар иде.

—Понятно! Димәк, алар бу машинаны угнали... Әсрарларның коймаларын ишеп, Габделәхәтнең соңгы казларын таптатып киткәннәр.

Бу сүзләрне ишетеп тыңлап торган әби дә: «Йә Аллаху, вәләәкүәтү», — дип укынып алды.

—И все-таки... Төс-битләрен чамалабрак калгансыңдыр ич, Сәрвәрия әби?

—Калдым, улым, калдым! Ничек дип әйтим...

Шулчак, барысын да ишетеп калыйм әле, дип яфрак араларыннан ярты гәүдәсе белән үк чыккан мәче, басып торган ботагы сынып, бик аздан гына җиргә очып төшмәде. Соңгы мизгелдә генә икенче ботакка сикереп ябышып кала алды ул. Мырау-а-у тавышыннан лейтенант та сискәнеп куйды, кобурасыннан пистолетын тартып чыгарып, әбидән дә борынгырак ике йөз яшьлек агачка төбәде.

—Әй, улым, ялгыш атып җибәрә күрмә тагын, минем яраткан песием бит ул. Чуаркаем!

—Понятно! Тик шулай да, вакытлы-вакытсыз ул мәчеләрегезне урамга чыгармый торсагыз да буладыр бит.

—Так точно, гражданин начальник, була. Эт урынына бәйләп куйсак.

—Ташлагыз әле, Сәрвәрия әби, шул тупас шаяртуларыгызны. Ул сериалларны карый-карый акылыгызга зыян килеп беткән инде сезнең. Тәк, димәк, икесе дә карачутыр дисез инде.

—Так точно, икесе дә дегет кебек кап-кара чырайлылар иде, теге ничек дип әйтим, чүркәләр кебек!

—Чүркәләр түгел, әби! Чуркылар! Понятно?

—Так точно!—дип, Сәрвәрия карчык үрә катты. Лейтенант Фаязович исә «тәк-тәк», — дия-дия, читкәрәк китеп үз-үзенә сөйләнеп, хәлне анализларга кереште: «Димәк, кара халык! Теге атнада гына Буада наркотиклар сатып йөрүче таҗикларны эләктергәннәр. Егерме кило героин чыккан. Икесе яшел «Жигули»га утырып качкан. Тукта-тукта, бу «Жигули» да яшел түгелме соң? Точно! Ә теге икесен тоткан минем кебек лейтенант Әһлиуллинга шундук өлкән лейтенант дәрәҗәсе дә, кыйммәтле бүләк тә биргәннәр. Вот, везет же шундый юк-бар малайларга, ә! Бу бит шанс! Әгәр дә, теге ике карачутыр шул качкыннар булып чыкса, эш пешәчәк минем!»

—Нәрсә пешә дисең, улым, — дип сорау биреп куюны кирәк тапты Сәрвәрия әби.

—Менә нәрсә, Сәрвәрия әби, без аларны кулга алабыз.

—Бик әйбәт булыр, улым, йөрмәсеннәр безнең авылда тавык таптатып, коймалар ишеп.

—Син, әби, шунда тор, мин әлегә дүрт көпчәкләрен сүтеп яшереп куям, качып китә күрмәсеннәр.

—Слушаюсь, мой генерал!

—Ну, Сәрвәрия әби, шул боевиклар карап ятып акылына янадан зыян килмәгәе.

—Так точно!

Шул вакыт өй эчендә телефон шалтыраган тавыш ишетелде.

—Гаяз улым, мин тиз генә, яме, балакаем. Кәримә әбиең элемтәгә чыгарга тиеш иде. Син сүтә тор, яме, былбылым!

—Ярый, әби, ярый. Тик озаклама! Бик ответственный эш бу!

Әби өйгә кереп китте, лейтенант Миңлегаяз Фаязович үз машинасыннан ачкычлар алып, шикле «Жигули» ягына юнәлде.

Агач башындагы мәче генә, хуҗасының кереп китүенә үпкәләп, моңсу гына мыраулап куйды. Ул да түгел, ачык тәрәзәдән Сәрвәрия карчыкның борчулы йөзе күренде.

—Улым дим, улым Миңлегаяз, кил әле, кил, тиз бул!

—Нәрсә булды инде тагын, Сәрвәрия әби! — дип, ике кулына машина тәгәрмәчләре тоткан участковый күренде.

—Улым, дим, син ул машинаны сүтеп дөрес эшлисең микән?!

—А как же!

—Анысы шулайдыр да, улым. Әле генә Кәримә дустым шалтыратты:

«Колхоз рәисе Рәфкатьләргә Казаннан яшел машина белән якын туганы кайтырга тиеш булган», — ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, Минлегаязның чырае агарынып чыкты. Өстәвенә, урысчалатып нидер сүгенеп тә алды.

—Әстәгъфирулла, жанкисәгем! Мәрхүм ананны искә алып сүгенмәсәң.

—Сәрвәрия әби, шуны башта ук ачыклып булмый идеме? Сүгенмәс жиреннән сүгенерсен, сезнең белән, дүрт көпчәкне сүтеп алгач кына әйтмәсәң.

—Нишлим соң инде, улым. Йөз иллегә житкәч, барысын да белеп бетереп булмый икән шул!

—Ярый, әби, ярый. Мин хәзер, тиз генә кире борып куям. Син күз-колак булып тор.

—Бар, улым, бор! Председатель туганы ди бит! — дигәч, әби арлы-бирле йөренергә тотынды. Шул вакыт янадан өй эчендә телефон тавыш бирде.

—Улым, дим, улым. Тагын Кәримә карчык шалтырата бугай.

—Бар инде, әби, бар, тиз генә кереп чык.

—Яхшы, улым, яхшы, мин хәзер, тиз генә, — дип, әби яңадан өенә теркелдәде. Озак та үтмәде, тәрәзәдән тагын әбинең кызларныкы кеби яңгыравык тавышы ишетелде:

—Улым, дим, Гаяз улым, тиз генә кил әле, эш бик важный бит, жаныем. Колхоз рәисенә кайтасы кеше житмеш яшьлек бабай икән. Теге ике кара чутыр кемнәрдер, белмиләр.

—Ну, башны катырсагыз да катырдыгыз инде, Сәрвәрия әби! — дип участковый тешләре арасыннан ачулы мырлап куйды.

—Әй, алайса, теләсәң нишлә инде, — дип, карчык, үпкәләп, тәрәзәдән күренмәс булды. Ул да түгел, яңадан тавышы ишетелде:

—Улым дим, Гаяз улым! Әнә, телевизордан теге ике чурканы күрсәтәләр. Авыллар буйлап наркотик сатып йөриләр икән, — дип сөйлиләр, әнә суратләренә хәтле күрсәтәләр.

Лейтенант чабып килеп тәрәзәгә башын тыкты.

—Точно шулармы, Сәрвәрия әби?!!

—Точно шулар, — диеп пышылдады карчык.

—Немедленно балта алып чык! Ишекләрен каерып ачып наркотикларын алырга кирәк!

—Хәзер, улым, хәзер!

Бер сәгать вакыт үтсә үткәндер, лейтенант Фаязович машинаны сүтеп бетерә язды. Инде өй тирәсе ремонт ясау цехын хәтерләтә иде. Бер өемдә көпчәкләр, икенчесендә карбюратор, трамблер, аккумулятор, генератор, өченчесендә утыргычлар...

Сәрвәрия әби дә исе китеп:

—Кара инде, әй, ат арбасы хәтле генә нәмәстәдән күпме тимер-томыр чыкты, — дип өемнәрне караштыргалап йөрде.

—Улым, дим, улым, йә нәрсә, таптыңмы соң наркотик? — дип, аннары машина эчендә казынган милиционерга эндәште.

—Юк әле, юк! Бик оста, бик тәжрибәле жинаятьчеләр ахры!

—Бәлкем алар наркосатучылар да түгелдер әле!

—Нишләп алай дип уйлыйсын, Сәрвәрия әби?

—Әле генә Кәримәттән шалтыраткан иде. Колхоз рәисе Рәфкатьнен теге житмеш яшьлек туганы үзе кайта алмаган, бик каты чирли, ди. Шуна күрә иткә үзбәк киявен жибәргән. Теге ике карачутыр шулар булып чыкты, ди. Фермада бер тананы суеп эшкәртеп бетерделәр, хәзер яшел «Жигули»га төяп, китәргә жыеналар ди, Миннегаяз балакаем!

—Елки-палки! Сез бит мине Кәриматтәй белән икәүләшеп тереләй суйдыгыз. Ә теге телевизордан күрсәткәннәрне шулар диден бит!

—Шулар дип, инде улым! Сон ул чүркәләрнен барысы да бертөсле бит. Кайсы кем икәнлеген кем белеп бетергән! — дип әби челт-мелт итеп күзләрен йомгалап алды.

—Икегезне бергә утыртам, Сәрвәрия әби! Ә хәзер шуны тыңла: син мине, мин сине күрмәдем. Сорасалар, ниндидер үсмерләр казынды, мин чыккач качтылар, кемнәр икәнлеген танымадым, безнен авыллар түгел иде диярсен.

—Ярар улым, ярар, әйтермен. Тик менә машинаны гына кем кире җыеп куяр икән?

—Борчылма, әби, үзенне кулда тот! Паникага бирелергә ярамый! Участок милициясе лейтенант Минлегаяз Фаязовичка хәбәр иттем, кешеләр җибәрермен дип вәгъдәләде диярсен. Шунын белән вәссәлам.

—Ярар, улым, ярар. Шулай диярмен.

Озакламый моннан сәгать-сәгать ярым элек очып килгән машина, бар көченә кире чабып китте. Капкадан бер кәтү тавык — бичәләрен ияртеп, әтәч тә килеп чыкты, канатларын җилпеп бөтен көченә кычкырып та җибәрде. Агач башындагы мәчегә дә җан кереп мырауларга керешге.

—Әйдә, әйдә, җаныкаем, төш! Көне буе агач башында утырып тамаккайларын ачкандыр инде синен, — дип, Сәрвәрия әби әйтеп бетермәде, өйдә янадан телефон шалтырады.

—Әйе, Кәримә дустым, әйе! Машинаны сүтеп ыргытты да качты. Беркемгә әйтәсе булма, дигән була. Теге юлы синен белән мине район бүлницәсеннән кайтканда утыртмыйча узып киткән иде бит әле. Үчен алдык, ахирәт, — дип Сәрвәрия карчык рәхәтләнеп кеткелдәп җибәрде. Ана Кәриматтәй дә кушылды. Ә әбинен аяк тирәсендә иркәләнеп яткан ала-колалы мәчесе дә боларның кеткелдәвенә кушылып, авызын җырып җибәрде.

---

Мөнирә
Галимҗанова

## БОРЫН

ШАЯН ХИКӘЯ

Тик торганда борыны кычыта башлады Сәлмәннен. Күчтәнәчкә юраудан узды шул... Ул аны кашып та карады, казынып та карады, файдасы булмады. Борын үтереп кычыта. Ул аптекага китте.

—Фи-и, исең киткән икән, аллергия бу!—диделәр аптекада һәм аңа май биреп җибәрделәр.

Бармак башы кадәрле бу майны алса да алды, алмаса да алды Сәлмән. Бәясен кыйммәтсенде—бер мең тора бит! Ярый ла, файдасы тисә!

Юк шул, тимәде.

Инде борын көнен-төнен кычыта. Бертуктаусыз кашый торгач, ул, шәмәхә төскә кереп, кабарып чыкты. Бер ай шулай газапланганнан соң, борын үзенең рәвешен югалтты. Врачка бармый чарасы калмады Сәлмәннен.

И, андагы чират, бөтен кеше чирле диярсең! Кичке якта гына врачка охшаган бер кеше килеп, утыз кешене ярты сәгатьтә карап та бетерде. Сәлмән иң ахырдан керде.

—Теләсә кая борыныгызны сузып йөрисез дә аннан шундый хәл килеп

чыга. Спидтыр әле, анализлар бирдеңме?—дип котын алды яшь врач Сәлмәннен.

—Б-б-б-б-бирдем,—диде Сәлмән, куркуыннан чак үлмичә.

Жирәндеме шунда, врач борынны карап та тормыйча рецепт язарга тотынды.

—Менә, абзый кеше, бу даруларны фәлән-фәлән җирдән алыгыз,—дип өйрәтеп җибәрде.

Юлда таныш врачы очрап, рецептны укымаса (ул икенче бер больницада өстәмә эштә—урам себерүче булып эшли иде), белмим, нәрсә булыр иде икән?!

—Әгәр син бу даруларны куллансаң, борының череп төшеп, икенчесе үскәнен көтәргә кирәк булачак,—дип, янә котын алды ул Сәлмәннең.

Инде бөтен гаилә аптырашта. Кычыта бит каһәр суккан борын, үтереп кычыта! Туганнар, дуслар, күршеләр, таныш-белешләр—барысы да зур хафага төште.

Көннәрдән беркөнне хатынының күңеленә: «Имчегә барыргамы икән әллә?»—дигән уй килде. Шулай эшләделәр дә.

—Бозым!—диде теге карчык. —Ун тапкыр килерсең. Төнлә генә кил, һәр килгәнеңдә дә кесәң буш булмасын. Гөнаһың бик зур синең, шул гөнаһ борыныңа төшкән.

Коты очты Сәлмәннең. Булган һәм булмаган гөнаһларын күңеленнән генә барлый башлады. И, Ходаем, кайсының каргышы төште икән инде. Фираяныкы, Хәдичәнекеме, Альбина чукынчыкныкымы әллә?

Ун тапкыр барды Сәлмән, әмма борынның кычытуы кимемәде.

—Күрдеңме инде,—диде хатыны Сәлмәнгә. —Гөнаһың бик зур синең, шуңа күрә дәва да килешми.

Бетте Сәлмән, үләр дәрәҗәгә җитте. Нужәли тазара алмас икән? Ну, тазарса, белер иде инде яшәүнең кадерләрен, сулга йөрү түгел, хатыннан башкаларга күтәрелеп тә карамас иде...

«Нишләргә инде? Асылынып үләргә микән әллә? Болай яшәү мөмкин түгел бит!

Чамасыз зурайган борынын көзгедән җентекләп карагач, бу уеннан кире кайтты Сәлмән. Борынның ни гаебе бар?

«Туктале, ник тышы түгел, эче кычыта соң бу нәрсәнең? Карап карыйм әле, нәрсә бар икән соң анда?»

Шулай сөйләнә-сөйләнә, үз борынын үзе өйрәнеп торганда ни күрсен—анда... ике йон бөртеге үсеп чыккан да, сулаган саен борынны кытыклый икән.

Йолкып атты аларны Сәлмән, күзләреннән яшьләр атылып чыкты... Шул мизгелдә үк борын кычытудан туктады. Сәлмән бу хәлгә ышанмыйча катып калды. Әйтерсең лә, сугыш бетте!

Борынның кычытуы юкка чыкты! Сәлмән дә элеккечә йөгерә-шатлана йөри. Дөнья матур, дөнья киң, яшәү шулхәтле рәхәт, шайтан алгыры! Тик борын гына, булган хәлләрне искә төшереп, бераз шәмәхә төскә кереп калды бугай. Сәлмәннең үзенә исә шул имчедән, төрле май-дарулардан, пычактан исән калган, фәлә нчә мең сумга төшкән зәңгәр борыны бик тә, бик тә кадерле иде. Исән генә булсын да... хатыннар каргышына ышаныр хәлләргә җиткереп кычытмасын гына!..

❋

Фарис
Фәсхи

# ЭПИГРАММАЛАР



## ШАМИЛ ЗАКИРОВ:

**— Шәһре Казан уртасында
Чайкала минем кораб.
Җилкәннәре киерелгән
Килер таңнарга карап.**

**Инкыйразга юл куйма, дип,
Татар угълын уятыр.
Нәкъ Тукайча, бу корабның
Исме — милли театр.**

## ИЛҺАМ ШАКИРОВ:

**— Җырларга үрчемле булды
Бу үзгәртеп корган чор.
Тузга язмаган сүзләрдән
Әвәләнә торган җыр.**

**Ул җырларны сүгенмичә
Һич тә тыңларлык түгел.
Шул сүзләрне үзгәртмичә
Һич тә җырларлык түгел.**

**Күргәнем юк сандугачның
Сайравын газап чигеп.
Концерт алдыннан җыр сиплим
Сәхнә артында чүгеп.**



Таңгөл

# КУРЬЕР

ХИКӘЯ

Бигрәк кытлык елы булды бу. Әни эшләми, кыштыр-мыштыр өй тирәсендә генә маташа. Кәефе төшенке, күңеле еламсырый, мина да артык сүз кушмый, үзалдына уйланып йөри бирә. Узган еллардагы кебек зур планнар да кормый, әйбергә дә кызыкмый, тормыш итәргә дә атлыгып тормый.

Үземнен дә хәлләр мактанырлык түгел. Көндезләрен—укуда, кичләрен арып-талып почта өләшәм. Әни хасталанып урынга егылган көнне үк эшен ташлады. Бер елга ничек тә чыдарбыз әле дигән иде. Чыдарсың чутыр-матыр! Кешеләрнеке кебек әтиең булса... Кичтән машинасына тутырып алып кайткан күчтәнәчләреннән суыткыч ишекләрең ябылмый торса! Әнә, күрше Илдарларныкы шикелле. Ул киемнең дә затлысын кия, җәяү дә йөрми. Нәрсәсен әйтәсең тагын: курьер булып та эшләми. Мин эштән кайтканда, үз турларында йә мороженое ялаган, йә чикләвек чырткән чагы булыр.

Илдар дигәннән, курьер эшен мина ул тапкан иде. Әтисенең Ямашев урамында бер фирмасы бар икән. Яшь кызларны көтеп кенә торалар, имеш. Эше дә артык түгел, ике-өч бәйләм кәгазь кисәге тоттыралар да оешмадан оешмага йөртәләр. Кем белән генә танышмыйсың да, кемне генә күрмисең! Кызларга егет карату өчен бер дигән юл бу, дип күз кыса, җитмәсә. Курьер булсам да, бер дә караганы юк әле үзенең. Мин узганда, әллә кем кебек, горур бер кыяфәттә генә сәламемне алып кала.

—Тик йөреп аргансындыр, ял ит!—дигән була.

Мин дә сер бирә торганнардан түгел. Тиз генә чәй эчеп алам да, кедаларымны, теннис калакларын тотып, фырт кына янадан аның яныннан узам. Мәктәп ишегалдындагы кортка барам, имеш. Үзем җиләс җил искән Кабан чирәмлегенә таба элдерәм. Шешенгән, сөялләнгән аякларым күл буеның хәтфә яшеллегендә хәл ала. Их, әни авырмаса, без әле балык тотып, җырлар да җырлашып утырыр идек лә ул!

Курьер эшенең авырлыгы җәяү йөрүдә икән дип уйламагыз тагын. Аның бөтен җәфасы эшләгән тиененне исәпләүдә. Тугыз-ундүрт катлы йортларның бикле ишек төбенә таннан ук барып утырасың да шәһәр абзыйларының эшкә киткәнен көтәсең. Дөнья үзе өйрәтә икән ул: кай подъезд төбенә яхшы машина килеп туктаса, шуннан бер симез генә хуҗаның килеп чыгасын көт тә тор. Ул абайламый калганчы, син ишекнең теге ягына кереп тә сызасың.

Кулым төшә-менә, төшә-менә. Үзем күңелдән генә табышны саныйм:

—7 тиен, 5 тиен, 7 тиен, 5 тиен...

Җидесе дигәнем—Эльдорадо кибетенең ялтыравыклы кәгазьләре, миңа 5 тиен вәгъдә иткәне—яңа гына ачылып килүче ниндидер вак фирма. Андыйларның кәгазе ватык почта ящикларының төбендә әле калынаерга өлгермәгән хуҗалары кебек бөрешеп кенә яталар. Көн дигәндә, дүрт мең кәгазенне таратасың да 280 сум акчанны учлап әниең алдындагы өстәлгә китереп саласың. Башта елмаеп, сөенеп киткән кебек күренгән әни, ишек яныннан узганда, әле бу атнада гына 500 сумга алган кроссовкаларның ачык авызына карый:

—Син дә акча эшләргә ярый башладың,—дип әйткән була үзе.

Язу эшеннән башканы беләмени сон ул әни?! Гомер буе тиенне тиенгә ялгап яшәмәгәч, менә минем шул тиеннәрне исәпләгән башны анлыймыни?! И-и, ди әнием, гомерем буе дүрт жирдә эшләдем, монын кадәр аяк киеме туздырмадым.

Башмагыннын башы башка-а-а...
Бәрмәгәнсен асфальт-ташка-а-а...

Урамда гел шул жырны жырлыйм мин хәзер, әни исемә төшкәндә. Ә анын исемә төшмәгән чагы бармыни?! Карап торган бердәнберем, мировой әни бит ул—минем әни! Көлә башласа, эч авырткanчы көлә. Елый башласа, минем күзгә яшь килгәч кенә туктый.

Авырып китмәсә, мин аны өйдә күрә дә алмас идем әле. Болай... Фәнзаман абый әйтмешли, ну да, рәхәт кенә... Ул өйдә, ашарга пешереп көтеп тора. Мин—курьер. Ай дигәндә, мен сумны кулына китереп тоттырам. Ул тагын елмая. Фатир өлешенне үзен түли башладын бит, кызый, ди. Сигез йөзе генә минеке бит дип әйтмим, безнен фатирда яшәмичә генә исәптә торган әти өлешен кайтарасы бар.

Әти, дидемме, көләсем генә килә. Ул да—мировой әти безнен. Күлмәк тә алып бирми, башкасын да. Барыбер туза ди торгандыр инде. Әнинен ана ачуы чыкмасын дип, әти өчен алиментны үземә үзем түлим мин, дигән идем, алиментка фатир түләве кагылмый дип кырт кисте. Кычкырып көлдек тә бетердек. Мин аны математиканы оныткан дип торам. Баксан, миннән дә яхшы белә икән әле. Хезмәт хакы прогрессия функциясенә ия түгел, дигән була.

Менә шулай. Гөлсем апагыз—курьер. Илдарнын әтисендә. Ул—баскыч төбе каравылчысы. Ну, ни өчендер безнен подъездныкы...

Илдар кайгысы юк әле монда. Подъезд тулы сәрхуш булыр, сәрхуш яны тулы—эт. Куркам да инде этләрдән. Әле дә ярый шул сәрхуш абзыйлар минем яннан аларны куган булып кыланалар.

Китегез моннан, кит! Пошшел! Урысча да анламыйлар болар, татарча да. Көлдереп, эчләрен катырам мин аларнын хәзер. Жыр жырлап! Телем тулы жыр бит минем. Анын барысы да кызларга килешми, ди әни. Шагыйрь кызларга килешә ул! Сатира-юмор остасына, мина—Гөлсем апагызга. Казаннын атаклы курьерына!

Башмагымнын башы башка...
Керен бара бу подъездга...
Кичтән эчкән абзый чыга...
Охшаган ул бер дунгызга...

Әһә! Ишек ачыла! Шылдым мин, егетләр! Бу йортка беренче генә керү әле. Ишекләренә код дигән нәмәрсә куйганнар. Кайчан килсән, ябык булыр. Бала тирбәтеп йөргән бер абыйдан башка чыккан-киткәнне күрмәссен. Ачтырасынмыни аннан?! Болай да тук күзләре белән әллә ничек ямьсез карап тора...

Юк кеше белән сөйләшеп, санда буталмыйм тагын. Бер ящик, ике ящик, өч, дүрт, биш... Ярыйсы гына чыкты бу. Жәмгысы ике сум да илле тиенлек булды. Яз, Гөлсем, баш миенә, бухгалтерлыкка укыйм әле, дигән буласын икән, онытма: бишесе ватык, өчесенен ишеге ачык, дүртенчесенә чүп тулган.

Санийсын санап, хәтерлисен хәтерләп кенә бетерүем булды, баскычтан көн дә мина күз ялтыратып караган абыйнын төшеп килгәне күренде. «Ах, чибәр кызыкай, Сезмени әле бу»—ди. Дәүләт хезмәтендәге ир-атка авыз ерырга ярамый. Кайдан белсен инде ул аны?! Бу яшьтә бөтенесенен башы тузадыр инде?

Минем башның башы башка,
Бәрелгән ул төрле ташка...

Иреннәремне турсайттым да, тупас җавап кайтармас өчен, тәрәзә төбенә куеп торган сумкаларымны алырга дип, бер баскыч югары күтәрелдем. Карашларыбыз күзгә-күз очрашты. Нинди әдәпсезлек булды соң бу, юлыннан читкәрәк чыгып, тәрәзәгә таба үттем. Ә аның исе дә китми: һаман сөйләнүендә, чутылдавында.

—Туктагыз әле, туташ, туктагыз!—димәсенме. —Исемегез ничек соң Сезнең? Кайчаннан бирле бу якларга йөрисез, һаман танышкан да юк.

Сәер дә инде бу ир заты. Һәр урамдагы кыз белән танышу мәҗбүри түгел ләса! Минем уйларымны укыгандай, өске каттан да шушы ук сүзләр яңгырады. Куркуданмы, башкасыннанмы, тәнемә суык йөгерде. Югары катка карадым. Аннан затлы киемле бер ханым төшеп килә иде:

—Яшең кырыкта, күзең ярыкта синең һаман!—диде ул, тупас кына. —Үз кызың булырдай бала-чагага тел сайратып тормасаң!

Абзый каршы җавап кайтармады. Мин аңа борылганда, аска карап, кыенсынгандай басып тора иде. Апа да тынычланды. Бераздан аның:

—Затлы, дим, Затлы, колясканы алып төш инде, аны да миңа күтәртмәссең ич?!—дигәне ишетелде.

Бу сәер, минем әтиемдә генә була ала торган исем белән яңагыма китереп суктылармыни?! Мин аның хуҗасына күтәрелеп карадым. Шунда аның ярылыбрак торган ияклөрен, киң борын яфракларын, искергән яшькелт яфрак кебек күзләрен шәйләдем.

Нәкъ шундый бер рәсем безнең өебездә дә бар! Тик күзләре генә шатрак, җетерәк, ягымлырак... Шундый ук исем минем курьерлыкка язылган килешү кәгазендә дә тора. Ул исем минем исемемнең ишкәкчесе шикелле әллә алга илтә, әллә артка, әллә мине тормыш дулкыннарының иң авырларында төрле-төрле якка чайпалдыра.

Исемнәрдән исем башка,
Исем кушмыйлар һәр ташка...

Шушы исемне күтәреп йөргән аркасында гына, мин— курьер, чөнки шул затлы исем өчен генә мине күрше подъезд малае Илдар ярата! Ул ératканга, әтисе эшкә ала. Шул исем өчен мине әни дә ярата бугай әле! Уң кулым кесә төбеннән бу подъездда аның исеменнән эшләгән акчаны кармалап, санап тора. Исемдә генә икән хикмәт!

Туктале, нигә төшеп китмим соң мин? Затлы әфәнде дә үзләренең почта әрҗәсенә таба атлады. Миннән уңайсызлануын яшерергә теләгәндәй, аның куллары да кесә төбендә ачкыч эзләгәндәй итенделәр. Түзмәдем, яна «танышыма» таба атладым.

Инде йөзенә карамый гына, ике сум илле тиенне көмешләтеп аның куллары көн дә капшаган әрҗәгә төшереп җибәрдем. «Абый» ни әйтергә белмәде булса кирәк. Әллә аптырады, әллә уенга санады.

Югары катта кире менеп киткән хатынының, мыш-мыш килеп, коляска өстерәгәне ишетелде.

Ишекне япканда, мин Затлы әфәндегә карап, бар көчемә:

—Беренче зарплатамнан синең өлеш ул, әти!—дип кычкырдым.

Исәнмесез, кадерле редакция хезмәт коллективы!

1922 елдан алып басылып килгән «Казан утлары»ның февраль аенда 1000 нче саны чыгу Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендә дә зур вакыйга булып, шуна багышланган кичәләр уздырылды.

Һәм менә без дә, бер төркем чиләбелеләр: Сафиуллина Әдибә, Мөхәммәтшина Әлфия, Гыймадиева Рабига, Габдрахманова Рәйсә, Вәлиева Әлфия, Садыйков Ришат, Абдуллина Сәлия, Гыйльмуллина Флюра, Башкортстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният эшлеклесе, шагыйрь, М. Акмулла һәм К. Даян исемендәге бүләкләр иясе Рамазан Шәгалиевлар, 7 март көнне «Меңенче сан — мең төрле уй» исемле түгәрәк өстәл артында сөйләшү үткәрдек. Чиләбе шәһәрендә эшләп килүче бердәнбер Ш. Бабич исемендәге башкорт һәм татар әдәбияты китапханәсенә Татарстаннан да, Башкортстаннан да күп кенә газит-журналлар килә, укучыларыбыз бигрәк тә күренекле әсәрләр басыла торган «Казан утлары» журналын көтеп алалар, аны беренче битеннән ахыргысына кадәр яратып укып баралар. 7 мартта журналда төрле елларда чыккан әсәрләр—Г. Ахуновның «Гомер юлы» романы, М. Хужинның «Айның уты сүнгән» хикәясе, Г. Галиеванын «Өзелгән өмет» повесте, шулай ук «Сатира һәм юмор», «Шигърият» рубрикаларындагы әсәрләр буенча фикер алышу булды, журналның әһәмияте, эчтәлеге турында җылы сүзләр күп әйтелде. Безнең фикеребезчә, «Казан утлары» журналы ул — хәзерге татар әдәбияты көзгесе.

2006 ел Татарстанда әдәбият һәм сәнгать елы булганлыктан, Чиләбедә дә төрле-төрле чаралар үткәрелде. Мәсәлән, юбилейларына багышлап, китапханә февраль аенда М. Җәлил иҗаты буенча әдәби-музыкаль кичә, 13 майда Г. Тукайга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрде. 27 майда, «Юлдаш» җәмгыяте белән берлектә, А.С. Пушкин кинотеатрында укучылар өчен «Г. Тукай, бөек син, милләтнең кояшы син» дигән китап күргәзмәсе оештырдык.

Быел октябрь аенда китапханәнең дә 100 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз.

Редакция хезмәткәрләренә саулык, иҗат уңышлары, журналда берсеннән-берсе шәп яна әсәрләр басылып чыгуын телибез.

Китапханәче
**Рәвия ГИМАЛОВА,**
*Чиләбе өлкәсе.*

**Редакциядән:**
*Без дә китапханә хезмәткәрләрен һәм аның барлык укучыларын китапханәнең юбилее белән тәбрик итәбез. 100 ел буена милли китапка, милли мәдәнияткә хезмәт итү — бик сирәк китапханәләргә генә тәтегән бәхет бу!*



ПЕН-Үзәгенең чираттагы утырышыннан соң. 1994 ел.



Композитор Заһид Хәбибуллин.
(1910-1983). 1982 ел.



Язучылар «Казан утлары» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Мөдәррис Вәлиев, Хәйдәр Гайнетдинов, Риза Ишморат, Мөдәррис Әгъләмов, Рашат Низамиев. 1982 ел.



*Көрәш еллары.*
*90 нчы еллар.*



*Шагыйрә Эльмира Шәрифуллина.*
*1993 ел.*



*Язучы Рәфкать Кәрами һәм режиссер Ростәм Фатыйхов. 1982 ел.*

## Наилә Миңнеханова



Наилә Наил кызы Миңнеханова 1955 елда Башкортостанның Туймазы шәһәрендә туган. Түмәнәк сигезьеллык, Туймазы 1 нче санлы урта-татар интернат мәктәбен тәмамлап, Әгертамак авылында клуб мөдире булып эшли. Үз вакытында Мәскәү халыкара сәнгать университетының башлангыч курсында белем алганнан соң, китапханәчеләр техникумын тәмамлый. Бүгенге көндә Туймазы медицина пыяласы заводында рәссам булып эшли. Рәссам- бизәүчеләр арасында оештырылган бәйгеләрдә беренче мәртәбә призлы урыннар яулый, республика Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 1998 нче елда Бәләбәйдә ел саен уздырыла торган төбәкара шигърият фестивалендә лауреат була. Шигырьләре Уфада ел саен дүрт телдә нәшер ителә торган «Йәйгор» дип исемләнгән шигырь җыентыкларында, «Кызыл таң», «Өмет», «Туймазы хәбәрләре», «Туган як» (Октябрьский шәһәре), «Татарстан хәбәрләре», «Аргамак», «Тулпар», «Казан», «Казан утлары», «Мәйдан», «Идел» басмаларында нәшер ителде. 2004 нче елда «Башкортостан укытучысы» журналында Ф. Әхмәтованың Н. Миңнеханованың иҗаты буенча сыйныфтан тыш дәрес — «Колагымда һаман бишек җыры» исемле фәнни хезмәте тәкъдим ителде.

«Сөю ташы», «Наз сүрәсе», «Күркә жиләк», «Хезмәтче җил», «Фәһемле сүз—үтемле», «Сүз—җәүһәр дә, гәүһәр дә» мөстәкыйль җыентыклар авторы. Алар төрле елларда Чаллыда һәм Туймазыда нәшер ителделәр.

Бүгенге көндә балалар өчен «Шәмсия итәкле Кояш», «Төшле яфрак», «Әйтемнәрем» исемле кульязмалары әзерләнеп нәшриятларга тәкъдим ителгән.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР БИШЕГЕ

6 июль көнне ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан рәсми делегациясе Алтай халкының Россия составына керүенә 250 ел тулуны бәйрәм итү чараларында катнашып кайтты.

Тантаналар Алтай Республикасына керү юлында Татарстан Республикасы исеменнән урнаштырылган «Алтай - Евразия йөрәге» истәлек билгесен ачудан башланып китте.

Истәлек билгесенең тугыз метрлы стелласында рус, алтай һәм борынгы төрки телләрендә «Киләчәк буыннарга юллама» язылган: «Без бу истәлек билгесен Таулы Алтайда - борынгы кабиләләр дәүләт эшләрен хәл итәргә җыелган, аргамакларга атланып батырлар яуга киткән истәлекле вакыйгалар унаеннан халык бәйрәм үткәргән урынга куйдык. Биредә төрки цивилизациясе башлангыч ала. Киләчәк буыннар, үз тамырларыгызны истә тотыгыз, бабаларыгыз кылган гамәлләр белән горурланыгыз һәм үзегез йөрткән исемгә лаеклы булыгыз…»

Истәлек билгесе Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев инициативасы буенча, «Татэнерго» ААҖ, «Зенит» банкы һәм шәхси затларның финанс ярдәмендә урнаштырылган. Билге Сәяр Айдаровның иҗат остаханәсе архитекторлары проекты буенча «Пифагор» фәнни-житештерү берләшмәсендә ясалган.

Тантанада Алтай Республикасы җитәкчесе Александр Бердников, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Алтай Республикасы Дәүләт Җыены – Эл Корылтай Рәисе Иван Белеков, Алтайдан РФ Федерация Советы әгъзасы Ралиф Сафин, Татарстан делегациясе әгъзалары - ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР Президентының сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе Рафаэль Хәкимов, ТР Дәүләт Советы депутаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров катнашты. Чарада шулай ук истәлек билгесенең авторлары, Алтай крае татар милли-мәдәни мохтарияте әгъзалары да бар иде.

Бәйрәмдә катнашучыларга Татарстан парламенты җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин мөрәҗәгать белән чыкты.

Аннары ул Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең Алтай Республикасы халкын сәламләү хатын укыды:

«Һәр халыкның тарихында кискен үзгәреш вакыйгалары була, сезнең өчен ул—Алтай халкының Россия составына үз иреге белән керү һәм безнең күп милләтле ил субъекты буларак, Алтай Республикасы оешу,—дип билгеләп үтелә Татарстан Президенты сәламләвендә.—Таулы Алтай җир асты казылмалары белән генә түгел, ә искиткеч табигате, яхшы кешеләре һәм тирән тарихы белән дә бай.

Алтайда, таш һәм корыган агач төпләре генә үз тамырлары турында белергә теләми, дигән әйтем бар. Бу безнең халыкка кагылмый. Татарлар үзләренең туганнан-туган Ватаннары—Алтай йорты турында белә. Татарларны һәм алтайлыларны бер язмыш, тарих, тел, мәдәният, рухи туганлык якынайта,—дип басым ясады Минтимер Шәймиев. —Киләчәктә Алтай Республикасы белән Татарстан арасында күпьяклы хезмәттәшлек ныгыячагына шикләнмим. Безне Россиянең демократик, федератив, көчле һәм чәчәк атучы дәүләт буларак күрү теләге берләштерә.»

Алтай халкының Россия составына керүенә 250 ел тулуны бәйрәм итү Алтай Республикасының яңадан реставрацияләнгән Милли театр бинасында тантаналы утырыш белән дәвам итте. Бәйрәмгә дәрәҗәле кунаклар - РФ Федерация Советы Рәисе Сергей Миронов, РФ Президентының Себер федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Анатолий Квашнин, Россия парламентының югары һәм түбән палатасы вәкилләре, Казакъстан, Кыргызстан, Монголия Республикалары, Новосибирск һәм Кемерово өлкәләре, Алтай крае, Татарстан һәм РФның башка субъектларыннан рәсми делегацияләр килгән иде.

Алтай Республикасы башлыгы Александр Бердников тантаналы жыелышта катнашучылар алдында чыгыш ясаганда, Алтай, Татарстан һәм Россиянен башка субъектлары белән беррәттән, халыкара ЮНЕСКО оешмасы игътибарын жәлеп иткән Россия төбәкләренен дүртенчесе булуын искәртте. РФ Президентынын Себер федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Анатолий Квашнин Россия Президенты Владимир Путиннын Алтай халкын котлау текстын укыды.

### ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Мәдәният, матбугат, телерадиотапшырулар өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен «Казан утлары» журналынын баш мөхәррире **Фәйзуллин Равил Габдрахман улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

*«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы Татарстаннын халык шагыйре, күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесен югары бүләк алуы белән ихлас котлый, аңа яңа иҗади уңышлар тели.*

### «СӘЛӘТ» ФЕСТИВАЛЕНЕҢ УҢЫНЧЫСЫ

Июль аенда Татарстаннын Алексеевск районындагы Биләр шәһәре янында «Сәләт»нен X Республика яшьләр фестивале үткәрелде.

Әлеге чара Татарстан шәһәрләре һәм авылларыннан гына түгел, Мәскәү, Саратов, Киров, Ленинград өлкәләреннән һәм Россиянен башка төбәкләреннән 800 гә якын мәктәп укучылары, студентлар һәм аспирантларнын иң сәләтлеләрен бергә җыйды. «Сәләт» лагерен күреп китәргә дип Татарстаннын күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, фән, мәдәният, сәнгать өлкәсендә исемнәре танылган шәхесләр, шулай ук Кытайдан да милләттәшләребез килгән иде.

Фестивальдә катнашучылар белән ТР Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов та очрашты.

«Без әлеге фестивальнен шартлары белән таныштык. Киләчәктә лагерь тормышын тагын да яхшырак һәм уңайлырак итү максатыннан, компьютерлардан куллану мөмкинлеге булсын өчен ярдәм итәргә исәбебез бар. Бу егет һәм кызларнын киләчәктә халык хуҗалыгынын ышанычлы терәге буласына шик юк. Чөнки сәләтле яшьләр - республиканын иртәгәсе көнгә ышанычы, уңышы ул», - диде ТР Хөкүмәте җитәкчесе.

Р. Миңнеханов Биләрнен искиткеч гүзәл почмагында фестивальнен инде менә ун ел дәвамында үткәрелеп килүен искәртте. Бирелгән тәҗрибә уртаклашу, үзара аралашу өчен генә түгел, балаларны социаль актив шәхес итеп формалаштыру өчен дә бөтен шартлар тудырылган. Быелгы фестивальдә катнашучыларнын киләчәге бик өметле, чөнки аларнын һәркайсы фәннен теге яки бу өлкәсендә ышанычлы адымнарын ясый, дип билгеләп үтте ул.

Очрашу ахырында «Сәләт» фонды генераль директоры, КДУ профессоры Җәүдәт Сөләйманов балалар исеменнән Премьер-министрга «Сәләт»нен кызыл төстәге лидер футболкасын бүләк итте. Җавап йөзеннән, Хөкүмәт җитәкчесе булдыклы егет һәм кызларга өр-яңа микроавтобус ачкычларын тапшырды.

### КАРДӘШЛӘР ЯКЫНЛЫГЫ

Министрлар Кабинетында узган матбугат конференциясендә Татарстан сәүдә һәм тышкы икътисадый хезмәттәшлек министры Хафиз Салихов, Әзәрбайҗан белән Татарстан арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек буенча хөкүмәтара уртак комиссиянен беренче утырышы нәтиҗәле булды, дип билгеләп үтте.

Министр хәбәр иткәнчә, хөкүмәтара комиссиянен Әзәрбайҗан Премьер-министры Артур Раси-Заде һәм Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган беренче утырышында яклар сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек перспективалары, фәнни-техник һәм гуманитар өлкәләрдә бәйләнешләр үсеше хакында фикер алышты. Хөкүмәтара комиссия әгъзалары шулай ук 2007 елда Татарстанда Әзәрбайҗан Республикасы елын, Әзәрбайҗанда Татарстан Мәдәнияте көннәрен үткәрү турында килешкән. Уку йортлары арасында турыдан-туры элемтә булдыру, якшәмбе мәктәпләре ачу, диаспоралар өчен (бүгенге көндә Әзәрбайҗанда 50 меңгә якын татар яши) балалар бакчалары ачуга ярдәм күрсәтү турында да сүз булган.

### ДЕРЖАВИН БӘЙРӘМЕ

Башкалабыз Казанда һәм бөек рус шагыйре, дәүләт эшлеклесе Гавриил Державиннын туган төбәге Лаешта «Державин укулары» дигән фәнни-гамәли конференция, шулай ук рус шигърияте бәйрәме узды.

Лаеш сәнгать мәктәбендә узган фәнни-гамәли конференциядә ТР Милли музее генераль директоры Г. Муханов һәм Казан югары уку йортлары галимнәре катнашты. Шунда ук быелгы Г. Державин исемендәге бүләкнен ияләре игълан ителде. Алар - Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Салават Юзеев («Сквозняк тишины» дигән китабы өчен) һәм Владимир Лавришко («Слеза на лице» дигән китабы өчен). Лауреатларга бүләкне Лаеш муниципаль районы башлыгы А. Тимофеев һәм Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Ә. Закирҗанов тапшырды.

Шагыйрьнен туган көненә багышланган бәйрәмнен дәвамы Казандагы Лядское бак-

часында, Г. Державин һәйкәле янында дәвам итте. Анда яна лауреатларны мәдәният министрының беренче урынбасары А. Гайнетдинов тәбрикләде.

—Минем мондый абруйлы бүләккә беренче тапкыр гына лаек булуым. Лаешыларга зур рәхмәт. Аларның үз якташларын шулай хөрмәтләүләре мине чын-чынлап бик сокландырды,—диде С. Юзеев.

Шигырь бәйрәмен шагыйрә Лилия Газизова һәм Казан Яшь тамашачы театры артисты Михаил Меркушин алып барды. Анда Г. Державин исемендәге бүләккә элеккерәк елларда лаек булган Әхәт Мушинский, Сергей Малышев; шулай ук Ольга Левадная, Борис Вайнер, Наилә Ахунова, Михаил Тузов һ.б. чыгыш ясады.

Шигырь бәйрәме «Яна музыка» инструменталь ансамбле чыгышы белән тәмамланды.

## ТАЛАНТЛЫ ЯШЬЛӘР ҮСӘ

«Алтын каләм» - «Золотое перо» XI республика фестивале төгәлләнде. 120 ләп яшь иҗатчы «Борис Полевой» теплоходында Чулман-Идел елгалары буйлап сәяхәт кылды. Дүрт көн дәвамында алар Болгар, Түбән Кама, Чаллы, Чистай шәһәрләрендә булдылар, тарихи урыннар, мәдәни җәүһәрләр белән таныштылар.

Быел Гран-прига — Кукмарадан Алсу Мәҗитова, Казаннан Александр Шагулин лаек булды. 17-19 яшьлекләр төркемендә I дәрәҗә Диплом Татьяна Корноуховага (Түбән Кама) һәм Айнур Вәлиевка (Чаллы), II дәрәҗә Диплом Адилә Гадиевага (Түбән Кама) һәм Алисә Шәкүровага (Арча) тапшырылды. III дәрәҗә Дипломга Эльмира Гарипова (Балтач) һәм Анна Макарова (Казан) ия булды. Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган номинациядә Балтач районыннан Резеда Гобәева җиңү яулады. Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулу уңаеннан игълан ителгән номинациядә Әгерҗе районыннан Алия Сипова беренче булды. Фестивальнең иң оста фоторепортеры булып Азнакайдан Рузил Вәлиев танылды.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬТӘ КАЗАН ТАРИХЫ

Санкт-Петербургта «Сынлы сәнгать ярдәмендә борынгы Казанга сәяхәт» исемле альбом-китап басылып чыкты. Анда XVII-XIX гасырларда иҗат иткән рус һәм чит ил рәссамнарының картиналары тасвирлана. Ул табигать күренешләрен сурәтләүче рәссамнар ясаган график әсәрләр, борынгы Казан һәм аның кешеләре образы сакланган картиналарга нигезләнеп төзелгән.

Альбом Татарстан Президентының мәдәниятне үстерү фонды, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, Казан дәүләт университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендәге кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, Милли музейда сакланган экспонатлар нигезендә эшләнгән.

## МИЛЛИ МУЗЕЙДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Күп еллар буе Милли музейның генераль директоры вазыйфасын башкарган Геннадий Муханов, республикабыздан күченеп китүе сәбәпле, Татарстанның төп музеена яңа җитәкче итеп биредә фәнни эшләр буенча генераль директор урынбасары булып эшләгән Гөлчәчәк Нәҗипова билгеләнде. Ул - Казан һәм Идел-Урал төбәгенең мәдәни тормышы, Милли музейның тарихы һәм аның хәзерге эшчәнлегенә багышланган 50дән артык фәнни мәкалә, берничә китап авторы, тарих фәннәре кандидаты.

## ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧКА ҺӘЙКӘЛ АЧЫЛДЫ

Башкортстанның Мишкә районында татар һәм башкорт халыкларының уртак классик шагыйре Шәехзадә Бабичның тууына 110 ел тулу уңаеннан Кыйгазытамак авылында күренекле шагыйрьгә яңа һәйкәл ачылды.

Тантаналарда катнашучылар Мөхәммәтзакир Бабичевның туган нигезенә чәчәкләр салдылар. Аннан соң Кыйгазытамак авылы мәктәбе янында Шәехзадә Бабичның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган митинг үтте.

Кунаклар соңыннан мәктәптә Шәехзадә Бабичка багышлап оештырылган музейда да булды һәм андагы экспонатлар белән танышты.

## САРА САДЫЙКОВА ҖЫРЛАРЫ

Санкт-Петербургта танылган композитор Сара Садыйкованың тууына 100 ел тулу уңаеннан «Дөнья матур, дөнья киң» дигән МРЗ диск чыкты.

Сара Садыйкованың шәхесе һәм иҗатына ихтирам йөзеннән, әлеге җырлар җыентыгы Санкт-Петербургтан милләттәшебез Фәйзрахман Камалов, шулай ук композиторның кызы Әлфия Айдарская тырышлыгы белән дөнья күрде. «Диск Әлфия Айдарскаяның шәхси архивында озак еллар сакланган Татарстан радиосы фонотекасы материалларына нигезләнеп эшләнде»,—ди Фәйзрахман Камалов.

Дискка барлыгы 110 җыр кергән. Алар арасында халыкчан җырлар, күңелле, шаян җырлар, романслар, танго һәм вальс, патриотик җырлар, инструменталь музыка бар.

## КИРӘКЛЕ КИТАП

Тарихыбыз өчен кирәк китаплар чыгып тора. 2006 елда Казанда нәшер ителгән «Урта Идел һәм Урал буе халыкларының

тарихын Казан дәүләт университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә өйрәнү (1878-1929)» җыентыгы да шундый фәнни хезмәтләрнең берсе.

Габделхәй Габдрахман улы Хәбибуллин язган монографиядә Казан университеты каршында 1878 елда оешкан археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең тарихына, эшчәнлегенә анализ бирелгән. Аның Россиядәге бик күп, бигрәк тә Идел-Урал төбәгендә яшәгән халыкларның тарихын өйрәнүдәге вазифасы күрсәтелгән.

Китап җәмгыятьнең эшчәнлеген беренче мәртәбә тулаем өйрәнүгә багышланган. Анда низамнамә (устав), алга куелган бурычлар, әгъзалар эшчәнлеге турында сүз бара. Китапның төрки һәм фин-угор халыклары тарихын өйрәнүне эченә алган бүлекчәләре дә бар. Укытучылар, югары уку йортлары студентлары, киң даирә укучылар өчен тәкъдим ителә торган әлеге басма күпләргә файдалы булыр.

### МАТБУГАТЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Казан дәүләт университетының филология буенча диссертацияләр яклау советының чираттагы утырышы булды.

Анда Түбән Новгород өлкәсендә журналист булып эшләүче Камил Фәтхуллин «Этник төбәк журналистикасын үстерү проблемалары (Түбән Новгород өлкәсе татар матбугаты мисалында)» дигән темага (фәнни җитәкчесе - филология фәннәре докторы Васил Гарифуллин) филология фәннәре кандидатлыгына диссертация яклады.

Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында, журналистика һәм социология факультетында быел яклаган диплом эшләре арасында татар теле, аны куллану, бүтән телләр белән чагыштырып өйрәнү темаларына язылганнары өч дистәгә җитте. Бу теманың быел татар журналистикасы бүлегендә дә артуын билгеләп үтәргә мөмкин.

### ТӘҢРЕЧЕЛЕКНЕҢ ТАМЫРЫ ТИРӘН

Инде бишенче ел рәттән Иске Казан янында татар, башка төрки һәм фин-угор халыкларын берләштерә торган «Таңбатыр» лагере эшләп килә. Монда җыелучылар тарихи лекцияләр тыңлыйлар, төрле экскурсияләр оештыралар. Тәңре динен тотучы яшьләр экологиягә дә зур игътибар бирә: берничә ел дәвамында Иске Казанның изге чишмәләре янында алар меннән артык каен агачы утырткан. Быел исә тагын бер күренекле вакыйга булды: мәҗүси келәүләр белән Чыңгыз ханның бөек төрки-татар дәүләте төзүенең 800 еллыгы унаеннан һәйкәл-таш ачылды. Биш метр биеклектәге ташбилгегә рун һәм кириллица алфавитлары белән язылган язма уелган. Ташбилге Орхон-Енисей ягындагы борынгы туганнары үрнәгендә эшләнгән. «Төркилек, татарлык кадерле булган һәркем монда килгәндә үзе белән кечкенә таш алып килеп ташбилге төбенә салса иде»,—диләр тәңречеләр.

### ЯҢА ФОНТАН

Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее янындагы бакчада башкалабыздагы 41 нче фонтан ачылды. Музей директоры Әлфия Тутаева әйтүенчә, бу үзенчәлекле бронза фонтанны «ВКНИИ-ВОЛТ» тәҗрибә-җитештерү заводы (директоры — С. Маруденко) һәм «Гранташ» җаваплылыгы чикләнгән ширкәт (директоры - И. Галиев) эшчеләре 2 ай эчендә өлгерткән. Ә бирегә җыелган халык бу фонтанны, анда сурәтләнгән гүзәл кызны карап хозурланды. Аннары биредә татар, рус телләрендә концерт күрсәтелде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Бүгенге татар әдәбияты өлкәсендәге казанышлары өчен язучы **Рәниф Шәриф улы Шәриповка** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сагыш». **Булат Гыйльфанов** рәсеме.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Нәкыйп Каштанов.**

# Яңа китаплар




Рауза Хәйретдинова. **Гомер сәхнәсе: истәлекләр, хатирәләр.**—Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.— 87 б. Тиражы—2000 данә.

«Мин—бәхетле. Тарих битләрендә язылып калырлык якты йолдыз булып балкыган артистлар белән партнер булып сәхнәдә бергә уйнарга туры килде. Мин үземнең яраткан спектакльләремдә уйнадым». Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 60 ел сәхнә тоткан халык артисткасының моңдый сүзләрне горурланып әйтергә тулы хакы бар.

Татар театрының 100 еллыгы унае белән нәшер ителгән, күп санлы фотолар белән бизәлгән бу истәлек-хатирә китабының мөхәррире—М. Хафизов, рәссамы—И. Шәмсетдинов.




Алмаз Гыймадиев. **Без андый малай түгел!** Хикәяләр, повесть.—Казан: «Мәгариф» нәшр., 2005.—184 б. Тиражы—1000 данә.

Балалар язучысы Алмаз Гыймадиевның әлеге китабында яшүсмерләр тормышындагы мажаралы вакыйгаларны сурәтләгән шаян хикәяләр һәм бер повесть урын алган.

Кыска гына хикәяләрдә геройларның холыклары, портретлары үткен сатира, көлү-киная аша тасвирлана. Нинди дә булса бер хикмәт ясап куйган бу балаларның көлкегә калуларын автор ышандырырлык итеп бирә. Үсмерләрнең шуклыкларын, тапкырлыкларын, самимилекләрен, хәтта алар телендәге жаргон сүзләрне дә бик белеп, урынлы файдалана. Әмма бу хикәяләр коры шаяруга гына корылмаган, аларның эчке мәгънәсе бар, укучы рухына йогынты ясарлык гыйбрәтле хәлләр алар.

Китапның мөхәррире—Л. Гыйззәтуллина, рәссамы—С. Ибраһимова.



Нәкыйп Каштанов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)